# Казан утлары

7

июль

1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

7
ИЮЛЬ
1969

## БУ САНДА:

### ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Давыл чәчәге. Новелла . . . 3
М. ХӘСӘНОВ. Ленинны аңлау, өйрәнү юлында. Мәкалә . . . . . . . . . . . . . . . 11
А. ПАРНИС. Ленин сүзе. Шигырь . . . . . . 23
В. БАЙДЕРИН. Ленин турында хикәяләр . . . . 25

### РОМАН, ШИГЫРЬ, ПЬЕСА

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Яшел Яр. Роман . . . . . . 36
Ш. МӘХМҮДОВ. Авыл кичә. Табигать йөзе. Балбаллар. Мәскәү язы. Кичке шәфәкъ. Марс каналлары. Ике тол. Мәрхүм абзыйга элегия. Китәбез. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 77
Э. МОСТАФИН. Йөрәк турында. Гомер кайдан башлана. Бу төннән... Ә мин һаман бер могҗиза көтәм. Күктә... Тәрәзәләр. Дөнья миңа пешкән алма иде. Рифма өчен. Кайгырабыз, шатланабыз. Күңелләргә ак нур булып... Яшәү авыр, яшәү матур... Шигырьләр . . . . . . 82
Г. МӨХӘММӘТШИН. Тынгысыз төн. Пьеса . . . 86

### ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

З. НАСЫЙБУЛЛИН. Уйлый идем. Кара шәле килә сөйрәлеп. Җөйсез яра. Моңсуланып карап калдым әле. Үзгәрттең дә куйдың. Ялганган җеп була төенле. Шигырьләр . . . . . . . . 124
К. СИБГАТУЛЛИН. Тамчылар. Эзлим үземне. Таң алдыннан агачларның шавы. Шигырьләр . . 127
Т. КАМАЛИЕВ. Казаным. Бу Ташкичү инде. Апалар. Баш ими йөргән кызлар бар. Шигырьләр. 128

### ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Т. СӘГЫЙТОВ. Күккә гашыйк егет. Очерк . . . 130

### ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНА 50 ЕЛ

А. ҖӘЛӘЛОВ. Яшьлек көрәштә чыныкты . . . 137

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЯТЬ

**Т. ГАЛИУЛЛИН.** Шигъри ачышлар һәм югалтулар елы . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
**Р. ХАРИСОВ.** Эредәнрәк, олыданрак . . . . . 153

### ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**А. СӘЛӘХЕТДИНОВ.** Канлы туфрак. Очерк . . 160

### СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

**Н. ИСӘНБӘТ.** Олы иҗат, халыкчан иҗат . . . . 169
**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Бай гомер юлы . . . . . 172

### ЯҢА КИТАПЛАР

**Ш. МАННАПОВ.** Шигъри дулкыннар . . . . . 178
**М. ГОСМАНОВ.** Файдалы хезмәт . . . . . . 179

### ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

**Т. МИҢНУЛЛИН.** Шикле кеше. Малайлар. Гаптелвәли. Хикәяләр . . . . . . . . . . . 182
**З. НУРИ.** Хатынга ярамагач... Икесе дә кетә. Килен белән кайнана. Әйтүе дә авыр. Күршең нинди. Улы атасын юата. Тиздән буласы ярдәм. Ике күрше сөйләшә. Хушлашканда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор **Зәки Нури**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 12/V-1969 ел. Басарга кул куелды 30/VI-1969 ел. ПФ 09020. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81 446 экз. Заказ В-247. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1969 ел.




## ЛЕНИН–
## БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**Рафаил Төхфәтуллин**

# ДАВЫЛ ЧӘЧӘГЕ

*Новелла*

...давыл чәчәкләре
Көтеп утыра кебек давылны.

С. ХӘКИМ.

Неподкупен, бескорыстен
И с сознанием правоты,
Непоборной силой истин
Над неправдой грянешь ты.

*М. А. Ульянова Володя бишектә чакта ук аңа шушы җырны җырлый торган булган.*

I



Сабый чакның хәтергә гомерлеккә сеңеп калган хатирәләре була. Нәни бер вакыйгамы, күренешме, әйберме күңел дәфтәренең чип-чиста битенә беренче эзләрен сыза.

...Дөньяга килүемә ничә ел, ничә ай булгандыр, кояшлы, бик мул кояшлы язгы иртәдә чәчәкле болында йөрүем истә. Болын тулы кешеләр, кая карама кешеләр иде. Биек колга башында матур чүпрәкләр җилферди. Сабан туе көне иде бу.

Кинәт, апаларның чуар итәкләрен бик зур кабартып, салкын җил исте. Минем башымдагы өр-яңа кепка, очып төшеп, бик күп аяклар астыннан тәгәрәп китте. Эре-эре тамчылы яңгыр ява башлады. Кешеләр барысы да каядыр ашыгырга, йөгерешергә тотындылар.

Әти мине җитәкләгән, без дә ашыгабыз. Минә баскан саен тетрәп китә торган түмгәкләр буйлап сикерә-сикерә атлый башладык. Әти мине күтәреп барырга итә, мин карышам — дереллдек түмгәктән түмгәккә сикерү миңа бик кызык.

Алда бер уем болын сап-сары иде. Бераз якынлашкач, күрдем: анда бик күп, бик күп сары чәчәкләр үсеп утыра икән. Берсе-берсе минем йодрык кадәре алтынсу-сары чәчәкләр. Барысы да җилдә иелә-бөгелә чайкалалар. Катлы-катлы нәфис таҗ яфракчыклары дерелдәп ачыла, йомыла.

Әти кемнәр беләндер сөйләшә:

— Давыл чәчәкләре... чәчәк аткан бит.

— Әйтәм җирле... Шуңа инде бу давыл.

Давыл чәчәкләре... Бу усал җил әнә шул дер-дер килгән таҗ яфракчыклары арасыннан чыгадыр, озын саплы бу йомры чәчәкләр, чайкала-чайкала, җилне тагын да көчәйтәләрдер кебек иде.

Чәчәкләр... Давыл чәчәкләре...

## II

Кырык елга якын гомер үткәч, мин тагын болын буйлап атлыйм. Мин инде күптән үзем әти кеше, төпчек кызымны җитәкләп барам.

Ушнә елгасы буендагы кечерәк кенә бу болын — гади болын гына түгел. Изге урыннар бу. Моннан бик күп еллар элек биредә Володя Ульянов йөгереп йөргән.

Без яңа гына Кокушкинодагы Ленин музей-йортын карап чыктык. Бу елга буйлары, бу болын — музейның дәвамы. Сабый аяклары болын, елга буеның кай җиренә генә җитми...

Тып-тыныч, тып-тын ага Ушнә. Кайчандыр кечкенә Володяны көненә унар тапкыр үз кочагында иркәләгән елга... Сөйли белсәче ул!

Болында кузгалак, акбаш күп икән. Ул вакытта да үскәндер алар, Володя да өзеп ашагандыр аларны.

Чәчәкләр дә күп болында. Тукранбаш, ромашка, күкебаш... Ә арырак...

Мин кинәт тукталып калам.

Күңелдә әллә кайчангы балалык хатирәләре кузгала. Шунда ук әле генә музейда күргәннәрем, Володя турында бар укыганнарым, бар белгәннәрем күңелемне өермәдәй биләп ала.

Күз алдыма китерәм... Ачыкланганнан-ачыклана...

Шулай булгандыр ул...

Кызым кулымнан тарта.

— Әти, әнә ул чәчәкләрнең исеме ничек?

— Алар... Давыл чәчәкләре, кызым.

— Нинди матур!.. Ленин да күрде микән аларны?

— Әлбәттә, күргән! Менә тыңла әле...

## III

Карт врач Александр Дмитриевич Бланкның Кокушкинодагы агач йорты, йорт каршындагы флигель — кыш буе тау-тау көртләргә күмелеп, мәрхүм хуҗасын сагынгандай тып-тын яткан шушы төшләр — җәйгә чыгуга, бөтен тирә-якта иң шау-шулы, иң күңелле урыннарга әверелә. Александр Дмитриевичның биш кызы да, әтиләре васыятенә тугрылыклы буларак, бөтен бала-чагаларын ияртеп, бирегә җыелалар.

...Ул җәйне Кокушкинога иң беренче булып Александр Дмитриевичның Казанда яшәүче олы кызы Анна Веретенникова балалары белән килеп төшә. Аның артыннан балалары белән Любовь Ардашова килә.

Ушнә буйларында шат авазлар яңгырый.

Ләкин нигә соң елга болай юксынулы-моңсу ага әле?

Биредә барысы да — олылар да, балалар да — Сембердән Ульяновларның килеп җитүен зарыгып көтәләр. Һәрвакыт шулай, онытылмас истәлекле иң күңелле көннәр алар килеп житкәч кенә башлана монда.

Илья Николаевичның шаян хикәяләре... Мария Александровнаның пианино уйнап, тын гына җырлаулары... Володяның берсеннән-берсе кызыграк уеннар уйлап табулары... Әнә шулардан башка нәрсәләр китек бирәдә.

Үшнә елгасы да үзенең иң җитез, иң зирәк, иң оста йөзүче кечкенә дустын сагынып, шулай моң гына ага булыр...

Володяның кордашлары Коля белән Петя, кечерәкләрне дә ияртеп, еш кына Апакай авылы янындагы юл чатына ук китеп баралар — көтелгән тарантаслар күренмәсме?

Ниһаять, күренә...

Дугалардагы кыңгыраулар чаңын дистәләгән шат авазлар күмеп ташлый. Атлар, колакларын шәмдәй торгызып, юл чатына җитәрәк туктыйлар.

Алдагы атның тарантас башында, һәрвакыттагыча, кучер белән янәшә, Володя утыра. Ефәктәй йомшак аксыл бөдрәләре җилдә җилферди. Аз гына кысыла төшкән коңгырт күзләре шаян да, бераз хәйләкәр дә очкыннар сирпеп елмая...

Артта, кечкенә Маняшаны алдына алып, Мария Александровна утыра. Анна белән Ольга да шунда.

Арттагы атта ирләр компаниясе — Илья Николаевич белән Саша һәм Митя. Һәр нәрсәдә Володя абыйсына охшарга тырышучы Митя да кучер янына менеп утырган.

Балалар тарантаслардан сикерешеп төшәләр. Ташып торган шатлыклы, шау-шулы төркем; атларны әллә кайларда калдырып, ул авылга таба йөгерә. Төркем өйдә туктап тормый, арттагы текә сукмактан туптуры Үшнә буена йөгереп төшеп китә.

— Безнең Кокушкинодан да матуррак урын дөньяда юктыр! — ди Володя, елга буендагы камышларга, елга аръягындагы чәчәкле болынга һәм калкудагы куксел нарат урманына күз йөртеп, тирән-тирән рәхәтләнеп сулый.

Үшнә, яшь дустын сәламләп, шат дулкынчыкларын ярга кага...

...Ашап-эчеп, аннары Үшнәдә су коенып менгәч, балалар флигельнең биллиард бүлмәсенә җыелалар. Гадәттә бөтен кызык уеннар шушы бүлмәдә уйлап чыгарыла, бирелә иртәгә һәм алдагы көннәргә бик күңелле планнар корыла.

Бу юлы да сүз шул турыда куера. Алданрак килгәннәр инде бу турыда күп сөйләшкәннәр, хәзер Володядан яңа сүз көтәләр.

— Беләсезме, без очырткыч ясыйк,— ди Володя хәйләкәр-күңелле елмаеп.

— Фи, таптың! — ди юкка-барга исе китмәүчән Петя.

Володяның йөзе җитдиләнә.

— Ә бу гади очырткыч кына булмас,— ди ул, кулын бик кискен селтәп куя.— Без аны бик зур итеп, менә, ишек кадәр итеп ясарбыз.

— Чыннан да! Ничек шәп булыр,— ди Коля Веретенников. Аның уйчан күзләре нурланып китә. Һәрвакыттагыча, Володяның һәр сүзен эләктереп алырга гына тора ул.

Шул көннән башлап, Үшнәдә кат-кат су коенудан, тишек көймәдә йөзүдән кала барлык буш вакыт бик зур очырткыч ясауга бирелә. Биллиард бүлмәсенең бер почмагы иске обой төргәкләре, бау кисәкләре, җеп йомгаклары белән тула. Шунда биллиард уйнаучы олылар, хәтта гимназиянең өлкән классларында укучы Саша Ульянов белән Шура Веретенников та моны бөтенләй күрмәмешкә, игътибар итмәмешкә салышалар.

Володя белән Коля үз кордашлары белән почмакта мәж киләләр. Эш арасында укыган китаплары турында сөйләшеп алалар.

— Тургеневның «Сәгать» дигән хикәясен укыганың бармы? — ди Володя.

— Юк.
— Ә «Төтен» дигән повестен?
Коляга һаман «юк» дип кенә җавап бирү уңайсыз, ул «әйе» дип мыгырдана.
Володя хәйләкәр генә елмаеп куя.
— Тургеневның «Литвинов» дигән повестен да укыдыңмы? — ди.
Коля тагын икенче кабат та ялганларга теләми.
— Юк, укымадым,— дип кырт кисә.
Володя көлеп җибәрә.
— Менә инде ялганың тотылды. Әгәр «Төтен»не укыган булсаң, Литвиновның шул повесть герое гына икәнен белер идең. Тургенев «Литвинов» дигән бернинди повесть та язмаган.
Коля чәч төпләренә кадәр кызара. Менә хәзер барысы да аннан шаркылдап көлә башларлар. Дөрес, балалар да, биллиард уйнаучы олылар да үз шөгыльләре белән бик мәшгульләр, бу сөйләшүне ишетмәделәр дә булса кирәк. Ләкин... Әгәр Володя хәзер генә аның ялганын тотканын кызык итеп барысына да сөйләп бирсә?.. Ух, шушы мәлдә җире ярылса, кереп кенә китәр иде...
Ул арада Володяның әле генә күңелле очкыннар чәчкән күзләре җитдиләнеп өлгерә.
— Ә син Тургеневның «Сәгать» хикәясен ничек тә табып укы. Аның герое Давыд какшамас нык характерлы егет була. Андыйлар үз максатларына, һичшиксез, ирешәләр... Кая, җилемне алып бир әле, койрык өлешен ныграк ябыштырыйк.
Коля, иркен сулап куеп, шундагы шешәгә үрелә.
— Очар микән соң бу? — дип, кыюсыз гына сорап куя.
— Очарга тиеш! — ди Володя барысы да ишетсен өчен тавышын күтәрә төшеп.— Без әле аңа кечкенә арба тагып җибәрербез.
— Арбага берәребез менеп тә утырыр.
— Чиратлашып утырырбыз,— дип башкалар да сүзгә кушыла.
— Һәм чиратлашып егылып та төшәрбез.
Гомуми көлүгә Коля да кушыла. Юк, Володя аның хәзер генә ничек итеп ялганын тотканын сөйләп, барысы алдында көлкегә калдырырга уйлап та бакмый икән...
Иртәгесен очырткычны ясап бетерәләр.
Аз гына җиләс җил дә исеп торган бик матур көн була ул. Чыннан да ишек кадәрле бик зур очырткычны җыйнаулашып күтәреп, шаулаша-гөрләшә болынга чыгып китәләр. Юлда аларга Кокушкинонның тагын бик күп малайлары да иярә. Володя узган килүләрендә танышкан малайлары белән күңелле генә исәнләшә. Арада таныш булмаганнар да бар. Әнә чем-кара күзле, бик терчә малайны Володя әле беренче очрата. Шул чем-кара күзләре, шул терчәлеге белән дә, сәеррәк киемнәре белән дә башкалардан аерылып тора ул малай. Башында кара түбәтәй малайның, күк киндер күлмәге өстеннән җиңсез камзул киеп куйган. Володяның мондый киемнәрне күрше Апакай авылының татар малайларында инде күргәне бар.
— Таныш булыйк. Мин — Володя,— ди ул, кара күзле малайга кулын суза.
— Мин Бәһави булам,— ди малай һәм оялчан гына елмая.
...Башта очырткыч җиңел генә һавага күтәрелеп китәргә теләми. Койрык бавына тагын бер таш бәйлиләр. Алгы бауны бушайта төшәләр... Юк, җирдән аз гына күтәрелә дә очырткыч, бөтерелә-бөтерелә, кире төшә... Әйдәгез, җилгә каршы ук түгел, бераз ян белән рәк йөгерәбез.
Малайларның бердәм шат авазларына Үшнә буендагы карт өянке башыннан бер көтү карга һавага күтәрелә. Каргалар белән узыша-узы-

ша, очырткыч та югарыдан-югарыга менеп китә. Ура! Оча бит, нинди зур очырткыч һавага күтәрелә!

Малайларның шатлыклары эчләренә сыймый. Шаулашалар, сикерешәләр, йөгерешәләр.

Чү! Очырткыч бавы Коля белән Петяның кулыннан ук ычкынып китмәкче була түгелме? Шундый да көч белән ыргып-ыргып тарта... Тизрәк, ярдәмгә!

Малайлар барысы да очырткыч бавына дәррәү килеп ябышалар. Юк, ычкына алмассың! Ләкин... Нәрсә бу? Очырткыч кинәт һавада бер бөтерелеп ала да, канаты сынган коштай, җиргә егыла... Мәтәлеп килеп тә төшә... Чыралары сына, кәгазьләре ертыла...

— Их, харап иттек,— ди кайсыдыр, бик тирән көрсенеп.

— Кинәт тартмаска иде аны, шуңа егылды ул,— ди икенчесе, жыларга житешеп.

Бер мәлгә күңелсез тынлык урнаша.

Шунда Володя, кинәт бөтен болынны яңгыратып, бик күңелле көлеп жибәрә.

— Зыян юк, дуслар,— ди ул.— Без үз дигәнебезгә барыбер ирештек. Очырткычыбыз очты, моңарчы кошлар гына хуҗа булган биеклекләргә менеп төште. Бик әйбәт бу!

Калганнар да, Володяга кушылып, күңелле көлешәләр.

## IV

— Әти, менә шушы болында очырткannarмы инде алар очырткычны?

— Шушында... Хәер, әнә тегендәрәк, калкуданрак очыртканнар булырга тиеш. Әйдәле, барып карыйбыз.

— Әйдә. Әти, ә син кайдан беләсең боларны?

— Кайдан беләмме? Миңа, кызым, боларны бик ачык итеп күз алдыма китерергә давыл чәчәге ярдәм итте.

— Ничек? Ә син давыл чәчәге турында бөтенләй сөйләмәдең дә әле.

— Хәзер менә давыл чәчәгенә дә житәбез. Тыңла.

## V

Үшнә ул көнне, һичшиксез, хәтерли торгандыр.

Кояш төшлеккә житеп килгән вакытлар була. Яр буендагы өянкеләр әлсерәгән яфракларын лепелдәтеп куялар да, нидер тыңлагандай, тагын тынып калалар. Су өстендә яшькелт-зәңгәр канатлы энә караклары очына.

Володя белән Коля яңа гына су коенып чыкканнар да, битләрен жылы нурларга куеп, яр буенда утыралар.

Өянке яфраклары юкка гына сагаюлы тынып калмаганнар икән, шунда аргы як ярдан моңлы бер жыр ишетелә.

— Баһави килгән, әйдә, янына барабызмы? — дип, Володя урыныннан сикереп тора.

Алар тегермән буасы янына йөгерәләр. Анда, буаны чыгуга, биредә барысы да «Аш өе» («Поварня») дип йөртә торган бер урын була. Чыннан да, көтүчеләрнең «аш өе» кебек була ул. Ялгыз карагай төбендә ашарга пешерергә таган асылган. Янәшә үк бик салкын, тәмле сулы чишмә дә ага. Көтүчеләр үзләре дә төшке ашны ашый монда, терлекләр дә елгада су эчеп, хәл жыеп ала.

Малайлар әнә шул урынга ашыгалар.

Баһави, Володя белән Коляны күрүгә, тагын яңа жыр суза. Һәрвакыттагыча, дусларын жыр белән каршылый ул. Володя белән Коля аның бу гадәтен яхшы белгәнгә, баш кагып кына исәнләшәләр дә яшел чирәмгә килеп утырып, тын гына жыр тыңлыйлар.

Беркөнне очырткыч очыртканда күрешеп танышканнан бирле, алар бирегә бик еш киләләр. Баһавиның кайбер җырларын чын татарчалап отып та алганнар инде алар. Русчага тәрҗемәсен дә беләләр.

Әнә хәзер дә Баһави аларга таныш җырны башлады.

Сары, сары, сап-сары
Сары чәчәк саплары.
Сагынырсың, саргаерсың,
Килсә сугыш чаклары.

Шунда ул, авыл ягына караган килеш, кинәт җырлаудан туктый. Сукмактан бирегә таба өлкән көтүче Антон килә икән.

— Тагын юлы уңмаган,— ди Баһави, тын гына көрсенеп.

— Нигә алай дисез?

— Әнә бит кулларын ничек ачулы селти... Көтүләрен көткән өчен берәрсеннән акча алып булмасмы дип киткән иде ул. Бирмәгәннәр, күрәсең.

Антон, чыннан да, бик ачулы. Ерактан ук Баһавига кычкырына-кычкырына килә.

— Нигә алып килдең әле син көтүне бу вакыттан! Төш җиткәнен белмәскә син... Күзең чыкмагандыр бит.

Володя урыныннан сикереп тора.

— Ә ул вакытны сәгатьсез кайдан белсен? — ди.

— Ник белмәскә! Дүрт чабата буе үлчәп алдың — менә сиңа төш вакыты.

— Ничек инде? Чабата сәгатьне алыштыра аламы?

— Алыштыра ала,— дип, Баһави да сүзгә кушыла.— Менә карагыз. Минем күләгәм хәзер, әнә, шул озын ат кузгалагы турысына җиткән. Хәзер атлап карыйм. Бер чабата, ике, өч, дүрт... Җиткән бит төш вакыты, Антон абый.

— Бу бик кызык,— ди Володя.— Беләсезме, бик борынгы заманнарда гномон дигән шундый беренче астрономик корал булган. Җиргә кагылган таяк һәм шуның күләгәсе ярдәмендә кояшның җирдән күпме биеклектә икәнен исәпләп чыгарганнар.

— Кара син!

— Беләсезме, беренче астрономнар, ягъни кояш, йолдызлар турында беренче белемнәрне язып калдыручылар, шулай ук көтүчеләр булганнар бит.

— Булыр, булыр. Болында, кырларда йөргәндә башка нинди генә уйлар килми ул! — ди Антон, аның баягы ачуы инде басылып та өлгергән.

Володя белән Баһави, аңа сиздермичә генә, бер-берсенә мәгънәле карашып алалар.

Антон, кесә төпләрен әйләндереп, учына тәмәке тузаны җыя. Инде үз алдына гына сукрана.

— «Ала каргада алачагың булсын», имеш. Көт син ул карганы. Бер чеметем тәмәке калмаган монда, күлмәк иңнәрдән өзелеп төшәргә тора... Эх, тормыш...

Бирелән кайтканда Володя гадәтенчә сикерә-сикерә йөгерми, салмак кына атлый. Йөзе бик житди-уйчан.

...Шушы көнне Кокушкинога тагын бер кунак килеп төшә. Уфа губернасының Бәләбәй өязеннән Коляның өлкән апасы Анна Ивановна ялга кайта. Бөтен күңеле, эшләре, һәр сүзе белән шәфкатьлелек һәм ягымлылык үрнәге була врач Анна Веретенникова. Казанда вакытта ук татар ярлыларын түләүсез дәвалый торган була ул. Инде әнә ерак Бәләбәй өязенә китеп, анда татар һәм башкорт ярлыларына армый-талмый ярдәм итеп ята. Аларны дәвалый, кайгы-хәсрәтләрен, шатлык-

борчуларын уртаклаша. Ни арада татарча бик оста сөйләшергә, укырга-язарга да өйрәнеп алган.

Шулай да бу юлы Анна Ивановнаның озынчарак аксыл йөзендә шактый талчыкканлык сизелә.

Әнә ул терраса күләгәсендәге чыбыктан үреп ясалган кәнәфидә Илья Николаевич белән сөйләшеп утыра.

— Татар һәм башкорт халыкларының хәле, гомумән, Россиядәге азчылык милләтләрнең хәле, мин әйтер идем, икеләтә, хәтта өчләтә авыр. Бер яктан, милли хокуксызлык, дини кысынкылык, икенче яктан, коточкыч ярлылык, сыйнфый изелү... Йөрәкләрне әрнетерлек хәлләргә көн саен юлыгасың.

— Әйе, әйе,— ди Илья Николаевич,— миңа да андый хәлләр белән даими очрашырга туры килә. Мине иң нык борчыганы — наданлык.

— Самодержавиегә азчылык милләтләрне караңгылыкта тоту файдалы ул. Ләкин килер бер көн... Батыр халык, эшчән халык, талантлы һәм намуслы халык алар, татарлар һәм башкортлар. Алар әле үз сүзләрен әйтерләр. Мин моңа ышанам.

Анна Ивановнаның йөзендәге талчыкканлык бөтенләй диярлек сизелми башлый. Ул уйчан гына елмаеп куя да дәвам итә:

— Миңа бик еш ерак-ерак авылларга барырга туры килә. Ат белән йөрткән өчен врач кешедән акча алуны татарлар гөнаһ саныйлар. Татар хатын-кызларының искиткеч тыйнаклыклары, түземлекләре мине сокландыра. Ирләр, егетләр армас-талмас эшчәнлекләре, аек акыллары белән таңга калдыралар.

Бер читтәрәк Саша белән Володя утыра. Алар да бу сөйләшүне йотылып тыңлыйлар.

Кичкә таба Саша, Володя һәм Коля Үшнә буйларын әйләнеп кайтырга чыгып китәләр.

Менә шунда, болында, Володя сары давыл чәчәге янында кинәт тукталып кала.

— Коля, хәтерлисеңме Баһавиның җырын? — ди ул.

Коля гадәтенчә кызу-кызу әйтеп бирә:

— ...Сары, сары, сап-сары...
Сары чәчәк саплары...

— Әйе. Менә хәзер мин беләм. Халык нәкъ менә шушы чәчәкләргә карап чыгарган бу җырны. Күрәсеңме, аларның таҗ яфраклары ничек сизгерләр. Алар нәрсәдер хәбәр итәләр, чыннан да давыл хәбәр итәләр кебек.

— Ләкин ул халыкка бары хәсрәт кенә алып килә торган мәгънәсез сугыш давылы гына булмас! — ди Саша нык тавыш белән.— Халыкка азатлык алып килүче революция давылы булыр бу.

Кайтышлый Володя әнисеннән бик яшьләй отып алган, гаиләдә барысы да бик яраткан җырның сүзләрен уйчан гына кабатлый:

А тебе на свете белом
Что-то рок пошлет в удел?
Прогремишь ли в мире целом
Блеском подвигов и дел?

Саша белән Коля җырның калган куплетларын эләктереп алалар:

Вождь любимый, знаменитый,
В час невзгоды роковой
Будешь крепкою защитой
Стороны своей родной.

Неподкупен, бескорыстен
И с сознанием правоты,

Непоборной силой истин
Над неправдой грянешь ты.

...Иртәгесен төш вакыты житүгә, Володя белән Коля янадан тегермән буасы ягына йөгерәләр. Өр-яңа мәгънә белән яңгырый бу юлы Баһавиның җырлары...

## VI

— Әти, үсеп житкәч тә очрашамы Ленин Баһави белән?

— Ихтимал, очрашкандыр. Яшь Ленин Кокушкинода сөргендә вакытта крестьяннарның тормышы белән аеруча кызыксына, алар белән бик еш озак-озак сөйләшеп утыра торган була. Авыл халкының моңзарларын, уй-өметләрен күнеленә тирән сеңдерә бара. Менә шул чакта Баһави белән дә очрашуы бик тә ихтимал.

— Ә үсеп житкәч кем була ул Баһави?

— Башта игенче-батрак, аннары солдат була. «Сагынырсың, саргаерсың, килсә сугыш чаклары» дип юкка гына җырламый Баһави. Беренче империалистик сугыш башлануга, инде кырык яшьтән узган Баһавиның биленә дә каеш буалар. Салкын окопларда аның җырлары тагын да хәсрәтлерәк, тагы да моңлырак яңгырагандыр... Аннары утлы революция, өермәле гражданнар сугышы еллары. Менә шунда инде Баһавиның җырлары бөтенләй бүтәнчә яңгырагандыр. Азатлык һәм көрәш җырлары булгандыр ул. Әлбәттә, үзенең бөек якташы Ленин турында да күп ишеткәндер Баһави, балалак дусты белән яңадан очрашырга да бик хыяллангандыр. Ләкин андый очрашу була алмый кала. Күпме утны-суны кичкән карт солдат Баһави гражданнар сугышының соңгы бәрелешләрендә батырларча һәлак була...

Аннары, шулай ук күз алдыма китерәм, ышанам... Бөек Ленин 1920 елны Татарстан автономияле республикасы төзү турындагы декретка кул куйганда, үзенең балалык дусты Баһавины да хәтеренә төшергәндер... колагы төбендә Баһавиның җырлары яңгырап киткәндер. Шулай булгандыр ул... Музыкага гаять дәрәҗәдә сизгер булган бит Ленин. Яңгырагандыр...

Менә нәрсәләр турында сөйли миңа бу давыл чәчәкләре, кызым.

Кокушкино — Әлмәт,
август, 1968

Мансур Хәсәнов

# ЛЕНИННЫ АҢЛАУ, ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Без бүгенге идеология эшенең барышына юнәлеш һәм принципиаль яңгыраш бирә торган зур сәяси вакыйга алдында торабыз: Владимир Ильич Ленинның 100 еллыгы якынлашып килә.

Чорыбызның иң зур, иң мөһим казанышлары аның исеме — Маркс һәм Энгельс тәгълиматын даһиларча үстергән, Коммунистлар партиясенең нигезен салган, дөньядагы беренче социалистик дәүләтне төзегән бөек Ленин исеме белән бәйләнгән.

Бүгенге көннең нинди генә актуаль мәсьәләсенә килеп тотынмыйк, без һәрвакыт Ленин белән киңәшәбез, Ленин хезмәтләренә таянабыз. Ленин тәгълиматының, ул калдырган мирасның тормышыбызда тоткан урыны искиткеч зур һәм кыйммәтле.

Әмма шушы рухи байлыкның халык аңына ныклап урнашуы, яңа тормыш төзү өчен көрәшкә күтәрелгән һәркемнең күңел түренә барып җитүе өчен еллар һәм дистә еллар кирәк булган, революцион карашлы укымышлыларның армый-талмый эшләве таләп ителгән.

Шул хакта сөйли торган күп мисалларның берсе буларак Галимҗан Ибраһимовны алырга, аның гыйльми эшчәнлегенә тукталырга мөмкин. Күренекле әдипнең марксизмны, В. И. Ленин әсәрләрен, рус революцияләрен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә язылып, гражданнар сугышы тәмамлануга ук басылып чыккан хезмәтләре иҗтимагый фикер үсешен һәм революцион хәрәкәтне фәнни өйрәнү өлкәсендә Татарстандагы беренче карлыгачлар булып санала алалар. Бу мәкаләдә сүз аның әнә шул хезмәтләре турында барачак.

* * *

Моңарчы Галимҗан Ибраһимовка багышланган хезмәтләрдә аның 1919 ел башыннан (ягъни Үзәк мөселман комиссариатыннан киткән вакыттан) алып 1920 ел ахырларына кадәрге эшчәнлегенә тиешле игътибар бирелми килде[1]. Хәлбуки, әдипнең бу чордагы эшчәнлегенең әһәмияте татарча совет матбугатына һәм республикадагы нәшрият эшләренә нигез салу, демократик карашлы язучыларны һәм журналистларны беренче совет газета-журналларына эшкә тарту белән генә чикләнми.

Кызыл Армиянең махсус заданиесе белән Колчак тылында йөреп кайткач, Галимҗан Ибраһимов Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә эшкә билгеләнә һәм аңа коллегиянең нәшрият эшләре тапшырыла. Нәшрият эшләрен юлга салудан тыш, биредә ул кызылармеецлар өчен сәяси курслар оештыра, аларга программалар төзи, лекцияләр

---

[1] Язучының В. И. Ленин әсәрләрен үзләштерү һәм пропагандалау, шулай ук Октябрь революциясен фәнни өйрәнү юлындагы хезмәтләре хакында минем «Ленинизмны ялкынлы пропагандалаучы» исемле мәкаләмдә («Социалистик Татарстан» газетасы. 1967 ел. 12 март саны.) һәм «Борцы за счастье народное» исемле җыентыкка (Казан. 1967 ел. 225—239 битләр. Рус телендә) кертелгән очеркта, Ү. Гыймадиевның «Галимҗан Ибраһимов — журналист» исемле китабында гына (Уфа, 1967 ел) кайбер мәгълүматлар бар.

укый. Шуларның һәммәсе өстенә, коллегиянең 1919 ел октябрь приказы белән, ул Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы булган «Кызыл Армия» газетасына даими эшче итеп билгеләнә[1] һәм РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмалары Үзәк Бюросының нәшрият бүлегенә мөдирлек итә[2].

Шушы кыска гына бер вакыт эчендә фәнни коммунизм тәгълиматын өйрәнү һәм аны татар-башкорт хезмәт ияләре арасында пропагандалау өлкәсендә Галимҗан Ибраһимов искиткеч зур эш башкара. Ул Татарстанда революцион хәрәкәт тарихын, Октябрь революциясе һәм Коммунистлар партиясе тарихын фәнни өйрәнү, Ленинның бай иҗат мирасын тирәнтен үзләштерү һәм пропагандалау эшен башлап җибәрә. Язучының марксизм-ленинизмга килү юлын һәм аның идея-политик карашлары эволюциясен күзәтү ягыннан бу хезмәтләрнең әһәмияте бик зур.

1919 елның декабрендә, ягъни әле большевиклар партиясенә кергәнче үк, Галимҗан Ибраһимов коммунистның карашы, инануы тарихи материализмга нигезләнә, дип язган иде[3]. Вак буржуаз революционерлык карашларыннан арына барып, ул үз язмышын Коммунистлар партиясе белән бәйли, «күптән үлеп, инде сөякләре үк чери башлаган»[4] сул эсерлар партиясе идеологиясен фаш итә. Ул һәр революционер фәнни социализм тәгълиматын, марксизм-ленинизмны үзләштерергә тиеш дип саный һәм үзе шулай эшли дә.

«Бөек бәйрәм» исемле мәкалә — Галимҗан Ибраһимовның бу юнәлештәге беренче хезмәте. Күләме белән кечкенә булса да, эчтәлеге белән искиткеч әһәмияткә ия булган бу мәкалә Октябрь революциясенең беренче еллык бәйрәменә багышлап язылган. Аннары әдип «Кызыл Шәрык» журналының 1920 елгы 1—4 саннарында «Сарайларга — сугыш, фәкыйрь өйләргә — туганлык» исеме белән зур-зур өч мәкалә бастыра.

Бу мәкаләләрдә сыйнфый көрәш һәм аның кешелек җәмгыяте үсешендәге роле, социаль революцияләр, 1789 һәм 1848 еллардагы буржуаз революцияләрнең характеры һәм төп асылы, бөек Октябрь революциясе, пролетариат диктатурасы, Октябрь революциясенең халыкара әһәмияте, аның дөньякүләм революцион процесска йогынтысы кебек үтә мөһим фәнни мәсьәләләр яктыртыла. Ул мәкаләләр, авторның бөтен дөнья тарихына караган мәсьәләләрдә киң эрудициясен күрсәтү белән бергә, аның Россиядәге революцион хәрәкәт тарихын, Октябрь революциясен һәм тарихи материализмны тирәнтен үзләштергән марксист булуы хакында да сөйлиләр. Г. Ибраһимовның үз сүзләре белән әйткәндә, аларда кешелек җәмгыятенең борынгы ыруглык чорыннан 1917 елның октябренә кадәрге бөтен тарихы «диалектик ысул» белән күздән кичерелә.

Хезмәт ияләрен изелүдән, һәртөрле җәбер-золымнан бары тик көрәш, сыйнфый көрәш кенә азат итә ала — Г. Ибраһимов мәкаләләренең буеннан-буена сузылган төп фикер әнә шул.

«Тарих үзенең ачы гыйбрәтләре белән исбат итте ки,— ди ул,— дөньяны каплап алган җәбер вә талауны вәгазь белән, үгет, нәсыйхәт белән, яхшы сүз белән генә бетерергә мөмкин түгел. Явыз кара көч талаудан, башкалар көче илә яшәүдән үз ирке белән туктаячак түгел; башка юллар һәммәсе файдасыз, тик бер генә юл инсаниятне азатлык өмидենә ирештерәчәк.

Ул да:

— Көрәш юлы»[5].

Сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш, дәүләт власте кебек иҗтимагый категорияләр бик күптәннән яшәп килсәләр дә, беренче тапкыр гыйльми аңлатма аларга бары тик фәнни коммунизмга нигез салучыларның хезмәтләрендә генә, атап әйткәндә, Ф. Энгельсның «Семья, хосусый милек һәм дәүләтнең килеп чыгуы», «Анти Дюринг» кебек әсәрләрендә бирелде. Г. Ибраһимов укучыларны бу хезмәтләрнең эчтәлеге

---

[1] Кызыл Армиянең үзәк архивы. 17 фонд. I тасвирлама. 11 эш. 196 бит.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивы. 1378 фонд. 1987 тасвирлама. 110 бәйләм. 378 эш. 30 бит.

[3] Г. Ибраһимов. Шәрык пролетариаты вәкилләре арасында. «Кызыл Армия» газетасы. 1919 ел. 28 декабрь саны.

[4] Шунда ук.

[5] «Мәгариф» журналы. 1918 ел. 1 сан. 2 бит.

белән таныштыра, дәүләтнең ничек, ни өчен килеп чыкканын аңлата, дәүләт аппаратының кемгә, нәрсәгә, кайсы сыйныфка хезмәт итүен күрсәтә. «Коммунистлар партиясе манифесты»ннан дәүләт машинасы турындагы сүзләрне китергәннән соң, әдип, бу машина кем кулында булса, шуңа хезмәт итә, тормыштагы бик күп фаҗигалар марксизмның нигез ташларыннан саналган шушы төп законны аңламаудан килеп чыга, ди. Тарихтан әлеге марксистик тезисны расларлык күпләгән мисаллар китерә. Мәкаләләрдә пролетариатның тарихи роленә югары бәя бирелә, хезмәт ияләренең барлык катлауларын азатлыкка чыгарырга сәләтле бердәнбер көч итеп ул сурәтләнә. Г. Ибраһимовның идея-политик карашларын, аларның өлгергәнлек дәрәҗәсен күрсәтү ягыннан бу фикер аеруча игътибарга лаек.

Ул үз мәкаләләрендә социаль революцияләргә зур урын бирә. Тарихта азмы-күпме әһәмиятле урын тоткан буржуаз революцияләрнең барчасын санап узганнан соң, Ибраһимов аларның төп асылын түбәндәгечә билгели: «Югарыда саналган революцияләрнең гамәли нәтиҗәсе, иске, черек феодализмны җимереп, хакимияткә яңа сыйныфны — буржуазияне мендерде, капитализмның киңәюенә юл ачты...»[1]

Автор фикеренчә, һәр революциядәге иң төп нәрсә — дәүләт власте мәсьәләсе. Билгеле булганча, бу — марксизм тәгълиматында нигез ташларыннан саналган проблема. Һәм аны аңлатуда Г. Ибраһимов үзен тагын бер мәртәбә өлгергән марксист итеп күрсәтә. Ә бит даһи юлбашчыбыз Ленин сыйнфый көрәш турындагы тәгълиматны пролетариат диктатурасын тануга кадәр җиткерә алган кеше генә чын марксист була ала, дигән иде.

Пролетариат диктатурасы мәсьәләсе уңае белән Галимҗан Ибраһимов Париж коммунасы тәҗрибәсенә тукталa, Россиядәге пролетар революция барышында ул тәҗрибәдән файдалану хакында сөйли. Шуның белән бергә ул, рус революциясе марксизмның сыйнфый көрәш һәм дәүләт власте турындагы өйрәтмәсен тулысынча раслады, ди һәм мәсьәләнең бу ягына аеруча нык басым ясый. «Россиядәге пролетариат революциясе нәтиҗәсендә,— дип яза Г. Ибраһимов,— хезмәт ияләренең җәмгыятьтә биләгән урыны һәм дәүләт властеның характеры тамырдан үзгәрде: ул эксплуатацияләнүче күпчелекне изү коралыннан эксплуататор сыйныфларны изү коралына, хезмәт ияләренең интересларын яклау коралына әйләнде». Күренекле әдипнең бу мәкаләләрендә безнең илдә пролетариат революциясенең җиңүенә һәм пролетариат диктатурасы урнашуга китергән экономик, политик, социаль сәбәпләр тикшерелә. Башка революцияләр белән тыгыз бәйләнештә карап, Г. Ибраһимов Октябрь революциясен сыйнфый көрәш үсешенең, кешелек җәмгыяте үсешенең закончалыклы нәтиҗәсе дип саный. Бөтен дөнья хезмәт ияләренең Октябрь революциясе белән тирәнтен кызыксынып яшәүләре, дәүләт властеның формасы, пролетариат диктатурасы кебек җитди мәсьәләләрне тизрәк хәл итүне сорый, шуңа күрә автор аларга тулырак тукталырга була.

Марксизм-ленинизм классиклары бу проблемаларга һәрвакыт зур игътибар бирә килделәр. Аерым алганда, алар Энгельс тарафыннан эшкәртелгәннәр, В. И. Ленин хезмәтләрендә яктыртылганнар. Г. Ибраһимов, мәсәлән, бөек юлбашчыбызның «Дәүләт һәм революция», «Пролетариат революциясе һәм ренегат Каутский» кебек хезмәтләрен телгә ала. Аңарчы татар телендә дәүләт власте, пролетариат диктатурасы хакында язылмавы, бу читен мәсьәләләрне татар ярлыларының аңына җиткерү юнәлешендә киң тәҗрибәнең булмавы, чыннан да, Г. Ибраһимов өстенә төшкән кыенлыкны тагын да авырайткан. Авторның теләге консерватив карашлардан котыла алмаган кешеләр белән сүз көрәштерү түгел, билгеле. Чөнки бу ташлы җиргә иген чәчү белән бер булыр иде. Бу мәкаләләрен автор сукадан бушаган авыл ярлысына, станоктан бушаган завод-фабрика эшчеләренә, хәрби эшләрдән буш сәгатьләрдә казармада кызыл почмакларга җыелган солдатларга марксизм-ленинизм тәгълиматын төшендереп бирү нияте белән яза. Күрәсез, Октябрь революциясе нәтиҗәсендә яңа тормыш төзү, аңлы политик эшчәнлек юлына баскан эшче, крестьян һәм солдат массаларына Ленин сүзен җиткерүне Г. Ибраһимов җитди бер эш дип санаган һәм үзенең гыйльми эшчәнлеген пропаганда эше белән бәйләп алып барган.

Галимҗан Ибраһимов мәкаләләрендә кузгатылган мөһим мәсьәләләрнең тагын

[1] «Кызыл Шәрык» журналы 1920 ел. 1 сан. 9 бит.

берсе — Карл Маркcның капитализмнан социализмга күчү чоры турындагы тәгълиматы. Бу чорның төп бурычы — капитализмны җимереп социалистик җәмгыять төзү. Бу чорда дәүләт властеның формасы пролетариат диктатурасы рәвешендә генә була алачак. Башка сыйныфлардан аермалы буларак, ди Ибраһимов, пролетариат үз диктатурасының сыйнфый характерда булуын ачыктан-ачык белдереп чыга. Алга таба ул дәүләтнең бетүенә бәйләнешле мәсьәләләргә туктала.

* * *

1917 елгы Октябрь революциясе тәҗрибәсе, аның характеры һәм төп көчләре, шулай ук рус революциясенең тарихи әһәмияте кебек мәсьәләләр Галимҗан Ибраһимовның «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле хезмәтендә тирәнтен һәм тулы яктыртыла. Бу хезмәт — «Социаль революция» исемле сериядән икенче китап. Матбугатка 1922 елда гына чыкса да, авторның үзенең күрсәтүенә карагандa, ул аны 1920 елның февралендә ук тәгәлләгән булган. Һәм бу сериядә чыккан беренче китабы кебек ук, автор аны «вакытсыз һәлак булган бөек революционер Мулланур Вахитовның» якты истәлегенә багышлаган.

Керештә автор үз китабын «Тарихка материаллар» дип атый. Икенче бер урында ул, үз алдыма Октябрь революциясенең тулы тарихын яктырту бурычын куймадым, ә бәлки аны хәзерләүнең һәм ясауның, шулай ук марксизм-ленинизмның пролетариат диктатурасы хакындагы тәгълиматының кайбер мөһим мәсьәләләрен генә яктыртырга теләдем, дигән искәрмә дә бирә. Әмма автор үз хезмәтен никадәр генә тыйнак бәяләмәсен, «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле китапның дөньядагы беренче социалистик революциясенең теоретик һәм сәяси характердагы күп кенә мөһим якларын фәнни яктан тирән чагылдырган, пролетариат диктатурасы, көчеш дәвере кебек мәсьәләләрнең практикада ничек тормышка ашуын яктырткан җитди марксистик хезмәт булуын әйтергә кирәк. Ул — әлеге темага караган күп санлы әдәбиятны өйрәнеп, архив материалларына, газета-журнал мәкаләләренә таянып язылган әсәр.

Методологик яктан бу хезмәт марксизм-ленинизм классикларына, В. И. Ленинның Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы турындагы әсәрләренә нигезләнгән. Ул — Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы хакында татар телендә язылган беренче оригиналь хезмәт. Анда революционер Ибраһимов революциянең күп кенә якларын һәм үзенең шул революциядә катнашуын киң итеп, тирән итеп күрә белүче, большевистик позицияләрдән чыгып бәяли белүче марксист тарихчы буларак күренә. Һәм бүгенге тарих галимнәренең, Октябрь революциясе хакында хезмәтләр иҗат иткәндә, күренекле әдип, танылган революционер каләме белән язылган бу хезмәтне читләтеп үтүләре һич тә аңлашылмый.

Китапның төп темасы Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы хакындагы мәсьәләләрне тикшерү булса да, моңарчы тарихта тиңе булмаган бу бөек революциянең әһәмиятен тирәнтен күзаллау нияте белән, автор 1917 елгы февраль революциясенә дә шактый киң туктала, патша самодержавиесен җимелүгә дучар иткән социаль көчләрне һәм экономик сәбәпләрне ачыклый. Шунсыз Октябрьның әһәмиятен аңлау кыен булачак, чөнки февраль «Октябрьның прологы» булды ди, Ибраһимов.

Алда күрсәтеп үтелгәнчә, Г. Ибраһимов царизмның җимерелүен, февраль революциясен никадәр генә шатланып каршыламасын һәм революцион көрәшкә никадәр генә актив катнашып китмәсен, баштарак әле бу революциянең төп асылы һәм характеры хакында аның фикере анык булмый.

Әдипнең бу китапта гаҗәеп үсеш кичергәнлеге күренә. Г. Ибраһимов хәзер февраль революциясенең характерын һәм максатларын, аның төп көчләрен һәм вазифаларын гаять төгәл билгели. Меньшевиклар һәм эсерлар революция буржуаз-демократик характерда булгач, максаты капитализмның үсүенә юл ачу, мөмкинлек тудыру булгач, февральдән соң власть буржуазия кулына күчәргә тиеш дигән фикер таратмакчы булалар. Г. Ибраһимов аларның бу сафсаталарына кискен каршы чыга. Мондый карашлар яңалык түгел, большевиклар белән меньшевиклар арасында бу мәсьәлә буенча көрәш РСДРПның II съездыннан бирле килә, ди автор.

Февральдән соң Россиядә ике властьлылык барлыкка килә: бер үк вакытта пролетариатның һәм крестьяннарның революцион-демократик диктатурасы органы сыйфатында эшче һәм солдат депутатлары Советлары да, буржуазия органы булган Вакытлы хөкүмәт тә яши. Г. Ибраһимов бу мәсьәләләргә дә туктала.

Советлар 1905 елда, пролетариатның самодержавиегә каршы көрәш утында туды һәм соңыннан капитализмнан социализмга күчү чорының дәүләт формасы булып китте. Ибраһимов беренче Советларның барлыкка килүләренә, царизмга каршы көрәшенә, революцион массалар арасында популярлык казануларына туктала, аннары аларның тарихи әһәмияте турында сөйли. Советлар Россия революциясенең зур казанышы булды, ди автор.

Илдә туган ике властьлылык турында ул болай яза:

«Барлык алпавытлар, фабрикант, банкирлар, боларның төрле төстәге ялчылары: уң профессорлар, адвокатлар, язучылар — бар да Милюков-Гучков компаниясенә кушылып, думаның вакытлы комитеты тирәсендә оештылар. Революцияне тудырган пролетариат, аңа кушылган гаскәрләр, крестьяннар, азмы-күпме революционер булган барлык демократия февральнең ахыргы көннәрендә оешып җиткән «эшче-крестьян Шуралары һәм аның башкаручы комитеты» тирәсенә җыелды. Бу ике оешманың соңгысы революцияне тудырса, аны саклау өчен бердәнбер чара булса, әүвәлгесе халык дулкынының көчләве белән тыштан революциягә кушылырга мәҗбүр кылынган буржуазиянең актык таянычы, революцияне авызлыкларга, буарга, аның куәтле агышын хакимиятнең борынгы алпавыт-крепостник мирзалар груһыннан капиталистларга күчүе белән туктатырга — бөтен эшне буржуазный дүртенче дума алдында мәсьүл хөкүмәт тудыру белән бетерергә тырыша иде»[1].

Моңдый хәл ничек туган соң!

Аның сәбәпләрен Г. Ибраһимов түбәндәгечә аңлата: буржуазия революциядән өркә иде, шуңа күрә бөтен чаралар белән монархияне саклап калырга тырышты. Әлеге фикерләрен раслар өчен, ул ышандырырлык тарихи фактлар (дәүләт думасы председателенең патшага телеграммалары, Милюковның чыгышлары һ. б.) китерә. Документлардан күренгәнчә, революциянең тирәнәя баруыннан курыккан буржуаз партияләр, үз араларындагы һәртөрле низагларны онытып, кадетлар канаты астында берләшергә мәҗбүр булалар.

Властьның буржуазия кулына күчү сәбәпләрен аңлатканда, Г. Ибраһимов халыкның байтак өлешенең аң ягыннан артта калган булуын, аларның буржуазия белән пролетариат арасында икеләнеп калуларын күрсәтә, шул хәлдән буржуазия оста файдалана белде, ди. Шулай ук пролетариатның җитәрлек дәрәҗәдә аңлы һәм оешкан булмавын да сәбәп итеп китерә. Автор фикеренчә, большевиклар партиясе җитәкчеләреннән күбесенең сөргеннәрдә һәм төрмәләрдә, ә В. И. Ленинның чит илдә булуы да эзсез калмый.

Революцияне пролетариат ясап та, аның җимешләреннән буржуазия файдаланган һәм, властьны үз кулына алып, аны пролетариатка каршы борган очраклар тарихта аз түгел. Мисал рәвешендә автор Франциядәге 1830 елгы июль монархиясен, 1848 елгы революция чорында генерал Кавеньякның канлы террорын, 1871 елда Париж Коммунасын бастыруны искә төшерә.

Электә изелгән халыкларның, аерым алганда, татар һәм башкортларның февраль революциясенә мөнәсәбәтләре мәсьәләсенә тукталып, Г. Ибраһимов бу халыкларның төрле катлаулары революцияне төрлечә каршыладылар, ди. Әйтик, дәүләт думасындагы мөселман фракциясе бу көннәрдә искиткеч бер эшсезлек күрсәтә. Урыннарда исә сыйнфый аерымлану һаман тирәнәя бара; буржуазия идеологлары һәм милләтчеләр Вакытлы хөкүмәтне яклап чыгалар, хезмәт иясе бәхете өчен көрәшүчеләр революцияне дәвам иттерү, аны социалистик революциягә әйләндерү өчен көрәш җәелдереп җибәрәләр. Шул соңгылар арасында Г. Ибраһимов үзе дә була.

Вакытлы буржуаз хөкүмәт капитал һәм алпавытлар интересын яклады, алай гына да түгел, халык массаларына каршы булган политика үткәреп килде. Ул җинаятьчел империалистик сугышны дәвам иттерде. Алпавытларның җир милке кагылгысыз кал-

[1] Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы. Казан. 1922 ел. 7—8 битләр.

ды. Милли изү бетерелмәде, хөкүмәт сигез сәгатьлек эш көнен законлаштырмады. Меньшевиклар һәм эсерлар партияләре Вакытлы хөкүмәткә халыкны алдарга ярдәм иттеләр.

Шушы нәрсәләрне күздән кичергәннән соң, Г. Ибраһимов Вакытлы хөкүмәткә мөнәсәбәт мәсьәләсенә тукталә. Ул бу мәсьәләдә өч төрле позиция булуын әйтә: буржуазия Вакытлы хөкүмәткә тулысынча ышаныч белдерә; вак буржуазия, Советларга оялап алган эсерлар һәм меньшевиклар килешүчәнлек политикасын үткәрәләр; большевиклар һәм алар артыннан барган революцион көчләр Вакытлы хөкүмәткә ышанмау тактикасы уздыралар. Авторның сул эсерларны тәнкыйтьләве характерлы. «Сул социалист-революционерлар,— ди ул,— әле һаман уң, урта иптәшләре белән бер оешмада баргангa, алар аерым оешма буларак бу чакта бер тактика тота алмады, тик аерым кешеләр, үз исемнәреннән генә большевиклар фикеренә кушылып эшлиләр иде»[1]. Монда, барыннан да элек, ул үзен һәм аның белән бергә «Ирек» газетасы редакциясендә эшләгән кайбер башка татар һәм башкорт революционерларын күздә тота.

Вакытлы хөкүмәт составына меньшевиклар һәм эсерлар кергәннән соң, ягъни «коалицион хөкүмәт» оешканнан соң да аның характеры үзгәрмәде, ди автор. Яңа хөкүмәт оешу фактын ул «никах мәҗлесе» дип атый һәм бу турыда болай яза:

«Шулай итеп, элекке саф буржуазиядән ясалган хөкүмәт урынына вак буржуазия белән капиталистлардан кушылып яңа хөкүмәт төзелде. Шура исеменнән эсер Чернов, халык социалисты Пешехонов, меньшевиклардан Церетели, Скобелев керде. Димәк, 3 нче майда Россия революциясе үзенең икенче дәверен башлады — моңарчы үзләре читтә торып... тәнбиһләр ясау, контроль хокукын кәгазьдә игълан кылу белән канәгатьләнгән вак буржуазия, шурада күпчелек булган уң эсерлар, меньшевиклар рәсми рәвештә буржуазия белән бер өстәл тирәсенә утырдылар — үзләренең буржуазия белән килешеп бару тактикаларын гамәлгә куйдылар»[2].

Галимҗан Ибраһимовның коалицион хөкүмәткә карашы башта ук большевиклар позициясе белән бер иде, ягъни ул да бу хөкүмәткә ышанмау ягында иде, «Бөтен власть Советларга!» дигән лозунг өчен көрәште. Әмма 1917 елда әдип күбрәк әчке бер сиземләү, чамалау белән генә барса, хәзер бу күренешкә ул дөрес марксистик бәя бирә.

Автор Октябрь революциясенең юлбашчысы В. И. Ленин турында тирән хөрмәт белән яза: ул 1917 елның апрелендә аның эмиграциядән кайтуын һәм атаклы Апрель тезислары белән чыгуын искә ала; китапта Ленинның барлык 10 тезисына да анализ ясала һәм аларның һәрберсенә бик мөһим аңлатмалар бирелә. Июль вакыйгаларына тукталып, Галимҗан Ибраһимов аларны зур фаҗигагә тиңли. Әлеге вакыйгалардан соң, революциянең җитәкчесе В. И. Ленин Вакытлы хөкүмәтнең шымчы этләреннән яшеренеп яшәргә һәм 1917 елның 24 октябрена кадәр революцияне хәзерләү эше белән читтән торып, башта Финляндиядә, аннан Петроградның эшче кварталларында яшәп, җитәкчелек итәргә мәҗбүр була.

1917 елның февраленнән октябрьга кадәр революцион хәрәкәтнең төп, җитәкче көче пролетариат — иң күп изелгән һәм иң күп җәберләнгән, шул ук вакытта иң оешкан һәм иң революцион сыйныф булды, ди Ибраһимов. Язучының идея-политик эволюциясен бәяләү, аның марксизм-ленинизм тәгълиматын никадәр тирән үзләштерүен аңлау өчен бу бик әһәмиятле тезис. Китапның буеннан-буена революциянең бердәнбер эшлекле, турылыклы җитәкчесе большевиклар булды, 1905 елгы революция җиңелгәннән соң массаларны яңа революциягә хәзерләгән, моның өчен көрәшнең легаль һәм легаль булмаган барлык формаларыннан оста файдалана белгән большевиклар партиясе булды, дигән караш уздырыла. Корнилов фетнәсеннән соң большевикларның массаларга булган йогынтысы көннән-көн киңәя, тирәнәя бара. «Әллә кайчангы сайлаулар буенча, Советларда күпчелек булып утырган меньшевикларның, уң эсерларның артларында халык беткән,— ди Ибраһимов,— болар бөлгән байның буш магазиннары өстендәге вывеска урынын тотып калганнар — һәммә көч большевиклар сафына барып тулган, большевизм, буаны җимергән язгы ташкын кебек, бөтен

[1] Шунда ук, 30 бит.
[2] Шунда ук, 28—29 битләр.

Россиянең авылларына, шәһәрләренә, завод-фабрикаларына, казармаларына җәелеп киткән иде» [1].

Большевикларны революциянең бердәнбер турылыклы, эзлекле җитәкчесе итеп тануның тагын бер мөһим ягы шунда, бу сүзләрне вак буржуаз революционерлык саташулары аша пролетариат хәрәкәтенең олы юлына чыккан һәм үзе дә революцион вакыйгаларда актив катнашкан әдип әйтә. Бу исә Галимҗан Ибраһимовның, эсерлык идеологиясеннән арынып, бөтенләйгә марксизм-ленинизмга килүе хакында сөйли.

Китапның махсус бер бүлеге большевизм тарихына багышланган. Политик бер агым буларак, большевизм РСДРПның 1903 елда Лондонда җыелган II съездыннан башлана. Нәкъ әнә шул съездда большевиклар белән меньшевиклар арасында якынлашып килгән революциянең характеры һәм төп көчләре, буржуазиягә мөнәсәбәт кебек мәсьәләләр буенча фикер аерымлыклары булуы беленә. Бу мәсьәләләргә Ленин ничек караган! Үзенең китабында Г. Ибраһимов шуны бик эзлекле аңлата.

Китапта 1905 елгы революция мәсьәләләренә дә шактый зур урын бирелә. Г. Ибраһимов беренче рус революциясенең асылына, аның характерына һәм җиңелү сәбәпләренә тирән марксистик анализ ясый. Моның исә әдип иҗатын өйрәнүдә килеп чыккан кайбер бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен дә әһәмияте зур. Эш шунда, Г. Ибраһимов үзенең 1905 елгы революция вакыйгаларына багышланган һәм 1914 елда ук тәгалләнгән «Безнең көннәр» романын бары тик Октябрьдан соң, тагын да төгәлрәк әйткәндә, 1920 елда гына китап итеп бастырып чыгара алды. Әнә шул фактка нигезләнеп, кайбер тәнкыйтьчеләр бу романга Ибраһимовның революциядән соңгы иҗаты, һич югында, Октябрьдан соң яңадан карап-төзәтеп чыгылган әсәр дип карадылар. Ләкин «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле хезмәтне, аеруча аның 1905 елгы революция турындагы өлешләрен җентекләп өйрәнү мондый карашларның чынбарлыкка туры килмәвен күрсәтә. Революциянең характерын һәм төп көчләрен бәяләүдә булсын, бишенче елгы революциягә караган башка мөһим мәсьәләләрне аңлауда булсын, 1920 елда инде Г. Ибраһимов үзенең 1914 елгы карашларыннан, ягъни романның беренче вариантын язган чордагы карашларыннан, күп өстен тора.

«Безнең көннәр»нең яңа вариантына язган соңгы сүзендә автор моны үзе дә күрсәтә: «Кульъязманы икенче тапкыр типографиягә биргәндә,— ди ул,— мин аны яңадан төзәтеп чыгу түгел, хәтта бер тапкыр карап, күз йөртеп үтәргә дә вакыт таба алмадым... 1914 елда ничек язылган булса, мин аны шул килеш кочагы белән илттем дә типографиягә тапшырдым» [2]. Әдипнең «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле китабында чагылыш тапкан идея-политик карашларына ясалган анализ бу сүзләрне тулысынча раслый.

Аннары Галимҗан Ибраһимов Октябрь революциясенә күчә. Октябрьда революцион хәрәкәтнең төрле ташкыннары: эшчеләрнең капитал изүенә каршы көрәше, крестьяннарның җир өчен көрәше, тынычлык урнаштыру, империалистик сугышны туктату өчен барган бөтен халык хәрәкәте, Россиядәге азчылык халыкларның милли изүгә каршы көрәше — һәммәсе бер максатка, капитализмны бәреп төшерүгә юнәлдерелде, ди автор. Әсәрдә революциянең февральдән октябрьга кадәрге барлык этаплары: Октябрьдагы кораллы восстание, Кышкы сарайны алу, Совет властен игълан итү һәм башкалар күздән кичерелә. Ибраһимов Ленин җитәкчелегендәге беренче эшче-крестьян хөкүмәтенең тулы составын китерә. Шуннан соң урыннарда Октябрь революциясенең ничек каршы алынуы турында яза, Уфа вакыйгаларына туктала. Китапның соңгы бүлеге Совет властеның чираттагы бурычларын аңлатуга багышланган. Ахырдан Үзәк мөселман комиссариатының төзелү тарихы һәм аның эшчәнлеге турында сөйләнә.

Галимҗан Ибраһимов мәкаләләрендә һәм китабында Октябрь революциясенең халыкара әһәмияте, аның дөньядагы революцион хәрәкәткә йогынтысы кебек мәсьәләләргә зур урын бирелә. Барлык мөһим социаль революцияләрне күздән кичергәннән соң, ул бер генә революция дә милли җирлек белән генә чикләнеп калмый, ярларыннан чыккан язгы ташкын кебек, башка илләрне дә үз эченә ала, дигән нәтиҗә-

---

[1] Шунда ук. 64 бит.

[2] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. III том. Казан, 1956 ел. 429—430 битләр.

гә килә. Шул ук вакытта реакцион көчләр дә тик ятмыйлар, алар, тел, дин, милләт аерымлыкларына карамастан, берләшеп алалар да, революция утын тизрәк сүндерергә азапланалар. Бу бик аңлашыла, чөнки теге яки бу илдә кузгалган революция башка илләрдәге хезмәт ияләрендә дә якты өметләр уята. Г. Ибраһимовның үз сүзләре белән әйткәндә, бер урында кабынган ялкын капитализмның черек бинасын башка урыннардан да камап алырга мөмкин.

«Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле китапта һәм югарыда телгә алынган мәкаләләрендә Г. Ибраһимов Октябрь революциясенең дөньякүләм революцион процесска, көнбатыштагы эшчеләр хәрәкәтенә йогынтысына аеруча нык басым ясый. Германия, Болгария, Австриядәге революцияләр, дип яза ул, турыдан-туры бөек Октябрь тәэсирендә кузгалдылар. Октябрь революциясенең эчке һәм халыкара әһәмияте турындагы мәсьәлә беренче тапкыр «Бөек бәйрәм» исемле мәкаләдә күтәрелә. Бу бәйрәмне әдип, большевиклар яки эшчеләр бәйрәме генә түгел, бәлки бөтен дөньяның изелгәннәре бәйрәме, бөтен кешелек бәйрәме, дип билгели. «Без өмет итәбез һәм ышанабыз,— дип яза ул,— Россиядә милли, икътисади азатлык байрагы хаким иткән Октябрь революциясе үзенең бишегендә генә калмаячак, ел үсәсен ай үсә, ай үсәсен көн үсә торган тарихи каһарманнар рәвешендә тизлек белән үсеп, куәтләнеп, бөтен дөньяның шаһларына, солтан вә хәлифәләренә, король вә императорларына, бөтен капитализмга каршы рәхимсез сугыш ачачак, золымның, капитализмның актык нигез ташларын җимереп, юк итеп, иске, буржуаз мәдәниятне ватып, инсаниятне яңа, якты, матур, тигез вә иркен хәятка чыгарачактыр»[1].

Октябрь революциясенең иң зур, иң мөһим халыкара әһәмиятләреннән берсе итеп Ибраһимов аның Шәрыкка булган йогынтысын саный. Экономик коллыкка, политик һәм милли изүгә каршы иң әзлекле революция буларак та, изүнең шушы формалары Шәрыкта аеруча нык сакланганга күрә дә, бөек Октябрь Шәрыкның изелгән халыкларына искиткеч көчле йогынты ясый. Октябрь тәэсирендә Азия, Африканың бәйле һәм колониаль илләрендә милли азатлык хәрәкәте кузгалып китә. Әгәр Шәрык халыкларын элек түбән раса дип йөртсәләр, Октябрь аларга булган мөнәсәбәтләрне тамырдан үзгәртә. Алар хәзер, рус эшчеләре һәм ярлы крестьяннар белән кулга-кул тотынышып, уртак дошманга — империализмга каршы көрәшәләр.

Октябрь революциясе Шәрыкның изелгән халыкларына үзләрен изүчеләргә каршы ничек көрәшергә кирәклеген генә күрсәтеп калмады, бу халыкларның дөнья тарихындагы рольләрен һәм әһәмиятләрен дә күтәрде, ди әдип. Бу — бик мөһим тезис. Россия тәҗрибәсе Шәрык халыкларына азатлыкка чыгу юлын күрсәтте һәм азатлыкка сыйнфый туганлашу аша түгел, ә бәлки сыйнфый аерымлану, сыйнфый көрәш аша гына ирешеп булачагын раслады. Шул уңай белән Г. Ибраһимов Үзәк мөселман комиссариатында һәм «Чулпан»да эшләгәндә аның үзенә милли буржуазиягә һәм буржуаз матбугат органнарына каршы ничек көрәшергә туры килүен искә төшерә, һәм хәзерге көндә Шәрыктагы милли-азатлык хәрәкәтен Европада барган сыйнфый көрәштән, халыкара эшчеләр хәрәкәтеннән аерып карарга маташучыларга кискен отпор бирә. Андый карашта торучыларны ул Робинзоннар дип атый һәм болай дип яза: «Шәрыктагы революция гомуми кузгалышның бер тармагы булгач, без Гарәп пролетариаты белән Шәрык мәзлумнарын иске коллыкка каршы күтәрелгән бер гаскәр итеп карыйбыз. Фәлән мәхәллә, фәлән авыл социализмга өлгергәнме, безнең очтагы Гайфетдин белән Сәйфетдин яңа нигездә тормыш төзи алачакмы, түгелме дип тикшерми, бәлки югарыда күренгәнчә, мәсьәлә бәйнәлмиләл үлчәүдә куела. Тарихның дәвере бер бөтен булып бара. Һиндтагы хәрәкәт Британиягә тәэсир итә, Мәскәү сәясәте Әфганны уята. Шулай минем үе аякка, кулга, йөрәккә һәм киресенчә тәэсир иткән кебек, иҗтимагый революция юлында Гарәп Шәрыкны бергә барырга тормыш, тарих көчли»[2].

Бу — халыкара эшчеләр хәрәкәтенең монолит булырга тиешлеген куәтли торган мөһим фикер. Мао Цзэ-дун группасының шовинистик хәрәкәтләренә каршы көрәштә бүген ул аеруча актуаль яңгырый.

---

[1] «Мәгариф» журналы. 1918 ел. 1 сан. 4 бит.
[2] «Кызыл Шәрык» журналы. 1920 ел. 3—4 саннар. 121 бит.

Шәрыктагы социаль революцияләр мәсьәләсе, ди әдип, бер пролетариатка гына кагыла торган нәрсә түгел, чөнки Шәрыкта җәелеп барган революцион хәрәкәткә төрле политик агымнар, төрле политик катламнар катнаша. Аның бу күрсәтмәсе дә искиткеч мөһим һәм бүгенге көнгә кадәр әһәмиятен югалтмаган. «Шәрыкта хәзер дәвам иткән хәрәкәт,— ди ул,— бу әле иҗтимагый булудан бигрәк, милли хәрәкәттер... Хәзерге көндә Шәрык хәрәкәтенең башында булган паннар, милләтчеләр, ватанчылар — болар Европа империализмын куып үзләре эш башына менгәнче ярлы халык белән бергә барачаклар. Моңа ирешкәч, мәсьәлә җир, суны, йортны, магазинны, байлыкны халыклаштыру эше нәүбәткә куела башлагач, болар кире чигенәчәкләр»[1].

Күрәсез, әле шул елларда ук Ибраһимов социаль революциядә милләтчеләр азакка кадәр халык белән бара алмыйлар, дип кисәтә. Инде социаль азатлык мәсьәләләренә килгәндә, Шәрык халыклары аңа үз буржуазиясенә каршы көрәш аша гына, дөньякүләм революцион хәрәкәт белән, Европа илләренең пролетариаты белән кулгакул тотынышып барганда гына ирешергә мөмкиннәр, ди. Бу хәрәкәтнең киләчәген аңлатып, Ибраһимов диңгез дулкыннарын ишкәкләр белән генә туктатып булмаган кебек, заманның котылгысыз бу хәрәкәтен дә тоткарлап булмаячагын әйтә.

* * *

Галимҗан Ибраһимовның 1919—1920 еллардагы гыйльми эшчәнлеге революциянең җитәкчесе һәм юлбашчысы В. И. Ленинга багышланган ике зур мәкалә белән тәгәлләнә. Аларның һәр икесе Ленинның 50 яше уңае белән язылп һәм һәр икесе ике газетада бер үк көнне (1920 елның 22 апрелендә) басылып та чыга. Бу мәкаләләрдә Г. Ибраһимов бөек юлбашчының бөтен бер образын тудырырга, даһи акыл, искиткеч зур политик һәм революцион талант, югары кешелеклелек кебек Ленинга хас иң мөһим сыйфатларны бер бөтен итеп бирүгә ирешә.

«Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» исемле мәкаләдә нигездә Ленинның февральдән Октябрьга кадәрге чордагы эшчәнлеге яктыртыла. Шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, мәкаләдә В. И. Ленинның иҗат эшчәнлеге, берьяктан, большевиклар партиясе тарихы белән, икенче яктан, аның марксизм тәгълиматын, аеруча аның пролетариат диктатурасы хакындагы өлешен, тагын да үстерүе белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә. Ул әнә шуңа күрә «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» дип аталган да.

Башка хезмәтләре кебек үк, бу мәкалә әдипнең идея-политик карашлар эволюциясен ачыклау өчен дә әһәмиятле. Язучының дөньяга карашындагы үзгәрешләр, барыннан да ачыграк булып, аерым шәхесләрнең һәм халык массаларының тарихтагы рольләрен аңлау мәсьәләсендә күзгә ташлана. Бу, күрәсең, Ибраһимов өчен иң кыен мәсьәләләрнең берсе булгандыр. Үзенең автобиографиясендә, большевиклар партиясенә керүенең 1920 елга кадәр сузылу сәбәпләрен аңлатып, Г. Ибраһимов болай дип язган иде:

«Миңа РКП(б) идеологиясе белән бәйләнгән, марксизм нигезләреннән килеп чыга торган кайбер мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк иде. Мәсәлән, яман аты чыккан ихтыяр иреге, шәхес һәм коллективчылык мәсьәләләре һәм башка кайбер мәсьәләләр. Миңа аларны теоретик хәл итү өчен шактый вакыт кирәк булды һәм аларны хәл итмичә торып мин үземне ахыргача инанган коммунист дип саный алмадым. Бу эш шактый вакыт таләп итте, һәм минем РКП(б) сафларына керүем сузылды»[2].

«Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» исемле мәкаләдән күренгәнчә, хәзер инде Г. Ибраһимов шәхеснең тарихтагы ролен аңлау мәсьәләсендә нык марксистик позициядә тора. Халык массаларының юлбашчыга булган чиксез хөрмәте, ә буржуазия ялчыларының аны кулралмаулары турында язганнан соң, автор бу — Владимир Ульянов дигән бер кешегә каршы сугыш түгел, бәлки тормышның төбеннән дәһшәт белән күтәрелеп килгән авып ярлылары белән пролетариатка каршы сугыш иде, ди.

---

[1] Шунда ук, 120 бит.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, 1378 фонд, 1987 тасвирлама, 110 бәйләм, 378 эш, 28 бит.

Мәкаләдә сүз Ильич тормышының һәм революцион эшчәнлегенең иң мөһим этаплары, аның эмиграциядән Россиягә кайткач коралды восстание белән җитәкчелек итүе турында бара. Биредә Г. Ибраһимов тагын бер мәртәбә Апрель тезисларының әһәмиятенә туктала, аларның теоретик, политик һәм практик кыйммәтен аңлата.

Галимҗан Ибраһимов Ленин белән очрашу бәхетенә ирешә, берничә мәртәбә аның чыгышларын тыңлый. Бу хәл аңа Ильичның күп кенә характерлы сыйфатларын җанлы, тормышчан итеп кәгазьгә төшереп калдырырга ярдәм иткән. Ленин революциядә сыйнфый көчләрнең бүленешен ачык аңлау белән бергә, революциянең ахырын да алдан ук күз алдына китерә ала иде, ди. Ибраһимов дөрес күрсәткәнчә, үз карашларын ахырга кадәр яклый белү, хәтта азчылыкта калган очракларда да артка чигенмәү — Ленинга хас сыйфатларның тагын берсе әнә шул була. Шул хакта сөйли торган мисалларның берсе рәвешендә Г. Ибраһимов Брест солыхы вакыйгасына туктала. Бу мәсьәләне хәл итүдә үзе дә якыннан торып катнашканга күрә, автор аны шактый киң итеп аңлата.

К. Маркс белән Ф. Энгельс сыйнфый көрәшнең котылгысыз рәвештә пролетариат диктатурасына китерәчәген 40 ел буена аңлатып килделәр. Париж Коммунасыннан соң моны фәнни яктан нигезләделәр. Ләкин үзләрен боларның шәкертләре дип санап йөрткән II Интернационал лидерлары марксизмның бу төп нигез ташын чүп-чар белән каплап күздән югалттылар, империалистик сугыш башлангач исә бөтен дөнья пролетариатын сугышучы буржуазиягә баш иярга чакырдылар. Ленинның бөек тарихи хезмәтләреннән берсен Г. Ибраһимов марксизм өстенә өелгән шул чүп-чарны көчле кул белән сибереп ташлауда, II Интернационал лидерларына, һәртөрле оппортунистларга каршы кискен көрәш алып баруда, марксизмның төп нигез ташын — пролетариат диктатурасы хакындагы тәгълиматын сафландырып югары күтәрүдә күрә.

«Ленинның әдәби хезмәтләре»[1] исемле икенче мәкаләсе юлбашчының гыйльми эшчәнлеген бәяләүгә багышланган. Автор мәкаләсенең башында ук Ленин бүлмәдә утырып эшләүче галим түгел, ә политик җитәкче, оештыручы, көрәшче дип күрсәтеп китә. Шуңа күрә гыйльми мәсьәләләргә Ленин үзмаксат итеп түгел, ә хәрәкәт өчен кулланма буларак карый. Ибраһимов юлбшчының иң мөһим хезмәтләренә туктала. Мәкаләдә сүз аның «Империализм — капитализмның иң югары стадиясе», «Дәүләт һәм революция», «Пролетариат революциясе һәм ренегат Каутский», «Большевиклар дәүләт властен саклый алырлармы!» кебек әсәрләре турында бара.

Автор ул хезмәтләрнең исемнәрен санау белән генә чикләнми, аларга шактый киң аңлатмалар да бирә. Аңлатмалардан авторның юлбашчы әсәрләрен тирән үзләштергән булуы сизелеп тора. В. И. Ленинның «Большевиклар дәүләт властен саклый алырлармы!» исемле хезмәтенең теоретик һәм практик әһәмияте зур булуына аеруча нык басым ясый. Дөнья әдәбиятындагы фәнни социализм мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр арасында Ленинның «Дәүләт һәм революция» исемле әсәре аеруча игътибарга лаек, ди. Мәкаләдә бу хезмәттә күтәрелгән бөтен проблемалар тикшерелә. Ибраһимов ясаган анализлардан, аның бөтен фикер йөртү логикасыннан ачык күренгәнчә, әдип искиткеч зур акыл хезмәте башкара һәм аның идея-политик карашлары җитди эволюция кичерә.

Галимҗан Ибраһимов махсус рәвештә Ленин хезмәтләренең тел, стиль якларына туктала. Аның каләмен ул капитализмның йөрәгенә төбәлгән ук белән чагыштыра. Ибраһимов фикеренчә, Ленин үз каләменнән очкын чыгарырлык менә дигән журналист. Ленинның катлаулы мәсьәләләрне укучы аңларлык гади итеп яза белүен аеруча нык басым ясап күрсәтә.

Ахырдан Ленин әсәрләренең төрле басмаларда таралып ятуларын, бөек юлбашчы хезмәтләренең сайланмаларын чыгару кирәклеген әйтә. Бу инде яңа тормыш төзүдә, кадрларга марксистик тәрбия бирүдә Ленин хезмәтләренең тарихи әһәмиятен тирән аңлау дигән сүз иде. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: Ибраһимов биреда союз күләмендәге әһәмияте булган бер мәсьәләне күтәрә.

Ленин, якты кояш сыман, пролетариатның барыр юлын яктыртты, революциянең пролетариат диктатурасына илтүче олы юлын күрсәтте, шуңа да аның исеме мәңгегә

---

[1] «Әдәби» сүзе басылып чыккан, матбугатта чыккан дигән мәгънәдә кулланыла — М. Х.

тарихка кереп калачак. «Тарих бик күп нәрсәне, бик күп кешеләрне онытыр,— дип яза Ибраһимов,— ләкин кешелек дөньясының бик күп изге өметләре, канлы диктатура аша шул азатлык, тигезлек әмәлләре һәм шуны гамәлгә куйю юллары белән бәйләнгән булганга, азат якты киләчәкнең бәхетле угыллары күңелендә Ленин исеме мәңге яшәр» [1].

Шул рәвешчә, 1918—20 еллар арасында, турыдан-туры революцион эшчәнлек алып бару белән бергә, Г. Ибраһимов марксизм-ленинизм тәгълиматын тирәнтен өйрәнү, большевиклар партиясе һәм Октябрь революциясе узган юлны күзаллау, матбугат битләрендә марксизм-ленинизмның төп законнарын пропагандалау буенча да гаять зур эш башкара. Бу эш тагын бер мөһим адымны ясау — язучының, Коммунистлар партиясенә кереп, үз тормышын идея һәм организацион яктан большевизм, Ленин партиясе белән бәйләве өчен дә кирәкле эш булып чыкты. РКП(б) сафларына керүе уңае белән язган ачык хатында Г. Ибраһимов болай дигән иде: «Дүртенче елы барган революциянең һәммә дәверендә, һәммә фаҗигаләрендә коммунист иптәшләр белән бергә булганлыгым,... фикердә һәм гамәлдә өч ел буенча бөтенләй РКП(б) белән бергә эшләмәклегем һәммә иптәшләрнең күз алдында иде.

Бу бердәмлекне рәсмиләштерү өчен, үзенең идеологиясе һәм тактикасы белән камил бөлгенлеге ачылган сул социалист-революционер интернационалистлар партиясеннән чыгып,... Россия Коммунистлар (большевиклар) партиясенә керүемне эшче-крестьян иптәшләргә, фикердәшләргә рәсми төстә белдерәм» [2].

Г. Ибраһимов большевиклар партиясенә 1920 елның декабрендә керә. Аның марксизм-ленинизм тәгълиматы һәм Октябрь революциясе тарихы өлкәсендәге хезмәтләрен искә алып, партия стажы 1917 елның 15 апреленнән расланa.

* * *

В. И. Ленинның үлеме Ибраһимовны тирән кайгыга сала. «Мәскәүдән телеграмм бар, Владимир Ильич дөньядан китте диделәр,— дип яза Ибраһимов.— Моны ишетү белән кызыл гаскәр Сарае залын авыр кайгы басты, уенчак шат йөзләр агарынып, үлек төсенә керде, берничә секундка тел бәйләнды, йөрәкләр хәрәкәттән тукталды, күп канлы көрәшләрне олуг даһиның юлбашчылыгы кул астында үткәреп чыккан революционерларның күз аллары томаланып китте, бара торган көрәш юлын яктыртучы йолдыз сүнгәндәй, кинәт караңгылык эченә кереп югалгандай, авыр, аптыраш бер хәл туды» [3].

Ленин идеяләрен һәр эшче, крестьян күңеленә илтеп җиткерүне, халыкны ленинизм идеяләренә бирелгәнлек рухында тәрбияләүне, бөек юлбашчының васыятьләрен практик төстә тормышка ашыруны Ибраһимов үзенең изге бурычы дип саный. Юлбашчының үлеме партия сафларында паника һәм таркаулык тудырмаска тиеш, ди әдип. «Революционер өчен күз яше түгеп, өметсезләнеп тору — ят бер эш. Ленин вафат булды, инде кая барабыз дип рух төшерүчеләр — Владимир Ильичның тәгълиматын аңламаган, аның кадерле, бай көрәш белән тулы даһи хәятыннан дәрес, гыйбрәт ала белмәгән зәгыйфь, кызганыч бәндәләр генә булачак. Безнең өчен хәзер бердәнбер юл менә шул төшенкелек белән көрәш булырга тиеш. Моңар иң яхшы чара олуг юлбашчының бөтен хезмәте, тормышы, тәгълиматы белән тирән танышу, үзләштерүдер» [4].

Матәм көннәрендә Ибраһимов пролетариат юлбашчысының истәлегенә багышланган ике мәкалә язып бастыра («Ленин үлде» һәм «Ленинны аңлау, өйрәнү юлында»). Аларда ул Ленин мирасының интернациональ характерына аеруча нык басым ясый, Ленин Россия хезмәт ияләренең генә түгел, дөньядагы барлык кимсетелгәннәрнең якын дусты иде, ди.

«Тарих күп кенә олуг даһиларны белә,— дип яза Ибраһимов,— күп зур җаннар адәм балаларын авыр коллыктан коткару өмете белән кузгалган көрәшләргә коман-

---

[1] «Кызыл Армия» газетасы. 1920 ел. 22 апрель саны.

[2] «Эшче» газетасы. 1920 ел. 3 декабрь саны.

[3] «Татарстан» газетасы. 1924 ел. 24 январь саны.

[4] Шунда ук.

дирлык кылдылар, пәкин дин, тел, җир, мәмләкәт, гореф-гадәт аермасына карамастан, бөтен дөнья мәзлумнарының һәммәсенең йөрәгенә бер дәрәҗәдә якын, бер дәрәҗәдә үк кадерле, үзенеке булу — тик Ленинга насыйп булды»[1].

Үзенең мәкаләләрендә Ибраһимов укучыларны юлбашчы эшчәнлегенең төп этаплары белән таныштыра. Мәкаләләрнең һәр бүлеге Ленин җитәкчелегендә Коммунистлар партиясе узган көрәш юлының бер этабын чагылдыра. Ленинның нәселе Идел крестьяныңа барып тоташа, Ульяновларның барлык балалары революцион көрәш юлына бастылар, Ленинның дөньяга карашы формалашуда бу факторларның әһәмияте зур булды, ди.

Узган йөзнең 90 елларында Петербургка килгән көннәрдә үк инде Ленинның өлгергән марксист булуын аңлатканнан соң, Ибраһимов аның таркау марксистик түгәрәкләрне «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзына» берләштерү өлкәсендәге мөһим эшчәнлегенә туктала. Сөргенлек елларын буржуаз идеологиягә каршы көрәшеп уздыруын әйтә, ул елларда иҗат ителгән философик хезмәтләренең идеалистик махизм фәлсәфәсен җимерүдә, марксизмның сафлыгын саклауда искиткеч кыйммәтле булуларын күрсәтә.

Тагын шунысы аеруча әһәмиятле, элекке хезмәтләрендәге кебек үк, Ленинданы гадилек белән юлбашчылыкны аерылмас бер бөтен итеп карый, Ильичның гадилеге һәм тирән кешелеклеге турында Ибраһимов: «Ленин — революция корабының капитаны, пролетариат гаскәренең командиры, капитализмга каршы көрәшнең юлбашчысы гына түгел, Ленин эшче-крестьянның кайгы-шатлыгын уртаклашкан, авыр көрәшләрне масса белән кулга кул бергә кичергән, хезмәт әһеленең тормышы, җиңү-җиңелү эчендә бергә булган якын, кадерле дусты һәм иптәшедер дә»[2], — дип яза.

Октябрьның 7 еллык бәйрәме уңае белән язылган «Октябрь һәм Ленин» исемле мәкаләсендә[3] Г. Ибраһимов юлбашчының тормыш юлы һәм аның Октябрь революциясен хәзерләү, аңа җитәкчелек итү өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйли. Шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, Г. Ибраһимовның югарыда искә алынган мәкаләләре искиткеч җанлы һәм пафослы әдәби тел белән язылганнар. Алар революцион публицистиканың менә дигән үрнәкләре санала алалар. Алар марксизм тәгълиматын пропагандалау эшенә зур өлеш керттеләр. Шуның белән бергә, алар иҗат кешеләренә әдәбиятта һәм сәнгатьтә бөек юлбашчының образын тудыру юлын да күрсәттеләр. Татарча лениниананы бер дә шикләнмичә Галимҗан Ибраһимовтан башларга була.

Ленин темасы, юлбашчы образы Г. Ибраһимовны алга таба да дулкынландырудан туктамый, бу темага ул гомере буе турылыклы булып кала. Инде утызынчы елларда, каты авыру хәлендә, аның турында зур күләмле әсәр иҗат итү уе белән яна. 1932 елның 24 ноябрендә Уфа журналисты М. Бикбулатовка җибәргән хатында Г. Ибраһимов болай ди: «Син гыйнварь 21-траур көне өчен мәкалә турында әйткәнсең. Ул тема үземнең дә башымнан чыкмый, инде күп уйлана торгач, Ленин турында бөтен бер китап төсенә керт планы кузгалды. Әгәр күңелем канәгатьләнерлек бер нәрсә туса, сиңа һич булмаганда шуның үзәк материалларыннан берсен җибәрергә тырышырмын».

Авыру булуы һәм аның үзенә бәйләнмәгән башка сәбәпләр аркасында, Г. Ибраһимов үзенең иҗат планнарын тормышка ашырырга өлгермәде. Бу эш тәгалләнми калды. 1937 елда, язучының архивы белән бергә, әлеге кульъязмалар да югала.

Әмма Г. Ибраһимов эшләргә өлгермәгәнне аның шәкертләре — яңа буын татар язучылары һәм сәнгатьнең башка төрләренең вәкилләре тормышка ашырдылар. Бөек юлбашчының 100 еллыгына хәзерләнгән бу көннәрдә татар совет язучылары, композиторлар, художниклар, театр һәм кино әһелләре Ленин идеяләрен, Ленин башлаган эшнең бөеклеген һәм җиңелмәслеген сәнгать әсәрләрендә гәүдәләндерүне үзләренең иң төп бурычлары итеп саныйлар.

---

[1] «Татарстан» газетасы, 1924 ел, 24 январь саны.
[2] Шунда ук, 27 январь саны.
[3] «Татарстан» газетасы, 1924 ел, 7 ноябрь саны.

## Алексис Парнис,

грек шагыйре.

# Ленин сүзе

*Грек легендасы*

Кан-яшь белән сугарылган
Изге ил туфрагында
Коммунист сүзе, чәчәктәй,
Балкымаган чагында,
Зәңгәр учында сөекле
Элладамны тирбәтеп,
Сукранган диңгез, елаган,
Сызланып, тел тибрәтеп:
«Грекларны тагын күпме
Көйдерер вә киптерер
Кайгы-хәсрәт сәмумнары? —
Греция, әйтче бер!
Кайчангача, сеңелкәем,
Кан-яшеңне түгәрсең?
Ят куллар салган богауны
Кайчан ватар-өзәрсең?
Мин менә дошманнарымны
Дулкынымда күтәрәм,
Күтәрәм дә упкыннардан
Чыкмаслык итеп бәрәм.
Синең биек тауларыңның
Юкмыни кыялары?
Кан эчүче залимнарны
Күтәр дә бәр аларны!
Тудыр син, сеңелем, батырлар —
Көмеш калканлыларны.
Балаларыңны кем изә,
Чап, туракла шуларны».
Диңгез ишетте тауларның
Кайнар йөрәк авазын,
Кайгы-хәсрәт тулы иде.
Элладаның җавабы:
«Ах, апам — чиксез диңгезем,
Иркендер киңлекләрең.
Дулкыннарың тавышында —
Хакыйкать бар, беләмен.

Тик төпсез упкыннарыңнан
Тирән минем сагышым,
Аңлап җиткерә алмыйсың
Элладаның кайгысын.
Күрмисең: ерткыч килмешәк
Ризыксыз итте безне.
Киптерде җелегебезне,
Саргайтты йөзебезне.
Икмәкне дә ул килмешәк
Агу кушып пешерә,
Аны да кол булсаң гына,
Бил бөксәң генә бирә.
Күрмисеңме, ул кабахәт
Көмеш чишмәм суларын
Каралтты һәм сихерләде,
Кушты да агуларын.
Икмәгем һәм суым агу!
Зәңгәр диңгез, әйт син, әйт:
Батыр уллар үстерергә
Кайдан алыйм көч-куәт?!»
Диңгез шушы сүзләрдән соң
Фәрман бирде җилләргә:
— Дулкыннарны илче итеп,
Җибәр,— дип,— җир гизәргә!
Тапсыннар алар саф сулар,
Яхшы икмәк тапсыннар,
Сеңелләре — Элладага
Шатлык алып кайтсыннар.
Дулкыннар юлга чыктылар,
Күз яшь булып кайттылар:
Һәр җирдә дә бер үк бәла,
Һәр җирдә дә кайгы бар.
Тик бары бер илче генә
Кайтты якты йөз белән,
Кайтты олы сәяхәттән
Җанга якын сүз белән:

«Мин булдым Төньякта,— диде,—
Анда тәртипләр яңа:
Ярлылар ирекле яши,
Тик байлар богауларда.
Кайгы-хәсрәт болытлары
Кояшны капламаган,
Балкыйдыр анда тирә-як,
Беркем юк шатланмаган.
Кабер йоткан явызларның
Вә тираннарның барын...»
«Ничек үстергән соң ул җир
Үзенең батырларын?
Нинди анда икмәк вә су?
Һәм кем аларны биргән?
Исеме ничек бирүченең?
Чыгышы кайсы җирдән?
Мөгаен, ярдәм итәрләр,
Бирерләр киңәшләрен,
Бар, белеп кайт, сорашып кайт:
Көтәләр иптәшләрең».
Китте дә дулкын сәфәргә,
Ак күбеккә уралып,
Кайтып җитте: «Белдем,—диде,—
Серен азат улларның.
Алар атый бер сүз белән
Икмәген, суын, җирен:
Көч-куәт биргән аларга,
Азатлык биргән — ЛЕНИН.
Эчә торган саф суларын
Һәм язгы кошлар телен,
Күктәге якты кояшны
Атыйлар алар — ЛЕНИН.
Җирнең барлык байлыкларын:
Бакчасын, диңгез-күлен,
Икмәкле иркен кырларын
Атыйлар алар — ЛЕНИН».
Чал диңгез, тыңлап илчесен,
Әйтте: «Шигем бар минем:
Шулкадәр күп мәгънәлеме
Бик кыска бер сүз — ЛЕНИН?»
Җавап бирде дулкын аңа:
«Озын сүзме соң — «Илем»?
«Тормыш» сүзе дә бит кыска,
Шундый ук инде — ЛЕНИН».
Эллада юлга җыена,—
Мәңгелек газап нигә? —
Килә ул бәхетле җиргә,
Килә ул азат илгә.
«Изге Русь! Җирләрең чиксез,
Тирәндер океаннарың.
Иң кечкенә илләрнең дә
Аңлыйсың аһ-зарларын.
Ак карларың каргагандыр,
Русь, сине дә элгәре.
Кайгылардан каралгандыр
Халкыңның ак йөзләре.
Зифа буйлы наратларың
Койгандыр күз яшьләрен,
Коллык газаплары игәч
Улларыңның башларын.
Богауларымны салырга
Көчләрем җитми минем.
Азатлык-хөрлек икмәген
Атыйсыз икән — ЛЕНИН.
Миңа да өлеш чыгар син
Шул тылсымлы икмәктән...»
Русь юмарт ул: өлеш биргән,
Киңәш биргән, өйрәткән.
Ул икмәк — нәкъ кояш кебек:
Яна... янса да кала.
Ул — ялкынлы сүзләр кебек,
Йөрәкләргә юл таба.
Дулкыннар аны, куанып,
Алып кайткан илемә.
Эллада җыр итеп салган
Улларының теленә.
Кемнең йөрәге яктырса,
Кояш булып, бу җырдан,
Шул азат итәр Ватанын
Коллыктан вә зынҗырдан.
Ленин сүзе! Син — икмәк-су
Һәр халык, милләт өчен.
Көрәшергә көч бирәсең
Хаклык — хөррият өчен.
Шул икмәктән авыз итте
Бик күп көрәшче ирләр,
Үсеп чыкты Элладада
Коммунист-баһадирлар.
Аларның кулы ил өчен —
Ягымлы, назлы, иркә.
Ул куллар дошманнар өчен
Әйләнәләр тимергә.
Коммунистлар илем өчен —
Гранит колонналардай:
Яшел виноград шикелле
Үрелә-үрелә аларга,
Күтәрелә яктылыкка,
Күтәрелә җылыга,
Яшәрә һәм чәчәкләнә,
Үсә, ныгый, чыныга,
Омтыла гел югарыга
Халкымның өметләре.
Алар ташка ябышып, шиңеп
Ята иде элгәре,
Кан-яшь белән сугарылган
Греклар туфрагында
Коммунист сүзе, чәчәктәй,
Балкымаган чагында.

МАРС ШАБАЕВ тәрҗемәсе

**Виктор Байдерин**

# ЛЕНИН ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

## ТӨРМӘДӘ

*Виктор Александрович Байдерин 1916 елда Чиләбе шәһәрендә туа. Педагогия институты тәмамлый. Берничә ел буена Урал, Таҗикстан һәм Казагыстан газеталарында эшли. Соңгы 14 ел дәвамында В. Байдерин — «Известия» газетасы хәбәрчесе. 1967 елдан бирле Казанда яши.*

*В. Байдеринның «Тахиа-Ташта» исемле беренче әсәре 1954 елда басылып чыга. Шуннан соң аның балалар өчен «Михнәт кышлагыннан нәни электриклар», «Таш турында хикәяләр», «Урман сукмакларында», «Хыял ракетасында сәяхәт», «Безнең Таҗикстанда», «Аю балалары», «Җәнлекләр һәм кош-корт мажаралары», «Һиндекуш тавы артында», «Тылсымчысыз туган могҗизалар» исемле һәм башка китаплары чыга.*

*В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән аның бала һәм үсмер чаклары турында язучының хикәяләр җыентыгы Казанда басылып чыгачак.*



Казан төрмәсе Кремль артындагы текә яр өстенә урнашкан. Кремльнең гаҗәп зур, калын соры стенасы, төрмә бинасы өстенә асылынып, аны басып торгандай күренә. Ә Казанкага төшә торган шәһәр урамыннан читтә утырган караңгы төрмә үзе бөтен дөньясы белән эчендәгеләрне басып-изеп торган.

1887 елның 5 декабрена каршы төндә шушы төрмәдәге бер кешелек камераларның берсенә Владимир Ульяновны китереп яптылар.

Володя артыннан аркылы бикне шалтыр-шолтыр китереп салганнан соң, ишекне бикләгәндә, аның башында бик күп сораулар чуала иде. Камераның ярлы гына җиһазы аны гаҗәпләндермәде. Моннан беркадәр элек, шушы 1887 елның язында, Петербургта асып үтерелгән абыйсы Александрның төрмәдә нинди шартларда яшәвен күз алдына китерергә тырышып, төрмә камерасы нәкъ шундыйдыр дип уйлый иде Володя. Бик югарыда, түшәм янында ук, тимер рәшәткәле тәрәзә, күнелсез соры

стеналар, идәнгә беркетелгән шыксыз гына караваг һәм артсыз урындык...

Ләкин хикмәт боларда гына түгел. Иптәшләрне нишләттеләр икән — шул борчый аны. Барысын да кулга алып бетерделәр микән? Үзләренең студентлык билетын ташлап калдыручылар йөзләп иде бит. Бәлки артыграк та булгандыр әле. Барысы да шушы төрмәдә микән? Нигә монда шундый тын соң? Ә, әйе! Биредә стеналар бик калын шул, хәтта күрше камерадагы тавышны да ишетеп булмый.

Сәгать ничәләр бар икән? Тиздән яктыра торгандыр инде. Гаҗәп, бер дә йокы килми. Ә өйдәгеләр ни хәлдә икән? Володяны алып киткән пристав артыннан ишек шапылдап ябылганнан бирле өйдәгеләр дә күз йоммаганнардыр.

Юк, болар турында уйламаска кирәк. Йомшаклык күрсәтергә ярамый. Алда торган эшләргә әзер булырга кирәк. Теләсә ни вакытта ачу китергеч йозак шыгырдап куярга, авыр бик шалтырарга, камера ишеге ачылырга һәм карлыккан тавышлы надзиратель: «Допроска!» дияргә мөмкин.

Тик иртәнгә кадәр йозак та, аркылы бик тә шалтырамады.

Володя, салкын стенага сөялеп, тар караватта утырган хәлдә йокымсырап китте. Нәкъ шул чакны ишектә ачкыч шалтырап куйды, төнлә, надзиратель Володяны камерага кертеп япканнан соң да, шулай булган иде.

— Чык, әйберләреңне дә ал,— диде надзиратель калын тавыш белән.

Кая алып баруларын Володя сорашып тормады, чөнки надзиратель аңа барыбер әйтмәячәк. Эндәшми генә барырга кирәк.

Тоныкына яктыртылган тар коридорлар. Пычранып беткән тайгак баскычлар. Һава тынчу. Әллә тычкан исе, әллә тир белән сасыган иске кием исе шунда. Гөмбәзле бинада аяк тавышы бик каты яңгырап ишетелә.

Кайдандыр сөйләшкән тавыш килә. Ул тавыш якынайганнан-якыная бара.

Надзиратель, тавыш килгән яктагы тар, авыр ишек янына туктап, аны ачты да, Ульяновка шунда керергә ишарә ясады. Володя артыннан камера ишеге ябылып та өлгермәде:

— Ульянов!.. Дуслар, Ульянов та безнең янда! — дигән тавыш ишетелде.

Володя бу зур камерадагы кичә сходкага катнашкан студентларның барысын да диярлек таныды, һәрхәлдә, студентлык билетын ташлап калдыручылар бөтенесе дә монда иде. Кулга алынган студентларның хәзер барысын шушы камерага керткәннәр.

Студент Корнилов Володяның җилкәсенә сугып алды да:

— Я, ничек, туганкай? Исәнлек-саулыкмы? — диде.

Володя иңбашларын җыерып куйды.

— Ә сез ничек?

— Без күңел ачабыз. Җырлыйбыз, җәнҗал куптарабыз, надзирательләргә тынгылык бирмибез.

Володя эчкәрәк узып, эскәмиягә барып утырды. Ул бик киң һәм бер дә җылы тотмый торган арестант халатына төренә төште. Биредә кеше күп булса да, нишләптер салкын иде. Күрәсең, барысы да инде күнеккәннәр, җайсызлыкларны сизмиләр.

Аргы почмактан:

— Дуслар! — дигән тавыш ишетелде.— Хәзер телдән генә бөтен кешедән сорап чыгабыз. Беркем дә алдашмыйча, дөрес һәм кискен итеп: «Төрмәдән чыккач, нәрсә эшләргә уйлыйсыз?» дигән сорауга җавап бирергә тиеш. Башладык. Я, беренче булып кем җавап бирә?

Барысы да тынып калды. Балаларча шаяру да, гамьсезлек тә шундук онытылды. Һәркем кичәге сходканың һәм төрмәдә утырып чы-

гуның ахыры нәрсә белән бетәсен күз алдына китерде. Моның өчен күбесенең өйгә кайткач та башларыннан сыйпамаслар. Университетка, әлбәттә, берсен дә кире алмаячаклар. Шулай булгач, эшкә урнашырга гына кала. Эш сорап баргач, эшкә алучы чиновник, син нәрсә эшли беләсең? дип кенә түгел, элек нәрсә белән шөгыльләнден, университеттан ни өчен кудылар? — дип тә сораячак.

Бик озак эндәшми тордылар.

Алай да булмагач, сорау алуны уйлап чыгаручылар фамилияләп әйтә башладылар. Монда дәшми кала алмыйсың инде.

Володя бунт күтәрүгә катнашкан иптәшләренең җавабын бик игътибар белән тыңлап торды. Күбесенең җавабы аны канәгатьләндермәде.

Алсу йөзле, таза гына бер егет (төн чыкканчы сакал-мыеклары шактый үсеп өлгерсә дә, бу анын бик яшь булуын яшерә алмый иде) ваемсыз гына болай диде:

— Минем турыда эти кайгыртсын. Җае чыгар әле.

Икенчесе, кашларын җыерып, ирексездән генә:

— Минем эш харап инде... Бөтен семьяның ышанычы мин идем. Ә хәзер мин кем, кемгә кирәгем бар минем? — дип куйды.

— Ә мин патшаның үзенә прошение язып җибәрәм! — диде чая гына бер егет (анын тар җилкәсеннән арестант халаты төшеп аптырата иде).— Казан властьларының студентлар белән ничек кыланганнарын патша белсә, күрмәгәннәрен күрсәтер! Ә безгә университетка янәдан кайтырга рөхсәт итәр дип уйлыйм мин.

— Көтеп тор!

— Тот капчыгыңны! — дигән тавышлар ишетелде.

Тавыш тынгач, чираттагы егет, төпле генә итеп, мондый җавап бирде:

— Эх, дуслар, күбрәк булсак икән без. Бөтен Казанны, бөтен Россияне күтәрә алсак икән... Без бик әз бит әле. Безне изеп, таптап бетерерләр, юк итәрләр...

Володя Ульянов, иптәшләрен тыңлап торганда, үзен төрмәгә алып килгән пристав белән ике арада булган кыска гына әңгәмәне исенә төшерде.

Төрмәгә алып килгәндә пристав берничә мәртәбә Володяның йөзенә карады. Бу студент малай аңа бик яшь булып тоелды. Пристав арестантларның: «Төрмәгә керә торган ишек капка кебек киң, ә чыга торганы таракан ярыгы кебек тар»,— дигән әйтемен яхшы хәтерли иде. Менә бу яшь әтәч, кулга алынган студент Ульянов,— күрәсең, кемнәргә каршы кул күтәрүен һәм башыннан ниләр үтәсе барын күз алдына да китерми торгандыр.

Приставка кулга алынган кеше белән сөйләшү катгый рәвештә тыела, билгеле. Әгәр кулга алынучы — кеше үтерүче янсә карак-фәлән булса — шулай ул. Ә бу яшь егет нинди җинаятьче булсын инде? Һәм, җаен туры китереп, пристав Володяга:

— Сез, егет, ни өчен бунт күтәрәсез? Алдыгызда стена бит! — ди.

Ә Ульянов:

— Ләкин черек стена ул, төртсәң ишелергә тора,— дип, уйлап та тормыйча, зурлар кебек җавап бирә.

Приставның арестант белән сөйләшәсе килми башлый. Ул гаҗәпләнеп: «Oho! Кара, нинди егет — чакматашмыни! Тышкы кыяфәтенә карап алданырга мөмкин!» — дип уйлап куя.

Володя пристав белән булган шушы сөйләшүен уйлап та бетермәде:

— Ульянов! Төрмәдән чыккач, сез нәрсә эшләргә уйлыйсыз? — дигән сорауны ишетте.

Барысының да күзләре Володяга текәлде. Патшага һөҗүм хәзерләүдә катнашкан өчен асып үтерелгән кешенең энесе нәрсә әйтер икән?

Володя әкрен, ләкин бик ышанычлы тавыш белән:

— Минем алда бер генә юл — ул да булса революцион көрәш юлы,— диде.

Студентлар Ульяновны беләләр иде. Аңардан башка төрле җавап көтмәделәр дә.

Ә Володя, сорауга җавап биргәч, читкәрәк китеп утырды да уйга чумды. Ул әле революцион көрәш юлының никадәр кыен һәм озын булуын, киләчәктә аны нинди авыр сынаулар көтүен белми иде. Әмма кыска гына яшьлек чоры үтеп китте инде, олы кешеләрдәй, ашыкмыйча, моннан соңгы адымнарны уйлап атларга кирәк иде.

Көрәшнең максаты бик ачык: хезмәт халкын патша самодержавиесе изүеннән азат итү, самодержавиене бәреп төшерү. Ләкин патша властен ничек җимерергә, ничек җиңеп чыгарга соң? Романовлар династиясе генә дә Россиядә өч йөз елга якын хакимлек итә бит. Володя үзенең: «Ләкин черек стена ул»,— дип приставка әйткән сүзләрен исенә төшерде. Әйе, бу стенаны нык торып, көч белән, бөтен халык көче белән штурмларга кирәк. Шуннан соң ул барыбер ишеләчәк!

Камера тәрәзәләренә декабрь кояшының сүрән генә нурлары карый башлаган иде.

Бу вакытта Россия өстенә яңа көн туып килә иде.

## ЮЛ УҢАЕНДА



Тышкы яктан нәрсәдер дөбердәп стенага бәрелде.

— Нәрсә булыр бу? — дип борчыла башлады Анна Ильинична.

Ул бозланып каткан тәрәзә янына килде дә, ишек алдына карау өчен, тәрәзә пыяласының бозын эретергә тырышып, бик озак өреп торды. Тик боз бик калын иде, пыяланы эретеп, ишек алдына карый алмады.

Шул арада Володя, пальтосын иңенә салып, болдырга чыкты. Ишек алдында үрәчәле чанага җигелгән ат тора иде. Чана янында тәртипсез аударылган каен утыны таралып ята. Таза гәүдәле, зур сакаллы Кокушкино крестьяны Матвей утын өя иде.

— Борчыдыммы әллә? — диде ул, Володяны күреп.— Менә бит әкәмәт! Утынны читкәрәк бушатырмын дигән идем, ат кинәт тартып алды да, йөк стенага килеп бәрелде.

Володя тиз генә өйгә кереп, апасына әлеге дөбердәүнең сәбәбен әйтте һәм ашыгып бүреген кия-кия:

— Мин Матвейга булышыйм әле,— дип, тиз генә чыгып та китте.

Крестьян исә Володяның ярдәмен шулай тиеш бер нәрсә кебек кабул итте. Тик яшь егет авыр, юан агачларны күтәрмәсен дип кенә күзәтте.

Сөргенгә җибәрелгән апалы-энеле Ульяновлар яши торган озын гына тәбәнәк йортка Матвейның утын китерүе беренче мәртәбә генә түгел иде.

Утынны өеп бетергәч, Матвей сакал-мыекларына каткан боз кисәкләрен сыпырды да, Володяның булышуыннан бик канәгать булып, ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды.

— Менә бит: тиз дә, әйбәт тә булды,— диде ул, биек итеп өелгән әрдәнәләргә карап.

— Хәзер юлга чыкканчы мин дә бераз ял итә алам инде.

— Ерак барасызмы соң?

— Казанга барам. Нужа куарга. Базарга берәр кисмәк тозлы гөмбә алып барырга иде исәп. Акчасыз бөтенләй эш харап бит.

Матвей әйбәтләп кенә «кәҗә сыйрагы» төрде дә аңа тәмәке тутырды, аннары тәмләп тарта башлады.

— Сез соң бүген үк китәсезмени? — дип сорады Володя.

— Юк, бүген үк түгел. Малкайга да ял кирәк. Күрәсез ич: тәмам туңган, калтырый, мескен. Әтәчләр кычкыра башлау белән, яктырганчы ук кузгалырбыз. Сузарга ярамый. Төнгә кайтып та житәргә кирәк.

Кинәт Володяның күзләрендә шаян чаткылар ялтырап китте.

— Матвей агай, мине дә Казанга алып бара алмассызмы? Бергә барып, бергә кайтыр идек.

— Ник алып бармаска? Минем йөгем авыр түгел. Тик менә...

Володя крестьянның нәрсәгә ишарә итүен шундук аңлап алды.

— Бернәрсә дә булмас, Матвей агай,— дип җәһәт кенә әйтеп куйды ул.— Бер караңгыда китәбез дә икенчесендә кайтып та җитәрбез, безне кем күрсен?

Матвей тәмәке төпчеген карга ташлады да итеге белән басып сүндерде.

— Алайса, үзегез карагыз инде... Мин нишләп алып бармыйм ди. Бик теләп алып барам.

— Шәп булды әле. Мин сезне юлга чыгып көтеп торырмын.

— Туңарсыз бит?

— Җылырак киенермен.

Анна Ильинична, Володяның Казанга барып кайтырга жыенуын белгәч, чын-чынлап борчыла башлады. Әгәр көтмәгәндә становой пристав килеп керсә, энесенең өйдә булмавын аңа ул нәрсә дип аңлатыр? Юлда тагы Володяны белә торган танышлары очрап куйса? Ә Казанда... Казанда ничек кеше күзенә күренер ул, анда бит Володяны университет студентлары да, полицейскийлар да һәм Ульяновлар өендә булган башка бик күп кешеләр дә таный.

— Нәрсә калган соң сиңа Казанда? Нигә үзеңне шундый куркыныч астына куясың? — дип сорады Анна Ильинична.

— Китап кирәк, Анюта. Бик кирәкле бер китап алып кайтасы бар, ансыз һич булмый.

— Ул китапны шәһәр китапханәсеннән соратып алырга кирәк. Җибәрми калмаслар.

— Андый китапларны китапханәләрдә тотмыйлар. Ул китап бик ышанычлы бер кешедә генә бар. Бөтен Казанга бер китап. Аңлыйсыңмы, Аня?

Аня аңлады. Бик куркыныч булса да, Володяны Казанга бармый калырга күндереп булмаячагын шундук сизеп алды. Һәм ул, борчылып каткан тәрәзә янына баскан килеш, шундый озын һәм куркыныч сәфәргә чыгарга ниятләгән энесен ничек итеп җылырак киендерергә икән дип уйлана башлады.

...Бу төнне Володя йокларга ятмады. Утны басып, ярым караңгыда укып утырды, әтәчләр кычкыруын ишетми калмагаем дип әледән-әле төнге тынлыкка колак салды.

Ниһаять, әтәчләр кычкыра башлады. Башта берсе, аннары икенчесе. Аннары кайдадырерактарак — өченчесе кычкырды.

Володя, өйдәгеләрне уятмаска тырышып, өстенә киенде, әкрен генә кунак бүлмәсенең ишеген ачты. Бүлмәдән аның каршысына Анна Ильинична чыгып килә иде.

— Бернәрсәңне дә онытмадыңмы инде? — дип сорады ул тыныч кына.

— Син йокламыйсыңмыни, Аня? — дип гаҗәпләнде Володя.

— Миндә йокы кайгысы юк, Володя. Син, зинһар, сак була күр инде. Үзең әйткәндәй, архи сак бул. Сүз бирәсеңме?

— Бирәм.

Кухня ишеге шапылдап ябылды. Володя чыгып китте. Анна Ильинична аяк астында кар шыгырдавыннан тышта бик салкын булуын аңлады.

Тигезле-тигезсез юлдан атлап барганда, Володя үзеннән шактый артта бер карамчык күреп алды. Бу — Матвей олавы иде.

Володяны куып житкәч, Матвей күңелле генә итеп:

— Тунгансындыр инде? Мин сезгә дип күршедән толып алган идем,— диде.

Володя чанага утырырга дип аягын күтәргән көе хәрәкәтсез калды.

— Күршегезгә нәрсә дидегез соң сез?

— Борчылмагыз юкка, утырыгыз. Гөмбә салган кисмәкне төрергә кирәк, югыйсә, юлда барганда гөмбәләр бозланып ката, балта белән чабып алырлык була, дидем. Утырыгыз, утыр!

Володя толыпка төренеп, чана түренә сөялеп утырды. Аның уң ягында гөмбә кисмәге иде.

Матвейның аты бик елдам булып чыкты. Ул үр менгәндә дә житез атлый, үр төшкәндә дә, башын селеккәләп, пошкыргалап, бик шәп юырта иде.

Матвей Володяны сораулар биреп йөдәтмәде. Әйтерсең, ул үзенең юлдашын бөтенләй оныткан иде. Ара-тирә атына гына чөңгереп алгалый, аңа, кешегә эндәшкәндәй итеп:

— Я, нәрсә колакларыңны торгыздың! Җәһәтрәк атла, җәһәтрәк! Кара син аны, ялкауны...— дип куя иде.

Бераздан Володя толып эчендә жылынып йокыга китте.

Моны Матвей да сизде булса кирәк, аты белән сөйләшүдән туктады. Аннары дилбегәсен каккалап, чыбыркысын һавада әйләндергәли башлады.

Бер борылышта чана бер якка чалулап китеп, чана табаны каткан кар өеменә бәрелде. Гөмбә салынган кисмәк Володяның кабыргасына китереп төртте. Ул күзләрен ачты.

— Без кай тирәдәрәк, Матвей агай?

— Казанга кереп киләбез. Сез кайда төшәсез?

— Мин шушында төшеп калам. Ә кичен сезнең белән әнә теге кабак янында очрашырбыз. Онытмассызмы?

— Кабакны ничек онытасың ди инде? Юлга чыкканчы берәрне бушатып чыкмый булмас әле. Я, юлың уң булсын!

Володя, жылы толып астыннан чыккач, бераз калтырый башлады. Таң алдыннан суыта төшкән иде.

Володя вакытын әрәм итеп тормастан, гади хезмәт халкы яши торган тар гына бер тыкрыкка кереп югалды, ә аннары тыкрыклардан һәм ташландык урыннардан үтеп, бөтен дөньясын кар баскан Арча кырына килеп чыкты. Хәзер инде танышының өенә таба текә урамнар буйлап аска, тын тыкрыкка гына төшәсе калды.

...Кич белән Матвей юл чатындагы кабак янында Володяны юкка гына көтеп тормады, кабакка кереп чыкты, чанасы тирәсендә йөренгәләде, атының алдына йомшак печән китереп салды. Аннары яңадан шау-гөр килеп торган төтенле кабакка кереп утырды, бер стакан чәй дә эчеп алды.

Караңгы төште. Матвей, кабактан чыгып, ат өстенә япкан калын киндерне алды һәм үз алдына: «Менә бит син, әкәмәт! — дип сөйләнә-сөйләнә юлга чыкты.

Аның башында ике төрле уй чуала иде. Беренчесе — бик борчулы: әгәр шәһәрдә Володяны берәрсе танып, полициягә барып әйткән булса?

Икенчесе исә бераз тынычландырырлык: бәлки Володя юл чатындагы кабакка Матвейдан элегрәк килгәндер дә берәрсенә утырып кайтып киткәндер.

— Әйдәгез, малкай! — дип, Матвей дилбегәне кагып җибәрде.

Озак басып торып шактый туңган ат кинәт кузгалып китте. Алар барысы да кайту юлына чыккач кызурак атлыйлар.

Бушлыктагы кар чокырыннан каршысына бер кеше килеп чыккач, Матвей сискәнеп китте. Дилбегәсен тартып: «Әллә юлбасар инде!» — дип куркынып куйды ул. Ләкин текәлебрәк карагач, ул гаҗәпләнде дә, шатланды да: юл читендә Володя Ульянов басып тора иде.

Ул атны танып алган күрәсең. Чана белән тигезләшкәч, Володя эндәшми-нитми генә чанага сикереп менде дә чанадагы толыпка төренеп ятты.

Матвей Володядан бер нәрсә дә сорашмады. Полиция шымчылары егетнең эзенә төшкәннәрдер дип уйлады ул, күрәсең. Матвей кабак янында озак юануына үкенеп куйды. Володя шушындый суыкта шул гомер туңып торган бит.

Текә ярлар артыннан шәһәр күренми башлагач, Володя терсәгенә таянып бераз калкына төште дә:

— Безнең арттан килүче юкмы? — дип сорады.

— Күренми. Ә сез ятыгыз, җылыныгыз. Аякларыгыз берни дә тоймый торгандыр инде.

— Тоя,— диде Володя, елмаеп.

Матвей атына чүңгереп куйды, югыйсә ат болай да бик шәп элдертә иде.

Володя тагын нәрсәдер сорады. Чана табанының шыгырдавы Матвейга аның сүзен ишетергә ирек бирмәде. Шулай да Матвей тагын артына борылып:

— Юк, безнең арттан берәү дә килми,— диде.

Бөдрә якалы толып астыннан әкрен генә көлгән тавыш ишетелде.

— Аны әйтмим мин,— диде Володя.— Мин: «Гөмбәгезне әйбәт саттыгызмы?» — дим.

— Ә, әнә нәрсәне сорыйсың икән! Бик шәп, бик әйбәт булды. Әйдә, малкай, җәһәтрәк кыймылда.

«Әгәр полицейскийлар куып житсә, безгә эләгә инде — Ульяновка да, миңа да»,— дип борчылып уйлана бирде Матвей.

Тик алар артыннан берәү дә кумый иде.

Кощак тавын менгәндә тәшвишле бер хәл булып алды (тар гына елгадан күтәрелә торган текә үрне халык арасында Кощак тавы дип йөртәләр, чөнки бу елга буена бәләкәй генә Кощак авылы утырган). Таудай калкып торган бу биек ярга менгәндә, атларга җиңелрәк булсын дип, олаучылар җәяүләп менәләр. Матвей да чанадан төште. Ат, көчәнә-көчәнә, чананы тауга каршы тартып алып китте.

Нәкъ шул чакта Матвей кыңгырау тавышы ишетеп артына борылып карады. Яхшы атлар җиккән тройка чана каты чаптырып каршы яктагы ярдан елгага төшеп килә иде.

Менә ул күперне чыкты да тауга менә башлады.

«Әгәр болар безнең арттан куып килүчеләр булса — алардан ычкынып булмаячак»,— дип борчылып куйды Матвей.

Ул, иелеп, толып итәкләрен Володяның астына кыстырды да әкрен генә:

— Почта килә. Сез инде кыймылдамагыз,— диде.

Тройка һаман җилдереп килә, якынлаша иде. Ямщикның: «О-гэй! Әйдә, җәһәтрәк!» — дип кычкыруы ишетелде.

Тауның түбәсенә менеп житәрәк тройка Матвей чанасы белән тигезләште. Күбеккә баткан атлар атлап кына бара башладылар. Матвейның тәне чымырдап китте.

Тройканың ямщигы ат башыннан төшеп, якын ук килгәч, Матвей тагын да курка калды.

— Тәмәке кабызыйк әле,— диде ямщик, һәм салкын һавада тәмсез аракы исе аңкып китте.

Матвей бик каушап чакматаш, корыч кисәге һәм чакма мамыгы салынган янчыгын чыгарды. Ямщик ашыкмый гына тәмәке кабызырга әзерләнде, берничә мәртәбә чакма чакты. Төнге караңгыда йомшак мамык өстенә, суккан саен, якты очкын чәчелә иде. Ниһаять, мамык, әче төтен исе чыгарып, пыскый башлады. Ямщик папиросын кабызды, аның авызыннан бөтерелеп төтен чыкты, аннары ул, мамыктагы утны бармагы белән сүндереп, Матвейның ут таба торган гади генә коралын үзенә кире бирде.

— Син дә тартасыңмы соң? — дип, ямщик кыйммәтле папирос салынган портсигарын Матвейга сузды.

— Юк, тартмыйм мин,— дип алдашты Матвей.

— Кокушкинога еракмы әле?

— Унбиш чакрымлап булыр. Кокушкинода кемегез бар соң, туганнарыгызмы, әллә танышларыгыз гынамы? — дип сорады Матвей, кыюлыгын җыеп.

— Беркемебез дә юк! Берәрсендә кунарбыз дибез. Безнең юл ерак әле — Алабугага кайтабыз. Купец Мешковны ишеткәнең бардыр бит?

— Ничек булмасын! — дип, Матвей тагын алдашты.

— Аны Казаннан туйдан алып кайтам. Ярый, хуш иттек!

— Хәерле юл! — дип, Матвей әзрәк бүреген күтәреп куйды.

Матвейның аты Кокушкинога килеп кергәндә, бер генә өйнең тәрәзәсендә дә лампа уты да, чыра яктысы да юк иде инде. Вакыт бик соң иде.

Володя чанада торып басты, каты итеп Матвейның кулын кысты һәм шыпырт кына: «Рәхмәт, Матвей агай!» — дип, шыгырдап торган кар өстенә ялт кына сикереп төште.

— Хәерле сәгатьтә! — диде Матвей һәм дилбегәсен кагып җибәрде.

Володя шушы яшерен сәфәрдән соң берничә көн буена чаңгыда йөрергә дә, ауга да чыкмады. Ул шәһәрдән алып кайткан теге китабын кат-кат укып утырды. Бу — Н. Г. Чернышевскийның власть ияләре тарафыннан тыелган һәм барлык китапханәләрдән җыеп алынган мәкаләләр җыентыгы иде.

— Бу мәкаләләрне син дә укып чык, Аня,— диде Володя апасына.— Һичшиксез, укып чык. Язга таба миңа Чернышевскийның зур әсәрен — «Нәрсә эшләргә?» романын җибәрергә вәгъдә иттеләр. Мин аны малай чакта ук укыган идем, дөресен әйткәндә, әсәрнең тирән мәгънәсен ул вакытта аңлап бетермәгәнмен.

Бер атналап вакыт үткәч, Володя тышта Матвейның утын ярганын ишетте. Ул чыгып исәнләште дә:

— Я, Матвей агай, эшләр ничек? — дип сорады.

— Эшләр шәптән түгел,— диде Матвей селтәнә-селтәнә туң каен кискәләрен яра биреп.

Володя аңардан балтаны сорап алып, ап-ак тузлы берничә юан агачны ярып ташлады.

Ләкин Матвей Володя эшләгәнне озак карап тормады. Балтаны кире алып, малаена эндәшкәндәй ягымлы итеп:

— Бар, кирегез. Салкын тидерерсез,— диде.

«Акыллы кеше. Әйтерсең лә, минем Казанга барып кайтуымны бөтенләй белми. Мондый кеше полициягә тотып бирмәячәк»,— дип уйлады Володя бу крестьян турында.

Р. **КАМАЛОВА** тәрҗемәсе

# ҮЗ АЧКЫЧЫ



— Володя, карале, мин сиңа нинди әйбәт бүлмә әзерләп куйдым.

Бик матур култыксалы, текә генә тар агач баскычтан Мария Александровна икенче катка менде дә ишеге ачык бер бүлмә янында туктап калды.

Чыннан да, кечкенә генә бүлмә гади һәм әйбәт итеп җыештырылган (моны Мария Александровна гына шулай эшли ала иде). Артык бер нәрсә дә юк биредә: стенага ачык төстәге чәчәкле обой ябыштырылган. Кечкенә булса да бик җайлы бер язу өстәле, матур итеп җыештырып куелган караваг, ике китап шүрлеге һәм түгәрәк артлы бер венский урындык. Идәндә буй-буй сугылган авыл паласы.

Әле күптән түгел генә Володя Ульянов Кокушкинодан сөргеннән кайткан иде. Анда да зур өйнең флигелендә нәкъ шундый палас иде.

Әнисе бүлмәнең бөтен җирен игътибар белән карап чыкты да, улым канәгать микән дигән сыман, аңа карады.

Володяның йөзеннән ниндидер уңайсызлану сизелеп тора иде. Бүлмә аңа нәрсәсе беләндер ошап бетмәде. Шулай да ул «миңа бу бүлмә ошамый» дип әйтә алмады, чөнки бу бүлмәне җыештыру һәм җиһазлауда күп көч түккән әнисенең кәефен җибәрәсе килмәде.

Мария Александровна бер ел сөргендә булу дәверендә тәмам үсеп җиткән, олыгаеп киткән улына нәрсәдер ошап бетмәгәнне сизеп алды. Ләкин ул, бүлмәнең нәрсәсе ошамады соң сиңа дип? — төпченеп тормады, ә гади генә итеп:

— Синеңчә ничегрәк кирәк иде соң? — дип сорады.

Әнисе аның канәгать түгеллеген сизеп алгач, Володяга уңайсыз булып китте.

— Беләсеңме, әни...

— Я, я, дөресен әйт — син алдаша белми идең. Оялма, әйт, әйт, син ничек теләр идең соң?

Әнисе шулай дигәннән соң, Володя кыюланып китте.

— Түбәндә, беренче катта, нишләптер ике кухня. Әгәр син каршы килмәсәң, ишектән кергәч тә уң яктагы кухняга урнашыр идем мин.

Мария Александровна кухняның җайлы булмавын белә иде. Беренче катта тәрәзәләрне агачлар һәм куаклар каплап тора, яктылык аз төшә. Күпме генә тырышсаң да, ул бүлмәне рәткә китереп булмый. Ишектән керүгә уң якта килбәтсез зур сәке, ул ревматизм авырулы картлар өчен генә яраклы нәрсә. Бу сәкенең яшь кеше өчен бер тиенгә дә кирәге юк.

Мария Александровна тиз генә шуларны уйлап алды.

Володяга бүлмәнең уңай булуы кирәк, әнисе моны йөрәге белән аңлый, ләкин бу турыда нишләп башта ук уйламаган соң әле ул? Улының күңеленә ошаган кухняның арткы ишеге дә бар, ә аннан туп-туры бакча ягына чыгып була. Ирек сөюче Володяга менә нәрсә кирәк икән!

Боларны аңлап Мария Александровна бер нәрсә дә сиздермичә, гади генә итеп:

— Син, улым, чыннан да, хаклысың. Сиңа анда яхшырак булыр, — диде. Аннары алъяпкыч кесәсеннән кухнядагы арткы ишекнең ачкычын алып Володяга бирде.

— Син гений, әнием! Син минем нәрсә уйлаганыма кадәр белеп торасың, ә? — дип шатланып елмайды Володя.

Әнисе дә ягымлы гына елмаеп куйды.

— Белергә тырышам тырышуын да, тик барысын да белеп бетереп булмый шул.

Әнисе Володяның артка тарап куйган аксыл озын чәченә, ияк һәм

яңакларында әле генә беленә башлаган кызгылт-сары бала йоннарына карады һәм үзалдына шатланып: «Кара, нинди үскән! Олыгаеп киткән! Ә мин аны һаман өч айлык сабыйны төргән кебек төрергә тырышам. Әни кешегә үзенең баласы гел кечкенә булып тоела, дип дөрес әйтәләр шул»,— дип уйлап куйды.

Ульяновлар семьясының Казанда Беренче тау урамындагы Орловлар йортының ике катлы флигеленә күчү тарихы менә шулай булды (хәзер ул йортта — Ульяновлар урамы, 58 нче йортта — Владимир Ильич Ленин музее).

Иртәгесен кухняга кергәч, Мария Александровна улының бирегә бик әйбәт урнашканын үз күзе белән күрде.

Володя бик тыйнак һәм талымсыз иде. Ул гади генә караваты янына китап шүрлеге урнаштырган, кечкенә өстәл өстенә бабасыннан калган кара савытын һәм лампа куйган, өстәлнең бер почмагына җыйнак кына итеп китапларын өеп куйган. Өч венский урындыкны да җайлы гына итеп урнаштырган. Шунысы гаҗәп: әлеге килбәтсез сәкене дә шахмат уйнау өчен көйләгән. Сәкедә ике шахмат тактасы ята иде.

Бүлмәнең спартаннарча искиткеч гади булуы сизелеп тора. Әмма Мария Александровна шушы кергәннән артык гади бүлмәгә кечкенә генә бер яңалык кертте: бакчадан ул яфракларында инде көз сулышы беленеп торган берничә өрәңге ботагы сындырып алды да бүлмәгә кертеп өстәл өстенә куйды. Бу букет ярым караңгы бүлмә эчен бөтенләй ямьләндереп җибәрде. Әйтерсең, Володяның өстәле өстендә ут кабынды — элекке кухня эче бик күңелле булып китте.

Володя да әнисенең мондый кайгыртуын игътибарсыз калдырмады. Төшке ашны ашаганда ул:

— Минем монах бүлмәсе шикелле күңелсез бүлмәмә ямь керткәнең өчен рәхмәт, әнием,— диде.

Әнисенә дә рәхәт булып китте һәм ул елмаеп куйды.

Бу өйдә Володя ике уй белән борчылып яши иде: беренчесе — ничек кенә булса да я Казан, я Мәскәү, я Петербург университетына укырга керергә тырышу; икенчесе исә — үзенең бөтен гомерен багышларга карар кылган иң төп эшкә — бөтен халыкны буып, аның канын эчеп торучы патша самодержавиесе белән рәхимсез көрәшкә хәзерләнү иде. «Ә моның өчен бертуктаусыз укырга кирәк»,— шулай иткәндә генә бу авыр мәсьәләләрне башкарып чыгып булачак, дип уйлый иде Володя.

Мария Александровна, Володя бүлмәсенә кергән саен, өстәлдә яңадан-яңа китаплар күрә. Дарвин әсәрләренең калын томнарын Бокль, Рикардо китаплары алыштыра. Алар янында ук Лев Толстой, Бальзак, Пушкин, Мериме әсәрләре була.

Көннәрдән бер көнне Мария Александровна үзенә китап сайлаганда Карл Марксның «Капитал»ын алды. Володя аны, күренмәслек итеп, башка китаплар белән каплап куйган иде.

Бу китап турында Мария Александровнаның күп мәртәбә ишеткәне бар иде инде. Бу китапның тормышка, бай һәм ярлы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә бөтенләй яңача карарга, тормышны яңабаштан корырга өйрәткәнен белә иде ул.

Мария Александровнаның йөрәге кысылып куйды. Хәзерге яшь буын алдында торган бурычны Володя үтәп чыга алыр микән? Әллә ул да абыйсы Александр хәленә төшәрме? Алла сакласын. Юк, юк, алай була күрмәсен! Ләкин нәрсә генә булса да, Мария Александровна Володяга каршы төшәргә уйламый иде. Үзе сайлаган юл белән барсын ул.

Мария Александровна кичләрен еш кына Володя бүлмәсенә төшә, тик Володя беркайчан да өйдә булмый диярлек. Кем белә, бәлки Володя шахмат клубына йөридер. Бәлки ул революцион түгәрәкләрнең яшерен утырышларына катнаша торгандыр.

Мария Александровна Володяның артык күп сөйләшмәвен дә, күп

кеше белән аралашмавын да, китап уку белән чиктән тыш мавыгуын да гафу итә иде. Ул инде зур кеше. Нишләргә кирәген үзе белә.

Володя әнисен бик ярата, аңа тулысынча ышана, әнисе аның мәшәкатьләрен, борчуларын, омтылышларын сүзсез дә аңлый, шуңа күрә әнисенә үзенең серен сөйләп, фикерләрен уртаклаша иде.

Кайчак, бүлмәгә әнисе кергәч, Володя аны үз янына утырта да дәртләнеп сөйли башлый:

— Әни, тыңла әле, хәзерге тормышның гаделсезлеген Карл Маркс нинди тирән итеп аңлатып бирә. Менә, тыңла әле, тыңла...

Ул «Капитал»ның билгеләп куелган битен ача да үзендә онытылмаслык тәэсир калдырган өзекне әнисенә укып күрсәтә.

Укып бетерүгә, тәэсирләнеп, үз фикерләрен дә әйтеп сала.

— Беләсеңме, әни, Маркс тәгълиматы пролетариат алдында нинди киң юл ача? Балкып тора торган, иксез-чиксез киң юл алар! Әгәр меңнәрчә, йөз меңнәрчә кешеләр Маркс тәгълиматларын аңласалар, алар искиткеч куәтле, чын мәгънәсендә җиңелмәс корал белән коралланырлар иде. Ул чагында алар бу дөньяның астын-өскә китерерләр, бар нәрсәне дә үз урынына куярлар, бөтен дөньяда әлегә кадәр кешелек дөньясы белмәгән гаделлек, ирек яулап алырлар иде!

Мария Александровна, улының сүзен бүлдереп:

— Володя, әллә син миңа да кылыч алып баррикадаларга чыгарга кушасыңмы? — ди.

Володя, артык хискә бирелеп, онытылып китүен аңлап ала да, уңайсызланып:

— Юк, әни. Кылычны башкалар алыр. Минем табигатем шундый инде: мин кая гына барсам да Маркс тарафдарларын эзлим һәм аның тәгълиматын өйрәнергә чакырам... Кичер мине...

— Әлбәттә, кичерәм,— ди Мария Александровна урыныннан торып.— Тик син минем киңәшемне дә тот: төннәр буе укып һәм уйланып үзеңне-үзең бетермә. Революционер өчен акыллы булу гына җитми, сәламәтлек тә кирәк.

— Яхшы, әни. Озакламый ятам. Бер брошюра гына карап чыгам.

Шушы сөйләшүдән соң берничә көн рәттән Мария Александровна Володя бүлмәсенең тәрәзәсендә ут күрмәде, Володя ул көннәрдә үзе дә өйдә булмады.

Әнисеннән алган кухня ачкычы Володяга иркенләп йөрергә мөмкинлек бирә иде.

«Тик бу ирektән жандармнар гына мәхрүм итә күрмәсеннәр»,— дип борчыла иде Мария Александровна. Бәхеткә каршы, андый хәлләр башка кабатланмады.

Владимир Ульянов Самарага (хәзерге Куйбышев шәһәренә) күчеп киткәнче, Николай Евграфович Федосеев оештырган марксистик түгәрәкләрнең берсенә йөрде. Дөрес, Володя Федосеевны күреп белми, ләкин үзенең Казандагы иптәшләреннән Федосеевның бик күп яхшы эшләре турында ишетеп белә иде.

Шулай да патша охранкасы Федосеев һәм аның иптәшләренең эзенә төшә. 1888 елның җәендә Николай Федосеевны һәм аның күп кенә иптәшләрен кулга алалар.

Соңрак Владимир Ильич бу турыда: «Әгәр ул җәйне Казанда калган булсам, мине дә бик җиңел генә кулга алган булырлар иде»,— дип язды.

Володя өчен Мария Александровна биргән ачкыч бәхетле ачкыч булып чыкты. Ул ачкыч, яшь революционерны күзәтү һәм кулга алулардан саклап, ишекне дә бик ышанычлы итеп бикләп тора иде.

**Р. КАМАЛОВА** тәрҗемәләре

**Габдрахман Әпсәләмов**

# ЯШЕЛ ЯР

РОМАН[1]

## 13

Менә башлангыч мәктәптә укулар да бетте инде. Уйласаң, бу көн һич килеп җитмәс төсле иде, никадәр борчу-мәшәкатьләр артта калган. Актыккы көндә әйтеләсе яхшы сүзләр дә әйтелгән, телисе яхшы теләкләр дә теләнгән. Балалар, портфельләрен баш өсләрендә болгый-болгый, шаулашып, көлешеп мәктәптән чыгып баралар. Утыз биш бала, утыз биш язмыш. Киләчәктә алар барысы да бер эздән барырлар дип уйлама, киләсе класска алар әле барысы да керсә дә, югары классларны барысы да уңышлы тәмамларлармы? Тормыш җилләре әле аларга кагылмаган, кагыла башлагач, ишеп-ишеп бәрергә тотынгач, күп нәрсә үзгәрер, алларында киртәләр калкыр. Мөмкинлеге булса, Гәүһәр аларга, билгеле, җил-давыл тидермәс иде, ләкин моннан инде хыял башлана. Язу да танымаган, акны кара, әлифне таяк дип тә белмәгән бу балалар ике ел буенча аның кулында булдылар, ул аларга хәреф өйрәтте, күзләрен ачты, йөрәк җылысын бирде, кешегә кеше итеп карарга өйрәтте.

Кешеләрнең күзләренә бәрелмичә генә тагын бераз буш класста утырасы иде, бетмәс-төкәнмәс уйларың белән ялгыз каласы иде. Ләкин мөмкин түгел. Болай да балалар аңа туктап-туктап аз карамадылар, алар бер нәрсә дә сизмәделәр дип үз-үзеңне юатып булмый бит, аларның яшеренеп карап торуларын күргәч, Гәүһәр, җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрдәй була иде. Нишлисең, укытучы, йөзек кашы кебек, һәрвакыт ялтырый, һәрвакыт өстә, карамас җирдән аңа карыйсың, балалар бигрәк тә...

Гәүһәр урамга чыкты. Ул балалар инде таралгандыр дип уйласа да, балалар китмәгәннәр әле. Тагын Гәүһәрне сырып алдылар, тагын бетмәс сораулар бирә башладылар. «Киләсе елда буласызмы, китмисезме?» дип кат-кат сорадылар. Һай, кая китсен Гәүһәр!

Күпмедер вакыт алар мәктәп каршында туктап тордылар, аннары бакчага чыктылар. Шау-шу, чыр-чу, ташып торган дәрт, көлү, елмаю, җәйге планнар, хыяллар — берсе дә калмады. Балаларны туктатырга да мөмкин түгел иде, алар инде бүген ни сөйләсәләр дә ярый икәнен беләләр, әйтеп бетермәсәң дә, төртелеп калсаң да, берәү дә ачуланмаячак, шуңа күрә алар тыелгысыз, бер-берсе белән сүз көрәштереп тә алалар һәм барысы да Гәүһәрнең елмайган, бәхетле йөзенә карыйлар. Ахыр килеп, аларга шул гына кирәк тә бит. Әнә кайсыдыр ак

[1] Дәвамы. Башы 6 санда.

тирәкнең ак мамыгын иптәшенең чәченә ябыштырган да дөньясын оныгып шуңардан көлә, икенчесе ямь-яшел яфраклар арасындагы нәни кошчыкны күрсәтә, чәбәләнә, иптәшләре күрми кала дип уйлый, ахрысы, өченчесе нииндидер бөҗәк тоткан...

Ниһаять, балалардан аерылгач, Гәүһәр бер минут чамасы алар артыннан карап торды, аннары, башын иеп, үз юлына китте. Әле бер минутмы, ярты минутмы ара бар, мәктәп тормышы әле онытылмаган, шәхси кичерешләре әле барысын каплап өлгермәгән. Иртәгә инде мәктәпкә барасы юклыгын уйлап алгач кына, ул кинәт боегып калды. Инде нишләргә? Мәктәпкә йөрү аның авыр тормышына әле нииндидер мәгънә бирә, аны яшәтә, көрәштерә иде. Хәзер ни белән юатыр үзен? Уку, имтиханнар беләнме? Читтән торып уку эчке тормышың түгәрәк булганда гына күзгә күренә, эчке тормышың чыгырыннан чыкса, укуларың бар дип тә исәпләнми.

Җәгъфәр белән ара көннән-көн катлаулана, кискенләшә бара. Гәүһәр һәлакәт киләсенә һич ышанмый иде. Кайгырса да, газапланса да, боларны вакытлы бер чир итеп карады, шуннан артыгын башына да китермәде. Семья җимерү — гайри табигый бер эш булыр иде, моңа барырга ярыймы соң?! Җәгъфәр дә, никадәр киреләнсә дә, акны кара дия алмас. Шуңа күрә ул Җәгъфәргә ничә мәртәбә: «Бетерик бу мәгънәсез талашны, минем дә бәгыремә төште, сиңа да җиңел түгеллеген күрәм», диде. Кайбер көннәрдә үзенә хәтта юк гаепне дә алды: «Син яхшы беләсең, мин актан ак түгел, пакьтан пакь булырга да җыенмыйм. Турсайган чакларым да, авыр сүз ычкындырган чакларым да булгандыр. Алары өчен гафу ит», диде.

Моңа каршы Җәгъфәр ачы көлемсерәде генә. Аның карашы гүя: «Тукта, артыграгын да танырсың әле»,— дия иде. Гәүһәр бу карашның мәгънәсен бик яхшы сизә. Ихтимал, шуңа күрә ярты сүздә аптырап туктап каладыр. Нәрсә соң бу, очы кая бара моның? Әле күптән түгел генә Гәүһәрнең тормышы түгәрәк, якын кешесе бар, кайтып зарын сөйли ала, эчне бер бушаткач, зар да зар булып күренми, ничектер бик тиз җиңеләя иде. Хәзер нәрсә?

Гәүһәр бик күп китаплар укыган иде, китапларда, вакыт барысын да эшли ала, аның кодрәте бик зур, дип язалар, әмма Гәүһәргә вакыт та ярдәм итмәде, киресенчә, аның хәлен көннән-көн авырлаштырды гына. Шулай булса да, ут йотса да, эчке тормышына ятларны якын китермәде, семья серен башкаларга белдермәде, бер рәтләнер әле дип көтте.

Көндәгечә бүген дә квартира буш, жансыз иде. Гәүһәр тәрәзә янына килеп утырды. Ул Җәгъфәрне көтте, бүген тагын бер мәртәбә аның белән яхшылап сөйләшергә булды. Болай ярамый бит, болай яшәргә мөмкин түгел. Җәгъфәр, ниһаять, моны аңларга тиеш. Кеше яшәргә туган, ә яшәү үз эченә шул хәтле күп нәрсәне ала, аның эчтәлеге бик зур. Квартира мәсьәләсе бик мөһим, ләкин ахыр килеп яшәү аның белән генә дә чикләнми. Хосусый квартирада торган чагында Гәүһәр бүгенгедән мең мәртәбә бәхетлерәк иде бит. Хәзер дә Гәүһәргә әллә ни күп кирәкми, ире аның кешелеген таптамаса, юк нәрсәләрдә аны гаепләмәсә, ана кеше итеп ачык чырай белән дәшсә, ул яңадан чәчәк кебек бөтен гүзәллеген ачарга әзер.

Җәгъфәр кайтты. Соңгы вакытта ул инде эчми башлаган булса да, хатынына барыбер ләм-мим дәшмәде. Сүзсез генә чишенде, сүзсез генә юынды, сүзсез генә тамагын туйдырды, Гәүһәрнең бер сүзенә дә җавап бирмәде. Шуннан соң Гәүһәрнең кухняга чыгып китүдән башка чарасы калмады. Тик Җәгъфәр тамагын туйдыргач кына, бүлмәгә кереп утырды.

— Җәгъфәр,— диде,— болай артык яшәп булмый бит. Син телисеңме, юкмы, безгә аңлашырга кирәк.

— Бер үк балык башын чәйнәргәме? Теләмим!

Шулай да Гәүһәр шатланды, димәк, Җәгъфәрнең теле ачыла башлаган.

— Җәгъфәр,— диде Гәүһәр, йомшак кына,— чын, иң якын кешеңә эчеңнән ачу саклау, аны әллә нәрсәләрдә гаепләү — бик зур гаделсезлек бит. Моны күтәрүе...

Җәгъфәр, иңбашларын җыерып:

— Шундый сүзләр әйтәсеңне элек уйларга кирәк иде,— диде.— Хәзер соң инде.

— Һаман да мин гаепле дип уйлыйсыңмы? — дип кычкырып җибәрде Гәүһәр.— Бу бит әллә нәрсә, син шуны аңлыйсыңмы?

— Аңламыйм, аңларга теләмим дә. Без инде киселгән кисәкләр.

— Ни сөйлисең, Җәгъфәр?

— Ни беләм, шуны сөйлим. Артык мине борчыма.

— Җәгъфәр, мин кемгәдер сөйләргә, киңәш сорарга мәҗбүр булачакмын бит.

— Анысы синең ихтыярың.

— Ичмасам, әйт: минем нинди гаебем бар? Тел төбеңнән мин сиңа хыянәт иткәнмен булып аңлашыла. Кайда, кайчан? Билал турында сиңа сөйләгән идем. Ул яшьлек юләрлеген онытмаган икән, анда минем ни гаебем бар? Мин ир хатыны икәнемне, аңа турылыклы буласымны...

— Зиннар, матур сүзләреңне чәчмә, мин барыбер ышанмыйм сиңа.

— Бер сүземә дәме? Мине коточкыч ялганчы дип уйлыйсыңмы?

— Ярый, сораулар тезмә. Мин сүздән туйдым инде. Җитте. Мин синнән хисап сорамыйм. Эшләгәнсең икән, белеп эшләгәнсең.

— Юк, Җәгъфәр, юк. Безне кемнәрдер буташтырган. Минем тузан хәтле дә гаебем юк.

— Мин боларны ишеттем инде.

Хәзер Гәүһәргә бер нәрсә ачык иде: Җәүъфәр семья татулыгы белән санашмый, аны кирәксенми, аннан котылырга тырыша. Гәүһәр дә шулай эшли аламы? Аңа да семья, аның тынычлыгы, аның серләре бернигә дә тормыймы? Ул да шулай бик ансат кына итеп «ихтыярың» дип әйтә аламы? Гәүһәрнең чигәләре шартлардай булып тибә башлады. Элек тә ул ара-тирә була торган җәнҗалларны авыр кичерә иде, ләкин элек алар арасында ниндидер уртак сер бар иде, ызгышлары да бик өстән генә була иде. Ә хәзер... Ул урыныннан торды, чайкала-чайкала тәрәзә янына килде, тышка карады. Анда кешеләр, машиналар уза, кемнәрдер көлә — тәрәзәләр ачык булганга болар ап-ачык ишетелә. Әнә кемнәрдер култыклашып, бер-беренә сыенып үтәләр, аларга мөгаен, рәхәттер, күңелледер. Гәүһәрнең дә кайчандыр шундый чаклары бар иде. Шулай ук кеше бәхете бер генә минутлыкмы икән, бик тиз үтәме икән? Бу бәхет өчен ничек көрәшергә кирәк? Әйе шул, бәхет өчен тарткалашырга, даулашырга кирәк, диләр. Ләкин болар сүз генә түгелме? Мин бәхет өчен көрәшәм, дип бөтен дөньяга кычкырмассың бит. Юләргә санарга да күп алмаслар. Шулай да ниндидер фикергә килергә кирәк, күрәсең, яшерен янулар, яшерен көюләр бетте инде. Оят, әмма кайгыны халык алдына чыгармыйча булмас.

Гәүһәрнең кайгысын сөйләрлек һәм аңларлык бердәнбер кешеләре— Рәхимә апа белән Галимҗан абыйсы бар иде. Тагын — Шәриф Гыйльманович. Аңа барсаң да, кире борып кайтармас, сүзеңне тыңлар, киңәшләрен бирер. Тик Гәүһәрнең аның өендә булганы юк, семьясын яхшылап белми, мәктәпкә барсаң, анда — Фаягөл. Аның белән һич очрашасы килми Гәүһәрнең. Шуна күрә иң яхшысы Рәхимә апа белән Галимҗан абыйларның өе. Алар Гәүһәрне үз кызларыдай якын күрәләр. Ин мөһиме Рәхимә апа — укытучы, ул Гәүһәрне яхшырак аңлар. Галимҗан абый кулыннан да йөзләрчә кешенең язмышы үткән.

Икенче көнне кич белән Гәүһәр аларга китте. Кызлары турында ничектер оныткан иде, баскычтан менгәндә исенә төшкәч, уңайсызлана калды, ләкин борылып кайтырга соң иде инде. Ул курка-курка звонокка басты. Ишекне Рәхимә апа ачты. Исәнлек-саулык сорашып өлгермәделәр, эчке бүлмәдән Галимҗан абый да чыкты.

— Бер дә кеше төсе калмаган үзеңдә, Гәүһәр,— диде Рәхимә апа диванга килеп утыргач та.— Өегездә иминлекме?

Кызлар өйдә юк иде, хәер, алар өйдә булсалар да, Гәүһәр инде үз-үзен тыя алмас иде. Ул үксеп елап җибәрде, бик авырлык белән генә хәлен сөйләп бирде. Сер ачу бик тә кыен кыенын да, нихәл итәсең, күңелдә саклаудан узган иде ул. Тыңлагач, Рәхимә апа да, Галимҗан абый да бер мәл дәшмәделәр, алар икесе дә Гәүһәрләрнең семья тормышы үрнәк, дип уйлыйлар. Бүген сөйләгәннәр ничектер башка сыймый. Аннары Гәүһәр бер сүз белән дә ирен гаепләмәде, аңа бәрелмәде. Исрафил Дидаров турында да сөйләмәде. Шикләнүен бик шикләнә дә, тотып әйтерлеге булмагач, Гәүһәр кешегә яла ягудан сакланды. Рәхимә апа белән Галимҗан абый да гаепне өченче берәүдән эзләргә омтылмадылар. Алар бары тик Гәүһәрне генә тынычландырдылар, болай булгач, мәсьәлә бик җитдиләнгән, уйлашырга кирәк, диделәр. Гәүһәр Галимҗан абыйсыннан Җәгъфәрнең эшләгән җиренә барып, партком белән сөйләшүен үтенде. Галимҗан абыйга Гәүһәрнең болай уйлавы ошады, оешкан семьяны вату, җимерү кыен түгел, ә менә саклап калу, туздырмау, ай-һай, күп көч сорый. Дөрес, Галимҗан абый да, Рәхимә апа да Гәүһәрнең бер гаепсез булуына ышаналар, шулай ук Җәгъфәргә карата да аларның һичбер усал уйлары юк, бәлки ике арада чыккан бер аңлашылмау гынадыр, яшьләр арасында мондый хәлләр дә булгалый, семья мәсьәләсенә алар кайчак уйлап житкермичәрәк карыйлар.

Башта Галимҗан абый Җәгъфәрнең үзе белән генә сөйләшергә булды, әгәр инде өйдә күндерә алмаса, соңыннан парткомга да барыр.

Икенче көнне Галимҗан абый Гәүһәрләрдә иде инде. Җәгъфәр аны күптән белсә дә, утырып бергә чәй эчкәннәре булмады. Ничектер бик уңайсызланды. Галимҗан абый да ни өчен килгәнен тиз генә әйтергә ашыкмады. Ул анысын-монысын сөйләп астан гына яшьләрне күзәтеп утырды, аннары әкертенләп семья хәлләренә күчте. Ул арада Гәүһәр чәй дә өлгертте, үзе дә өстәл кырыена килеп утырды. Аралары тирәнгә киткән, ахры, бер өстәл артында утырсалар да бер-берсенә сүз катмыйлар, икесе дә я аска, я читкә карыйлар. Галимҗан абый көлеп җибәрде.

— Әллә инде үпкәләшкәнсез, көлмисез, сөйләшмисез. Яшьләргә бу ярый торган эш түгел. Я, нәрсә булды, нәрсә бүлешә алмадыгыз?

Җәгъфәр дә, Гәүһәр дә эндәшмәделәр.

— Я, озак шулай уйнарсызмы? Мин икегезне дә беләм бит, арагыздан кара мәче узарлык нәрсә булганы юк шикелле, турсаймагыз әле. Тормыш шундый ямьле, бигрәк тә яз көннәрендә, юк жанжаллар белән аны бозмагыз. Ни булды, әйтегез дә салыгыз. Кая кулларыгыз, я әле, Гәүһәр, бир кулыңны, менә шулай, ә хәзер, Җәгъфәр, син. Я?

Җәгъфәр тиз генә урыныннан торды, йөзе агарынып китте.

— Галимҗан абый, әгәр эш шулай ансат булса, без үзебез дә килешкән булыр идек, балалар түгел. Кызганычка каршы, эш тирәнрәк... Хәзер минем кабатлыйсым килми, аннары бу кирәк тә түгел. Мин үз тойгыларыма җавап бирәм, шулай ук Гәүһәр дә нинди юлга басканын белеп эшләгәндер.

— Җәгъфәр, син ялгышасың, син бер дә булмаганны уйлыйсың...

Галимҗан абый бу кичтә алар белән бик озак сөйләште, тавышын бер дә күтәрмәде, бер дә кызмады, сүзләрнең дә кирәкләрен генә сайлады. Әмма болар барсы да нәтиҗәсез калды, Җәгъфәр араны өзәргә нык карар иткән булса кирәк, үз сүзендә нык торды. Ул Гәүһәрне

хурламады, сукмәде, ләкин аңа чиксез тирән нәфрәт белән карый, килешергә һич тә уйламый иде. Галимҗан абый торган саен тирәнрәк уйга батты. Монда килгәндә ул эшләр бу кадәр үк тирән дип уйламый иде. Болай булгач, парткомга бару да берни бирмәячәк.

— Шулай да тагын бер уйлагыз әле, чүлмәк ватмыйсыз ич, семья ватасыз! — дип урыныннан торды.— Мин дә, билгеле, читкә китмәм, ләкин мәсьәләне хәл итүчеләр — сез. Моны нык уйлагыз.

Ул хәерле төн теләп чыгып китсә дә, бу төн хәерле булмады, Җәгъфәр белән Гәүһәр бер-берсен хурламасалар да, кычкырышмасалар да, бер-берсеннән ерәклаштылар. Гәүһәр елады, әмма аның күз яшьләре берәүнең дә йөрәгенә тимәде. Шулай аның күз яшьләре дә кипте. Иртән торганда ул тәмам йончыган, хәтта аз гына чайкала да иде. Җәгъфәр бер сүз әйтмичә, ашамый-эчми чыгып китте. Ул да ябыккан, Гәүһәр аны вакыт-вакыт кызганып та куя иде. Озакламый инде дачага да чыгарга вакыт, ләкин күңелендә ут булгач, дача матурлыгы кемгә кирәк? Кайгыны суга агызып булмый бит.

Галимҗан абыйның парткомнан чыгуын Гәүһәр урамда көтеп торды. Ниһаять, аның башын иеп атлавын күргәч, барысын да аңлады, димәк, актыккы өмет тә өзелгән! Галимҗан абый әле нидер әйтергә теләде, уйлашыйк диде, әмма Гәүһәр хәзер бер нәрсә дә ишетмәде.

— Соңыннан әле мин сезнең янга бер керермен, Галимҗан абый, минем сездән башка беркемем дә юк, ә хәзер... хәзер мин үзем мәсьәләне хәл итәргә тиешмен. Хушыгыз.

Гәүһәр сыгыла төшеп китеп барды. Галимҗан абый аны куып җитәргә дә, туктатырга да белмәде. Әллә кайтып Рәхимәгә сөйләргәме? Ул, ихтимал, берәр җаен табар? Хатын-кыз бит мондый чакта сизгеррәк була.

Гәүһәр инде күздән югалган иде. Галимҗан абый ашыгып троллейбус тукталышына китте. Күрәсең, машина күптән булмаган, халык бик күп. Гәүһәр беркайда да күренми иде. Кайда икән, берәр яры кердеме, әллә җәяү киттеме?

Галимҗан абый тукталышның бер башыннан икенче башына хәтле узды. Еракта троллейбуслар күренде, бер, ике, өч... Баштагыларга Галимҗан абый утырмады, анда халык күп була. Өченче машинага утырып өенә кайтып китте.

## 14

Семья тормышы шундый кискен бер төс алган вакытта, Гәүһәрнең имтиханнарга утыруы, тыштан гына булса да аңа бөтен күңелен беркетүе аңлашылмый иде. Нәрсә бу? Семья бәхетсезлеген шулай туктатырга уйлыймы? Бу бик икеле чара түгелме? Ихтимал, имтиханнарга хәзерләнгән булып, уйларга вакыт отуыдыр? Мәсьәлә бит бик катлаулы, четерекле. Ничек баш ватмыйсың? Әле уйлап-уйлап та очына чыга алсаң, ярый. Бәлки, уйларга да калмагандыр инде, вакыт узган булса, авырткан тешне алдырудан башка чара калмый лабаса. Яки Гәүһәрнең тагын нинди дә булса бер уе бардыр, кемне дә булса көтә торгандыр?

Җәгъфәргә Гәүһәрнең төп уйларын белү кирәк иде. Вакыт кына уздыру, имтиханнар уе гына булса, Җәгъфәр салкын канлылыгын җуймыйча көтәр, моңа гына аның түземлеге җитәр, әгәр инде башка берберенсә исәпләсә, әзер булырга кирәк.

Гәүһәр тыштан бер нәрсә дә сиздермәде, хәтта беркадәр гамьсез кыланды. Кайчагында Җәгъфәрнең рәтле җавап бирмәвен белсә дә, ашыйсың килмиме, чәй кайнаттым, әчәсең килсә, бергә эчик, дигән төсле беркатлы сүзләр әйтколи, ире чыгып китсә дә, кайтып керсә дә тавыш кубармый, табын һәрвакыт әзер була. Үзе соң кайтса, бүген консультация булды яки имтихан бирдем, дип әйтә. Моңа каршы

Җәгъфәр мыгырдап җавап кайтарса да, хәтер калдыра торган сүз әйтсә дә, Гәүһәр ишетмәгәнгә салыша. Ул көннән-көн үз эченә бикләнә бара, көннәр буе дәреслекләре белән утыра, беркая йөрми. Хәер, берике мәртәбә ул Галимҗан абзыйларга барды. Җәгъфәр,囧 эштә булганга, моны белми дә калды. Күрәсең, ахыр килеп, Галимҗан абзый аңа парткомда булган хәлләрне барысын да сөйләгән иде. Гәүһәрнең ирен почмакларына тирән сызыклар ятты, карашы бер ноктага күбрәк туктала башлады, маңгаендагы текә сызык ешрак калтыранды. Кайчагында, бер үзе утырганда күзләре дә дымланып китә, яшьләрен сөртмичә, терсәгенә таянып, тәрәзә почмагыннан күккә карый. Тагын бер атна, атна ярымнан халык инде дачага чыгар. Җәгъфәр дә автомашинасын көйләп куйды. Ләкин Гәүһәр бу машинага кабат утырырмы, дачага барырмы икән? Элеккерәк елларда алар, институтта имтиханнар бетмәсә дә, дачага чыгалар иде. Гәүһәр имтиханнарга бер вакытта да артык көч куеп хәзерләнмәде, ә имтиханнарын барысын да яхшыга, бик яхшыга тапшырып килде. Өйдә инде Гәүһәрнең институтта укуы, әлеге шул стенадагы этюдлары кебек, берәүгә дә мәшәкать ясамый торган бер нәрсәгә әверелгән иде. Хәтта аның турында житди итеп сөйләмәделәр дә. Ә менә Җәгъфәрнең һәр кечкенә генә эше дә өйдә давыл кубара. Диссертациясен тәмамлаганда өйдә гомумән аерата киеренке булды. «Тавышланмагыз, Җәгъфәр диссертациясен яза... Зинһар, әкренегез, Җәгъфәр эшләп утыра... Җәгъфәрнең бик тыгыз чагы, башын да күтәргәне юк, тәмам ябыгып бетте...» Шуның өчен сүзләрне Гәүһәр үзләренә килгән күршеләренә, кунакларына, дусларына күпме пышылдагандыр, бер алла белә. Нигәдер ул үзе дә Җәгъфәрнең һәр эше мөһим дип уйлый, үз эшен һәрвакыт кечерәйтеп, түбәнәйтеп карый иде.

Уйлар... Аларның очы да, кырые да юк. Гәүһәр яшьле күзләрен сөртә дә янадан китапларына төртелә. Тагын сәгатьләр буена онытыла, тагын бөтен дөньяны билэп китаплары гына кала. Гәүһәр үзе дә, аның мәшәкатьле язмышы да юк. Хәтер генә бар, ул хәтер имтиханнарга кирәкле вакыйгаларны, елларны гына истә тота, башкасы әһәмиятсез кебек, аларны белер, аңлар һәм аңлатыр өчен көч тә сарыф итәргә кирәкми.

Соңыннан тагын Гәүһәрне дөньяви уйлар билэп ала. Алар тынгысыз, мәшәкатьле, куркыныч, алар белән ялгыздан ялгыз һич каласы килми. Шундый чакта якыннары да юк, алар булса, ичмасам, бер сөйләшеп эчен бушатыр иде. Туган авылында күршеләре генә бар. Күршеләр инде күршеләр, кирәк чакта аларга барып егыла алмыйсың. Менә әнисе булса, Гәүһәр берни белән дә исәпләшеп тормас иде. Ана, ничек кенә булсаң да, кабул итәр, җылы кочагына алыр иде.

Күңелсез уйларга артык бирелмәс өчен Гәүһәр урыннан тора, сәгатенә карый. И-и, консультация вакыты җитә язган ич! Ул тиз генә капкалый, аннары китапларын җыештыра, киенә, көзге алдында иңнегән сөртенә дә ашыгып урамга чыга. Тышта кояш, эссе. Ходаем, мондый көннәрдә ничек шәһәрдә утырырга кирәк. Кара, асфальт та йомшарган, нәкъ келәм өстеннән атлыйсың кебек. Ә халык! Бар кеше урамга чыкканмы әллә? Кая ашыгалар, ни чабалар? Юлларында очраган һәр кибеткә кетүләре белән керәләр. Гәүһәр шикелле беркая керми ашыга торганнары да бар.

Троллейбустан төшкәч, Гәүһәр беркадәр вакыт иң җанлы урам — Бауманнан барды, аннары Болак буена борылды. Базар юлы булганга монда да халык байтак әле, ләкин Баумандагы кебек өелеп акмый. Күбесенең кулында хуҗалык сумкасы, боларның кая барганнары ерактан ук күренеп тора.

Төп студентлар инде таралышып беткәннәр, институтта читтән торып укучылар гына хуҗа. Әмма яшьләре белән алар беркадәр өлкәннәр, аннары күбесен инде тормыш та басарга өлгергән, алар җилбәзәк

яшьләр кебек очынмыйлар, аларда ниндидер өлгергәнлек, житдилек сизелеп тора.

Консультациядә Гәүһәр ике сәгать утырды, ике сәгать буена башын күтәрмичә укытучының сүзләрен язды. Ул тиз, стенографистка шикелле диярлек яза. Бер дәфтәр булгандыр. Укытучыга бик күп сораулар бирделәр. Гәүһәр укытучы биргән җавапларны да төгәл итеп язарга тырышты.

Вакыт әле иртә иде. Гәүһәр Галимҗан абыйларга шалтыратты. Бу вакытта кемнең дә булса өйдә булуы бик икеле иде. Әмма Рәхимә апа өйдә булып чыкты.

— Керсәм, комачауламаммы икән?

— Нинди комачау булсын. Әле кичә генә Галимҗан белән телгә алган идек үзеңне. Кил, кил, көтәм. Кызлар чирәм җирләргә киттеләр, Галимҗан эштә. Кил, Гәүһәр.

— Алайса, барам. Бик азга гына.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, Гәүһәр инде таныш баскычтан күтәрелә башлады. Коридор эче ярым караңгы, салкынча. Эсседән кергәнгәдер инде, Гәүһәр тирләп чыкты, баскычтан менгәндә кулъяулыгы белән маңгаен сөртә башлады. Ишек төбендә хәтта берничә секундка туктап тын алды. Аннары звонокка басты. Рәхимә апа, ахрысы, көтеп торган, ишекне бик тиз ачты. Якын итеп күрештеләр.

— Әйдүк, утыр. Тирләгәнсең, бик эссе, ахрысы. Минем чыкканым да юк әле.

— Тышта кояш, күләгәле яктан килсәң дә тиргә батасың.

Рәхимә апаның табыны әзер иде. Чынаякларга чәй ясап, Гәүһәр каршына куйды.

— Я, рәхим ит. Менә бу тортны да кабып кара, кичә пешергән идем, белмим, ничек чыккандыр. Кичә кунагыбыз бар иде, Галимҗанның сеңелесе Бибинур Яшел Ярдан кызы белән килгәннәр иде. Кичә үк курортка да китеп бардылар. Кара диңгез буена.

— Кызы зурмы соң?

— Җиденчене бетергән.

— Балаларны курортка җибәрәләрмени?

— Бибинур әйтә: санаторийдан ерак түгел минем танышларым бар. Аларда торып торыр, ди.

— Тортыгыз бик килешкән,— диде Гәүһәр.— Сезне Казанның аш остасы дисәң дә ярый.

Мактау ошады булса кирәк, Рәхимә апа аз гына кызарып:

— Вакыт юк, Гәүһәр,— диде.— Мәктәптә эш бик күп, менә хәзер азрак бушадым.

— Ялга берәр җиргә бармыйсызмыни?

— Путевкалар июль ахырында гына.

Гәүһәр көрсенеп алды. Менә кешеләр путевка турында уйлыйлар, ә Гәүһәр нишләр икән? Тагын ике имтиханы калды. Аларны тапшыргач...

Йөрәк, никадәр кысып бәйләсәң дә, авырта икән! Гәүһәр бер без генә түгел, дип әйтеп тә карады. Кая ул! Болай тыныч кына тора кебек, кинәт һичбер сәбәпсез-нисез кан саркырга тотына. Сәбәбе бар, билгеле, «һичбер сәбәпсез-нисез» дигәндә кеше аның кисәктән башлануын гына әйтә торгандыр. Димәк, ул һәрвакыт бар, һәрвакыт кан саркый, тик кайвакыт йомылып тора, кайвакыт тыпырчына...

— Гәүһәр,— диде Рәхимә апа, шуны сизгән кебек,— син һәрвакыт ямансулыйсың. Мин хәлеңне беләм... Бер үзгәреш тә юкмы?

— Юк, Рәхимә апа. Җәгъфәр ят кеше булып бара... Кайчагында дөньясына карамас идем. Нинди адым атларга да белмим. Болай да ярамый... Галимҗан абыйдан киңәш сорамакчы идем. Беркемем дә юк бит минем.

— Галимҗан, ул-бу булмаса, бишенче яртыда кайтырмын, дигән иде. Һаман телефон шалтыравын көтәм... И-и, әнә шалтырый да инде. Әйтерсең, сорап алдылар.

Рәхимә апа алгы якка чыкты да телефонда сөйләшеп керде. Гәүһәр ишетеп торды: Галимҗан абыйларның бүген производство киңәшмәсе, Гәүһәргә күп итеп сәлам әйтә, көтә алса, көтсен, сәгать тугызларда, уннарда кайта, булмаса, иртәгә керсен.

Рәхимә апа сөйләшеп бетергәч, шуларны Гәүһәргә дә әйтте. Гәүһәр бераз уйлап торды да башын күтәрде.

— Алай булгач, мин инде кайтыйм. Берсе көнгә имтиханым. Хәзерләнәсем бар. Иртәгә дә килә алмам инде. Имтиханымны тапшыргач килермен. Белмим, нәрсәдер булды миңа, Рәхимә апа, имтиханнарны болай бер дә кыйналып тапшырмый торган идем.

— Борчылма, Гәүһәр, бу юлы да тапшырырсың. Буш вакытың булу белән кил, Галимҗан өйдә була.

— Бибинур апа кичә генә китте дисеңме? Белмәгәнмен... Ярый алай, сау булыгыз.

Эссе бераз сүрелгән, хәзер урамның күләгәле ягыннан бару рәхәт. Гәүһәр җиңел сулап алды. Узышлый афишаларга карады, ләкин аларны күрдеме икән? Күзләре тукталмыйча шуып кына үттеләр бугай. Элек ул аларны укый, хәтта имтиханнар арасында да театрга барырга вакыт таба торган иде, җәй көне Казанга гастрольләр күп килә бит. Хәзер әллә бар алар, әллә юк. Имтиханнары да хәтта минут саен артка чигә. Гәүһәр чыга алмаслык тирән сазлыкка кереп бата сыман, нишләргә белми.

Бакча аркылы үтеп бара икән. Гәүһәр үзәк юлдан бераз читкә китте дә бер буш урындыкка утырды. Бу бакчаның исемен дә рәтләп белми иде ул. Шәһәр үзәгеннән ерак та түгел, тау башында. Бер ягыннан хәтта университет почмагы күренә. Бакчаның бу башында карт юкәләр үсеп утыра. Урындыкларда китап-дәфтәрләрен җәеп салган студентлар. Гәүһәр көлемсерәп куйды. Читтән торып укучылар икәне әллә кайдан күренеп тора. Билгеле инде, шәһәрләрдән, авыллардан килгәнгә күбесенең утырыр почмаклары да юк. Яңгыр яумаса, аларның эшләре рәхәт, бакчадан аларны берәү дә куамый, теләгәнчә утыра бирәләр. Аларның күңелләре укуда гына шул, аларга башка берни дә кирәкми. Хәер, үзләренә күрә кайгы-хәсрәтләре дә бардыр инде, кеше кош баласы түгел, пырылдап очуны гына белми. Әнә утызлар тирәсендәге бер хатын калын дәфтәр укып утыра, янында ак мамык юрганга төргән баласы йоклый. Күрәсең, баласын калдырыр урын юк, баласы йоклаган арада имтиханнарга хәзерләнә. Йөзе бик житди, уйчан, киеменә дә артык игътибар итмәгән. Ахрысы, тормышы җиңел түгелдер. Тыштан караганда гына ул зарланмый. Бер заман авыр көннәре үтәр, тик шунысы бар: берәү дә аның батырлыгы турында сөйләмәс, үзләре тормышның ачысын-төчесен күрмәгән кешеләр хәтта моның кай җире батырлык, монда туплар ярылмый ич, диярләр.

Гәүһәр урыныннан торды, бераздан агач баскычлардан төшеп үзәккә якынлашты, аннары троллейбуска утырды. Гәүһәр әкрен-әкрен үз уйларыннан аерылды, дәфтәрләрен ачты. Ул берни сизми укый башлады. Ул шул хәтле бирелгән иде, тукталышны узып китә язды. Бары тик актык минутта торып, халыкны этә-төртә троллейбустан төшеп калды.

Гәүһәр өендә азык ягы такыр икәнен исенә төшерде. Җәгъфәр дә озакламыйча эштән кайтыр инде. Ире искә төшү Гәүһәргә житә калды, ул тиз генә кибеткә борылды, берьюлы тегесен-монысын сатып алды. Кибеттән чыкканда аның пакеты тулы иде. Ашыгып, беркая тукталмыйча, өенә юнәлде.

Җәгъфәр кайтмаган иде. Гәүһәр киемен алмаштырды да, биленә ак алъяпкыч бәйләп, кухняда аш хәзерләргә кереште. Ул эше бик тыгыз

кеше сыман кыланды. Әллә кай арада гына табада май чыжылдый башлады, коймагы пеште, чәе кайнады. Тик Җәгъфәр генә кайтмады. Инде караңгы төште. Гәүһәр, пешкән ашлары суынмасын өчен, плитаның утын кысып куйды. Үзе яңадан китапларына утырды. Ярты сәгать, бер сәгать, аннары сәгать ярым үтте. Җәгъфәр кайтмады. Гәүһәр китабыннан аерылып, терсәгенә таянды, тәрәзәдән карап тора башлады. Инде эңгер-меңгер сүнеп, чын-чынлап караңгы төшә башлаган. Урамда бала-чага тавышы, чыр-чу, ә өй эчендә тын, моңсу. Нигәдер күзгә яшь килә. Кычкырып-кычкырып елыйсы иде, ә аннары...

Гәүһәрнең күзенә яшь килсә дә, кычкырып еламады. Керфегенә эленгән берничә бөртек күз яшен сөртте дә ничектер кырысланып китте. «Шулай ук ул...— Гәүһәр, бу куркыныч уен дәвам иттерергә куркып, сискәнеп китте.— Юк, ул моны эшли алмас, ул бары тик юләрләнә генә». Балалары да юк, ичмасам, Гәүһәргә дә юаныч булыр иде, Җәгъфәр дә тилермәс иде. Болай нәрсә, уңга китсә дә, сулга китсә дә кыйбла, берни тотмый... Шулай да кайда йөри икән? Вакыт бик соң бит инде...

Кайчандыр ике бүлмәле квартираның бөтен бүлмәләре җырлап, чынлап тора иде. Стеналарда ереле-ваклы рәсемнәр, алар ниндидер матурлык бөрки иде кебек. Китап шкафы, гардероб башындагы, сервант өстендәге төрле зиннәтләр дә яшәүгә мәдхия җырлыйлар иде кебек. Хәзер барысы да беткән, сүнгән. Күрәсең, шатлык барында гына алар күзгә күренәләр, телгә киләләр. Элек радиода Гәүһәр гел «Маяк» станциясен уйната, җырлата, сөйләтә иде, хәзер радио да эндәшми. Бүлмәдә кабер тынлыгы. Хәтта куркыныч кебек...

Кинәт ишектә звонок шалтырады. Гәүһәр сискәнеп китте. Кем булыр? Җәгъфәрнең үз ачкычы бар иң.

— Шәриф Гыйльманович! — дип кычкырып җибәрде Гәүһәр, ишекне ачкач.

— Керергә ярыймы?

— Әйдүк, әйдүк.

— Исәнмесез. Көндезрәк бер кагылган идем дә, өйдә булмадыгыз.

— Институтта идем шул, әйдә, бүлмәгә рәхим итегез,— Гәүһәр ут кабызды.

— Рәхмәт.— Шәриф Гыйльманович эшләпәсен ишек төбендәге элгечкә элде дә, бүлмәгә кереп, урындыкка утырды. Аның Гәүһәрләрдә беренче булуы иде, бүлмә эченә күз йөртте, аннары тынып, сагаеп калган Гәүһәргә борылды.— Гомердә бер кереп, сезне аптырашта калдырдым бугай, гафу итегез. Күрәм, Җәгъфәр өйдә юк шикелле.

— Юк шул,— диде Гәүһәр, көрсенеп.— Мин хәзер чәй куям, аңарчы бәлки Җәгъфәр дә кайтыр.

— Юк, борчылмагыз. Мин хәлегезне генә белә килдем. Дөрес булса, күңелсез хәбәрләр ишеттем.

— Шулайрак шул, Шәриф Гыйльманович. Шушы көннәрдә сезгә керергә дип тә торадыр идем.

— Алай икән... Ишеткәч, башыма тимер таяк белән суккандай булдылар. Мин бит болай булыр дип һич уйламаган идем, Гәүһәр.

— Мин үзем дә уйламаган идем, Шәриф Гыйльманович. Әле хәзер дә ни булганын яхшы гына төшенмим, ниндидер бер яман төш күрәм кебек. Җәгъфәр бөтенләй читләште, хәзер мин аңа әллә бар, әллә юк. Бер сүземне тыңламый, аңлашыйк дисәм, иңбашларын гына җыера. Миңа калса, ул аңлашудан кача, шул ук вакытта миңа түзә алмаслык шартлар тудыра. Мин семьяны ватарга, җимерергә теләмим, Шәриф Гыйльманович. Шул ук вакытта минем өметем дә калмаган. Тәмам аптыраган инде, нишләргә дә белмим. Дөресен сөйлим, Шәриф Гыйльманович, минем бер гаебем юк. Дөрес, мин яшьлегемдә таныш бер егетне очраттым, ул мәхәббәтен сайрый башлагач, мин аңа үземнең

ир хатыны икәнемне, аңа мәңге турылыклы буласымны әйттем. Шуннан ул китеп барды бугай.

— Кая?

— Ленинградка. Ул анда тора, анда эшли дә.

— Кем булып?

— Төзүче инженер булып.

— Син аны кыз чакта яратадыр идеңме?

— Юк, Шәриф Гыйльманович. Ул яхшы дус иде. Шул гына.

Вакыт инде соң, унбер тула иде. Җәгъфәр кайтмады. Шәриф Гыйльманович Гәүһәрнең кылын тартып караса да, ул ире хакында бер начар сүз дә сөйләмәде. Тик ахырда, кызарып, аның күңеле башка бер хатын-кызга төшкән булса кирәк, тик үзе турысын әйтми, боргалана, диде. Шунда да аның яратуы искиткеч иде. Шәриф Гыйльманович анын ихлас сөйләвенә нык ышанды. Шуның белән алар бүгенге сүзне бетерделәр. Буш вакыты булу белән Гәүһәр мәктәпкә кереп чыгарга булды.

— Һичшиксез, кереп чык. Бергәләп уйлашыйк әле. Мин синең өчен кулымнан килгәнне барысын эшләргә хәзер, Гәүһәр. Хәерле төн.

— Хәерле төн, Шәриф Гыйльманович.

Ишекне япкач, Гәүһәр баскан урынында уйга калды, уттай кызган ике яңагын тотты. Мәктәптә аның хурлыгын беләләр! Билгеле, әллә нәрсәләр сөйли торганнардыр инде. Гәүһәргә бу көнне кургәнче үлем артыграк булып тоела иде. Менә ул көн дә килде, Фая Идрисҗанова тантана итә торгандыр, ә Гәүһәр яши! Алай гына да түгел, аңа беркадәр җиңелрәк булып китте кебек. Нәрсә бу, моны ничек аңларга?

Уникенче ярты булды, уникс тулды. Җәгъфәр һаман юк.

## 15

Тәрәзәдән ишек алдының бер өлеше белән урам чите күренә. Әнә Җәгъфәр килә. Озынбуйлы, киң җилкәле. Өстендә югославский плащ, башы ялан баш, кара чәчен шома итеп артка тараган, шуңа күрә башы, шактый зур гәүдәсе өчен, бераз кечерәк сыман.

Урам читен һәм ишек алдының бер өлешен узкәч, Җәгъфәр инде күренми, ләкин Гәүһәр белә: хәзер ул парадныйга керә, өченче катка күтәрелә...

Җәгъфәр бүлмәгә кермичә туры кухняга үтә, анда юынамы, чәй кайнатамы, болай гына басып торамы — нигәдер бүлмәгә бик озак керми. Гәүһәр тәрәзә янына креслога утырган, ул бетмәс-төкәнмәс уйдан алҗыган, урыныннан күтәрелер хәле дә юк, башында бер генә фикер: «Бүген яки беркайчан да». Бу уй коточкыч булып күренә, шул уйны якын китермәс өчен ул вакытны суза, тәрәзә янында утырып тора, югыйсә аңа күптән чыгып китәргә кирәк. Кая — анысы ул кадәр мөһиммени?

Гәүһәр моңлы күзләре белән бер караңгыланып килгән урамга, бер бүлмә эченә карый. Ул бер нәрсә дә алмады, тик рәсемнәрен генә чемоданы төбенә салды. Яңа квартирага күчкәч, бүлмәне тырышып-тырышып бизәүләре, төрле вак-төяк әйберләр сатып алулары Гәүһәрнең хәтерендә, шуларга карап шатлануларын һич онытасы юк — бүлмәләр курчак өе кебек булган иде, Җәгъфәр никадәр сөенде. Инде шуларны башкага калдырыргамы?

Кемдер радиосын тоташтырган, кичке музыка әкрен генә тынып, эреп бара. Гәүһәр, терсәгенә таянып, шул музыка тәэсиренә чумган кебек.

— Матәм маршын туктатырга вакыт, өйгә кара чебен кертерсен,— диде Җәгъфәр, ниһаять, бүлмәгә кереп. Ут кабызды, аннары тәрәзәне барып япты.

Гәүһәр берни әйтмәде, тик иренә бик озак карап торды. Бу салкын, ят караштан Җәгъфәр ничектер уңайсызланды, эчтән калтырап та китте. Мондый хәлнең әле булганы юк иде, ул, пошынып, нәрсәдер көтте. Хәер, ул үзе шул көннең килүе өчен барсын да эшләде түгелме? Дөрес, ул кулына да, теленә дә ирек бирмәде, ләкин ул шулай итте, ахыр килеп кеше моңа чыдый алмаска тиеш иде. Шуннан соң Җәгъфәр дә җәмәгатьчелек каршында уңай фикердә калачак, ул хатынын кумаган, хатыны үзе...

— Мин хәзер китәм,— диде Гәүһәр шуны раслаган кебек.

Җәгъфәр бу сүзне күптән көтә, аның мәгънәсен бик яхшы аңлый иде. Әмма аңламамышка салынып, иңбашларын җыерды да:

— Төнгә каршы кая барасың? — дип сорады, күзе сервант янына куелган урта кул чемоданга төште. Гәүһәрнең кайдадыр Ерак Көнчыгышта кардәшләре бар — әллә шунда китәме? Әллә ялгамы?

Гәүһәр куллары белән йөзен каплады, башын түбән иде, кара чәче каерылып төште. Бер үк бу сүзсез сәхнә Җәгъфәргә тәэсир итмәде, ул тәрәзәгә борылды, инде караңгы төшкән урамга карап тора башлады. Ул көтә иде.

Ниһаять, Гәүһәр башын күтәрде, тузгып торган чәче арасыннан ике күзе ялтырады. Җәгъфәр аңа иңбашы аша гына карап алды, бер генә минутка сагаеп калды. Бүгенгә кадәр Җәгъфәр хатынының күзләрендә мондый тирән рәнҗүне күргәне юк иде. Ләкин икенче секундта инде ул башкага күчте: «Юмалый, хатын-кыз юмалый белә ул». (Хәер, бу сүзләр аның үзенеке түгел, кеше сүзләре күптән инде аның үз сүзләре булып киткән иде.)

Ул катыланды, кырысланды. Ир кеше хатынына ләббәйкә дип кенә торырга димәгән ләбаса! Без яңа йортлар күп салабыз, аларны бизәү турында да күп язабыз, ә үз торагыбызны кайчан бизәрбез? Үзе бәхетсез кешенең башкаларны бәхетле иткәнен кем күргәне бар? Андый хәлләр дөньяда булмый, диалектиканы яхшы белергә кирәк!

Гәүһәрнең күзләрендәге ялтырау белән рәнҗү дә сүнгән булып күренде хәзер Җәгъфәргә. Мондый чакта ул үзен ышанычлырак итеп сизә. Дөрес, барыбер ул күп сөйләмәячәк, сүздән ботка пешми. Гәүһәр ике кулы белән ике чигәсен кысып утыра икән, утырсын, китәргә ашыкмый икән, ашыкмасын, бер-ике көннән әллә ни булмас, Җәгъфәрнең нервылары нык әле, моңа гына түзәр. Ул, ике кулын күкрәгенә кушырып, хатынына таба ярым борылып басып торды. Күрсен, тагын бер тапкыр белсен: әнә нинди нык ул, пошынусыз, йөзендә дә бер аллыкызыллы тап юк. Үзен хаклы итеп сизмәгән кеше шулай тораташ кебек басып тора алыр идеме? Дөрес, әле Гәүһәрнең дә сыгылып төшмәвен күрә. Сыгылып төшкәч, ул инде үзен яклый алмый. Хәер, Гәүһәрнең көче күп калмаган, китәм, диде бит, чемоданын да әзерләп куйган.

Кинәт гөлт итеп ут сүнде. Бер минут чамасы икесе дә караңгыда торып тордылар. Ул арада күзләр дә бераз күнекте. Тышта күзгә төртсәң күренмәслек караңгы түгел. Бигрәк тә агач башлары аермачык күренә. Гәүһәр шул агач башыннан күзен алмыйча:

— Әнә күрәсеңме? — дип сорады.

— Нәрсә күрәмме? Бернәрсә дә күрмим,— диде Җәгъфәр.

— Кызганыч,— диде Гәүһәр, аңлатуны кирәк тапмыйча. Башы корган карт тирәк тәрәзәдән ап-ачык күренә иде.— Син башкалар алдында әүлия... Мин дә сине бик озак әүлияга санап килдем. Син үзеңне катлаулы натура дип, зур идеаллар хезмәтчесе итеп күрсәтергә яратасың. Иңбашларыңны җыерма, син бит өйдә хатының белән сөйләшкәндә дә ясалма кылана идең. Моны бер дә сизмәделәр дип беләсеңме? Мин синең чиксез кимсетүеңне, җансыз әйбергә санавыңны да күреп килдем. Курыкма, мин сиңа пычрак атмыйм, сине буямыйм, бары

тик үземнең шулай беркатлы булуыма гына гаҗәпләнәм. Синең зур идеалларың булгач, минеке дә бардыр, дип уйларсың дип көттем. Бик тирән ялгышканмын. Синең куян кебек мескен җаныңны күрмәдем. Син бит актыккы минуткача чын уйларыңны сөйләмәдең, куркакларча аларны яшереп килдең. Әгәр күңелең башкага төшкән икән, ирләрчә турысын әйтергә кирәк иде. Мин авыр булса да... Ярый, иңнәреңне җыерма. Мин синең юлыңа аркылы төшмим. Ләкин уйла, син үзең теләмәсәң дә, иске гадәтләрең көченә буйсынып булса да, сазга әчкәрәк керәчәксең. Бу минем соңгы сүзем. Ләкин мин синең сазга чумуыңны теләмим...

Гәүһәрнең бу кадәр рухи киеренкелек белән беркайчан да сөйләгәне юк иде. Ул, бөтен көчен сарыф итеп, тәмам хәлсезләнеп калды. Чигә тамырлары баягыдан да көчлерәк тибә, йөрәге баягыдан да ныграк әрни, ә миендә һаман шул бер борчулы уй утлы кадак кебек әйләнә: «Я бүген эшлим, яки аны беркайчан да эшләп булмаячак!»

Инде торып китәсе генә калган, әйтеләсе сүзләр дә барысы да әйтелгән, ихтимал, артыгы белән дә әйтелгәндер, әзерләп куйган чемоданын алып чыгып китәргә генә кирәк, ә ул шушы актык минутта да нидер көтеп утыра әле. Могҗиза юк бит, үзеңне үзең алдарга ярамый.— Хәер, моны акыл әйтә бит, йөрәкнең үз законнары...

— Син мине теләсә ничек мыскыл итә аласың,— диде Җәгъфәр, бик тирән хәтере калган кеше булып.— Син бер сүз дә әйтмичә китеп барсаң, бик сәер булыр иде. Тагын бер мәртәбә әйтәм: син үзең турында гына уйлама, калганнарны да искә ал. Калганнар син уйлаганча ук юләр түгелләр, аларның үз башлары бар.

Гәүһәр бүтән сүз көтә иде, ничектер өшеп китеп, калтыранып куйды, юк, могҗиза булмый икән шул, үзеңне булмастай нәрсәгә ышандырып вакытны сузудан мәгънә көтмә. Гәүһәр, нәрсәнедер өзгән кебек, кинәт урыныннан торды, плащын, чемоданын алды.

— Әйтмәсәм, шушы җан өзгеч минутта шушы сүзләреңне әйтмәсәң иде, Җәгъфәр,— диде әрни-әрни.— Ахрысы, син һаман үз туксаныңны туксан дип уйлыйсың... Ярый, түземсезләнеп иңбашларыңны җыерма. Әйтәсе сүзем бик күп иде дә җилгә очты. Бәлки минем китүем сине... Хуш!

Гәүһәр, яшенә тыгылып, өйдән чыгып китте, Җәгъфәр, кулларын күкрәгенә кушырган хәлдә, басып калды. Башта аның иреннәренә салкын елмаю чыкты: күптән инде ул Гәүһәрнең шушы адымын көтә иде, менә булды. Хәер, бу кадәресен ул башкаларга түгел, үзенә дә әйтмәде. Җәмәгатьчелек бар бит әле, аның алдында кыерсытылган ир ролен бик озак уйныйсы бар бит әле. Бер кешене ышандыруы берни түгел, җәмәгатьчелекне ышандыруы ай-һай авыр, аннары язылмаган гадәт буенча семья мәсьәләсендә иң элек ирләрне гаеплиләр, имеш, бөтен бәла аларда гына. Шуңа күрә Җәгъфәрнең иреннәрендәге яшерен елмаю әкрен-әкрен сүнде, борчу, ниндидер кара борчу торган саен аны катырак басты. Бу Гәүһәрнең бөтенләй китүеме, әллә болай гына, куркытыр өчен генәме? Җәгъфәр ачу белән ишеккә карады. Әгәр Гәүһәр кире борылып керсә, Җәгъфәр аңа ни әйтер? Авыз йомып торырмы? Юк, ул сүз табар! Табар!

Сервант өстендәге сәгать һаман тыкылдый, минутлар һаман үтә, кайтмаска, мәңгегә үтә, ишектә шылт иткән тавыш юк, баскыч та тын, анда аяк тавышлары да, сөйләшкән тавышлар да ишетелми. Юк, әнә кемдер менә, якынрак, якынрак. Әнә бөтенләй туктады. Җәгъфәр тын да алмыйча ишек ачылуын көтте. Әллә ишек төбендә елыймы, күршеләр күрмәгәе,— дип уйлады кинәт Җәгъфәр. Уң як квартирада бер усал хатын бар, бергә унны кушар. Юк, тавыш бөтенләй ишетелми, әллә күршеләргә кердеме, әллә өскә менеп киттеме? Вакыт узды. Җәгъфәрне биләп алган киеренкелек әкрен-әкрен кимеде, ул ишек төбеннән китте,

яңадан, кулларын күкрәгенә кушырып, идән буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

Кинәт Җәгъфәрнең башына икенче уй килде: тукта, бу Гәүһәр нишләп болай ансат кына чыгып китте соң әле? Кыйммәтле әйберләрне чемоданына тутырмадымы? Аларның үзләренә күрә алтын-көмеш әйберләре бар иде. Шул турыда уйлый-уйлый Җәгъфәр шкаф тартмаларын актара башлады. Саклык кенәгәләрен алмаган, хәтта кыйммәтле муенсалары, беләзекләре, кашлары да шкатулкада, затлы киемсалымы да шифоньерда...

«Кызык, буш чемодан күтәреп киткәнме әллә?... Ә-ә, кайтырга уйлый торгандыр, мине шүрләтер өчен генә чыгып киткәндер», дип Җәгъфәр тагын бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә башлады. Тәрәзә янында туктады. Бая нәрсәне Гәүһәр күрәсеңме диде әле? Рәтләп бернәрсә дә күренми, караңгы. Бөркү дә бераз. Җәгъфәр тәрәзәне ачып җибәрде, шунда башы корый башлаган тирәкне күрде. Йөзен чытты, тәрәзәне япты.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Җирдә нихәтле кеше булса, шул хәтле гомер дә бар. Берсе икенчесенә бөртек су тамчысы кебек охшаган гомерләрне табуы кыен. Ул гомерләрнең уртак яклары никадәр генә күп булмасын, һәрбер йөрәк гомерне үзенә бер төрле итә. Ихтимал, иң шәп электрон машиналар да бер төрлелекне исәпләп бетерә алмаслардыр.

Менә Яшел Яр шәһәре урамы буйлап ике укытучы бара. Еракган карасаң гына алар икесе дә бер төсле кебек. Якынрак килгән саен аерма ачыграк күренә. Математика укытучысы Миләүшә Баһманова-га тормыш һәм киләчәк ике тапкыр икең дүрт кебек ачык, аңлаешлы, аның бер күләгәле ягы да юк шикелле. Ул Гәүһәрдән өч-дүрт яшькә кече, университетны тәмамлавына да әле өченче генә ел. Кайчакта аңа студентлык еллары әле дә дәвам итә кебек тоела. Ә тулай торакта торган студентка күп кирәкмени? Тамагын туйдырырга икмәге, өстенә кияргә бер-ике күлмәге булса, аның белән ярышып кара менә. Ул туйганчы көләр, киносына чабар, дәресләренә дә вакыт табар...

Гәүһәр сизеп алды: Миләүшә Баһманова кешеләр белән тиз дусламшә икән. Күрәсең, бик кеше җанлы булганга шулайдыр. Башкалар читтән килгән, тормышында нәрсәдер сынарга да өлгергән, аз сүзле Гәүһәргә саклана төшеп карасалар, Миләүшә аны берьюлы үз итте, Яшел Яр шәһәре белән дә, мәктәп һәм аның коллективы белән дә таныштырды. Гәүһәр аның үз шәһәренә, үз мәктәбенә артык гашыйк икәнен күрсә дә, сүз әйтмәде. Ул, билгеле, Миләүшәнең аркан борылуыннан курыкмады, борылса ни дә, борылмаса ни, ул Миләүшәне бөтенләй диярлек белми. Хәзергә аңа бары тик Миләүшәнең холкы ошый. Бер очрашуда барысын сөйләде: быел жәй көне Кавказга барган, тауларга йөргән, диңгездә су коенган, туйганчы кояшта кызынган, табигать күренешләренә сокланып утырган, киләсе елга Кырымга барырга дип чамалый, Ай-Петридән кояш чыкканын күзәтү гаҗәп, дип әйтәләр, ди. Миләүшә менә шул турыда хыяллана. Укыту эшендә, аныңча, бер комачау да юк, район мәктәпкә бик уңай карый, укытучыларны хөрмәт итәләр, мәктәптә бирелгән сәгатьләр үтәлмичә калмый, директор Бибинур апа Хәбибуллина моны бик нык күзәтә. Миләүшә Баһманованы былтыр класс җитәкчесе иткәннәр. Яшел Яр шәһәрендә булган атаклы кешеләрне дә, Казаннан килеп киткән галимнәрне дә классына чакыргалаган Миләүшә.

— Башкалар андый чакларда пошыналар, борчылалар, төн йокла-

мыйлар. Мин, дөресен әйткәндә, боларны, Гәүһәр апа, бик үк аңлап та бетермим. Сөйләшкән, аңлашкан, калганы, тимер юлдагы кебек, тимер графикта. Берәр өзелгән мероприятиене яки вәгъдә итеп тә килми калган галимне мин белмим. Ә вак-төяк нәрсәләр шунда калкалар да, шунда бетәләр, алары өчен аз гына да борчылмыйсың, иртәгә аның эзе дә калмый. Тормышта да шулай, Гәүһәр апа. Киләчәккә калдыра барсаң, бик күңелсез була.

Гәүһәр көлемсерәп куйды: билгеле, тормыш язып куелган шикелле шома гына акса, ни әйбәт булыр иде дә — күп вакыт ул синең ихтыярыңа буйсынмый. Хәер, Миләүшәнең тормышы шулай бара икән, барсын, бик яхшы, аны алдан вәсвәсәгә салунын кирәге юк. Тора-бара тормышның катлаулырак булуын аңлар, тормыш үзе үк аңа киңәшен дә бирер.

Миләүшә уртача буйлы, юка гына гәүдәле, кыска сары чәчле, ак йөзле, күзләре зәңгәр, кашлары кара — буягандыр инде, авызы кечкенә, борыны почык. Карар күзгә әллә ни матур дип әйтеп булмый, тик рәхәтләнеп бер көлүе сине әсир итә шикелле, син инде Миләүшә турында гомумән уйламыйсың, колак төбендә шул челтерәп торган көмеш көлүе бар да син шул көлүдән нәрсәдер өмет итәсең.

Ул авылда туган, авылда үскән. Семьялары бик ишле булган, житмәсә барысы да кызлар икән! Миләүшә сигез кызның уртанчысы булган, ул кече яшьтән үз көнен үзе күрергә өйрәнгән. Әтисе-әнисе бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр колхоз эшендә, өлкән апалары, буй житкәч, колхозда эшләгәннәр яки ялланып чит шәһәрләргә киткәннәр. Миләүшә өй эшләрен дә эшләгән, сабагын да укыган. Зарланырга, назланырга аның башына да килмәгән. Өлкән классларда чакта, жәй көннәрендә, ул колхоз эшенә дә чыккалаган, пионер лагеренда да эшләгән — колхозның үзенең елга буендагы әрәмәлектә менә дигән пионер лагере булган. Миләүшә үзенең тагын укырга теләге барлыгын әйткәч кенә әти-әнисе уйга калганнар:

— Без бит сиңа ярдәм дә итә алмабыз, дигәннәр.

— Анда стипендия бирәләр ди, жәй көне эшләрмен. Миңа шул житәр,— дигән кыз һәм аны, тәвәккәлләп, укырга озатканнар. Беренче курсларда аның хәле шактый авыр булган булса кирәк, әле дә, сөйләгәндә, күзләре карасуланып китә, ә соңга таба бар да рәтләнгән, жәй көннәрендә студентлар бергәләшеп чирәм жирләргә барганнар, Миләүшә эшнең иң авырыннан да курыкмаган. Шәһәр тормышына ул студент буларак кына күнеккән, укып бетергәч шәһәрдә калу турында уйлап та карамаган. Беренче елларда ук Миләүшә авыл укучыларының математикага сәләтле булуларын күреп ала. Билгеле инде, үзе дә көчен кызганмый белемен дә бирә, оештыру сәләтен дә. Аннары Миләүшәләрнең мәктәбе бөтенләй авыл мәктәбе дә, шәһәр мәктәбе дә түгел, ул ничектер ике арада калган кебек. Ихтимал, бу Яшел Яр шәһәренең үзенчәлегеннән дә килә торгандыр. Яшел Ярның рәсми рәвештә шәһәргә әйләнүенә әле бернечә ел гына, шул ук вакытта ул район үзәге дә. Илле-алтмыш километрда яңа шәһәр салына, бик зур химия комбинаты төзелә. Киләчәктә мәктәп шуңа кадрлар хәзерләшүгә күчәрдер. Балаларның яртылашы авылдан, мәктәп каршындагы интернатта торалар. Ике катлы, зур, яңа, таштан салынган мәктәп. Яктылык бик мул, класслар да бик унай.

Тагын бер-ике көннән укулар башланырга тиеш, ләкин бүген үк инде укытучылар берән-сәрән мәктәпкә киләләр. Миләүшә бернич.) тапкыр инде мәктәптә булды, шунда Гәүһәр белән дә танышты. Бибинур апа, эшенең бик тыгыз икәнен әйтеп:

— Синең Миләүшә, әзрәк вакытың булса, Гәүһәр апаңны шәһәр белән дә, мәктәп һәм укытучылар белән дә таныштыра тор. Гәүһәр монда яңа кеше,— диде.

Миләүшә ялгызак кеше, өендә әллә ни эше юк, Бибинур апасының кушканын рәхәтләнеп үтәде.

Спорт мәйданчыгы янында Миләүшә туктады, баскетбол уйнаучыларга карап:

— Әй, булмаганнар, шулай уйныйлармыни... Ә менә монысы ярый, әләктерде... Тизрәк, тизрәк, уңга бир, уңга...— дип кычкырды.

Ул куллары белән рәшәткә башына тотынып, спорт мәйданчыгына карап тора башлады. Күзләре ялтырап, сулышы бераз ешаеп китте.

Гәүһәр аның чәбәләнүеннән үз алдына көлемсерәп: «Кара инде бу Миләүшәне, уенга шул кадәр исе киткән», дип уйлады, үзе аңа сокланып куйды: менә тормышны да шулай бер шартсыз кабул итсәң иде, аның әллә кай якларын уйламасаң иде. Ничек бар, шул көенчә алсаң, тормыш әнә нинди матур, нинди тирән. Хәер, кеше күбрәк яшәгән, күбрәк күргән саен алай беркатлы була алмый торгандыр инде, җаны борчулы булса, уйлары да ерак китми торгандыр. Бар иде бит Гәүһәрнең дә баш ватмаган чаклары, яшәү дә җиңел иде аңа, тирә-як та шундый нурлы күренә иде, ә хәзер барысын да ниндидер калын соры пәрдә каплаган кебек, сулыш алулары да авырайган шикелле. Элеккечә дөньясын онытып, Миләүшә кебек тагын бер көлгән чаклары булыр микән, әллә актык көннәренә кадәр шул күзгә күренмәс кайгы йөген күтәреп йөрерме?

— Бигрәк кызыксынасыз икән,— диде Гәүһәр.

— Ай, Гәүһәр апа.

— Сезгә физкультурник буласы калган, Миләүшә.

— Алай димәгез, Гәүһәр апа. Математиканы мин алмаштырмыйм. Физкультура эш арасында гына ул.

Миләүшә коймадан төште, күлмәген кагып алды. Инде саргая башлаган үләннәр, агачлар көз якын икәнен әйтсәләр дә, көн ифрат җылы, кояшлы, хәтта азрак кыздыра да. Ике атна булыр инде яңгыр тамганы да юк, урамда тузан, ләкин җил булмаса, ул тыныч кына ята, һава чиста, ниндидер хуш ис аңкый. Якында гына мәктәпнең алма бакчасы, тәмле ис шуннан килә торгандыр инде. Бакча зур, матур, урта аллеяда Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырларга обелиск куелган, аның әйләнәсендә әле дә чәчәкләр үсә. Гәүһәр белән Миләүшә бакчада бик озак йөрделәр. Миләүшә Яшел Яр шәһәренең бер үзеннән генә дә Ватан сугышында меңнән артык кеше үлгәнлеген сөйләде. Зур һәйкәл шәһәр үзәгендә яки елга буенда куелырга тиеш икән.

Гәүһәр ябыккан, үз эченә бикләнгән. Моннан ярты ел элек ул кайчан да булса Яшел Яр шәһәрендә торырмын, балалар укыта башлармын дип уйлап та карамый иде. Җәгъфәр белән аерылышканнан соң аның Казанда каласы килмәде, монын тоташ бер газап буласын ул белә иде, читтә кайгысын оныту ансатрак булыр шикелле тоелды аңа. Уйлана, киңәшә торгач, Шәриф Гыйльманович та, Рәхимә апа белән Галимҗан абый да аңа Яшел Ярга китәргә киңәш иттеләр, анда Галимҗанның сеңелесе Бибинур мәктәп директоры, эшкә дә ул урнаштырыр, диделәр. Гәүһәргә барыбер иде. Язылган хатларга җавап көтеп ул Галимҗан абыйларда торып торды. Әллә ни озак көтәргә туры килмәде, Бибинурдан хат көлеп төште. Ул Гәүһәргә кил дигән, өченче класста урын бар дигән. Гәүһәр риза булды һәм күп тә үтмичә юлга да чыкты. Институттан бер елга академик ял алды, чөнки ят җирне белеп булмый бит, ничек урнашасың, тору шартлары ничек хәл ителә, укырга әллә мөмкинлек була, әллә юк.

Гәүһәр гостиницага төшәргә уйласа да, Рәхимә апа да, Галимҗан абый да каршы килделәр, Бибинурның хәтерен калдырырсың, ул килгән кешене бик ярата, диделәр. Шулай да Гәүһәр кешене мәшәкатьләмәскә булды, әмма пароходтан төшүгә, аны Бибинур апа кызы

Гөлназ белән каршы алдылар, аңа гостиница турында авыз ачарга да ирек бирмәделәр.

Бибинур апа кырык биш-илле тирәсендәге хатын икән, чәче ап-ак, үреп, артка төеп йөртә, йөзе кояшта янган, күзләре коңгырт, авызында ике якта ике алтын теше бар, борыны итләч, гәүдәсе уртача. Буйга-сынга, төскә-башка Галимҗан абыйга бик аз охшаган, әмма ачыклыгы, кешегә мөнәсәбәте анык төсле. Гәүһәр аны гомерендә беренче тапкыр күрсә дә, бер дә каушамады, ничектер берьюлы үз итте. Гөлназ да Гәүһәргә ошады. Сигезенче класска күчкән бу кыз оялчан, нечкә гәүдәле, чәчен толымлап үргән. Кулындагы чәчәкләрен Гәүһәргә биреп, үзе шунда ук Гәүһәрнең бер чемоданын алды.

Казанда пристаньда озатып калган Галимҗан абый:

— Башкасын, Гәүһәр, белмим, мин мәктәп кешесе түгел, әмма Яшел Ярның суы бар. Хәтерем ялгыштырмаса, син бит Иделне ярата идең. Анда — Кама. Ә Кама — Иделнең сеңелесе.

Гәүһәр моңсу гына елмайды: елга кайгысымыни аңарда! Каманың салкын сулары аның кайнар кайгысын барыбер юа алмас. Тик нихәл итәсең, түзмәсәң дә түзәргә кирәк.

Миләүшә һаман сөйли дә сөйли, көлә дә көлә иде. Гәүһәр җеп очын югалтмаслык итеп кенә тыңлады. Бу вакытта алар инде бакчадан чыккаННар, шәһәр үзәгеннән баралар иде. Бераздан Кама буена ук борылдылар. Ара-тирә Гәүһәр монда ни, тегендә нәрсә күренә? дип сораштыргаласа да, асылда аның күңеле уйланулар белән мәшгуль иде. Казанда Шәриф Гыйльманович белән завуч Гәүһәрне шәһәрдә калырга димләделәр. Гәүһәр аларга яхшы теләкләре өчен рәхмәт укыды, ни өчен Казанда кала алмавын белдерде. Завуч, хатын-кыз кеше, ахыр килеп мәсьәләне төшенде, шундый хәл килеп чыккан икән, нишлисең инде, ә Шәриф Гыйльманович Гәүһәрне мәктәптән җибәрү турында ишетергә дә теләмәде. Аның белән бик озак тартышырга туры килде. Гәүһәрне озатканчы Галимҗан абыйларга килеп йөрде, һаман саен Гәүһәргә, уйла әле, бәлки калырсың, диде. Частный булса да квартир табарбыз, диде. Гәүһәр калмады. Ләкин дөрес эшләдеме соң ул?

Менә алар яр буйлап баралар. Кама өсте җем-җем итә, елга нәрсәдер сөйли кебек, Миләүшәнең көлүе дә аңа әллә кайдан гына еракган ишетелә кебек.

— Гәүһәр апа, көрсенмәгез, зинһар. Бар да яхшы булыр. Яшел Яр ул йөрәк яраларын төзәтә.

Яшел Ярның шундый сихәте булса! Әгәр ул яраларны гына арттырса? Гәүһәр зәгыйфь кенә елмайды, Миләүшәгә ышанмыйчарак карап алды.

— Юк, Гәүһәр апа, тырнак очы кадәр дә шикләнмә.

Миләүшә Гәүһәрне култыклап алды.

— Менә укулар башланыр, алар белән бергә мең төрле мәшәкать килер, үз тормышыңа әйләнеп карарга да вакыт булмас. Мин, мәсәлән, вакыт үткәнен бөтенләй сизмим. Ә җырларга вакыт табам, хәтта хисап мәсьәләләре чишкәндә дә җырлыйм.

— Димәк, синең көннәрең шундый матур.

— Шулаймы икән? Юк, мин гомумән тормышка каш җыерганны яратмыйм. Нигә алдан күз яше түгәргә? Нигә кайгыны сорап алырга? Син дә, Гәүһәр апа, бик уйчан булма. Уй бетерә бәндәне,— дип кинәт җырлап җибәрде Миләүшә, шуның артыннан ук чәчрәп көлә башлады.

## 2

Гәүһәр уку башлану көне турында уйламаска тырышты. Моңарчы укытмаган түгел бит, укытты, моннан соң да укытыр әле. Беренче уку көннәрендә була торган гадәти дулкынлануны да кичермәс шикелле

ул. Кичерде инде, Миләүшә өзелеп сөйләсә дә, Яшел Ярда аның әллә ни аермасы юктыр инде. Беренче планда Гәүһәрнең эчке дөньясы, кичерешләре, уйлары, бары тик икенче планда гына ул укытучы... Элек ул мәктәпкә аерата зур әһәмият бирә торган иде, класска беренче тапкыр бару, класс белән танышу аның өчен гомумән зур вакыйга булса, һәр сүз, һәр адым алдан уйланса, хәзер моның әһәмияте калмаган шикелле. Шулай уку алды көннәрс дәвам итте. Билгеле, ул яңа мәктәпкә дә барды, расписаниеләр белән дә, мәктәп тормышы белән дә, гомумән шәһәр белән дә беркадәр танышты, ләкин болар ничектер үзеннән-үзе эшләнә, Гәүһәрнең җанын актарып салмыйлар. «Нинди-дер салкын күңелле, балаларга да шулай караса...» — диләр иде мәктәп укытучылары аның турында, үзара сөйләшкәндә. Алар элекке укытучы Ламиганы яхшы беләләр, аның китүен кызганалар, мәктәпкә шундый сәер укытучы тапкан Бибинурны да тиргәп алалар иде. Янәсе, Гәүһәр аның якын кардәше, үзләрендә тора да, ят кеше булса тотар идеме? Бибинур акчага хирыс түгел, күпме торып, хәтта иң авыр елларда да кеше кертмәде.

Укулар башлануга бер-ике көн калганда Гәүһәр кинәт уянып киткәндәй булды. Тагын беренче планга укытучы чыкты. Бу Гәүһәрнең ихтыярыннан тыш диярлек эшләнде. Ул борчыла башлады, Миләүшә белән дә, Бибинур апасы белән дә кат-кат сөйләште, үзенең дәрес планнарын карады. Каяндыр караңгыдан бөтенләй таныш булмаган Ламига килеп чыкты. Аның күзләре генә ялтырый. Ул күзләр Гәүһәргә текәлгән. Вакыт-вакыт бик якын сыман, кайчак шундый өздереп карыйлар, Гәүһәр түзми, артына борыла: күзләр томан эченә чигенгәндәй булалар.

Иртәгә мәктәпкә киеп барасы киемнәрен Гәүһәр кич белән бик тырышып үтүкләде. Гөлназ аңа булышып йөрде. Ул кунакка әнисеннән дә болай шат иде. Ламига турында әллә ни әйтә алмаса да, мәктәп һәм үз класслары турында Гәүһәргә байтак яңалыклар сөйләде. Завучны бик мактады, аны бөтен балалар ярата, берәүгә дә кычкырмый, диде. Моннан Гәүһәр бер нәтиҗә ясады: балалар кайда да бер икән, кычкырганны, әрләгәнне яратмыйлар. Өченче «А» классы да шундыйдыр инде. Өченче «А»... Нинди класстыр ул? Билгеле, Ламигага алар ияләшкән булгандыр, аның киткәнен белсәләр дә, беренче сентябрь көнне иртән класска кермәвен күргәч, күңелсезләнерләр. Казанда чакта Гәүһәр үз классының сулышын, аның барлык яшерен теләкләрен белә торган иде. Шәриф Гыйльманович Гәүһәрне һәрвакыт мактады. Беренче классларда бала нәрсәгә өйрәнсә, өлкәнрәк классларда да шуны кабатлый, дия торган иде ул.

Шәриф Гыйльманович бик тәҗрибәле укытучы. Шулай да бер класс үрнәгендә нәтиҗә ясарга иртәрәк булгандыр, дип уйлый иде Гәүһәр. Ихтимал, очраклы рәвештә аның классына бар да яхшы укучы, сәләтле балалар туры килгәндер. Ә башка тәҗрибәсе Гәүһәрнең юк. Яшел Ярда ул өченче классны ала. Димәк, үзе булмаса да монда икенче кешенең ихтыяры, методы зур роль уйнаячак. Гәүһәр моны бик өнәмәсә дә, каршы килергә дә мөмкин түгел иде: ул бит буш урынга килә, ә буш урыннар синең теләгең буенча гына хасыйл булмый.

Ихтыярсыздан Гәүһәрнең күз алдына Казандагы классы килде. Иртәгә ул класска яңа укытучы керер. Балалар ничек каршы алырлар? Гәүһәр апаларын бер сагынырлармы икән? Аның бөтенләйгә киткәнен белгәч, күңелсезләнмәсләрме? Гәүһәр классның язмышы турында Шәриф Гыйльманович белән дә, завуч белән дә күп сөйләште. Шәүкәткә, Дамирга игътибарлы булырга кирәклеген әйтте. Аларга ачкыч табылган иде бит. Менә шул ачкычны югалтмыйсы иде. Яңа укытучы шушы эшнең никадәр мөһим икәнен аңлармы, әллә Гәүһәр үз бәясен күтәрер өчен генә шаулаган икән дип уйлармы?

Күрсенеп куйды. Аннары үтүкләгән киемнәрен киеп карады. Я алла, ничек ябыккан ул! Төймәләрен күчереп такмасаң, киярлек тә түгел.

— Гөлназым, инә-җебең бармы? Кара, ничек ябыкканмын.

— Бар, Гәүһәр апа.— Ул тәрәзә пәрдәсеннән кара җеп сапланган инә алып килде.— Шул ярыймы?

— Ярый.

— Сезнең ябыгуга мин ышанмыйм, Гәүһәр апа. Сез һаман шундый булгансыз кебек. Болай килешә дә төшә сезгә.

— Юк, мин тазарак идем, Гөлназ...

Гәүһәр, тәрәзә янына утырып, эшкә керешге. Ул арада Бибинур апа да кайтты.

— Барысы да хәзер кебек... Ел саен шул хәл, ел саен борчылу. Мин, ахрысы, башка директорлар кебек, салкын канлы булырга өйрәнә алмам. Гөлназ, чәй эчерәсенме, кызым?

— Хәзер, әни.

— Менә тәмам ябыгып беткәнмен, төймәләремне күчереп тагам, Бибинур апа,— диде Гәүһәр.— Гөлназ болай сипа килешәрәк төшә дигән була.

— Төймәләреңне тагып бетердеңме? Я әле, киеп кара.

— Хәзер, Бибинур апа.

Гәүһәр икенче бүлмәгә чыгып китте. Бераздан өстенә ак кофта, кара костюм, аягына биек үкчәле ак туфли кигән Гәүһәр күренде. Ул бик тыйнак, шул ук вакытта бик нәфис. Бибинур апа укытучыларның киемнәренә игътибар итәргә күнеккән иде. Гәүһәрне укытучы буларак әле белмәгәнгә, бигрәк тә җентекләп күзләп кичерде. Ул киеменә игътибарсыз булган укытучыларны яратып бетерми иде. Үзе яхшы итеп киенә белмәгән укытучы башкаларны ничек итеп яхшы киенергә өйрәтсен? Аннары сүз балаларның тышкы кием-салымы турында гына бармый, сүз аларны рухи киендерү турында бара. Укытучыдан балалар һәр яклап үрнәк алалар бит.

— Я, ничек, Бибинур апа?

Бибинур апа җинел сулап куйды. Ул беренче тапкыр Гәүһәр укытучы белән очрашты. Коллегаларының Гәүһәр турындагы сүзләре аны шактый борчыган иде. Дөрес, Галимҗан белән Рәхимәгә ул бик нык ышанды, начар кешене алар тәкъдим итмәсләр, шулай да... Хәзер, Гәүһәрне беренче тапкыр укытучы киемендә күргәч, Бибинур эчке бер канәгатьләнү белән:

— Мина ошый,— диде.

— Күпләр шундый костюм тектерерләр әле,— диде кухнядан чыгып килгән Гөлназ.— Безнең яшьләр яхшыны күтеп кенә торалар. Әни, чәй булды.

— Әйдә, табын әзерлә, кызым. Үтүгең кайда? Чәйдән соң мин дә киемемне үтүкләрмен.

— Мич каршында гына, әни. Ә мин үземнекеләрне күптән үтүкләп куйдым инде.

Чәй эчтеләр. Аннары Гәүһәр портфелен барларга утырды. Казаннан алып килгән методик күрсәтмәләрне карады, өстәмә әсбапларга күз салды. Дәрескә бер нәрсәне дә онытырга ярамый. Син портфеленә тотынасың икән, аннан ни дә булса чыгар. Бер нәрсә дә алмыйсың икән, әһә монысын оныткан, дип уйлый укучы, үзенә дә «онытырга» ярый, дип нәтиҗә ясый. Бу — рәхимсез логика.

Әлбәттә, Гәүһәр Бибинур апага да күз салгалады. (Кайчак әле бер өйдә бер-берсенә асла охшамаган ике укытучы булыр.) Ничек киенә, үз-үзен ничек тота. Аннары Бибинур апа — гади бер укытучы гына түгел, ул мәктәп директоры, тәҗрибәле, олы кеше.

Иртән сәгать тугызда Гәүһәр мәктәп директоры Бибинур апа белән өченче «А» классының ишеген ачып керде. Бер генә секундка

Гәүһәргә Казандагы күптән таныш классның ишегеп ачкан кук тоелды. Хәтта балалар да бер иде сыман, булмә дә шул ук кебек. Хәлбуки, барысы да башка, балалар тынган, алар бик зур киеренкелек белән яңа укытучыга карыйлар, аның беренче сүзен, тавышын көтәләр. Ләкин хәзергә әле балаларга таныш булган Бибинур апа гына сөйли. Ул балаларны яңа уку елы белән тәбрикләгәч, Гәүһәр белән таныштырды.

— Балалар, сезнең Ламига апагыз башка шәһәргә күчеп китте. Аның урынына менә яңа укытучы — Гәүһәр Рәшидовна, Гәүһәр апагыз. Сез аны яратырсыз дип ышанам. Үткән елларда сезнең классыгыз начар укымады, тәртибе дә матур иде, моннан соң да шулай булыр дип өмет итәбез. Ә хәзер, балалар, сезне Гәүһәр апагыз белән калдырам. Рәхим итегез, Гәүһәр Рәшидовна...

Бибинур апа чыгып киткәч, Гәүһәр өстәл янына килде, портфелен, журналын бер читкә куйды һәм ягымлы, ачык тавыш белән:

— Балалар, дәресне башлыйбыз,— диде.

Бер карасаң, балалар балалар инде, алар янына бик борчылып керәсе дә юк. Ләкин белсәң иде, Ламига ничек класска керә, ничек исәнләшә, ничек портфелен ача, ничек класс журналын карый торган булган. Вак кына нәрсәләр кебек, ә шуннан укытучының зур образы туа. Гәүһәр һәрбер укучыга карый-карый аларны истә калдырып, исемлек тикшереп чыкты. Балалар тынганнар, аларның әйтер сүзләре дә бик күп, шул ук вакытта алар Гәүһәрне дә белмиләр. Иске укытучылары булса, кушканны да көтмичә, һәркем җәйге тәэсөратларын сөйләргә тырышыр иде. Җәй буе алар никадәр яңа нәрсәләр күрделәр, никадәр җирләрдә булдылар! Хәлбуки алар тып-тын утыралар, бер якты нур ялтырап уйнамый. Укытучының һәр кискен борылышыннан соң алар сискәнеп-сискәнеп куялар. Менә ул алар бөтенләй белмәгән нәрсәләрне сорар кебек, аннары: «Бер нәрсә дә белмисез, җәй буе шар сугарга кирәкмәс иде!» дип әйтер төсле.

Гәүһәр укучыларның карашларын аңлый иде булса кирәк. Ул елмайды һәм дәрескә керешге. Башта ул үткәннәрне кабатлады, сүз арасында укучылардан әледән-әле, «моны үттегезме?» дип сорады. Күрәсең, программада күрсәтелгән дәресләрне Ламига бик тырышып алып барган, балалар һәр очракта «үттек» дип җавап бирделәр. Башта аларның җаваплары бик үк ышанычлы яңгырамады, тавышлары берән-сәрән генә ишетелде. Гүя алар үз тавышларыннан үзләре оялалар иде. Нииндидер афәт башланыр кебек көттеләр. Соңыннан алар беркадәр җанландылар. Беренче тәнәфестән соң сакланып кына көлгән тавышлар да ишетелгәләде. Гәүһәргә алар әле барысы бергә — балалар гына иде, берсенең дә исеме юк. Бары тик икенче дәрес беткәндә генә ул бер малайның исеме Акназар, бер кызчыкның исеме Зилә икәнен белеп алды. Алар икәү янәшә утыралар, икесе дә тиктормаслар булса кирәк. Гәүһәр балаларга кушаматлар тагарга ярамавын яхшы белә. Шулай да Акназарга Караназар дип әйтергә кирәк иде, ул кап-кара, күрәсең, башкорт малае булса кирәк, йөзендә башкорт чалымнары ярылып ята. Кызчыкның исеме Гәүһәргә үзенең сирәк очравы, җырга ятышлы булуы белән ошады.

Тәнәфес вакытында Гәүһәр укытучылар бүлмәсенә бармады, үзен урап алган балалар белән калды, алардан җырлый беләсезме? дип сорады. Белмичә!

— Бик яхшы, мин башлыйм, ә сез миңа кушылыгыз. Ярыймы?

— Ярый!

Гәүһәр балаларга бик таныш булган бер җырны башлады. Аның тавышы артык көчле булмаса да ягымлы иде. Балалар бераз тыңлап тордылар, аннары Гәүһәр кулларын селкеп алгач, бердәм кушылдылар. Бигрәк тә Зиләнең тавышы чишмәдәй челтерәп яңгырады. Малайлар җырга катнашмады, алар коридорга ук чыгып киткәннәр иде.

Жыр тавышы ишетелә башлагач, алар берәм-берәм класска керделәр. Гәүһәр, жырлый-жырлый, аларны жырга катнашырга чакырды. Аның кул изәүләренә каршы малайлар, бер-берсен төртешеп, елмайдылар гына. Бары тик бер-икесе генә кушылды.

Соңгы ике дәрес — арифметика. Монысы инде гомумән корырак дәрес дип санала. Казанда Гәүһәрнең бу дәресләре ярыйсы күңелле үтә иде. Әллә нәрсәләр уйлап чыгара, бер дә иренми иде. Монда ничек булыр тагы? Беренче дәрестә аның күзләре житди һәм сак иде. Соңгы дәресләрдә елмая башладылар. Бу күзләр инде балаларны куркытмый иде.

Гәүһәр берничә мәртәбә мәсьәләне аңлатты. Аны яттан чишәргә кирәк.

— Ашыкмагыз, уйлагыз.

Бер малай шунда ук кулын күтәрде.

— Күрәм,— диде Гәүһәр.— Башкалар уйладыгызмы? Сүз бирәбезме?.. Я әле, әйтеп жибәр, Илдар.

Зур башлы ябык малай бик батыр әйтә башлаган иде, кинәт төртелеп калды.

— Кабаланма. Башта бик яхшылап уйла,— диде Гәүһәр, ачуланмыйча гына.— Я, уйладыңмы? — Малайның мыгырдавын күреп: — Әйдәгез, балалар, бергәләп Илдарның хатасын табыйк,— диде Гәүһәр.

Актыккы дәрестә балалар арыдылар инде. Гәүһәр бөтен классны аякка бастырып кыска гына физкультура ясап алды. Аннан дәрес янадан дәвам итте.

Дәрестән соң Гәүһәр директор янына керде.

— Я, Гәүһәр, дәрес ничек үтте? — дип сорады Бибинур апа.

— Болай яхшы кебек, Бибинур апа. Мин класстан хәзергә канәгать.

— Мин синең классыңа тагы керермен, тик берничә көн үтсен. Класс белән яхшылап танышырсың, уртак тел табарсың. Миңа сүзләрең юкмы?

— Юк, Бибинур апа.

— Алайса кайтырга ярый. Минем әле эшләрем бар.

Бибинур ападан чыккан чагында Гәүһәргә Миләүшә очрады.

— Әһә, күзләреңнән күрәм, Гәүһәр апа! — диде ул.— Күңелең кайтмаган. Беренче көн өчен бик ярый бу. Тора-бара зуррагы да булыр әле. Хәзер өйгә кайтасыңмы? Ярый, хуш иттек.

## 3

Укулар башлануга инде бер егерме көн үтеп киткән иде. Гәүһәр көн саен мәктәпкә йөреп, көн саен балалар укытса да, үзен һаман командировкага килгән кеше кебек хис итте. Мәктәптәге вакыты артык сизелмичә үтсә дә, өйдә вакыт ничектер тукталып кала иде сыман. Үзе белән алып килгән чемоданнарын берсен дә бушатмады, такта белән генә бүленеп алынган бүлмәсен бер дә бизәмәде, гүя ул монда бик аз вакытка гына тукталган. Бибинур апа, бездә генә торып тор, без икәү генә бит, дисә дә Гәүһәр риза булмады, дөресрәге, киң күңелле Бибинур апаны артык борчыйсы килмәде. Шуннан соң, шул ук Бибинур апа үзләреннән ерак түгел ялгызак бер хатында бүлмә табып бирде. Дөресрәге, бу бүлмә дә түгел, бер почмак кына иде, ләкин квартир хуҗасы Зәбирә түти бер үзе генә торганга, олы якка да чыгып утырырга мөмкин иде, әлбәттә. Кайчандыр Зәбирә апаның ире дә, энисе дә булган. Ире сугыштан кайтмаган, энисе былтыр үлгән. Зәбирә түтинең бер аягы да бала чактан зәгыйфь булганга, шулай бер үзе өендә торып калган. Өе зур түгел, ишле кешеләрне квартирга кертә алмый. Әмма Гәүһәр әллә ничегрәк, әллә квартирны яратмый, әллә китәргә чамалый, нәкъ вокзалдагы шикелле тора. Болай Гәүһәр аңа ошады,

борының чөйми, эшкә дисән, кулы ята, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра, тик нәрсәсендер югалткан, төшергән кебек, бик еш уйга чума, сәгатьләр буенча каядыр карап, сагышланып утыра, Зәбирә түти килеп әйтмәсә, ашарга да оныта.

— Бик сәер кеше китерден әле, Бибинур җаным,— диде бер көнне Зәбирә түти, мәктәп директорын урамда очратып.— Аптырадым инде.

— Әллә бимазалыймы, Зәбирә түти? — дип сорады Бибинур борчылып.

— Юк, юк, бимазалау түгел, тавышы да ишетелми. Уй-сагышка чумып утыра, кемнедер уйлыймы, болай кайгысы бармы — менә канаты сынган кош кебек инде, валлаһи.

Бибинур апа, Гәүһәрнең хәсрәтен белсә дә, Зәбирә түтигә әйтергә кирәк тапмады.

— Уй-сагышсыз кеше булмый инде, Зәбирә түти, дөньяда. Анысына инде артык игътибар итмәгез, вакыты белән кайгысы таралыр әле,— диде Бибинур апа һәм китеп барды.

«Кеше дигәнең шулай инде, кайгы адәм башыннан йөри, картмы, яшьме дип тормый», дип уйлады Зәбирә түти һәм бәрәңге бакчасына кереп барган каз көтүен чатанлый-чатанлый куып китте.

— Һәй, рәхмәт төшкерләре, кая керәсез, анда бер нәрсә дә юк ич инде.

Бүген ял көне. Мондый көндә ничек өйдә утырмак кирәк. Җомга көн аз гына яңгыр сибәләгән иде, ә бүген шундый аяз, шундый тын, шундый җылы, сәхрәгә чыгып китмичә яки су буена төшмичә ничек түзәсең. Пароходлар нәкъ җәйдәгечә йөри, тавышлары әллә кайларга китә. Ара шактый ерак булса да, моннан да ишетелә. Әнә пароход ничек ухылдый. Монысы инде пристаньга килә торгандыр, тавышы һаман якынлаша, ә менә монысы китеп бара торгандыр инде, әнә ничек ерагая. Юк, Зәбирә апа, гарип кеше булса да, өйдә утырмас иде әле мондый көнне, тик үзенә күрә тавык-кошы, кәҗәсе бар дигәндәй.

Чокыр буена ук сыенып утырган өе турысына җиткәч, Зәбирә түти ихтыярсыздан күзен тәрәзәгә төшерде: Гәүһәр терсәгенә таянган да каядыр урамга карый. Бая, Зәбирә түти чыгып киткәндә дә, шунда утырган иде, әле дә урыныннан кузгалмаган. Зәбирә түти эченнән көрсенеп куйды, аннары капканың келәсен күтәреп, ишек алдына керде. Гаңгылдашып казлары урыннарыннан күтәрелде. Лапаста пешкән бәрәңгесе бар иде, Зәбирә түти, ишекне ачып, казларны чакырды.

— Ашагыз, аша, җан кисәкләрем,— дип сөйләнде ул үз алдына, аннары казларны чокыр буена чыгарып җибәрде. Арт капканы япкан чагында өйдән Гәүһәр чыкты.

— И былбылым, нишләп мондый көндә өйдә утырасың? Әбиләр чуагының кыска гомерле икәнен белмисеңмени? — диде Зәбирә түти.

— Нигәдер чыгасы килми, Зәбирә түти. Аннары, Миләүшә керермен дигән иде.

— Көне бик матур бит, Гәүһәрем. Безнең ише карт-корыларның да күңелләре җилкенә, яшьләрнекен әйтмисең дә инде.

Бу сүзләргә каршы Гәүһәр берни әйтмәде, хак сүзгә җавап юк дип уйладымы, әллә бөтенләй ишетмәдеме, бераз торгач, яңадан өйгә кереп китте. Тәрәзә янына барса, ни күзе белән күрсен, кемдер тәрәзә төбенә бер чәчәк куеп киткән. Кем булыр икән бу рәхмәтле җан? Гәүһәр тиз генә тәрәзәдән үрелеп тышка карады. Әнә бер нәни генә малай йөгереп китеп бара, әнә урамның теге ягыннан шундый ук бер кызчык кул изи. Гәүһәр елмайды. Күр, балалар монда да аны ярата башлаганнар түгелме? Бу кечкенә генә ачыш Гәүһәргә бик зур булып тоелды: аның Бибинур апалардан башка беркая да барганы юк, бирәдә аны беркем дә белми, дип уйлый иде. Хәтта Миләүшәләргә дә кергәне юк, ял көннәрендә дә өйдә утыра. Шулай да балалар инде аны

белеп алганнар, өенә кермәсәләр дә, чәчәк китергәннәр. Кара, нинди матур чәчәк, исе нинди хуш. Гәүһәр аны кат-кат иснәде һәм Яшел Ярга килгәннән соң беренче мәртәбә үз алдына чынлап торып елмаеп куйды. Өй эче дә әзрәк яктырып китте кебек. Чыгып стаканга су салды, аннары чәчәкне шунда утыртты, өстәлчегенә куйды.

Ишек алдында Миләүшәнең шат тавышы ишетелде. Гәүһәр олы якка чыгып, ишек алдына караган тәрәзә янына килде. Миләүшә Зәбирә түти белән кочаклашып күреште, хәл-әхвәлен сорашты, аннары ишеккә таба борылды: Гәүһәр өйдәме?

— Өйдә, өйдә, әйдә кер, Миләүшә кызым. Кунагымның бераз күңелен ач, нигәдер бик ямансылый, уйлана да уйлана...

— Уйланырга ирек бирмәм әле, Зәбирә түти җаным,— диде Миләүшә, көлеп.— Күр, тышта нинди ямьле, мондый чакта кем өйдә утыра.

— Дөрес әйтәсең, Миләүшә кызым, дөрес. Баягынак Гәүһәргә үзем шулай дип әйткән идем дә, нигәдер чыгасы килми дигән булды. Син инде аны алып чыга күр. Су буена төшегез. Бик рәхәт бит анда.

— Нәкъ шул ният белән килдем дә, Зәбирә түти җаным.

Миләүшә өйгә керде, шау-гөр килеп Гәүһәр белән күреште, җыр башлады, аннары стакандагы чәчәкне күреп алып иснәде, нинди матур дип мактады, ул да булмады, күзе стенадагы мольбертка төште.

— Әнекәем,— диде.— Әллә рәсем ясыйсыңмы?

— Нигә шул хәтле гаҗәпләнәсез? — диде Гәүһәр йомшак кына.— Минә чәчәк башка ул...

Миләүшә, Гәүһәрнең чәчәк турында нидер әйтергә теләгәнен сизмәде булса кирәк, үзенекен дәвам итте:

— Рәсем ясый белгән кеше шундый матур көндә өйдә утырамы соң? Әйдә, киен. Мин монда бер урын беләм, борынгылар әйтмешли, оҗмахларың торсын бер якта.

Гәүһәрнең беркая да барасы килмәсә дә, Миләүшәдән котылып буламы соң?! Гәүһәрнең ай-ваена карамыйча, аны өйдән алып чыкты да, һаман ишек алдында казынган Зәбирә апасына кул изәп: «Без киттек!» дип кычкырды.

— Хәерле сәгатьтә, хәерле сәгатьтә,— дип калды Зәбирә апа.— Кайтышлый безгә керегез, чәем кайнаган булыр.

— Ярар, ярар,— диде Миләүшә, мольбертны җайлап иңенә тага-тага.— Моның нәмәстәкәе бар икән дип уйласыннар әле.

Алар, тар тыкрыктан бераз баргач, зур урамга, аннары үзәккә борылдылар. Монда халык чын шәһәрдәгечә күп, барлык кибетләрнең ишекләре ачык, халык керә дә чыга. Урамның ике ягыннан машиналар чаба, атлар да бар, ләкин күп түгел. Яшьләр бик пөхтә киенгәннәр, асфальт тротуар буйлап көлешеп баралар. Миләүшәнең иңендәге мольбертка бик азлары гына борылып карый. Кайберләре бәләкәй радио алгычлар тоткан, уйнатып баралар, төрле модный җырлар яңгырый.

Миләүшә бертуктаусыз сөйли дә сөйли, аның дөньяда кызыксынмаган вакыйгасы да юк бугай: ул космостан алып җир йөзендәге барлык хәлләр белән, илдәге төзелешләр һәм район эшләре белән, Яшел Яр шәһәрендә булачак төрле яңалыклар белән баладай кызыксына. Бер темадан икенчесенә ул гаҗәп җиңел күчә, шуңа күрә ничектер барысы турында да берьюлы сөйли, барысы да аңа бердәй кызык кебек. Гәүһәр инде аның бу үзенчәлегенә бераз игътибар иткән иде. «Дәрестә дә шулай сөйләсә, бик сәер килеп чыга торгандыр», дип уйлады ул, ләкин Миләүшәгә берни әйтмәде.

Ул арада алар, үзәкне үтеп, су буена төштеләр, ләкин пристаньга таба борылмадылар, сулгарак киттеләр, шәһәрдән бөтенләй чыктылар. Бу җирләргә кадәр аларның килгәне бар иде. Әнә теге скамейкаларда Камага карап утырып торганнары бар. Моннан ары Гәүһәр аяк басмаган яр буе урманы башлана.

Табигать һәрвакыт Гәүһәргә ял һәм ләззәт бирә торган иде. Шуна күрә ул, Миләүшәгә ияреп, тирә-ягына карана-карана һаман барды да барды, күңеленә нәрсәдер аз-азлап тула башлады. Уйлары, кичерешләре, кечерәеп, артка чигенделәр, алгы планга үзенең бөтен матурлыгы белән балкып табигать килеп чыкты. Ул, гүя тере нәрсә кебек, үз телендә гаҗәеп бер музыка чала кебек. Моңарчы Гәүһәр табигатьне күрә, тоя гына белә иде, баксаң аны тыңлый да белергә кирәк икән. «Табигатьнең үз теле бар», дип Гәүһәр күп тапкырлар ишетте, укыды. Әмма бу гади хакыйкать һәр кешенең аңына барып җитсен өчен һәр кешенең үзенә күрә ачыш ясавы кирәк икән. Моңарчы Гәүһәрнең ниндидер хисләре йомылган идеме, ул табигать белән сөйләшә алмады. Художниклар табигать белән ачыктан-ачык сөйләшә торганнардыр инде.

Бара торгач, Гәүһәр бөтенләй туктады, тирә-ягына карап алды: чыннан да мондый матур урында булганы юк иде әле аның. Бер якта яфраклы көзге урман, икенче якта әз генә шадраланып торган елга. Җәйдәгечә җылы да. Ничектер барысын кочып аласы, табигатькә нәрсәдер әкрен генә пышылдасы, иң тирән серләреңне ышанып әйтәсе килә.

Миләүшә туктамады, бераз алга китте дә, артына борылып:

— Әйдә, әйдә, ник туктадың,— диде ул.

Алар тагын яр буйлап киттеләр, вакыт-вакыт куе агачлар арасына керделәр. Кама бөтенләй күренми башлады, ләкин озакка түгел. Тау астына төшеп, үргә менгәч, кинәт тагын яктырып китте: хәзер яр буйлары да, елга да гаҗәеп бер көч белән музыка уйный иде сыман.

— Менә карагыз инде, таң калырлык бит! — диде Миләүшә.— Мольбертыңны мә, эшлә, мин сиңа комачауламыйм, аннары килеп алырмын. Сәгать ярымнар йөрсәм ярыймы?

Кинәт Гәүһәр бер нәрсәгә игътибар итте: Миләүшә аз гына күңелсезләнгән кебек иде. Гәүһәр шул турыда авыз ачарга гына уйлаган иде, Миләүшә йөгереп китеп барды, еректан кулын гына болгады. Гәүһәр ни әйтергә дә белми калды, аннары тирә-ягына каранды, бераз читкәрәк китте, туктады. Аның күзләре чак кына кысыла төшкән. Менә монда бик яхшы күренеш. Гәүһәрнең йөрәге сикереп куйды, аны эшкә тотынып алдыннан була торган күтәренкелек биләп алды. Тагын бераз көзнең мул бизәкләренә, яр кырыендагы мәһабәт ялгыз имәнгә, елгага, елганы ярып килгән аппак пароходка карап торды да мольбертын рәтли башлады.

Художниклар эшендә беренче сызык зур роль уйный бугай, һәрхәлдә, Гәүһәргә шулай тоела иде. Кайчакта ул әлеге беренче сызыкны тота алмыйча аптырап бетә, кайчакта бу беренче сызык ничектер үзеннән-үзе сызыла кебек. Шуннан соң инде туктамый эшләргә генә кала. Бүген әлеге шул беренче сызык өлгереп җиткән идеме, ничектер бик ансат сызылды, дөресрәге, ул юк кебек, бөтен картина үзеннән-үзе кәгазьгә күчә иде кебек.

Колагында музыка. Ул Гәүһәргә ничек эшләргә кирәген пышылдый кебек. Гәүһәр аңа буйсына, шул уңайга җитез генә пумаласын йөртә. Иреннәренә кунган җиңелчә елмаюны да сизмичә, ул эшли дә эшли. Күпме эшләде ул? Бер сәгатьме, артыкмы? Юк, сәгатькә карамады ул, аның өчен вакыт туктаган иде, ул бары тик буяу салуын гына белде, күзләре гүя урман, елга өсләреннән кирәкле төсләрне алалар да рәсеменә күчереп куялар, куллары гүя күзләренең дәвамы, алар күз күргән уңайга гына хәрәкәтләнәләр.

Ниһаять, Гәүһәр күзен йомды, шулай берничә минут утыргач, ачып җибәрде. Бер рәсемгә, бер табигатькә карады. Эшләгән чакта бик әйбәт чыккан иде кебек, хәзер бик беркатлы күренә. Юк, ул чын художник түгел шул. Ул уйга калды. Башта, билгеле, рәсем турында, аны

ясау, осталык турында, талант турында уйлады, аннары уйлары Миләүшәгә кайтты. Нигә ул Гәүһәр яныннан китеп барды? Чыннан да аны зур художник дип уйлыймы? Менә күрсен, Гәүһәрнең бер нәрсәгә дә яраксыз икәнен белсен. Хәер, монда баш ватып торасы да юк, Гәүһәр һәвәскәр генә, аның рәсемнәре бары тик үзе өчен генә. Ә менә ни өчен бая Миләүшәнең тавышы сагышлы сыман тоелды аңарга? Гәүһәр алданмагандыр бит, юк, андый хәлләр булмый торган иде. Үзен күп мәртәбәләр сынап караганы бар, ялгышканын хәтерләми. Димәк, Миләүшә чыннан да сагышланган иде. Ләкин нәрсәгә булыр икән? Бая гына ул бик шат кебек иде бит. Сагышлануын сиздермәс өчен Гәүһәр яныннан да китеп баргандыр инде, әйе, шулай билгеле. Ә Гәүһәргә ул кайгыра да белми кебек тоелган иде. Юк шул, кеше никадәр беркатлы булып күренмәсен, аңа өстән карарга ярамый икән, бер килеп икенче ягы белән әйләнә ул.

Гәүһәр, бәләкәй нәфис ияген бергә кушылган кулларына терәп, кояшта ялтырап торган Камага карый. Башта аның уйлары һаман шул Миләүшә тирәсендә әйләнде, аннары Каманы үз ихтыярларына җиккән кешеләр турында уйлый башлады. Бар икән шундый батыр кешеләр, аларның берсен Гәүһәр Яшел Ярга килгән чагында пароходта да очратты. Билгеле, үз хәле хәл булмаса, Гәүһәр күп нәрсә белгән булыр иде. Гәүһәр исә аны рәтләп күзәтә дә алмады, аның сүзләренә дә әллә ни игътибар итмәде. Тик менә хәзер, Камага карап утырганда гына, алар аның хәтер чоңгылыннан бөтерелеп чыктылар. Ул урта яшьләрдәге кеше нефтьпромыслы идарәсенең башлыгы иде бугай. Аның бер сүзе Гәүһәрнең хәтерендә уелып калды: ул татар нефтенең бер стаканы газлы суның бер стаканыннан кырык тапкыр арзанрак, диде. Ул чакта бу чагыштыру Гәүһәрнең аңына барып та җитмәде. Тора торгач кына ул хыялны били икән. Ничәмә ничә мең метр җир астында яткан нефтьне шул кадәр арзан итәр өчен нинди темп белән эшләргә кирәк! Ул нефтьне җир астыннан чыгарыр өчен миллион-миллион кубометр су кирәк бит. Аны кайдан алырга? Әлмәт һәм Лениногорск тирәләрендә зур елгалар юк. Зәйнең һәм ясалма Карабаш диңгезенең сулары гына моңа җитми. Нефтьчеләр Әлмәттән йөз километр читтәрәк аккан Камага барып баш ияләр. Шуннан Әлмәткә таба юан торбалар сузыла. Кама суының бер өлеше, үзенең агышын үзгәртеп, көньяк-көнчыгышка таба юл ала. Нефтьчеләргә бөтен бер җир асты елгасы ага! Ләкин тора-бара бу су да аз була. Икенче нефтепровод салалар...

Гәүһәр бу батыр кешеләр белән турыдан-туры аралашмый, ләкин аларның якында булулары Гәүһәр ишеләргә дә нур бирә түгелме? Үз кайгыңнан, билгеле, кача алмыйсың, әмма батыр кешеләр сине дә батыр булырга өйрәтә. Нинди беркатлы кеше булсаң да моны тоймыйча яши алмыйсың бит.

Көн инде кичкә таба авыша, күләгәләр озая, табигатьтә моңсулык арта. Мондый чакта ялгыз утыру авыр. Гәүһәр торды, Миләүшә китеп барган якка карый башлады. Кайда югалды? Инде кайдан эзләргә? Гәүһәр, кулын авызына куеп, берничә мәртәбә «Миләүшә-ә-ә-ү!» дип кычкырып та карады. Тавышы әллә кайларга китеп яңгырады да урман эчендә тынып калды. Шуның артыннан ук кулына сары яфраклар тоткан Миләүшә дә күренде. Гәүһәр аны озак йөрүе өчен шелтәләргә уйлаган иде, Миләүшә шундый матур итеп елмайды, Гәүһәрнең бер үпкәсе дә калмады.

— Уф, арыдым,— диде Миләүшә,— әзрәк утырам. Абау, нинди матур ясагансың.

— Әйттең инде... табигатьнең карикатурасы.

— И, яманлаган булыгыз инде. Мин болай ясый алсам, түбәм күккә тияр иде.

— Миләүшә, чын, ташлыйк әле ул рәсемне. Әйт әле: нигә син ялгыз? Минем өчен генә килдеңме монда?

— Менәтерәк... Тагын кем кирәк миңа?

— Белмим, ләкин кемдер кирәк, Миләүшә.

— Я инде, әллә ниләр сөйләмә, Гәүһәр апа. Менә көз артыннан кыш килә, уйласаң, бездән дә тилерәк кеше юктыр бу дөньяда, Гәүһәр апа, чын. Барлык халык тишек-тошыгын ямый. Картлар кышның корсагы озын дигәннәр, суыгы да, ачысы да, булыр. Без генә ул чикерткә кебек...

Гәүһәр тынып калды. Әйе, ялгышмаган, Миләүшәнең мәхәббәте башлана. Ихтимал, ул үзен кая куярга белмәгәнгә монда килгәндер. Шулай да Миләүшә бик бәхетле, аның өмете алда, ә Гәүһәрнең... Җылы өе дә, бәхете дә, сөйгән кешесе дә юк.

Кинәт Миләүшә учларына капланып үксеп елап җибәрде, аңа карап Гәүһәр дә елый башлады. Озак еладылар алар. Монда аулак, беркем дә күрми, ә урман белән елганың кешеләргә сөйләргә телләре юк, алар бары тик сүзсез шаһит кына була beләләр...

Ниһаять, Миләүшә исе китеп Гәүһәргә карап торды да кычкырып көлеп җибәрде:

— Тилеләр без, Гәүһәр апа, әйе бит.

— Әллә тагы.

Һәм алар килгән якка җай гына атлап киттеләр.

## 4

Казаннан Яшел Ярга, аннан да ераккарак, дөнья читенә дә китәргә мөмкин, ләкин аңа карап кына кеше уй-хәсрәтеннән аерыла аламы соң? Миләүшә кебек үз уйларыннан көләргә, тилереп туганнар, дип әйтергә мөмкин. Аңа карап ни үзгәрә? Нәрсәне яшереп, кемне алдап була? Бигрәк тә үз-үзеңне алдарга мөмкинме? Әлбәттә, Миләүшә уйлары белән Гәүһәр уйларын чагыштырырга нигез юк. Миләүшә үз уйларын теләсә ничек дип атасын, алардан теләсә ничек көлсен, ләкин алар якты, нурланып тора, ә Гәүһәрнең киләчәктә нәрсәсе бар?

Ул ихтыярсыздан ире турында уйлый. Әйтерсең, аерылмаганнар да. Менә Җәгъфәре эштән кайткандыр, өйдә кайнар аш та юк. Күлмәге керләнеп беткәндер, студентлар гаеп итәрләр, ә шкафта аның юган күлмәкләре дә беткәндер. Ара ерак булмаса, беркемгә әйтмичә, беркемгә күренмичә иреnең каралган күлмәкләрен генә барып юар, аннары кайнар аш пешерер иде. Гәүһәре булмагач, кем аның теләкләрен үтәр, кемгә кирәк ул? Җәгъфәр бит сүзгә артык юмарт түгел, аның теләген күз карашыннан сизеп алырга кирәк. Гәүһәр хәтерли, бер тапкыр ул Җәгъфәргә әйтмичә генә чумар пешерде. Өйдә онның беткән чагы, кибетләрдә дә он әсәре юк, Җәгъфәр машинасы белән бөтен шәһәрне әйләнеп йөреп тә бер кашык он таба алмады. Менә шундый чакта бер миски кайнар чумар! Җәгъфәрнең ике күзе дүрт булды, бик тәмләп ике тәлинкә чумар ашады. Соныннан онны каян алдың да каян алдың дип сораштыра башлады... Хәзер он да бар, тик кем Җәгъфәргә чумар ашатыр?

Билгеле, мондый уйларның очы-кырые юк. Бетәсе түгел алар. Әнә инде караңгы төшкән, торып ут кабызырга кирәк, ләкин Гәүһәрнең утырган җиреннән кузгаласы килми. Аннары уйларга караңгылык комачауламый да бит. Юк, әгәр мөмкин булса, хәзер ул Җәгъфәр янына барыр иде. Җәгъфәр аңлагандыр, аңларга тиеш. Ана нахак сүзләр ишеттергәннәр. Әлбәттә, җаннан артык сөйгән кешен турында шундый сүзләр ишетү бик авыр булгандыр, Җәгъфәр күтәрә алмагандыр. Гәүһәр моны аңлый лабаса.

— Һай, өй эче нинди караңгы, кабер кебек.— Зәбирә түти ут кабызды, аннары чатанлый-чатанлый Гәүһәр бүлмәсе янына узып, ишеккә корылган пәрдәне күтәреп карады.— Абау, ник караңгыда утырасың, кызым? Өй эчендәге карангылык күңелгә дә күчә бит.

— Гафу ит, уйга чумганмын,— дип зәгыйфь кенә елмайды Гәүһәр.

— Уйлы булсаң да караңгыда утырма,— дип, Зәбирә түти Гәүһәр бүлмәсенә дә ут кабызды.— Менә нинди күңелле булып китте.

— Утыр, Зәбирә түти.

— Рәхмәт.— Зәбирә түти өстәл кырыендагы урындыкка утырды, күзе чәчәк куйган стаканга төште.— И-и, кара инде, әле һаман корымаган.

— Мәхәббәтле чәчәк ул, Зәбирә түти, шуңа күрә бирешми.

— Шулайдыр шул. Ә син, Гәүһәр, шундый чәчәкләр бар чагында, ятим кебек, яңагыңа таянып утырасың.

— Шундый инде мин, Зәбирә түти, ачуланма.

— Мин ачуланмыйм да, яшәү бар бит дөньяда. Яшәүнең ямен җибәрсәң, нәрсә кала? Кеше бит ике яшәргә килми. Бер үткән көнне кайтарып та алып булмый.

Гәүһәр Зәбирә түтине күкрәгенә кысты.

— Оялттың син мине, Зәбирә түти, ләкин нишлим соң? Зинһар, авыз йомып торма, чәбәклә.

— И-и, Гәүһәр, әйтерсең инде. Безнең эше надан кешеләр ни белә, такылдый шунда тузга язмаганны.

— Юк, алай димә инде, Зәбирә түти. Халык акылы безгә, яшьләргә, җитенкерәми.

— Безнең эти, мәрхүм, гел әйтә торган иде: мәрҗән өзелсә, тизрак тегәрҗепкә тез дип. Кешеләрнең өзелгән мәрҗәннәре бик күп тә, безнең тегәрҗебебез ул хәтле бармы соң? Ярый, күп сөйләдем. Самовар куйыйм, тамак кипте, йоклар алдыннан әзрәк чылатып алсаң, яхшы була.

Зәбирә апа олы якка чыкты, аның белән бергә Гәүһәр дә. Олы якта, гөлләр арасында, ничектер күңелле, ямьле иде. Гәүһәрнең күз алды яктырып китте. Аның үз бүлмәсендә дә кына гөле бар, ул шактый куе, чәчәкле, ләкин ул гөл бүгенгә чаклы Гәүһәрнең күзенә чалынды микән? Хәер, нәрсә ул гөл, Гәүһәр күп нәрсәне күрми әле. Әйтерсең, аның күз алдына соры пәрдә корганнар.

Зәбирә апа белән Гәүһәр табын әзерли башладылар. Биш-ун минуттан өстәлгә аппак самовар да килеп кунаклады, башына кукраеп ак чынаяк чәйнек тә менеп утырды. Бераздан тып-тын бүлмәдә самовар җырлый башлады.

— Әттә генәсе,— диде Зәбирә түти,— менә ничек әйттерә. Гәүһәрем, ишетәсеңме?

— Ишетмичә.

— Һай, үзәгемне өзә. Һай, туктады. Я инде, тагын бер сайра. Я инде!

Гәүһәр дә бераз көтеп торды, ләкин самовар гүя үлгән иде, тавышы-өне чыкмады.

— Җыры өзелде,— диде ул, авыр сулап.

— Юк, Гәүһәрем, күңелдә ул сайрый.

— Син, Зәбирә түти, бик тә тормыш җанлы кеше икәнсең, мин сиңа карыйм да исем китә. Чын менә.

Зәбирә түти, тамак астыннан бәйләгән кызыл бөрчекле яулыгын чишеп, кайтарып, колак өстеннән артка бәйләде, күрәсең, эсселәгән.

— И Гәүһәрем, тапкансың ис китәрлек кеше. Дөрес, гомерем буе җебегәннәрне җенем сөймәде, әмма да үзем авызымда кош сайрата торганнардан түгел идем. Сездә энҗе чәчәк дип әйтәләрме? — дип кинәт сорады Зәбирә түти.

— Ландыш чәчәгенәме? Ишеткәнем бар.

— Бала чакта шул энҗе чәчәкләрне күп итеп җыярга ярата идем. Кай җирләре боларның чын энҗе икән дим. Тиле кыз шикелле, бер сәгать, ике сәгать карап утырам. Энҗене диңгез төбеннән җыялар диме?

— Шулай ди шул. Ә ни өчен энҗе чәчәк дип әйтүләрен белдегезме, Зәбирә түти?

— Юк, анысын белә алмадым. Сорасам да юк белән башны катырма, дип тиргиләр иде. Элек энҗе белән калфак чиккәннәр. Мин, үземчә, бу исемне калфакчы кызлар кушмадымы икән дип уйлый идем.

— Мин телче булмасам да, синең бу уеңда нәрсәдер бар шикелле, Зәбирә түти.

— Бармы, юкмы, мин шулай уйлый идем. Төбен казысаң, халык сүзенең мәгънәсе чыга торгандыр инде. Ләкин мин моны шуның өчен әйтәм: берсе белеп, берсе белмичә булса да күңелгә юаныч эзли. Нәрсә белән күңелеңне юатасың, анысы синең эш, диңгез төбеннән энҗе аласын килә икән, ал, әмма күңелең ачылгач, тирә-ягың кара булып күренми.

— Зәбирә түти, син, валлаһи, агитатор.

Зәбирә түти чынаягын биш бармагы белән тотып, эф-эф итеп өрә-өрә, чәй эчә иде. Гәүһәрнең сүзләрен ишеткәч, чынаягы чак түгелеп китмәде. Күзеннән яшь чыкканчы көлде дә, кулын селтәп:

— Үтердең, Гәүһәрем, Чатан Зәбирә агитатор булган дисәләр, тавыклар егылып көләр. Сайлауларда агитаторларны тыңламыйм дисәм, хата булыр, әмма башка чакта килеп әйтсәләр дә тыңларга вакытым юк. Минем сафсатам күбрәк чәй янында, капка төбендә яки кибет юлында. Яхшысын, яманын шунда ишетәм. Син әйткән энҗе бөртекләре шунда ялтырап китә инде.

Гәүһәр Зәбирә түтигә кинәт яктырып киткән күзләре белән карап торды. Ахрысы, озаграк булгандыр, Зәбирә түти моны сизеп:

— Гәүһәрем, күз нурыңны түгеп, миңа болай өздереп бакма. Мин булганымны да туганчы ук югалтып бетергәнмен,— диде.

— Юк, Зәбирә түти, мин сиңа юлыгуыма бик шатланам әле. Кулында энҗеле чәчәгең бар шикелле.

— Харап! Борынгылар әйтәләр иде: сүзең алтын булса, чат саен сипмә, кадере китәр, диләр иде. Мин, тиле башым белән, көчем җиткәнчә синең күңелеңне ачарга тырышам икән, бу әле бик кечкенә нәрсә, Гәүһәр. Зинһар, энҗеле чәчәкләр белән чагыштырма, кеше көләр... Син Зәбирәнең ләчтитен генә тыңлама, ашың да капкала, чәенә дә җитеш.

Икенче көнне Гәүһәр мәктәпкә ниндидер үтә бер җиңеллек тоеп барды. Классына да якты чырай белән керде. Хәзер инде ул ышанып әйтә ала: Яшел Яр мәктәбе чын шәһәрнекеннән бер дә ким түгел, аңардан бер ягы белән дә аерылмый. Гәүһәргә мәктәпнең иске бинасын да күрсәткәннәр иде. Кысан, караңгы. Анда яхшы укыту өчен үз эшеңне чиксез яратырга кирәк. «Безнең өлкән укытучыларның барысы да диярлек шул мәктәптән инде, Гәүһәр»,— диде Бибинур апа. Гәүһәр моны күз алдына китерергә тырышты. Аңа шул ук Яшел Ярда да, авылларда да иске мәктәпләр әле шактый икәнен әйттеләр, хәтта Гәүһәр үзе дә иске авыл мәктәбендә укыды. Шулай да Гәүһәргә бу борынгы авыл булып тоела. Ул борынгы сүзен кулланудан тартынмый. Аның арасы биш-ун ел белән үлчәнә икән, үлчәнсен, шулай да ул «борынгы» инде. Бу балаларны ул иске мәктәпләргә кертеп утыртып булмас иде. Алар яңа мәктәпләр өчен туган балалар!

Еш кына Гәүһәр үзен Казан мәктәбендә укыта кебек хис итә. Өряңа парталары да, зур кара тактасы да, якты тәрәзәләре дә — бары-

сы да андагы кебек. Хәтта балалар да андагы балалардан бер яклары белән дә аерылмый. Шундый ук зирәкләр, шуклар, үткеннәр, көлемсәрләр. Әлбәттә, Гәүһәр аерым-аерым аларның һәрберсенең исем-фамилияләрен хәзер белә, әмма еш кына, гомумән алганда, класс аңа шул Казан классы булып тоела. Бу, ихтимал, балалар белән якыннан танышып җитмәүдән дә килә торгандыр. Ул бары тик ике-өч баланың гына өендә булды. Бер экскурсиягә барганы юк, бер сәйранга чыкканы юк. Хәтта тәрәзә төбенә чәчәк китереп куйган баланың кем икәнен хәзер яхшы белсә дә, ул да гомумән балалардан аерылмый. Шул ук вакытта балалар аны берьюлы якын иткән. Әгәр Гәүһәр аларга озаграк игътибарсыз булса, балалар аңа аркан борылачаклар. Бала күңеле шундый инде, ул синең күңелеңдәге катлаулы хисләр белән исәпләшми, аларны аңламый да, ул укытучының күңеле дә, үзенеке кебек, беркатлы һәм саф дип уйлый. Дәрес, дәрес вакытында Гәүһәр үзенең шәхси тормышын онытып тора, ә мәктәптән чыгуга, кайчакта хәтта мәктәптән чыкмас борын ук Җәгъфәре исенә төшә. Аңа Җәгъфәр Яшел Ярга килгәндер, Зәбирә түти янында көтеп утыра торгандыр күк тоела. Өйгә кайтып кергәч, беркемне дә күрмәгәч, күңелсезләнә, кайчак Зәбирә түтидән: «Миңа хат юкмы?» дип сорый. Хат та булмагач, тагы да бигрәк күңелсезләнә. Бер-ике тапкыр хат булды булуын, ләкин Гәүһәр көткән хатлар түгел иде. Менә шуннан соң инде, ашагач-эчкәч, балаларның дәфтәрләрен карыйм дип, олы якка, гөлләр арасындагы өстәл янына килеп утыра да тагын дәфтәрләрен оныта, терсәгенә таянып, уйга чума, шулай сәгатьләр буенча кузгалмый.

Зәбирә түти өендәген тышка чыгарып йөри торган хатын булмаса да, сер өйдә бикләнеп ятмый. Әле еш кына тәрәзәләр ачык була, Гәүһәр бер нәрсә күрмәсә дә, балалар барысын да күрә бит. Аларның күзенә чалынган нәрсә илгә тарала. Бу — балаларның гайбәт яратуыннан түгел, балалар әле андый нәрсәдән өстен. Алар чын күңелдән һәм Гәүһәр апаларын аз гына кызгана төшеп сөйлиләр.

Ишек алдында Миләүшәнең күңелле тавышы ишетелде. Зәбирә түти аңа нәрсәдер пышылдый башлады.

— Ярый, ярый, Зәбирә түти, калганын үзем беләм,— дип ул өйгә керде, включательнең кайда икәнлеген белгәнгә, үрелеп ут кабызды.— Нишләп тагын караңгыда утырасың әле, акчаңны кызганасыңмы? Берәү ут яндырмый торып, таш пулат салган, ди.

Миләүшә яңгыравыклы тавыш белән көлеп җибәрде, аңа кушылып, иреннәре белән генә Гәүһәр дә елмайды.

— Зәбирә түти, моның пәриләре юкмы, күрмәдеңме? Пәриле кешеләр генә караңгыда ялгыз утыралар, ди.

— Әй, Миләүшә, тел очыңда безең икән,— диде Зәбирә түти, чатанлый-чатанлый кече якка узып.— Хәзер самовар өлгертеп җибәрәм. Әзрәк сөйләшә торыгыз.

— Сөйләшергә дисәң, безне көмәч белән дә сыйлама, Зәбирә түти.

— Күмәчем юк әле, Миләүшә. Башка берәр нәрсә генә тапсам.

— Ярар, безгә кыстыбый булса да ярый. Волейбол уйный-уйный тәмам ачыгып беттем, өйгә кайтып җитәрлек тә хәлем калмады. Ә син, Гәүһәр апа, шундый кичтә өйдә утырасың. Мин әле сине чакыртырга дип кеше җибәрергә дә уйлаган идем. Күршеңдә шундый спортплощадка булгач, ничек инде өйдә утырырга кирәк. Әле менә өлкән класслар белән баскетбол оештырырга йөрибез. Физрук бераз авырып эшне бозды.

— Син барында физрук нигә? — диде Гәүһәр, көлемсерәп.— Синең кебек уйнаучыны барыбер табалмаслар.

— Юк, мин Вилданны тәкъдим иттем. Син химия укытучысы Вилданны беләсеңме? Гаҗәп оста спортчы.

— Синең кебек оста булмастыр инде.

— Юк, мин аның янында өйрәнчек кенә.

— Аңлыйм,— диде Гәүһәр, иренен аз гына кыймылдатып,— кайбер кызларны Кама буена төшеп җыларга мәҗбүр итә ала икән, яхшы уйный торгандыр.

— Әттә генәсе, Гәүһәр апа, синең күзең шундый очлымыни әле. Белмәгәнмен, телемне тыйган булыр идем.— Ул, Гәүһәрне муеныннан кочып, бик озак көлде.

— Менә чәй булды,— диде Зәбирә түти, олы якка чыгып табын җәя башлады.— Бик чынлыйсың, Миләүшә, хәерлегә булсын.

— И-и, инде, Зәбирә түти, син дә күрдең. Сезгә килеп шаярырга да ярамый, хәзер Чатыргали абзый чатына боралар.

— Без Чатыргали чатына борсак та, син үзең башка бер чатны сайлыйсын бугай. Рәхим итегез, утырышыгыз.

Бик күңелле итеп чәй эчә башладылар.

— Сез инде минем болай вакытлы-вакытсыз килеп чыгуым өчен гаепләмәгез,— диде Миләүшә.— Гәүһәр апа булганга гына шулай. Баярак Бибинур апаны күргән идем. Ул да Гәүһәр апаны сорашты, үземнең дә ничә көн инде яхшылап күргәнем юк. Аннары мин бит ялгызак кеше, кайчан исемә төшә, шунда чыгам да китәм. Туктатыр кешем юк.

— Бу эшеңә, Миләүшә, рәхмәт кенә әйтәм,— диде Зәбирә түти.— Ләкин Кама суы кирегә акмый. Күреп алырлар үзеңне.

Зәбирә түти Миләүшәнең үзе турында сөйләшәсе килгәнлеген төшенеп алган иде инде. Хисләре ташыганда кеше тын утыра алмый, кыбырсый.

— Шулайрак шул, Зәбирә түти,— диде Гәүһәр.

— Харап, икегезнең ике яктан кысрыклавын белсәм, өемнән чыкмаган булыр идем.

— Юк, Миләүшә, кыртлый торган тавыкны караңгыга япсаң да кыртлый ул. Син инде өйдә бер үзең утыра алмагансың... Кызарма, була торган хәл, син генә башламаган, син генә бетермәссең дә.

— Ә синең шундый чагың булдымы, Зәбирә түти?

— Булгандырмы, юкмы, минем башымнан җилләр искән инде, Миләүшә. Үткәнгә кайтсаң да чыгар җирен таба алмыйсың. Синең бәхетең менә алда, буласы әле. Гәүһәр дә бик чынаягына карамасын иде. Кешенең күңеле кайчак, самавыр кебек, бер дә көтмәгәндә сайрый башлый.

Миләүшә өйне яңгыратып көлеп җибәрде.

## 5

Галимҗан абыйны Яшел Ярда көтмиләр иде, ә ул алдан хат та язмыйча, телеграмма да сукмыйча тотты да килеп төште. Пароходны каршы алучыларның ыгы-зыгысына артык игътибар бирмичә, чемоданнарын күтәреп, пристаньнан чыкты, аннары ашыкмыйча гына тау башына менә башлады. Бу җирләр аңа беркадәр таныш иде. Бибинур монда күчеп эшли башлагач, ул бер-ике тапкыр килеп китте. Шуңа күрә телеграмма да биреп тормады. Телеграмманың үзенә күрә мәшәкате була, әзерләнергә кирәк, ә Бибинурның моңа вакыты бармыни. Директорның эше муеныннан, ул күптән инде мәктәптәдер, шунын өстенә сәгатьләре дә бар бугай. Ял итә-итә барып җитәр, урамын, йортын бик яхшы хәтерли, үзәктән ерак түгел.

Көн болытлы. Көзнең матур бизәкләре тоныкланган сыман. Тагын бер ун көн һавалар бозылмаса, яхшы булыр иде дә, вакыт үзенекен итә. Октябрь башы бит. Кайчак октябрьда һавалар матур гына торса да күп елларны бу ай куандырмый, яңгырлары, салкыннары үзәккә үтә.

Тау башында Галимҗан абзый әзрәк ял итте, кул яулыгы белән маңгаен, муенын сөртте, ни әйтсәң дә, йөрәк хәбәр бирә икән, кара

ничек кага. Фу, шайтан алгыры, Галимҗан болай ук дип уйламаган иде. Юк, бу күптән җәяү йөрмәгәнгәдер. Заводта эшләгәндә Галимҗан күбрәк бинада була, ял алдыннан кичләрен дә әзрәк калырга туры килгәләде. Ярар, үтәр әле, һавалар яхшы торса, Яшел Ярда әзрәк йөрер, су буйларына да төшәр, кара нинди иркенлек монда, махсус ял итәргә килгән кебек. Галимҗан абый елмайды, йөрәк турындагы күңелсез уйлар каядыр артка чигенде. Кирәкми аларны искә төшерергә, югыйсә очрашу шатлыгы да шатлык булмас.

Галимҗан абзый, чемоданнарын күтәреп, тагын кузгалды. Яр кыреennан бераз баргач, коры елга аркылы салынган күперчеккә керде. Дөресрәге, бу күперчек тә түгел, ике-өч такта киңлегендәге басма гына. Үзе бик озын, ике йөз метрлар булмагае. Аяк атлаган саен сыгыла. Яшьләр, билгеле, мондый басманы санга да санамыйлар, йөгерәләр дә үтәләр, карт кешегә әзрәк сакланырга кирәк. Дөрес, чокырның урта бер җирендә генә биш-алты адымлык су бар, калган җире коры, шулай да аска карамау яхшырак, я башың әйләнеп китәр. Иң яхшысы — елга аръягындагы шәһәргә карап атлау. Бу басма үткәннәрне хәтерләтә. Моннан унбиш еллар элек, Бибинур беренче тапкыр Яшел Ярга килеп укыта башлагач, Галимҗан да хәл белергә дип килде. Галимҗан ул вакытта күрше районда райком секретаре булып эшли иде. Райком секретаренең көне юк, төне юк, Бибинур янына килергә ничек вакыт арттыра алгандыр, ул кадәресе хәзер онытылган инде. Хәер, ул вакыттан бирле байтак сулар аккан булса да, Галимҗанга бер нәрсә дә үзгәрмәгән кебек. Менә басма... Басма ул чакта ук бар иде. Ихтимал, ул пристань салынганнан бирле торадыр. Басманы аркылы чыкканда Бибинур кинәт кычкырып җибәрде. Галимҗан алдан бара иде, артына борылса, ни күрсен: Бибинур котлары очып чүгәләгән дә ике кулы белән башын кысып тоткан. Аны тынычландыру, елга аръягына алып чыгу бер бәла булды. Хәер, Бибинурның ул чак кайгылы вакыты иде шул: сугыш юлларын үткән ире, бер дә авырмыйча, урамда барган җирендә йөрәге ярылып үлде. Ихтимал, шул нәрсә аның бөтен көчен суырган булгандыр. Басмадан чыккач та, чигәләрен кысып, Бибинур байтак вакыт стенага сөялеп торды...

Галимҗан абый басманы аркылы чыкты да бик борынгыдан калган, заманында, мөгаен, ниндидер бер крепостьның почмак корылмасы булган башняга карап барды. Су бик күп булган кайсыдыр елны ташкын шул башняның яртысына җиткән, диләр. Галимҗан артына борылып карады: о-о! Басма бит бөтенләй су астында калган булган!

Үзәк урамга борылгач, Галимҗанның күңеле күтәрелеп китте. Бүген гади бер көн булса да, урамда халык шактый күп икән. Аларга инде мондагы яңа биналар да, кибетләр дә «күптәнгеләр» булып тоела, әнә берсе дә борылып карамый, гүя шулай кирәк, шулай күптән булган. Элек атлар белән тулган урам бүген автомобильләр белән тулы икән, аларга бу да бик табигый кебек, һәрхәлдә, берсенең дә исе китми. Райком шунда ук икән, тик элек аның бакчасы юк иде бугай, әллә булып та яңа утыртылган идеме, хәтердә калмаган. Хәзер райком бакчасы бик нык үскән, җәен ике катлы бина бөтенләй күренми торгандыр инде. Ә менә больница һаман иске, ишек алдына гына яңа биналар салганнар, ахрысы, элек болары юк иде шикелле...

Бибинур өйдә икән, Галимҗан капканы ачып ишек алдына кергәч, Бибинур йөгереп каршы чыкты, абыйсы белән кочаклашып күреште.

— Абый, нишләп телеграмма бирмәдең, каршы чыккан булыр идек. Рәхимә апа, кызлар исәннәрме?

— Миннән исән калдылар, сезгә йөге белән сәлам тапшырырга куштылар.

— Рәхмәт, сәламәт булсыннар.

— Галимҗан абый! — Гөлназ ишектән йөгереп чыкты да абыйсының муенына асылынды. Ул әнисе белән җәй көне генә Казанда булган, абыйларында торган, шуңа күрә Галимҗан да, аның өй халкы да аңа бик якын, барысын берәм-берәм сораштыра башлады.

— Тукта әле, Гөлназ, абыйны өйгә алып керик, күрәсең, ничек тирләп пешкән. Әйдә, абый, өйгә рәхим ит. Абау, ничек күтәрдең бу чемоданыңны?..

Өй ике бүлмәле, шактый иркен. Гөлләр бик күп, түр як стена рәсемнәр белән бизәлгән, идәннәр сары итеп юылган. Кечкенә өстәлдә дәфтәрләр, китаплар. Монысы инде Бибинурныкы. Гөлназ әнә зур өстәлдә дәрес әзерләп утырган. Ачып куелган дәреслекләре дә шунда. Өй бераз салкынча, тышта җылырак бугай, ихтимал, ике чемодан күтәреп килгәнгә шулай тоелгандыр.

Галимҗан эшләпәсен, пальтосын салып ишек төбендәге чөйгә элде дә йөзен җиләтә башлады.

— Тәмам тиргә батканмын икән,— диде ул, елмаеп.— Соң, ничек торасыз, исәнлек-саулыкмы?

— Бик шөкер, абый. Акылымны җыя алмыйм әле, ничек безнең якларга килеп чыгарга булдың? Юл өсте дә түгел бит.

— Килергә уйласаң, бөтен җир юл өсте була, Бибинур. Менә сезне исән-сау килеш күргәч, тәмам тынычландым әле.

Гөлназ мич каршында самовар куеп йөри иде инде. Бибинур үзе яңарак кына мәктәптән кайтып кергән, ике сәгатьтән тагын барырга җыена, бүген өлкән класс укытучыларының җыелышы.

— Абый, пароходта ничек килдең, тынычмы?

— Бик тыныч. Гомумән, су өстендә килүләре рәхәт икән, Бибинур, сулышлар киңәеп китә. Минем инде күптән пароходта йөргәнем юк иде, утыруыма бер дә үкенмәдем. Рәхимә болай борчылган иде борчылуын.

Чәйне бик иркенләп эчтеләр, бик күп сөйләштеләр.

— Я, яңа укытучыгыз ничек? Иләшәме? — дип сорады ахырдан Галимҗан абый.

— Болай иләшеп килә шикелле... Ләкин монда зур кала түгел шул, зур кала кешеләренә авыррак. Гәүһәр дә һаман сагышлана, һаман борчыла да уйлана.

— Әни, мин мәктәпкә киттем,— диде Гөлназ, икенче бүлмәдән бөтенләй киенеп чыгып.— Галимҗан абый, син әзрәк ял ит. Мин кичке сменада.

— Борчылма, Гөлназ. Мин монда хуҗа кеше, нишләргә кирәген белермен.

— Гөлназ, Гәүһәр апаңны күрсәң, абый турында әйт әле. Мин барганчы аның кайтып киткән булуы мөмкин.

— Ярый, әйтермен.

Гөлназ чыгып киткәнче сүз өзелеп торды, аның артыннан капка ябылуын ишеткәч, Галимҗан абый тагын өзелгән сүзне ялгады.

— Сагышлана, борчыла дисеңме?

— Әйе, абый. Яшь кеше дә. Монда бит, үзең беләсең, күңел ачар җир әллә ни юк.

— Дуслары да юкмы?

— Бу арада гына тапмагандыр әле. Миләүшә белән генә әзрәк сүзләре килә бугай.

— Кем ул Миләүшә?

— Бер укытучы, математикадан. Болай яхшы кеше ул, тик яшьрәк, кыз кеше, тормышны да белеп бетерми бугай.

— Ул Миләүшә кем белән тора, монда әти-әниләре бармы?

— Юк, ул бөтенләй башка районнан. Монда бер апада квартирда тора.

— Алай икән... Гәүһәр үзе кайда тора?
— Мин язган идем бугай. Ерак түгел, бер апада тора. Ялгызак кеше.
— Шулай шул, боларын язган идең. Алай-болай үзгәрешләр юктырдыр бит?
— Юк, абый.
— Казанны сагынамы?
— Болай әйтми әйтүен дә, сагына бугай. Зәбирә түти дә гел уйланып утыра, ди, Миләүшә дә. Үзем дә күрәм.
— Шулай...
Алар икесе дә уйга калдылар, ләкин Гәүһәрне күреп сөйләшмичә бу уйларның очына һич ничек тә чыгарга мөмкин түгел иде. Кеше күңеле караңгы, диләр. Бу очракта, ихтимал, тагын да көчлерәк сүз кулланырга кирәктер, чөнки Гәүһәрнең чын уйларын бераү дә белми, ә аның сагышлануы, борчылуы бары тик күңелендә нәрсәнеңдер үсүен генә сөйли. Күрәсең, ул аерылса да үзен аерылдыга санамый. Бу бик авыр хәл. Галимҗан абый Җәгъфәрнең өйләнергә йөрүен сөйләргә теләгән иде, болай булгач, сөйләмәү хәерлерәк булмасмы икән? Һәрхәлдә, ашыкмаска кирәк, югыйсә каш ясыйм дип күз чыгарырга мөмкин.
— Кара әле, Бибинур, күрешү шатлыгыннан мин бөтенләй онытып та торам, менә монда Рәхимә сезгә күчтәнәчләр җибәргән иде бит,— дип, ул кечкенәрәк чемоданын ачып аннан өстәлгә төрле ашамлык әйберләр куя башлады.
— Нигә инде шул хәтле мәшәкатьләнергә, әйтерсең, монда юк,— диде Бибинур, күчтәнәчләрнең күплегенә гаҗәпләнеп.
— Картлар гадәте, Бибинур, без генә аны үзгәртә алмабыз.— Галимҗан елмайды.— Менә чемодан да бушады. Монысын Рәхимә Гәүһәргә җибәрде. Чәкчәк бугай. Менә бу чемодан да Гәүһәрнеке. Ул бит кышкы киемнәрен берсен дә алмаган иде. Монда кыш суык була торгандыр.
— Була инде,— диде Бибинур өстәлдәге әйберләрне кухняга ташый-ташый.— Без бит мәктәпне җылыту турында гына кайгыртабыз, урам безнең эш түгел.
Бибинурга кушылып Галимҗан да елмайды. Тышта кар яумас борын салкыннар турында сөйләве бераз сәеррәк тә, нишлисең, кыш киләчәк бит.
Ишек алдында капка ачылган тавыш ишетелде. Гөлназ Галимҗан абыйның килүе турында Гәүһәргә әйткән булса кирәк, әнә атлыгып килеп тә җитте. Күрәсең, бик кызу килгән, яңаклары тәмам кызарып чыккан. Чәче дә бераз тузгыган. Һәрвакыт бик пөхтә йөрүче Гәүһәргә бу килешеп тә бетми, әмма үзе моны сизми булса кирәк. Өй алдында ул бераз туктап торды, күрәсең, өстен-башын рәтләде, сулыш алды. Аннары ишек ачылды.
— Галимҗан абый! — дип кычкырып җибәрде Гәүһәр һәм кул биреп бик җылы күреште. Аннары Бибинур белән дә исәнләште. — Гөлназ әйткәч, ышанмый торам. Галимҗан абый, ничек безнең шәһәргә килергә уйладыгыз?
— Мин, Гәүһәр, озак уйламадым, тоттым да килдем,— диде Галимҗан, елмаеп.— Бибинур, Гөлназ һәм син булгач, миңа тагын кем кирәк?
— Гәүһәр, әйдүк өстеңне сал, иркенләп утыр. Миңа мәктәпкә барырга вакыт. Менә хәзер самовар кайнап чыга, Галимҗан абыең белән сөйләшә-сөйләшә чәй эчәрсез.
— Галимҗан абыйның тамагы тук булса, минем өчен артык борчылмагыз, Бибинур апа,— диде Гәүһәр өстәл яңарта башлаган Бибинурга.

— Чәй зарар итми, Гәүһәр,— диде Галимҗан абый, көлеп.— Син, Бибинур, кичегә күрмә.

Бераздан табын әзерләп, кайнаган самоварны да өстәлгә утыртып, Бибинур мәктәпкә китеп барды. Ул гүя яшәргән, хәрәкәтләре шундый житез, йөреше шундый кызу, әйтерсең, кыз чагы, хәлбуки ул шактый юанайган, чәче дә ап-ак агарган. Әле беренче күргәндә үк бу ак чәчләр Галимҗанның йөрәгеп өткән иде. Тора-бара ул бу турыда бөтенләй онытты, ихтимал, яшь Гөлназның монда булуы да тәэсир иткәндер. Болай оялчан күренгән Гөлназ үзе иялэшкән кешеләр арасында ул бик чая. Галимҗан да шуның өчен аны ярата.

— Я, Гәүһәр, ничек торасың соң? — диде Галимҗан чынаякларга чәйләр ясап, берсен кунак алдына да куйгач.— Я әле, эчеп җибәр. Мәктәптә көне буе сөйли-сөйли тамагың кибеп беткәндер.

— Без өйрәнгән инде, Галимҗан абый. Тормышым шулай бер төрле, әллә ни мактанырлыгым юк. Эшемнән канәгать.

— Анысы иң мөһиме, Гәүһәр.

— Үзем дә шулай дип торам. Югыйсә, болай пошынган чакларым да, сагышланган минутларым да була. Коллективка зарлана алмыйм, барысы да ачык чырайлы, ягымлы, кырын караучыны күргәнем юк. Билгеле, яңа кешегә тәмам ачылып бетмиләрдер, үзем дә шулайрак.

— Квартираң ярыйсымы?

— Бибинур апага бик зур рәхмәт, яхшы кешегә урнаштырды, үзем, билгеле, тиз генә тапмас идем.

Шуннан Гәүһәр Казан турында сорашты. Галимҗан белгәннәрен бик теләп сөйләде. Гәүһәр үзенең классы турында да сорашты. Галимҗан бу кадәресен, билгеле, белми иде. Тик Шәриф Гыйльмановичны бернична тапкыр урамда күргән, Рәхимә дә аны бер көнне киңәшмәдә очраткан. Классында балалар Гәүһәр апаларын бик сагыналар, ди, укытучылар да әледән-әле телгә алалар икән.

— Ә кемне укытучы итеп алганнар? — дип сорады Гәүһәр.

— Педучилищедан бер яшь кенә укытучы, ди. Мин аны белмим, Шәриф Гыйльманович та аның турында күп сөйләмәде.

Шуннан соң сүз әкренләп Галимҗан абыйларның семья тормышларына күчте. Рәхимә апа турында, кызлар турында Гәүһәр күп сорашты, аннары гомуми тормышка да кагылдылар. Тормышлар болай күркәм генә, кибетләрдә азыгы да, промтовар әйберләре дә күп. Билгеле инде, Галимҗан үзе кибетләргә еш чыгып йөри алмый, көннәре һаман заводта үтә.

— Дидаров һаман да баш инженермы? — дип сорады Гәүһәр, аска карап.

— Хәзергә ул. Дөрес, бер шелтә бирделәр.— Һәм бу турыдагы әңгәмәне дәвам итмәс өчен булса кирәк Галимҗан урыныннан торып чемоданын алып килде.— Менә монысы сиңа Рәхимәнең һәм кызларның бүләге, нәрсә куйганнардыр белмим, үзең карарсың.

— И-и, рәхмәт инде, нигә борчылганнар.

— Ә болары, Гәүһәр, синең җылы киемнәрең.

— Минем кышкы киемнәрем? Каян алдыгыз? Мин сездә бер нәрсә дә калдырмаган идем бит.

— Мин юк чакта Җәгъфәр килгән булган, ул китергән... Үзең алмагач, мин аптыраштa да калган идем, Рәхимә апаң ике аягымны бер итеккә тыкты, үзе китереп биргәч, каршы торалар диме. Гәүһәр бер кышкы кием алып китмәде, ди. Аннары бу киемнәр закон буенча да синеке, Гәүһәр.

— Кирәкмәс иде алырга,— диде Гәүһәр, зәгыйфь кенә каршы килеп. Һәм башын иеп аска карап торды, әллә күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышты инде. Бераздан башын күтәрде, үзе Галимҗанга туры карамыйча,— Җәгъфәр ничек тора соң? — дип сорады.

Бу тавыш, бу сорау Галимжанга күп нәрсә сөйләде: Җәгъфәрдән күңеле суынмаган икән, ул аны гафу иткән, хәтта барысын да онытырга да әзер! Галимҗан аптырап калды. Ул моны бик үк аңлап та җитми, күрәсең, хатын-кыз күңеле бик четерекле. Бибинур белән сөйләшкәндә үк Гәүһәр белән саграк булырга кирәк, дигән карарга килүе бик дөрес булган. Хәзер моның никадәр мөһим икәнен Галимҗан тирәнрәк аңлады.

— Күптән күргәнем юк инде аны, Гәүһәр.

— Заводыгызга йөрмимени?

— Быелгы укулар әле башланмаган. Аннары быел политэкономия булмас та дип сөйлиләр.

— Өйләнмәгәнме соң? — дип сорады Гәүһәр, үз соравыннан үзе курыккан кебек.

— Ишетелмәде...— диде Галимҗан бераздан.— Андый хәл булса, ишетелми калмас иде,— дип өстәде.

Гәүһәр башын түбән иде. Бусы әле яхшы булды, югыйсә Галимҗанның уңайсызланып кызаруын күрер иде. Гомумән сер яшерү авыр икән, гомер буе турысын сөйләргә күнеккән кешегә бигрәк тә. Ләкин, ни хәл итәсең, тормышның шундый яклары да бар. Гомумән хатын-кыз белән мондый темага сөйләшүе авыр. Рәхимә монда булса, барысын үз өстенә алыр иде дә, укыта шул ул хәзер.

Галимҗанны бер нәрсә борчыды, аерылган булса да Гәүһәр үзенен элекке ирен онытмый икән. Ә Җәгъфәр аны ничек кенә хурламады. Билал Шәнгәрәевны да, артист Алчынны да нәфрәтләнеп телгә алды. Ул чакта Галимҗан абый Гәүһәр берәр нәрсә яшермиме дип тә уйлаган иде әле. Ә хәзер ул Гәүһәрнең күңелендә бары тик Җәгъфәр генә булуына тирәнтен ышанды. Менә шул кешенең, өйләнүен ишетсә, Гәүһәр ничек түзәр? Билгеле инде, Галимҗан абыйның да алдашуын аңлар. Әллә әйтергәме? Юк, хәзергә, һәрхәлдә, әйтмәскә кирәк. Рәхимә дә шулай дигән иде, ә хатын-кыз мондый чакта бик акыллы сүз әйтә. Менә Бибинурга сөйләргә кирәк булыр...

## 6

Мәктәп Гәүһәрне көннән-көн үз эченә күбрәк тарта бара. Баштарак, бигрәк тә килгән атналарында, ул үз алдына, мәктәп, балалар үз алларына яшиләрдер дип уйлый иде, Гәүһәрнең шәхси кичерешләрендә мәктәпнең, укучыларның һәм укытучыларның ни эшләре булсын да, алар ни өчен моны йөрәкләренә якын итеп алсыннар. Алар нәкъ тимер юл рельслары кебек, бер вакытта да кисешәчәк түгелләр. Күрәсең, ул бик нык ялгышкан, күпме торып та тормышның чын табигатен белмәгән. Аерым кешенең эч серләре коллективта сер булып калмый, тик берәү дә Гәүһәргә нинди булса гаеп тагарга җыенмый иде бугай. Ул моны бик ачык сизде. Баштарак, монда нәрсәдер бар, бу болай булмаска тиеш, дип тә йөрде. Бөтен бер коллективны гамьсезлектә гаепләмәссең бит, ир белән хатын мәсьәләсе һәр җирдә, бигрәк тә мәктәптә кискен тора, монда яшь буын яңа әхлак үрнәкләрендә тәрбияләнә, аларга бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләп булмый.

Тыштан караганда бу нәрсәләргә Галимҗан абыйның бөтенләй катнашы юк иде шикелле. Килде, хәл белде, сөйләште, Гәүһәрнең аругына урнашуы өчен күңеленнән шатланды. Кыска гына итеп әйткәндә, менә шул, күп түгел дә шикелле. Ул киткән чагында Гәүһәр, Бибинур апа, Гөлназ һәм тагын берничә укытучы аны озата төштеләр. Уен-көлке сүзләр арасында Галимҗан абый:

— Мин шактый тынычландым, Гәүһәр,— диде.

Гәүһәр моңа каршы бик мәгънәле итеп аһ! дип кенә җавап бирде. Галимҗан абый дус итеп аның иңбашына кулын гына куйды. Ләкин

Галимжан абый булып ул да хатын-кызның күңелен белеп бетерми иде. Хатын-кыз бер нәрсәне сизенсә, шуны анык төпченмичә тынычланмый. Гәүһәр Галимжан абыйның икелерәк җавап бирүеннән Җәгъфәрнең өйләнергә нияте барын сизеп алды. Шуннан Казандагы бер дустына хат язып Җәгъфәр турында сорады. Ара якын булса да, хат юлы шактый ерак икән. Нигәдер, җавап тиз генә килмәде. Хат язгач, Гәүһәр дә бераз тынычланды булса кирәк. Аннары көндәлек эшләр өелде, вакыты бөтенләй җитенкерәми башлады. Бер тапкыр балалар белән экскурсиягә дә барып кайттылар. Экскурсия табигать кочагына — яр буйларына иде. Бу вакытта инде октябрь ае бетеп бара. Көзнең соңгы бизәкләре генә анда-санда калган. Җил дә ярыйсы салкын, болытлар да түбәнтен генә агыла, көт тә тор, бүген-иртәгә кар явар. Шулай торганда көз тагын ялтырап китте. Шуннан файдаланып, Гәүһәр балаларны яр буена алып төште. Балалар шулкадәр шатланырлар дип ул башына да китермәгән иде. Нәкъ кәҗә бәтиләре кебек сикерешәләр! Ул күңелле шау-шу, ул ыгы-зыгы — сөйләп тә бетерерлек түгел, әйтерсең, Мәскәү яки Ленинградка баралар. Сөйләшүләре тагы! Болай карасаң, билгеле, аларда эзлеклелек юк, алар күз ачып йомганчы бер темадан икенчесенә сикерәләр, берсе башлаганны икенчесе бүлдерә, гүя аның әйтергә теләгәне кызыклырак та, мөһимрәк тә. Яр буена төшкәч, алар гүя бөтенләй бәйдән ычкынды, әй чабалар, әй йөгерәләр, көләләр, төрле яфраклар, ташлар табалар, су өстендә килгән көймәләрне, баржаларны бер-беренә күрсәтәләр, ниндидер кызык күрәләр, укытучыдан минут саен сораштыралар, тегесе нигә алай да, монысы нигә болай... Гәүһәр аларга җикеренми, юк белән башымны катырмагыз дип кул селтәми, гүя ул үзе дә балага әверелгән, һәммәсенә җавап бирә, күз иярмәс тизлек белән бер темадан икенчесенә сикерә, һәммәсен күрә.

Табигать кочагында бала үзен бик табигый сизә, рухына богау юк, уе гаҗәп тиз эшли. Сүзләрне күбесен әйтми калдыра. Гәүһәр бер вакытта да балалар арасында түземсезлек яки канәгатьсезлек күрсәтмәде. Мәгълүм булганча, укытучылар балаларны бер үк вакытта укырга да, уйларга да өйрәтәләр. Тәҗрибәле укытучылар бу эшкә беренче класстан ук тотына. Башта баланың зиһене таралып тора. Укыганда ул аңлап укымый, чөнки бер үк вакытта укырга һәм уйларга өйрәнмәгән. Шул ук хәл язган чакта да кабатлана. Баланың бөтен игътибары хәрефләр язуга, хәрефләрдән сүзләр оештыруга китә, ә нәрсә язганын уйларга вакыты да калмый. Йөзе, кулы киеренке, маңгаенда бөрчек-бөрчек тир тамчылары.

Бәхеткә каршы, элекке укытучы Ламига Гәүһәр классында балаларны беренче класстан ук укый-укый уйларга, уйлый-уйлый укырга, язарга өйрәтә башлаган булган. Гәүһәр шул уңышлы башлангычны дәвам гына иттерде. Дәрестә дә, менә бүгенге кебек су буена чыкканда да балаларның менә шул сыйфатын яхшырак үстерергә тырышты: бала кечкенәдән үк катлауланганнан катлаулана барган шартларда эшләргә күнексә, соңыннан, өлкән классларда, бигрәк тә югары уку йортына кергәч, аптырап калмый, чөнки фәнни эшнең элементлары аңа ят түгел инде.

Билгеле, балаларны яшьләреннән өлкән итәргә ашыкмаска кирәк, бу файдасыз. Гәүһәрнең укучылары бик күп яфрак җыйдылар, кайсыберләре гаҗәп матур чәчәкләр табып китерде, ташлар, күбәләкләр алып кайтучылар да булды. Һәрберсе китергән әйберсенең матурлыгын сөйли, шуны таба алуы белән горурлана. Гәүһәр барысын карады, балалар аңлардай итеп аларның үзенчәлекләре турында сөйләде, укучыларны тагын да кызыксындырды.

— Көзен йомып йөргән кеше генә бер нәрсә дә абайламый, кызыксынган кешегә табигать бар серләрен дә ача, балалар.

Сүз арасында Гәүһәр яр буйларына карап-карап алгалады: бу тирәләр аңа бик таныш. Менә монда ул беренче тапкыр рәсем ясаган, менә монда Миләүшә белән утырып елаганнар иде. Гәүһәр бик дөрес сизенгән булган: Миләүшә муеннан гашыйк! Ул чакта Гәүһәр, билгеле, белми иде әле, хәзер инде Миләүшә дә сер сакламый: ул шул ук мәктәпнең химия укытучысы Вилдан Зәйнуллинны ярата.

— Мин шулай булыр дип бер дә уйламаган идем, Гәүһәр апа,— диде бер көнне Миләүшә, уйчан гына.— Бик куркыта да, күңелгә төрле уйлар да килә, ә үзем шул Вилданга тартылам. Белмим, нәрсәсе белән тарта торгандыр инде бу Вилдан. Карап торырга бер нәрсәсе дә юк кебек.

Кызык, Миләүшә инде җырламый, көлми башлаган иде. Сагыш һәм моң аңа шулай ук ятышмый. Ләкин мәхәббәт нишләткән аны! Тик ни дип әйтергә инде аңа? Юату яки акыл бирү — файдасыз, Миләүшә барыбер тыңламаячак, дөресрәге, тыңлый алмаячак. Аннары бу яктан Гәүһәрнең үз хәле хәл: ул теләсә дә әллә ни әйтә алмаячак.

— Яратасыңмы соң, Миләүшә? — дип сорады ул.

— Әллә тагы... Шулай юләрләнгәч, ярата торганмындыр инде.

Бәйрәм алды көннәрендә Гәүһәр, ниһаять, Казаннан хат алды. Иптәше аны онытмаган, язмый торуының сәбәбе башкада булган. Хәзер барысы да ачык: Җәгъфәр өйләнергә җыена, бәйрәм араларында туйлары булырга тора ди. Җәгъфәр Исрафил Дидаровның балдызы Фаягөл Идрисҗанованы ала!

Хатны укыганнан соң, Гәүһәрнең башына күсәк белән суккандай булды. Җәгъфәрнең өйләнүе турындагы хәбәр никадәр җан өшеткеч булса да, Гәүһәр аны йөрәге белән көтә иде. Әмма Фая Идрисҗановага өйләнүе, Фаяның кайчан да булса Гәүһәр торган бүлмәләрдә тора башлавы, Гәүһәр ачып кергән ишектән керүе, ул утырган машинага утыруы, Гәүһәр торган дачада яшәве, Идел буена чыгып, кечке суга карап торулары — монысы инде аның башына да килмәгән иде. Коточкыч сизенүдән Гәүһәрнең сулышы капты: болар барысы да шул Исрафил Дидаровның эше түгелме? Әйе, әйе! Монда аның кулы уйнаган булса кирәк. Кем белә, бәлки Гәүһәр белән Җәгъфәрнең аерылуында да аның роле бардыр әле, Җәгъфәр янына килеп йөрүләре бер дә бушка булмагандыр. Гәүһәр генә теге вакытта моны сизмәгән.

Гәүһәрнең күлмәгенә, әйтерсең, ут капты. Ярый әле бу хәл өйдә булды, ярый әле, аңа бер нәрсә дә эшләргә кирәкми иде, югыйсә Гәүһәр кузгала да алмас иде. Гаҗәпләнүдән хәтта елый алмады, шулай һичбер хәрәкәтсез-нисез үз бүлмәсендә утыра бирде. Зәбирә түти белән үз хәлләре турында ул сөйләшми, киңәшми иде. Күпмедер шулай өнсез торгач, «Җәгъфәр нинди тозакка эләккәнен белмимени соң, ул томана сукырмыни соң?» дип уйлады ул һәм тиз генә киенә башлады, аннары кухняда мич алдында нәрсәдер эшләп маташкан Зәбирә түтигә:

— Мин Бибинур апаларга барам әле, Зәбирә түти,— диде һәм ашыгып чыгып китте. Урам инде караңгы, аяк асты пычрак. Октябрь ахырларында һәм ноябрь башларында һавалар ару гына торса да, көз көзлеген итте: бер көн эчендә көн бөтенләй үзгәрде, салкынайтып җибәрде, яңгыр аралаш кар очкалый башлады. Менә хәзер дә күктә каракучкыл болытлар агыла, йөзгә салкын дым да кагыла. Иртәгә чынлап торып кар явардыр.

Гәүһәр бик ашыкты, шуңа күрә, ахрысы, суыкны да тоймады. Өй ышыгында ул хәтле җил булмаса да, Бибинур апаларга барып җиткәнче ката язды. Капкадан кергән чагында гына аңлады: ул тыштагы салкыннан бигрәк эчтәге салкыннан туңа икән. Бибинур апасына ул ни әйтер икән? Ничек сүз башлар? Бибинур аның хәлләрен бераз

белсә дә, бөтенесен белми бит. Аны тагын никадәр бимазалау булачак. Ләкин Гәүһәр кемгә барсын да, кемнән киңәш сорасын?

Бибинур апа кичкенә өстәл янында дәфтәрләр карап утыра иде. Гөлназ әле мәктәптән кайтмаган, күрәсең. Бәлки, комсомол җыелышларыдыр.

— Абау, Гәүһәр, төсләрең киткән, хәлең бармы? — диде Бибинур, бик борчылып. Аннары Гәүһәрне кулыннан тотып өстәл янына китереп утыртты. Ихтимал, монда аны башкачарак каршы алсалар, ул әле үзен тыеп калган булыр, күз яшенә артык ирек бирелмәс иде. Бибинур апа шулай йөрәгенә якын итеп каршы алгач, Гәүһәрнең күзләреннән яшь бәреп чыкты. Сүзен әйтә алмыйча, ул байтак елады. Бибинур апа аңа су бирде, ана шикелле йомшак сүзләр белән юатты, тынычландырды. Ул бит үзе дә кайгылы кеше, кешегә күрсәтмәсә дә, ихтимал, үз алдына елый да торгандыр, иреннән иртә аерылган, аның рәсеменә генә карап юанырга калган хатын-кыз бер елмайса да бер елар, кеше гомерендә төрле чаклар була.

Ниһаять, Гәүһәр тынычланды, еламый башлады. Бибинур апа түземлек белән Гәүһәрнең сүз башлавын көтте. Дөресен әйткәндә, ул инде беркадәр сизенгән иде, Галимҗан да сөйләп китте.

Гәүһәр бәйрәм арасында Казанга барып кайтырга рөхсәт сорады.

— Бик яхшы, барырсың,— диде Бибинур апа,— тик яхшы уйладыңмы?

— Белмим,— диде Гәүһәр, турысын әйтеп,— бармый да булдыра алмыйм... Җәгъфәр өйләнә бит... Аерылгач, анысы инде аның үз эше... Мин аны онытмасам да, муенына тагылырга җыенмыйм. Ләкин... ул... Бибинур апа, җаным, ничек әйтим инде сиңа, ул Исрафил Дидаровның балдызы Фаягөл Идрисҗановага өйләнә ди бит.

Галимҗан бу турыда да Бибинурга сер итеп сөйләгән иде. Күрәсең, Гәүһәр дә моны белеп алган. Дөрес, ул Дидаровны да, Идрисҗанованы да белми, ни өчен Гәүһәр аларны шулкадәр күрә алмый торгандыр, анысы да Бибинурга караңгы.

— Мин Җәгъфәргә әйтергә тиешмен... Ул кешеләргә ышана, кеше һәрвакыт дөресен генә сөйли дип уйлый. Дидаров аның башын-күзен әйләндергән. Җәгъфәр бәлки мине тыңламас та, шулай да әйтәсем килә. Беренче саф мәхәббәтем хакына... Минем аның алдында тырнак очы кадәр дә гаебем юк. Үземне аклар өчен генә булса, бармас та идем.

— Нәрсә әйтим сиңа, Гәүһәр. Хатын-кыз йөрәгенең нәрсә икәнен ул кешеләр кайчан булса аңлармы, белмим. Син барырга уйлагансың икән, мин каршы килмим. Ләкин шулай эшләү кирәкме икән? Ярый, син үзеңнең сүзләреңне аңа әйтерсең. Ә ул? Мин үзем дә хатын-кыз, миңа калса, Җәгъфәр синең сүзләреңнең пакьлеген аңламас, киресенчә, сине мәкерле дип гаепләр, гомер онытмаслык каты сүз әйтер. Болары, Гәүһәр, бер. Аларда бәхәссез дөреслек чаткылары булса да, синең төп теләгең, үзеңә дә әйтми торган яшерен уйларың...

Гәүһәр, күзләрен зур ачып, Бибинур апасына карады.

— Син мине, Гәүһәр, бәгырьсыз, рәхимсез дип гаепләмә. Мин бит хатын-кыз, безнең күңелләр бер камырдан әвәләнгән. Мин синең башта ук Җәгъфәрне оныта алмавыңны сиздем, синең аңа кайтырга ниятең юк түгеллеген дә күрдем, тик ул үзенең хатасын гына аңласын, дисең. Ләкин, минемчә, Җәгъфәр андый юлга тиз генә басмас. Аңа тормыш сынавын үтәргә кирәк. Ә бу вакыт сорый. Аннары, дөресен әйткәндә, сиңа да ул сынауны үтәсе бар. Күңелеңә авырга алма, тормыш җиңел холыклылыкны яратмый. Аның үз законнары бар.

Гәүһәр сыгылып утырды. Дөрес, ул еламый иде, ләкин ул үз эченә тирәнгә чумган. Мондый чакта инде ул бүтәннәрнең сүзен дә ишетми, аңа сүз дә артык кирәкми. Ул үзе хәл итәргә тиеш.

— Ярый, мин киттем,— диде ул, бик авырлык белән генә урыныннан күтәрелеп.— Иртәгә хәтле уйлыйм әле.

— Уйла, уйла, җаным. Безнең өлешебез шундый инде. Табын әзерлим хәзер.

— Юк, рәхмәт.



7

Гәүһәр Казанга бармады, ләкин ул бөтенләй үзгәрде, аны танып та булмый башлады. Гүя аны алмаштырганнар, канатларын йолкып ташлаганнар, дөньясына күтәрелеп карамый, узган-барганны танымый, дәшмәсәләр, туктамый да. Өстендәге киемнәре барысы да ят кешенеке кебек, җил исмәсә дә тибрәнеп тора. Мәктәптән башка беркая да йөрмәде, кешеләр белән аралашмады, бары тик балаларын гына белде. Хәтта Миләүшә белән сөйләшмәгән чаклары күп булды. Ә Миләүшәнең чын хәлен белер өчен күп тә кирәкми бит: бәхете гүя кырыеннан ташый, йөзе гүя чәчәк аткан, сөйләшә башласа, гүя илһам чишмәсендә йөзә. Хатын-кыз моның нәрсәдән икәнен әйтмәсәләр дә әллә кайдан сизә. Дөрес, Миләүшәләрнең әле туйлары булганы юк, мөгаен, язсыз булмастыр да, ләкин кешенең эчке шатлыгы кош түгел бит, аны читлеккә япмассың, ул ике арада аңлашу булганнан соң һаман сайрый. Вилданы алай әйткән дә, Вилданы болай әйткән, Вилданның чәче чем-кара, күзләре нурлы, үзе Миләүшәдән шүрли дә...

Гәүһәр аны игътибарсыз гына тыңлый, көлми, шаярмый, мондый чакта җиңелчә шаяртсаң да урынлы. Миләүшә хәтта аптырашта кала, аерылганнар икән, нигә шулай кайгырырга?! Эшләр шуңа барып җиткән икән, Миләүшә борылып та карамас иде, нигә борыны белән чәнчелеп китми. Кайчакта Миләүшә уйга да кала: кешенекен сөйләве ансат, кеше кайгысы яныңнан су кебек ага, бер җиреңне авырттырмый, ә үз кайгың, кечкенә генә булса да, утлы күмер кебек куыра... Моны сөйләп бирүе дә кыен, моны сынарга кирәк. Миләүшә сынады инде. Кыз кешенең сыналмаган, әйтелмәгән мәхәббәте... Мең төрле уйлар, шикләнүләр, яшерен газаплар, яшерен күз яшьләре... Шулай да... шулай да болар Гәүһәр кайгысына охшамаган төсле. Миләүшәнең иң кара дип әйткән төннәрендә дә еракта җемелдәгән йолдызы бар иде, ә Гәүһәрнең күге тоташ кара төсле. Куркыныч! Шундый хәлдән ходай сакласын!

Гәүһәр яңадан Бибинурларга бармады, бер көнне мәктәп директоры үзе аның янына килде. Билгеле, ул Гәүһәрне кабинетына да чакыра ала иде, рәсми сөйләшер өчен шуннан да яхшы урын юк иде. Ләкин Бибинур алай итмәде, директор булып та эрләмәде, акыл өйрәтмәде, өлкән хатын-кыз буларак, ана буларак гәпләште. Башта бер нәрсә дә сөйләмәскә карар иткән Гәүһәр бу йомшаклыкка каршы тора алмады, Бибинур апасына барысын да сөйләп бирде.

— Гафу итегез, Бибинур апа. Мин сезнең киңәшләрегезне яртысын гына үтәдем. Мин Казанга бармадым, ләкин бер яхшы танышым, минем соравым буенча, Җәгъфәрне күргән, минем сүзләремне аңа җиткергән... Сез хаклы идегез, Җәгъфәр мине... кара елан дип атаган. Мин моңа бик кимсендем, Бибинур апа.— Гәүһәр күзенә чыккан яшьләрен сөртеп алды.— Мин аны бу кадәр вак җанлы дип уйламаган идем.

— Ярый, Гәүһәр. Буласы булган, инде дә балаларыңа игътибарлырак бул. Аларның укытучыларыннан якын кешеләре юк.

Гәүһәр кызарды.

— Мин җебедем шул. Бәйрәмнән соң балаларның үземә карата бераз салкыная төшүләрен сиздем. «Кемгә кирәк мондый елак укытучы!» дип уйладым. Мине бит, Бибинур апа, монда озак тотмассыз. Балаларны имгәтергә бирәү дә юл куймас. Моның өчен мин сезгә дә,

коллективка да үпкәләмим, бары тик үзем генә гаепле. Кая барырмын — белмим. Кайдадыр Ерак Көнчыгышта әнинең апасының малайлары бар барын да, мин аларга бара алмыйм, хат та язышмыйбыз...

— Син, Гәүһәр, юк нәрсәләр уйлама әле, син Яшел Ярдан беркая да китмисең,— диде Бибинур апа, Гәүһәрнең беләгеннән сыйпап.— Җәгъфәрне бөтенләй оныт. Элек синең хәтереңне калдырырмын дип әйтмидер идем, хәзер әйтәм: ул синең яхшы теләгеңне аңламаган икән, сиңа авыр сүз әйтергә теле әйләнгән икән, ул сиңа тиң түгел. Балаларга игътибарлырак бул. Аларның күңелләре бик киң, алар ике арадагы салкынлыкны бик тиз онытып, сиңа кайтачаклар. Мин моны, Гәүһәр, үзем дә кичердем. Ирем үлгәч, миңа да дөнья беткән кебек тоелган иде, балаларның эчкерсез мәхәббәте генә терелтте мине. Сине дә терелтәчәкләр алар.

Ул көнне Бибинур апа озак утырды, Зәбирә түти өйдә булса да алар янына кермәде. Эчтән ут йотса да, Гәүһәрне чын күңелennән кызганса да — чыгып сүз әйтергә батырчылык итмәде. Бары тик Бибинурның килүенә, акыллы киңәшләренә сөенеп бетә алмады. Ниһаять, Бибинур китәргә җыена башлагач кына ул самоварын кертеп куйды, әйдәгез, берәр чынаяк чәй эчеп алыгыз, диде.

— Аштан, Зәбирә түти, беребез дә олы түгел,— диде Бибинур.— Каршыга килгәнне кире кайтармабыз.

— Шулай, шулай, Бибинур. Аштан өстен булып булмый.

Гәүһәр, хәзер чыгам дип, үз бүлмәсенә кереп китте. Зәбирә түти чынаяк белән чәен һәм ашларын кунак каршысына әтәрде, үзе дә өлешсез калмады.

— Сиңа бер әйткән идем дә шикелле, Зәбирә түти,— диде Бибинур, тавышын әкренәйтә төшеп.— Гәүһәр минем үз кызым кебек. Ана хакы итеп сорыйм, син инде аңа үз була күр. Алдан аны эшлә дә, моны эшлә дип әйтеп булмый. Кешегә нинди сүз күбрәк тәэсир итә торгандыр, аны да тәгаен белмим. Йөрәгең ни кушса, шуны эшлә дип әйтүем генә.

— Рәхмәт, Бибинур, иманлы сүзеңә. Минем болай да хәйрангавайранга калган башым нинди мәгънәле тәгъбир чыгарыр икән,— Зәбирә түти Бибинур әйткәннәрне Гәүһәр әйтсә яхшырак буласын артык тирән яшереп тормады. Гәүһәр бит үзенә кирәк чакта туп-туры Бибинур апасына йөгерде, аннан кайткач, тагын авызына су капкан төсле, Зәбирә түтисенә ләм-мим. Билгеле инде, Зәбирәнең акылы — чыпчык йомыркасы хәтле генә дә, ул Гәүһәрне ярата бит. Борчыла, рәтле киңәш бирә алмаса да, белеп торасы килә.

Бибинур карчыкның яшерен үпкәсен аңлады булса кирәк, бик саклык белән генә:

— Шулай инде, Зәбирә түти, башың әйләнгәч, яныңдагы нәрсәне дә әллә кайдан ерактан эзлисең. Аптыраган бер карчык маңгаендагы күзлеген көне буе эзләгән, дип сөйлиләр бит.

Гәүһәр чыгып табын янына утырды.

— Ашагыз әле, валлаһи, Бибинур. Ашагач, сүзнең тәмлесе дә чыга.

Бибинур әкрен генә елмайды.

— Безнең тәмле сүзләр әле калган булса ярый.

— Тәмле күп булмый, Бибинур. Әзрәк булгач, аның кадере дә арта. Аяк астында аунаса, аны кадерләгә дә санамаслар иде.

Башка вакыт булса, Гәүһәр Зәбирә апаның бу кадәр үлчәп сөйләшүенә түзә алмас иде. Әмма бу юлы ул аларны яхшылап ишетмәде дә. Ничектер боегып, аска карап утырды, ашамады, эчмәде. Кайчагында гына күзләрен кысып, гөл яфраклары арасыннан каядыр еракка карады, мөгаен, нәрсәдер күрә, бәлки күңеленнән алар белән сөйләшә дә торгандыр. Бибинур белән Зәбирә түтинең гәпләшүе гүя аның ту-

рында да түгел, керфеген дә селкетми. Бу бик сәер. Зәбирә түтинеп гомердә укытучы булганы юк, заманында хәтта мәктәпкә дә рәтләп йөри алмады, ләкин ул укытучының сөмсерләре коелуы яхшы түгеллеген күңеле белән сизә. Җитмәсә, Бибинур, теләпме, теләмичәме, арага бөтенләй катнашы булмаган Зәбирә түтине дә кертте. Хатын-кыз бит серен алай зурга җәяргә теләми, ул аны яшерә.

Ниһаять, Бибинур, тыныч төн теләп, китеп барды. Гәүһәр һаман гөлләр арасында утырды, җил улавына, буран котыруына колак салды. Кашлары кысылды. Бибинур апа юк нәрсәләр уйлап, үз-үзенне бетермә, ди. Ничек уйламыйсың! «Ходаем, кара елан!» дигән бит. Моны ничек күтәрергә? Ник әйткән моны Җәгъфәр? Ул бу кадәр тупас түгел иде бит? Аннары бу сүзләр анныкымы?

Зәбирә түти өстәлен җыйды, аннары кече якта чынаякларын юды, җил тавышын тыңлап, җылы мичкә аркасын терәп, артсыз урындыкка утырып торды. Җил көчәя, буран котыра. Өй иске, таңга кадәр бөтен җылыны суырып бетерер. Тишек-тошыкны хатын-кыз ямап бетерә аламы соң?! Күптән инде өйне сипләтергә кирәк, ир-ат булмагач, кыен шул. Аннары бу Гәүһәр... Кайгы, билгеле, кеше башыннан йөри. Төрле кешенең кайгысы да төрлечә. Менә Зәбирәнең, Бибинурның бәхете кайтмас җиргә киткән, күпме офтансаң да башны ташка бәреп еласаң да бернәрсә дә үзгәрәчәк түгел, бары тик сабырлык кына кирәк. Гәүһәрнең хәле бик авыр да, бәхете кайтмас җиргә китмәгән ич әле. Буранлы көннәр бер үтәр дә тагын кояш чыгар. Шуңа күрә болай өзгәләнмәскә кирәк иде. Өзгәләнсәң, шайтан гына кинәнә бит.

Өй эче тын, олы якта уйга чумган Гәүһәр утыра, монда Зәбирә апа. Бибинур бер карасаң, бик акыллы сүзләр әйтеп калдырды бит. Кемнең ни эше бар Гәүһәрдә? Таңга кадәр шулай утырса да беркем килеп караячак түгел. Тик Зәбирә түти генә аны күрә, нинди сүзгә күбрәк мохтаҗ икәнен дә төсмерли. Әлбәттә, кеше күңеленә тулысынча кереп булмый, шулай да аның кайбер кылларын тибрәтергә мөмкин.

Зәбирә түти колак салып тыңлап тора. Җил улавыннан, буран котыруыннан башка берни ишетелми. Нишли икән бу Гәүһәр? И алла, һаман өстәл янында утыра, Зәбирә түти көрсенеп ала, аннары урыныннан тора, бер аягына янтая төшеп, олы якка чыга.

— Уйны, Гәүһәрем, борынгылар да уйлап бетерә алмаган, бик уйлы булма әле,— диде йомшак тавыш белән.

Гәүһәр аны кочты да, күкрәгенә капланып, елап җибәрде. Тулган икән! Җылавы яхшы, бераз җиңелрәк булыр. Кешенең күзеннән яшь чыкмаса, ут йотса — авыр.

Гәүһәр көрсенеп куйды. Соңыннан әкренләп тынычланды, күз яшьләрен сөртте. Кулъяулыгы тәмам чыланган иде, яңасын алды.

— Менә яхшы булды әле,— диде Зәбирә түти аңа, бераз үчекли төшеп,— югыйсә суган суы агыз да агыз...

— Гафу ит, Зәбирә түти... Мин синең алда гомумән гаепле. Синең яхшы күңелле булуыңа шикләнмәсәм дә, күп серләремне сиңа ачмадым. Рәнҗеткән булсам, гафу ит.

— Син минем алдымда гафу үтенмә әле, Гәүһәрем. Теләсәң, сөйлисең, теләмәсәң, юк. Инде киң күңелең белән миңа шундый ышаныч белдерәсең икән — рәхмәт. Авыр чакта бер-береңә канат булу кирәк. Югыйсә тормыш юллары һәрвакытта да такыр түгел бит.

— Рәхмәт, Зәбирә түти, рәхмәт.

— Син мине, Гәүһәрем, бу әллә нинди яхшы сүзләр сөйли дип оялтма тагы. Мин сүзне алай үлчәп сөйләмим. Телемә килгәнне әйтәм дә бирәм. Дөньяда ир белән хатын аерылуы була торган хәл. Бер үк кеше дигән дәрәҗәңне югары тотарга кирәк. Сыгылып төшеп, өстәлгә

капланып бирәүне дә шаккатыра алмыйсың. Киресенчә, үзеңне генә түбәнсетәсең.

— Нахак сүзне күтәрүе авыр, Зәбирә түти. Мондый әшәке сүз белән беркемнең дә мине мыскыллаганы юк иде.

— Ярар, төкер ул сүзләргә. Чәй эчәсең килсә, хәзер самавыр куям. Бая бит бер нәрсә дә эчмәдең.

— Әллә чыннан да эчәбезме икән?

— Эчәсе килә икән, нигә эчмәскә? Мичтә әле күмерем бар, хәзер самавырым гөрләп чыгар.

Татар өендә мең авыруга бер шифа — чәй. Бөртекле чәйгә такта чәен дә кушып җибәрсәң, әгълә инде. Зәбирә түтинең алдан хәзерләп куйган бөтен нәрсәсе бар. Гәүһәрдән квартира өчен ала торган акчасын да шуңа гына диярлек тота. Аннары каймаклы сөтен дә чыгарып куйды. Аш — баягыдан калганы җитәрлек.

Чәй эчкәч, күңел дә ачылып киткән төсле булды. Зәбирә түти тагын бер мәртәбә чәйне мактап алды, аннары кабат уйлана башлаган Гәүһәргә карап алып:

— Чәй янында гына түгел, яхшы кешеләрнең чәйдән соң да күңелләре көр була,— диде.— Әнкәй мәрхүм шулай әйтә торган иде.

Гәүһәр чак кына елмаеп алды, аннары иртәгә кирәкле китапларын әзерли башлады. Дәрес планына күз төшерде. Нәрсәдер уйлап алды, кара бөдрәләрен чөеп, башын селкеп куйды, кечкенә блокнотына ниндидер билге ясады. Сәгатькә карады.

— Зәбирә түти, сәгать унике була инде. Бүген ятабызмы, юкмы?

— Син, Гәүһәрем, ят инде. Аргансыңдыр да, башың да авырта торгандыр. Мин дә хәзер эшемне бетерәм дә ятам.

Бераздан Гәүһәр бүлмәсендәге ут сүнде. Зәбирә түти савыт-сабаларын шалтыратмаска тырышып бик әкрен кыланды. Аннары кухнядагы ут та сүнде. Кечкенә өй эче тирән караңгылыкка чумды. Ләкин Гәүһәр рәтләп йоклый алмады. Әллә ничек саташып чыкты шунда. Бары тик таң ата башлагач кына йокыга китте. Ләкин ул арада инде Зәбирә түтинең:

— Гәүһәрем, тор инде, мәктәбеңә кичегәсең,— дигән тавышы ишетелде.

Гәүһәр шунда ук күзен ачты, сузылып сәгатенә карады һәм ашыгып киенә башлады.

— Мин бүген йокламадым да шикелле, Зәбирә түти. Башым тубал.

— Чәй эчеп җибәрсәң, башың-күзең ачылыр. Әйдә юын, комганга җылы су салдым.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, Гәүһәр, киенеп, урамга чыкты. Тышта яктырган, буран басылган. Гәүһәр мамык кебек карга баса-баса мәктәпкә ашыкты. Кичәге уйларны хәзер уйлыйсы килми, аннары көн яктысында алар инде башкачарак, ул хәтле йөрәкне кисмиләр иде.

*(Дәвамы бар.)*

## Шамил Мәхмүдов

# Авыл киче

Кич килә.
Эңгер сулары карасында,
кайдадыр галәм уртасында, далада,
яшел сыртлар, түбәләр арасында
утыра безнең авыл өйләре,
кезге басуларда зураттай —
кычкырган паровозлардан, гудоклардан,
күкне баганадай күтәреп торган
кызыл завод морҗаларыннан
еракта.

Кич килә.
Чыга капка төбенә сылу кызлар,
каршы ала алар назлы эндәшеп,
сагынып кайткан сыерларын...

(Нишли алам соң мин көнләшеп:
бар аларның батыр шаһзадәләре,
миңа түгел — сөю җырлары...)
Кичке чыклы үләнгә
озын кара күләгәләр яталар.
Ерак таулар әкренләп
алсу шәфәкъ суларына баталар...

Гәүкешедәй, хәйран күз белән
карыйм бу зәңгәр кичкә,
                    кетәм жан атып:
балаларның, чыпчыкларның
көмеш кыңгыраулары кинәт тынар да
хәбәр итәрләр
авыл түбәләре өстенә
төн
җәйгәнне
йомшак, җылы канатын.

Димәк,
җир читенә төшкән кызыл кояш урынына
балкыр безнең өйләрдә икенче кояш —
безнең һәркөнге кичке аш —
                    икмәк.

## Табигать йөзе

Моңа нинди дәлилләр бар безнең,
сөйлибезме әллә сәбәпсез —
бәлки, ташлар җансыз да түгелдер,
ә агачлар хиссә сәләтсез?

(Тоела миңа кайчак: гүяки
яфрак-үлән телен мин беләм.
Әгәр кеше булмасам,— ышанам,
булыр идем агач я үлән.)

Күрсәтмиме бөек бу табигать,
мең сыйфатын, төсен, чыраен?
(Без шул аның иң тирән серләрен
белмибез дә булыр, мөгаен!)

## Балбаллар[1]

Утыралар көйгән буш далада
яссы битле өнсез таш сыннар —
йөзләренә заман сырлар салган...
Ни аларга
безнең моң-шомнар?

Кайда хәзер ул дәһшәтле караш?
Онытканнар дөнья кызыгын...
Янгыр юа йөзләрен, җил кисә,
башларына куна ач козгын...

Кем калдырган аларны? Кай заман?
Сарматлармы, кырыс һуннармы?
Явыз эшләр билгесеме алар,
канлы җиңүләргә ядкарь сыннармы?
Әллә кыргый дала улларының
булганнармы
поты-тәңресе?
Кемнәр килгән,ниләр булган җирдә —
безнең өчен хәзер мәңге сер...

Утыралар алар исем-атсыз,
күрми-белми дөнья кызыгын.
Янгыр юа йөзләрен, җил кисә,
башларында ял итә козгын...

## Мәскәү язы

Күрәсең, бу инде яз. Юкса нидән
атлый шулай иренеп
гел ашыккан Мәскәү халкы?

---

[1] Борынгы төрки кабиләләр калдырылган таш сыннар. Орхун, Енисей елгалары буенда һәм Саратов өлкәсендә очрыйлар.

Бульварлар чуп-чуар:
әби-сәби, бала-чага,
чыкканнар, ахры, кыштан ялкып...

Юкәләр кызарганнар, бүрткәннәр.
Күк инде язча балкый...

Сәер булыр иде
кара кайгыда булсаң мондый көнне:

яз ул — бердәнбер кыз дөньяда,—
дошман итми беркем белән беркемне,
көнләшү дә уятмый
беркемдә беркемгә карата,
ә шулай да, бөтен кеше гашыйк аңа,
бөтен кеше аны ярата...

Әллә мин яшь булганга гына,
бармы әллә башка сәбәпләр,
аермый яз миннән беркемне,—
бер-бер артлы үтә сәгатьләр.
утырабыз юкә бульварында —
Тверскойның очында,
нәни кулың ята учымда...

Ишетелә талгын көй.
«Чәчәкләр вальсы». Чайковский.
Язча киенгән кызлар узалар.
Мәскәүдә
күренде беренче мимозалар.

## Кичке шәфәкъ

Шәфәкъ сулары кан — кызыл.
Тарак сыртлы борынгы кәлтәләр сыман,
утыра таулар тын яныл.
Кайдадыр эчтә, тирәндә, курку уятып,
әкияттәге аждаһалар баса дөньяны...

Нинди ялгыз, кечкенә без мондый кичтә —
караңгы йөзле сагыш омтыла эчтән,
яраланган кош сыман талпына, кагына,
оча җәеп канатларын ал офык ягына,
һәм, кереп кызыл ялкынга, югала күздән...

Кояш баткан саен нидер сүнә бездә.

## Марс каналлары

Чиксез еракта,
әнә анда, Марста,
гүя аңлы тормыш эзләре,
әллә нинди сәер тап сызыклар
тора даим үзгәреп...

Ни соң алар? Корган каналлармы,
тасма-тасма сузыламы елгалар?
Әллә утрау-утрау яшеллекме
үлек шәһәрләрне чолгаган?

Ә ник алар арта елдан-ел?
Салкын бозлар җәеләме котыптан,
олы янгыннармы тѳтенли?
Кайда кешеләр? Планеталарын
ташлап киткәннәрме бѳтенләй?

Әллә бѳек хәрабәләр тудырып,
күмелеп калганнармы үзләре?
Һәм без телескоплардан
күрәбезме
сүнгән тормыш эзләрен?

## Ике тол

«Ике тол ѳйләнешсә —
бер түшәктә дүрт кеше».
**Халык сүзе.**

Бер түшәктә башка-баш
ялгыз ике тол ята,
кылыч кебек, арада
күренмәгән кыл ята...

Кыл — араны үткәнче,
куллар кулга җиткәнче,
кичеп булмас юл ята,
үткәннәрдән бу көнгә
таулар хәтле ел ята...

Син дип кочам — син түгел,
ә син үпкән — мин түгел,
язмыш биргән изге җир,
бер түшәктә дүртәү без—
ике хатын, ике ир.

Бер түшәктә башка-баш,
уйлы ике тол ята,
кичеп булмас, арада
кылыч кебек кыл ята...

## Мәрхүм абзыйга элегия

Булмагандыр, ахры, безнең абзый
артык алай әдәп иясе,
җиңел булсын инде таш-туфрагы
(башка тагы нәрсә диясең?) —
Рәтсез яшәп, сәер үлем тапты,
гѳнаһлары булган муеннан:
эчкән, тарткан, хатын-кызлар сѳйгән,
ләззәт тапкан азгын уеннан.
Сѳйләгәннәр усал телләр,
эре ярып гайбәт борчагын:
«Шул азгынның тисә чабу очы
күбә хатын-кызның корсагы!»
«Мәхәббәткә хурлык юк ул!» дигән,
бар диеп тә белмәгән...
Үчле ирләр күсәк белән суккан,
чәнечкәннәр — үлмәгән,
баһадир адәм иде — җиде пот! —
Әйтә иде: «Анай биргән сѳт әрәм,
ат күтәрми мине, сына биле,
ә мин менә атны күтәрәм.
Чәнечтеләр, суктылар,— ди иде,—
ә мин менә дуп-дубрый һаман,

чалгы тоткан теге нәрсә килгәндә дә
бирешергә юк чамам!»
Ә үлде юктан гына: исерек килеш
чыккан да ялан өс — чирләде,
«Чирмени бу!» диеп ятты һаман,
ә өч көннән... жирләдек.

Гомер буе ярлы, ләкин пошмас,
булган анын башка даны да,
оста уенчы дип бар тирә-як
хөрмәт иткән аны, таныган.
Уйнап жибәрсәме, гүя сихри
моң агылган скрипка кылыннан.
Әйткән картлар: «Иблис өйрәтәдер,
бу эш килмәс адәм кулыннан!»
Ләкин шул илаһи моңы өчен
һич бозмады халык йоланы —
гафу итте аны, бәхилләде,
женазада күпләр елады...

Сихри моң иясе, чын музыкант,
ул тик матурлыкка кызыккан —
сабый кебек саф күңелле, садә,
жаны ерак булган бозыктан.

## Китәбез

«Ирләр ваз кичәлми йола-гадәттән:
ирләр илдән китә авыр сәгатьтә».

Без бит ирләр, без һәрвакыт китәбез.
Китәбез балачактан, туган яктан,
аналардан, яныл сөйгән ярлардан.
Көзен кошлар киткән кебек, китәбез —
Көзге салкын яңгырларда, кырларда...
Туктый-туктый, күз талдырып карыйбыз —
югалганчы туган өйләр кыегы...

Китәбез без канатланып, ашкынып,
яки илгә үги сыман, боегып —
китәбез тик үпкә, тик ачы гына
төяп аркадагы юл капчыгына...

Кычкырабыз талгын искән жилләрдә:
«Саулар булсак, бер кайтырбыз илләргә!»
Я китәбез кайтмаска, еллар буе
онытмаска, сагынырга, көяргә,
илләр искә төшкән саен, буылып
тамак төбендәге ачы төердән...

Ни сон дучар итте безне
бу тынгысыз язмышка?
Гомер буе без юлларда йөрибез,
тилмерәбез кайчак хәтта телемгә...
Ләкин без бит ирләр, без һәрвакыт китәбез —
Ил чакырса — жир читенә, үлемгә.

## Эдуард Мостафин

### Йөрәк турында

Кошларның моң-зары бар синдә,
Бар синдә каеннар ярасы.
Йөрәкне бер кысып кулларга
Бар әле жир буйлап барасы.

Сабыйлар шатлыгы бар синдә,
Бар синдә кояшның җылысы.
Йөрәкне ачып бу дөньяга
Бар әле өздереп җырлыйсы.

### Гомер кайдан башлана

Дулкын гомере җилләрдә.
Җилләр йөри илләрдә.

Таш гомере тауларда.
Батыр гомере яуларда.

Ут гомере учакта.
Үч гомере пычакта.

Ат гомере чабышта.
Чишмә гомере агышта.

Көч гомере beләктә.
Бәхет гомере теләктә.

Сагыш гомере буйдакта.
Караның гомере акта.

Сүз гомере калыпта.
Шагыйрь гомере халыкта.

### Бу төннән...

Бу төннән миңа тик зәңгәрлек,
Зәңгәргә төренгән моң кирәк.
Сынык ай яктысын чүмерә
Ялгызы, моңаеп, карт тирәк.

Бу төннән миңа тик җыр кирәк:
Агылсын тын гына чайкалып.
Дулкыннар сыенып ярларга,
Зәңгәр көй тыңласын тын калып.

Бу төннән миңа тик син кирәк.
Бу төндә ни файда сүзләрдән...
Бу төннән миңа тик төн кирәк —
Яшерсен мәкерле күзләрдән.

## Ә мин һаман бер могҗиза көтәм

Төшемдәме, әллә өнемдәме,
Хәтерләмим, үзем төш идем.
Ут яндырып кара тауга менгәч,
«— Давыл килә, бире төш» — дидең.

Көтмәгәнсең таудан төшкәнемне,
Эрегәнсең кереп томанга.
Тик яулыгың калган эленеп талга,
Сагынырга — ямансуларга.

Ә мин һаман бер могҗиза көтәм.
Яулыгыңны алып куеннан,
Менә тагын өмет алып кайтам
Кемнәрнеңдер бәхет туеннан.

●

— Күктә очкан бөркеттәге
Көч бит миндә.
Утка кергән күбәләктәй
Көйдем синдә.
Көйдерерлек көчең булгач,
Терелт инде.

— Канат бирәм, тик монган соң
Янма,— диде.

Алҗып йөрим, канатларны
Ачып булмый.
Утың тарта, бер янсам да
Качып булмый.

## Тәрәзәләр

Сарайларда тәрәзәләр,
Төрмәләрдә тәрәзәләр,
Чормаларда тәрәзәләр,
Күңелләрдә тәрәзәләр.
Уты янган,
Тамчы тамган,
Гөлләр үскән,
Кояш төшкән,
Бозлар туңган,
Кошлар кунган тәрәзәләр...

Тол хатынның сагышыдай
Пәрдә тарткан тәрәзәләр,
Гашыйкларның бәхетедәй
Челтәр япкан тәрәзәләр.
Шагыйрьләрнең күңеледәй
Ачык-якты тәрәзәләр...

Тәрәзәгә төн оялый,
Ай кунаклый күктән төшеп.
Кыр казлары канатыннан
Сәлам ташлый, безгә дәшеп.
Тәрәзәдән кайгы керә,
Шатлык керә, җырлар керә.
Кайгыларын чәйни-чәйни
Тәрәзәгә этләр өрә.

Тәрәзәләр көтеп ала,
Озатып кала ана кебек.
Һәрбер тәрәздәге утлар
Синен өчен яна кебек.
Тамчыларын агыза-агыза,
Тәрәзәләр көтә хәбәр...
Тәрәзәләр телгә килсә
Сөйләр иде шундый хәлләр...
Мусаларның теле белән,
Лоркаларның күңеле белән,
Сөйләр иде: «Төрмә тынчу,
Ә җир өсте яшел келәм.
Сыйдырганча кояш бирдем,
Яулык кадәр күкне бирдем.
Минем аша туган илдән
Сәлам булып җилләр керде.
Миңа карап җырлар туды —
Җыр таралды җир шарына —
Давыл булып җәелде ул
Тын океан ярларына».

...Туган йортта дүрт тәрәзә.
Көтәләрдер зар булып.
Шул тәрәзәгә тик бер көнгә
Кунсам иде таң булып.

●

Дөнья миңа пешкән алма иде,
Тик кулыңны бары суз гына.
Дөнья миңа сөтле елга иде,
Кунак йорты иде, уз гына.
Нигә, язмыш, ымсындырып-алдап,
Яшь кыз, диеп, карчык димлисең.
«Син кеше бит бары, карулашма,
Синең аллаң җирдә мин»,— дисең.
Без шулай да, язмыш, көрәшәбез,
Мәйданнар киң, ай-һай киң әле;
Кеше булып бугазыңнан алам,
Алла булып мине җиң әле!

## Рифма өчен

Зәңгәр төндә моңсу ак ай кирәк,
Ай янына серле йолдызлар.
Шундый төндә инде ярап куя
Рифма өчен булса да кызлар.

Айлы төндә мәхәббәт тә була,
Мәхәббәттә кирәк ак каен.
Римфа өчен булса да каеннар
Яфрак яра шаулап яз саен.

Пакьлык өчен каен кирәк булса,
Ныклык өчен кирәк имәннәр.
Имәннәре нинди нык булса да
Римфа өчен дип баш игәннәр.

...Шагыйрьләргә канат биргән туфрак
Гөлбакчалы туган ил икән.
Мангаемнан тамып төшкән тирем —
Рифма өчен тамган тир икән.

## Кайгырабыз, шатланабыз

Кайгырабыз ат егылса,
Акча бетсә кайгырабыз.
— Кияү чыкмас, картаям,—
дип,
Егермедә кайгыра кыз.
Бурыч түләп кайгырабыз,
Кайгырабыз чиратларда.
Күз яшьләрен тоталмыйча,
Кайгырабыз зиратларда.
Язалмасак кайгырабыз,
Кайгырабыз язмыш өчен.
Еллар имин килерме, дип,
Кайгырабыз яз-кыш өчен.

Кайгы китсә шатланабыз,
Шатланабыз авыз ерып —
Шатланабыз сабыйлардай
Кайгыларны жиргә орып.
Шатланабыз табыннарда,
Сөю килсә, шатланабыз.
— Егерме яшь чәчкә чагым!
Көт әле,— дип шатлана кыз.

●

Күнелләргә ак нур булып
Бәхет кунды.
Күпме кеше шул бәхеткә
Кулын сузды.
Күнелләргә сөрем булып
Кайгы кунды.

Күпме кеше шул кайгыны
Читләп узды.
Бәхетемне бүлеп бирдем
Дусларыма.
Кайгыларны ялгыз сыктым
Учларымда.

●

Яшәү авыр,
Яшәү матур, диләр,
Яшәүнең бар, диләр, шатлыгы.
Тормыш әллә биек йортлар кебек
Күп баскычлы, йөзәр катлымы?
Яшәү авырлыгын куллар үлчи,
Йөрәк үлчи салып бизмәнгә.
Ак дулкыннар корабларны юа
Кара кайгы төяп йөзгәндә.
Шатлыклары бер елмаю булып
Күзләренә кереп сыена,
Үткән гомер йөз яшьтәге талдан
Сары яфрак булып коела...

Газиз Мөхәммәтшин

# ТЫНГЫСЫЗ ТӨН

ӨЧ ПӘРДӘЛЕК КОМЕДИЯ

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гөлбану.
Ләйсән.
Ләйлә.
Хак.
Гаяз.
Нәжип.
Яз.
Фәпүсә.

Вакыйга безнең көннәрдә Кама буенда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәйге көн. Уң якта йорт. Ишек алдында җимеш агачлары, чәчәкләр үсә. Тирә-якта урман. Сул якта Камага төшә торган сукмак. Яр астында Каманың бер борылмасы ялтырап күренә.

Сукмактан ишкәк тотып Гөлбану менә.

Гөлбану. Тып-тын. Әллә кайтмаганнар инде. Ләйсән!.. Ләйлә!.. Кызым!.. *(Өйгә кереп чыга.)* Юк, кайтмаганнар... Нишләтергә соң инде бу имгәк моторны, ә?..

Хак керә.

Хак. Сәлам, Гөлбану!
Гөлбану. Исәнме, Хак!.. Ләйсән!.. Ләйлә!..
Хак. Тәки китәләрме инде?
Гөлбану. Канатлары ныгыган кош балаларына туган оялары тарая башлый шул. Әткәләре исән чагында икесен ике учына утырта иде дә, игезәкләрем, матурларым, дип үчти-үчти сөя иде. Кай арада житкән кыз булдылар.
Хак. Бәлки син үзең дә алар белән китәрсең?
Гөлбану. Юк, юк! Мин ул кабызып калдырган маякларны, аның изге туфрагын ташлап китә алмыйм. Без аның белән шушында таныштык, шушы өйдә беренче төнебезне үткәрдек, шушы өйдә кызларыбыз туды.
Миһербансыз син, Кама! Үзеңне өзелеп яраткан адәмнәрне аласың. Әмма күңелне тарта торган нинди тылсымлы көчең бардыр!.. Менә хәзер үзем дә синдә жиде ел буе аның маякларын кабызам...

Ә кызлар Каманың акбашлы дулкыннарын ташлап китә... Сезнең белән генә китсәләр бер хәл иде дә бит...

Хак. Мин алар белән тагын сөйләшеп карармын әле.

Гөлбану. Тик сүзләренне бик уйлап, үлчәп сөйләш. Алар сабый әле.

Хак. Ата-ана өчен үз баласы утызга җиткәч тә сабый була, ди. Борчылма, үземә ата булу бәхете эләкмәсә дә, мин аларны үз кызларым кебек күрәм. Рәнҗеттермәм. Әйе, кырык-иллегә җитсәм дә өйләнеп тә, бала-чага үрчетеп тә булмады шул. Гомерем буе чегән шикелле дөньяның иңен-буен айкап йөрдем. Кайларда гына сузмадым мин ул электр чыбыкларын! Чакрымнарын саный китсән — чутына чыгарлык түгел. Тыныч кына бер урында төпләнеп калырга, рәхәтләнеп яшәргә иде дә, булмый. Өйрәнелгән. Язмыштыр инде. Әмма, кем белсен, язмышы да кайчакта шаяргалап куя инде аның!..

Транзистор тавышы ишетелә.

Гөлбану. Әллә нишләп моторым кәҗәләнә. Тагын кабызып карыйм әле. *(Ярдан аска төшеп китә.)*

Хак. Әй, Гөлбану, Гөлбану!..

...Кыен икән картайгачтын
Гөлбану өчен янү!..

Транзисторын уйнатып Гаяз керә.

Хак. Кайттыңмы, чибәр егет?

Гаяз. Ничек шул хәтле дөрес әйттегез! Без чыннан да чибәр дә һәм дә ки кайттык та.

Хак. Башыңны җүләрлеккә салма. Ник тресттан килгән вәкил алдында мине мәсхәрә иттең син, ә? Ник мин кушканча эшләмәдең?

Гаяз. Мин үземнең яңа методымны кулланып карадым. Сезнеңчә эшләсәм, бер пролет белән сакал сыпырып калган булыр идем, ә болай мин ике пролетның эшен бетердем. Рационализация дип атала бу. Премия өмет итәм әле.

Хак. Киңәшмичә, законлаштырмыйча... Борып куй әле шул нәмәстәкәеңне, акыртма... Трест вәкиле генә кайтып китсен, мин сиңа күрсәтермен премияне, чучка малай!

Гаяз. Син, бабай, миңа җикермә әле, пожалуйста. Сиңа түгел, аллага да үземә акырырга-бакырырга ирек бирмәм. Шуның өчен ясадыкмыни без революцияне? Шуның өчен кызыл каннарыбызны койдыкмыни!

Хак. Ә? Революция ясадык, дисеңме? Хе! Кем! Син ясадыңмы?

Гаяз. Мин — иркле индивидуум. Җикерүләр минем натурама ярамый.

Хак. Ничек, ничек? Кем? Нәрсә?

Гаяз. Индивиду-ум. Мәдрәсәгездә латин теле үткән булсагыз — шәхес!

Хак. Һе!.. Лаеш шулпасы чүмереп караганың юк шул, энем. Рәхәтлеккә чыдамыйча туеп сикерәсез... Индюм-миндюм... Һе!..

Гаяз. Хак абзый!.. Хак абзыкай!..

Хак. Я, нәрсә хакылдыйсың?

Гаяз. Үзең беләсең инде!

Хак. Белмим, белмим!

Гаяз. Монета?!

Хак. Тагынмы?

Гаяз. Ике генә унлык. Авансга бирермен.

Хак. Соң, алланың беспутный бәндәсе, яңа гына зарплата алдык бит. Сиңа да почти-что минеке кадәр эләкте. Булкига кыстырып бутерброд итеп ашыйсыңмы әллә син аны?

Г а я з. Хәзерге акча бәләкәй, ашасаң да туеп булмый. Аннан соң кесә тишек — төшә дә кала. Ямарга хатын юк, хатын алырга әпәйт теки акча юк.

Х а к. Һөнәр училищесында әз генә акчаны да житкерә идең бит.

Г а я з. Ул чагында син дә саранбай түгел идең, мастер.

Х а к. Биш арслан үкереп килсә дә бирмим. Туйдым, нәкәнис. Бу бер ел эчендә тәмам теңкәне корыттың. Миңа бәйләнеп ятканчы кызлар белән сөйләшер идең әнә!

Г а я з. Кызларга ни булган?

Х а к. Яңадан Себергә китәргә йөриләр.

Г а я з. Ну-ну?!. Әле безнең белән дигәннәр иде бит. «Галиябану» көенә биетим әле мин аларны ул чакта!

Х а к. Тик кара аны, ыспай егет, уеңда инә очы хәтле генә тегендимондый, шухрый-мухрый нәрсә булса да *(Гаязның борын төбенә йодрык китерә.)* менә шушы кавыннан авыз итәрсең. Аңлап калдыңмы?

Г а я з. Аңладык, мастер. Ләкин без кавын яратмыйбыз.

Х а к. Менә шул. Гөлбану апаңа булышыйм әле. Тагын моторы гуктаган. *(Ярдан төшеп китә.)*

Г а я з. Ләйсәнемне рәнжетәмме соң инде мин, Хак абзый! Ләйсәнем!.. Нинди матур исем!.. А-а-а, иптәш дөнья!.. Ләйсәнем, дип, үзенә өзеп әйтер чагым булырмы?! *(Утыра. Моңаеп уйлана.)*

Юк, ю-ук, яратмый ул мине. Ник кирәк аңа, бүген монда, иртәгә кәжә авылында, дип йөри торган зимагур?!. *(Торып йөренә. Утыра. Кесәсеннән перевод бланкасы, авторучка ала. Яза.)* Куда? В Уфу. Кому? Тә-эк... Сумма... сумма... Сколько? Тридцать пять или двадцать пять? *(Кесәсеннән акчаларын алып санап карый.)* Болар белән генә Чикаго миллионеры булып булмый икән шул. Һем... Ялгыз кешегә бала үстерү дә җиңел түгел. Аны әби кеше белән әни кеше генә белә... Һем, үземә әллә яңа күлмәк алырмынмы дигән идем шул, чукынган. Проявитель бетте. Пленка... пеленка, дигәндәй... Һем... Кызчыкның туган көне җитте шул — утыз биш сум кирәк булыр... Сумма прописью. Мягкий знак дигән знагын кай тирәгә төртергә соң? Гомергә башны бутады шул имя числительное дигән җен. *(Күзләрен йомып, башын тотып, селкенә-селкенә исенә төшерә.)* Именами числительными называются слова... Правописание количественных числительных... Одиннадцать пишется с двумя н, миллион, миллиард с двумя л... Вот миллион сум акча булса иде!.. Әһә, әһә, слова... тәк-тәк-тәк... пишется с мягким знаком на конце... Димәк, тридцать — мягкий знак и пять — тоже мягкий знак... Ә Ләйсән белән бүген сөйләшергә кирәк...

Л ә й с ә н керә. Гаяз язуын тиз генә кесәсенә яшерә.

Л ә й с ә н. Привет! Җаныеңа тагын хат яздыңмы?

Г а я з. Җаныема тагын хат яздым.

Л ә й с ә н. Миңа да укыт әле?

Г а я з. Ярамый, мамзель, секрет!

Л ә й с ә н. Пожалуйста!

Г а я з. Йөрәгемне ярып бирәм, ләкин...

Л ә й с ә н. Юри генә әйтәм. Йөрәгегез дә, секретыгыз да үзегезгә булсын. Безгә бирәү йөрәген бүләк итте инде, икәү кирәкми. Ауфведерзәен! *(Өйгә кереп китә.)*

Г а я з *(кул селкеп кала)*. Һай-дю-дю-дю!

Өйдә Ләйсән җырлый. «Дулкыннар» романсы.

Алсуланып таңнар атканда
Дулкыннарның тавышын тыңладым,
Дулкыннарның тавышын тыңладым да
Сиңа атап җырлар җырладым.

Гаяз *(тәрәзәгә барып)*. Сорарга мөмкинме?

Ләйсән. Рәхим итегез!

Гаяз. Җырыгызны миңа атап җырламыйсыздыр бит?

Ләйсән. Һич юк! *(Өйдән чемодан алып чыга. Әйберләрен кагып кире тутыра.)*

Сине сагынып җырлар җырладым,
Синдә генә минем уйларым;
Сагына микән иркәм мине, дип,
Көмеш дулкыннардан сорадым.

Гаяз. Миңа да сорарга мөмкинме?

Ләйсән. Мөмкин.

Гаяз. Иркәгез мин түгелдер бит?

Ләйсән. Түгел!

Ак дулкыннар шаулап килделәр,
Болай диеп җавап бирделәр:
— Монайма син, сеңелем, уйланма,
Иркән сине сагына,— диделәр.

Гаяз. Тагын сорарга мөмкинме?

Ләйсән. Мөмкин түгел.

Гаяз. Ләйсән, Себергә китәсезмени инде?

Ләйсән. Әйе.

Гаяз. Нишләп?

Ләйсән. Чакыралар.

Гаяз. Кемнәр чакыра?

Ләйсән. Әйтергә ярамый, сэр. Секрет!

Гаяз. Ә без — тилебәрән орлыгы ашаган нәрсәләр... *(Чишенә.)* Ярый, китегез. Син дә котылырсың һәм, әйтергә кирәк ки, мин дә... Аркага су сал әле, зинһар өчен, бик бөркү.

Ләйсән. Коеныл мен.

Гаяз. Бүген унҗиде тапкыр коендым, ләкин тәнем һаман мунча ташы шикелле... Эчем-тышым ут. Йөрәгем яна, йөрәгем, йөрәгем, йөрәгем!.. Сүндерергә пожарниклар гына юк... Я инде, җаным, бер генә тынла инде!

Ләйсән. Ялланган ялчын юк, егет.

Гаяз. Пожалуйста! *(Чыга.)*

Ләйсән. Соңгы көн итеп кенә, ишетсен колагың. *(Бер чиләккә бармагын тыгып карый. Аньсын куеп икенчесенә тыга. Хәйләле генә көлемсерәп шунсын алып чыгып китә. Артта Гаязның: «Ай, беттем, беттем, үтердең!» — дип кычкырганы ишетелә. Керәләр.)*

Гаяз. Нинди су булды бу?

Ләйсән. Гап-гади су — һаш два о.

Гаяз. Гаҗәп. Антарктикадан килгән диярсең. Воспаление легких эләктерергә мөмкин.

Ләйсән. Чишмә суы шулай баса ул. Йөрәк утың да сүнәр, усаллыгың да бетәр. Югыйсә, тешләк ат шикелле тешләшергә генә торасың.

Гаяз. Дөньясы шулай. Күп кешеләр тешләшә. Үбешеп кенә торганнары сирәк.

Ләйсән. Түгел. Син аларны күрергә генә теләмисең. Җир өсте гүзәл бакча кебек. Илһам Шакировны тыңлап кара. Ул да «Дөнья матур, дөнья киң» дип, тикмәгә генә җырлый дип беләсеңме әллә?

Гаяз. Мескен чеби! Син тормышны җыр тыңлап кына беләсең шул. Дөнья катлаулы ул, ай-һай, катлаулы. Шул катлаулары арасына бер кереп адашсаң — кире чыгармын димә... Ятасыз шунда пошыйлар шикелле өчәүләп. Кама ярында.

Ләйсән. Иртәгә китәбез.

Гаяз. Лэйсэн!

Лэйсэн. Ә-ә. Кем тия?

Гаяз. Безнең янга дигэн идегез бит. Бергә эшләр идек!

Лэйсэн. Себергә!.. Чакыралар.

Гаяз (*киенә, фотоаппарат, транзистор аса*). Хушыгыз, миледи!

Лэйсэн. Хушыгыз, сэр! Кырмыска халкын кәртечкәгә төшерергә китеп баруыгызмы тагын?

Гаяз. Дөрес, туташ, күрәзә икәнсез. Икенче тапкыр хушыгыз, туташ. (*Лэйсәннең кулын үпмәкче була.*)

Лэйсэн (*аның җилкәсенә чүмеч белән суга*). Хуш, Әгерже диванасы!

Гаяз (*җилкәсен ышкый-ышкый чыга*). Бәхил булыгыз, игезәк иптәш!

Лэйлә керә.

Лэйсэн. Я, күрдеңме?

Лэйлә. Порядок!

Лэйсэн. Молодец син, Лэйлә. Кая, бер үбим эле шуның өчен.

Лэйлә. Кит әле, кит, кит! Әнә, Гаязың белән үбеш.

Лэйсэн. Гаязның бүтән кешеләре бар. Үзе генә калдымы, уйлана-моңлана башлый. Ай саен акча сала. Эшкә китик тә эшкә китик, ди. Телендә коңгыз да суалчан, тиен дә төлке. Ә яратам дияргә, юк — хәленнән килми.

Лэйлә. Минеке дә, бергә калдыңмы, төрле тимерчыбыклар, трансформаторлар турында сөйләргә тотына. Бик кызык дип белә инде әллә.

Лэйсэн. Яратмыйлар алар безне. Безнең ишеләрне күп күргәндер инде алар. Көләрләр, шаярырлар да тагын икенче җиргә китеп барырлар.

Лэйлә. Син дә бик кәнфитләнеп тормыйсың.

Лэйсэн. Кыз кеше әз генә ялындырырга, егет кеше ялынырга тиеш.

Лэйлә. Ялыну-ялындыруларның чамасын белмисез шул, оланнар. Шуның аркасында күпме чын гашыйклар аерыла.

Лэйсэн. Аерылу!.. Син моның мәгънәсен элек уйлый идеңме, апа?

Лэйлә. Юк. Хәзер уйлый башладым. Бик авыр икән ул.

Лэйсэн. Иртәгә бу вакытта без биредә булмабыз. Ә бу өй, бу чәчәкләр, бу каен, безнең юклыгыбызны да сизмичә, һаман шулай тыптын утырырлар. Апа, бәлки кире уйларбыз, ә?

Лэйлә. Бүтәннәр коммунизмны төзеп бетергәч кенә, исәнмесез, менә без дә килдек, дип барып керербезме?

Лэйсэн. Без монда да эшлибез ич.

Лэйлә. Ял йортында өстәл саен тәлинкә белән аш өләшәбез, ә? Мин зур тормыш эчендә кайнарга телим. Киләчәктә, кешеләрнең күзләренә туп-туры карап, фәлән шәһәрне мин дә салыштым, ул электр станциясен мин дә төзештем, диярлек булсын.

Лэйсэн. Себер барыбер Себер инде ул. Анда кая барып төшәрбез, кемдә торырбыз? Әллә чыннан да Хак абзый бригадасына гына эшкә керәбезме? Егетләргә дә шулай дигән идек бит?

Лэйлә (*көрсенә*). Шулай дигән идек шул!.. Юк, юк! Чынлап сөйсәләр әйтерләр иде. Китәбез!.. Себергә!.. Мәхәббәтең чабуыңнан тартып торуына карама.

Лэйсэн. Мәхәббәт! Нинди мәхәббәт?

Лэйлә. Кайнар! Көчле! Миннән дә яшерәсең, ә? Онытма: мин синең апаң. Мин синнән ундүрт минутка алданрак туган. Мин синнән үскәнем, ундүрт минутка олырак.

Л э й с ә н. Мин дә синең сеңелең, шуны онытма. Ундүрт минутка соң туганмын. Рәтле апалар үз сеңелләреннән көлмиләр.

Л ә й л ә. Я, я, сеңелем, үпкәләмә. Үпкә пешереп ашатырга үпкәм юк. Юлга аяк киенгән чакта ачуланышмыйлар... Я, көл әле, көл!.. Вот порядок!

Ярдан Х а к менә.

Х а к. Сәлам гүзәл сеңелкәшләргә — чибәр игезәкләргә!

Л ә й с ә н. Исәнмесез, Хак абзый!

Л ә й л ә. Привет!

Х а к. Һм, һм!.. Кая, әнкәгез чиләк дигән иде. *(Чиләк ала.)* Һм, һм!.. Сез, балалар, ике асыл егетне буйдак калдырырга йөрисез, ахры. Шулайрак сизелә.

Л ә й с ә н. Ай, кемнәр икән соң ул булачак бәхетсез буйдаклар?

Х а к. Кемнәр? Әкәм-төкәмнәр. Шуларның йөрәк утларын сүндерер идегез.

Л ә й л ә. Пожарник чакырсыннар.

Л ә й с ә н. Кайсысы кемне яндырырга тели соң ул утлы егетләрнең?

Х а к. Анысын инде үзегез чамалагыз. Кызларның күңел кылы нечкә — саба җиле кагылса да сизә.

Л ә й л ә. Юк инде. Безнең егетләребез бар. Шулар белән башкаларыбыз әйләнгән. Берсе бүген кунакка килә әле. Шуңа әзерләнеп йөрибез. Әйдәле, Ләйсән, теге чөгә балыгын чистартып куйыйк. Ул чөгә ухасын бик ярата.

Х а к. Чөгә? Стерлядь ухасы? Кайдан таптыгыз?

Л ә й с ә н. Мәхәббәт әллә нәрсәләр таптыра ул.

Л ә й л ә. Порядок!

Х а к. Никакой не порядок! Гаяз әйтмешли, нинди фиргавен мумиясенә ул?

Л ә й л ә. Хак абзыкаем, син ял йортының директоры түгел шул, кызганычка каршы. Бездән ул гына отчет сорый ала.

Керер китәләр.

Х а к *(артларыннан кычкырып кала)*. Их, үземнең унҗиде яшьлек чагым булса! Бик тиз өйрәтер идем мин сезне. Һм, һм... *(Як-ягына карапып.)* Дөресен генә әйткәндә, унҗиде яшьтә дә әллә ни кыра алмадым инде мин. Кырсам, шушы яшемә чаклы хатынсыз тормас идем...

Чыгарга бара. Каршысына Н ә җ и п очрый.

Н ә җ и п. Нишләмәс идең, Хак абзый?

Х а к. Авызымны ачып, күктән юк карганы санап йөрмәс идем. Син тиле өчен чәчәк шикелле кыз өзелеп тора. Ә син? Тьфү!?. Их, үземнең унҗиде яшьлек чагым булса! Күп мыңгерәүләнеп йөрсәң, кызыңнан колак какканыңны сизми дә калырсың.

Н ә җ и п. Колак? Кем кага?

Х а к. Кага түгел — кактырыр. Унган егетләр!.. Һм, һм!.. *(Чыга.)*

Н ә җ и п. Гаяз?!. Булмас! Ә ник булмасын? Кайбер хыянәтчеләр кызлар өчен дустын түгел газиз әнкәсен сата.

Өйдән Л ә й л ә чыга.

Л ә й л ә. Иң соңга калып син йөрисең, эшем нясе.

Н ә җ и п. Мин бит кайберәүләр шикелле әлле-мәлле, эттем-төрттем эшләмим. Көн буе чулт-чулт су кереп тә ятмыйм.

Л ә й л ә. Сиңа хат бар.

Н ә җ и п. Хат? Авылдан, әткәйдәндер.

Л ә й л ә. Әтиең Тәзкирә исемле икән.

Н ә ж и п. Түгел! Әйттем бит инде, эткәй үзе неграмотный. Күршедәге бәләкәй кыздан яздыра. Һаман ышанмыйсыңмы әллә?

Л ә й л ә. Юк. Давай, минем алдымда ач, минем алдымда кычкырып укы!

Н ә җ и п. Пожалуйста! Кая, бир әле.

Л ә й л ә. Бирде ди! Бие!

Н ә җ и п. Аю шикелле лап-лопмы? Булмый.

Л ә й л ә. Булмаса, җырла!

Н ә җ и п. Бозык патефон шикеллеме? «Ай янында якты йолдыз, ай янында якты йолдыз, ай янында якты йолдыз...» Булмый.

Л ә й л ә. «Мин җүләр!» дип өч мәртәбә кычкыр.

Н ә җ и п. Ләйлә! Зинһар, дим... Әкрен. Гаяз ишетсә, данымны бөтен дөньяга тарата бит. Европада торырлыгымны калдырмый.

Л ә й л ә. Азиягә китәрсең. Ишетми. Өйдә юк ул. Я инде, Тәзкирә исемле этиеңнең хатын укыйсың килмимени?

Н ә җ и п. Мин җүләр.

Л ә й л ә. Ишетелми.

Н ә җ и п. Мин җүләр!..

Л ә й л ә. Ишетмәдем — катырак!

Н ә җ и п. Мин җүлә-ә-әр!..

Л ә й л ә. Молодец! Җүләрлегеңне кешедән яшермисең — кычкырып әйтеп йөрисең. Юкса, бу дөньяда бик күп җүләрләр акыллы булган булып, акыл сатып йөриләр. Мә.

Н ә җ и п. Син... Кешегә ни-ни!

Л ә й л ә. Порядок!

Н ә җ и п. «Хат башы, алу белән яз каршы. Сезки бездән еракта... Сәлам.... Шәкерт абыйларыңның өй эчләре белән сәлам... Мулла түткәннән сәлам, абыз әбиеңнән сәлам... Бәләкәттәйдән, ерак җингидән, яшь җингидән... һем... һем... сәлам, сәлам, сәлам, сәлам... Бәрәңгеләрне бер ярты биреп тырматтык... Бер сарык зыянлады, страхаваен алдым... Сабан туйларына зар-интизар булып көтәбез... Тәк, тәк, тәк, тәк... Сагынып, эткәең һәм әнкәең дип белерсең... Хатны язды күршегездәге Тәзкирә сеңелең...» Я, ышандыңмы инде эткәйдән булуына?

Л ә й л ә. Юк. Хатны аны теләсә ничек укып була.

Н ә җ и п. Соң ул вакытта үзең укып кара, үз күзләрең белән. Мә!

Л ә й л ә. Ю-ук, кеше хатын укырга... Начар почтальонмы әллә мин... Кайтасыңмы соң? Сабан туена.

Н ә җ и п. Обязательно! Ел да кайтам, ел да көрәшәм. Егетләрне дөп итеп сыртлары белән җиргә салганда, җир дерт итә.

Л ә й л ә. Көрәшкәнеңне бер читтән генә карап торасы иде, мактанчык.

Н ә җ и п. Давай кайтабыз бергә: уртадан карап торырсың. О-с, безнең авылкай! Урман арасында, Ык буенда. О-о, яз көне! Сандугачлар — чут-чут, балыклар — чулт-чулт, бакалар — бака-как, бака-как, черкиләр — беззз-беззз!.. Июньнең икенче яртысында кара балык уйный башлый. Иртән питил карыйсың, питил таягы, көймә якынлашу белән, дырт-дырт итә башлый. Күтәрәсең — кара балыклар, табан балыклар — чупыр-чупыр, чупыр-чупыр!.. Йөрәк — леп-леп, леп-леп!.. А-ах, кайтам, кайтам, кайта-ам. Чын, әйдә син дә минем белән. Ыкта җәен тотарбыз.

Л ә й л ә. Чыннан да алып кайтыр идеңме?

Н ә җ и п. Кайтыр идем, әгәр...

Л ә й л ә. Әгәр?

Н ә җ и п. ...«Сөям!» дип өч тапкыр кычкыр!

Л ә й л ә. Акылыгыз алтын икән, нәнәм. Миннән ул сүзне ишеткәнче сакалың биленә җитәр... Кара әле, тегене сөйләп бетер инде!

Н ә җ и п. Кичәгенеме?

Л ә й л ә. Әйе.

Н ә җ и п. Кай төштәрәк калган идем соң?

Л ә й л ә. Шалт! дигән төштә.

Н ә җ и п. Ә-ә. Шуннан үзе сизми дә кала — шалт тимерчыбык моның кулына. Теге... пух җиргә. Очып төшеп китә. Чыжт — биш метрлы сырынды эченә. Безнең йөрәк — жу. Тик пычагым да булмады. Ялт килеп чыга бу кар астыннан. Өстен кага да... тып-тып китә дә бара разбойник... Бетте.

Л ә й л ә. Бер егетнең имтихан биргәнен ишеткәнең бармы?

Н ә җ и п. Юк.

Л ә й л ә. Бер егет институтка керергә географиядән имтихан бирә икән. Моңа вулканнар турында сөйләргә чыккан. Авыл егете. Русчаны ипи-тозлык кына белә. Нишләргә? Шуннан соң тоткан да, ди, бу «Земля — эһ, магма — пых!» дип әйткән ди.

Н ә җ и п. Батыр булган икән. Кергәнме соң?

Л ә й л ә. Кергән. Хәзер үзе шул институтта география укыта, ди. Син дә нәкъ шулай. Чаж-чож, шалт-шолт!

Н ә җ и п. Нишләмәк кирәк, ходай сүз байлыгыннан мәхрүм иткәч. Аннан соң...

Л ә й л ә. Я, я!

Н ә җ и п. Башка урында болай ук түгел мин.

Л ә й л ә. Ничек?

Н ә җ и п. Меж-меж түгел — ялт-йолт!

Л ә й л ә. Нишлисең ялт-йолт?

Н ә җ и п. Сөйлим.

Л ә й л ә. Ә-ә...

Н ә җ и п. Ләйлә!

Л ә й л ә. Тыңлыйм.

Н ә җ и п. Китәбезме инде?

Л ә й л ә. Китәбез инде, Нәҗип — Себергә! Бик нык чакыралар бит, сездән башка Себернең яме юк, диләр.

Н ә җ и п. Уф!.. Янам. Тастымал чыгар әле, Камага чумып чыгыйм!

Л ә й л ә. Хәзер. *(Тастымал алып чыга.)* Мин дә коенам.

Н ә җ и п. Мин тиз генә. Чулт — чумам, пулт — чыгам.

Л ә й л ә. Мин дә чулт — чумармын, пулт — чыгармын. Чыкмасам, коткарып медаль алырсың. Ни күрсәк тә газиз башкайларыбыз бергә күрер, җаным.

Н ә җ и п. Ташла әле шул мыскыл итүенне.

Л ә й л ә. Ничек? Шык итепме?

Н ә җ и п. Шаяртма! Йөрәгемне ярсытсаң...

Л ә й л ә. Йөрәгең ярсыса нишләрсең, минем кыю монтажнигым?

Н ә җ и п. Башканы ярата дип тормам, тотармын да чыр-чыр кычкыртып үбәрмен.

Л ә й л ә. Чүп итепме? *(Тастымал белән Нәҗипнең муеныннан эләктерә дә, сикереп үбеп ала.)*

Н ә җ и п. Ах, әле син алаймы?

Л ә й л ә. Порядок!

Куышып су буена төшеп китәләр. Г а я з керә. Кепкасына нидер салып тоткан. Музыкасын бетерә. Сак кына тәрәзәгә килә. Шакый.

Г а я з. Ләйсән!.. Ләйсә-ән!..

Кулына кəзге тотып тезәнә-тезәнә Л ә й с ә н чыга.

Л ә й с ә н. Тыңлыйм.

Г а я з. Мин сиңа керпе бүләк итмәкче идем. Урманда тоттым. Менә!

Л ә й с ә н. Бәлки сез йөрәк дамагызга дикообраз яки аждаһа гына бүләк итәрсез, ә?!. *(Кереп китә.)*

Гаяз. Барып чыкмады бу, керпе иптәш. Балаларың елашып ята торгандыр, бар, шулар янына кайт. Аларны ташлама. Ятимнәргә дөньяда яшәү бик кыен. *(Читкә чыгып керпене җибәрә.)* Я, ник китмисең? Ник йомарландың? Күзеңне-башыңны күрсәтергә теләмәсәң, инәле сыртыңны булса да картечкәгә төшереп калыйм әле. Очрашуыбызның кайнар истәлеге итеп, сагынганда карармын. Кара, хәзер менә моннан чыпчык очып чыга... Булды, керпе туганкай, хуш! Бала-чагаларыңа миннән сәлам әйт!.. *(Транзисторын боргалый. Стильный танец тота. Кызыгып бии башлый. Хәрәкәт тизләнә, кыза. Гаяз кычкырып-кычкырып җибәрә.)*

Лэйсән чыга. Баскычка басып аңа карап тора.

Гаяз. Читкә китәсең инде, ә?.. Тормыш кайнаган җиргә, ә? Шушындый танцылар оясына!.. Өйрәнеп барырга киңәш итәм... Уңайсыз хәлдә калмас өчен...

Лэйсән горур гына баскычтан төшә. Очынып-очынып бии башлый. Гаяз гаҗәпләнеп, хәлдән таеп туктарга мәҗбүр була. Музыка бетә. Лэйсән, Гаязга янадан горур караш ташлап, өйгә кереп китә. Нәҗип белән Лэйлә су коенып менәләр.

Лэйлә. Нигә бик күңелсез син, Гаяз?

Гаяз. Койма ярыгыннан да көлеп йөрүче кыз булып тумаганмын. Натурам шундый.

Лэйлә. Үз натураңа да баш була алмагач, чыннан да кыз булып туасың калган. *(Кереп китә.)*

Нәҗип. Натураны аны шартлатып кулга алырга кирәк.

Гаяз. Син, балакай, бөтенләй икенче нәрсәне кулга алырга йөрисең бугай?

Нәҗип. Анысы инде безнең эш.

Гаяз. Бәлки анда бүтәннәрнең дә эше бардыр?

Нәҗип. Юк. Бүтәннәр үз эшләрен генә белергә тиешләр. Минекенә чыш-пыш тыгылмасыннар!..

Гаяз. Мин сезне никтер аңламыйм, сэр. Сез кеше территориясенә басып кереп «Каравыл» кычкырырга җыенасыз шикелле?

Нәҗип. Киресенчә, без үзебезнекен генә саклыйбыз. Әгәр кайбер акыллы башлар кешенекенә омсына башласалар, без инде үз иминлегебезне якларбыз отпор бирербез.

Гаяз. Ультиматумыгыз кабул ителде. Инде безнең чикне үтәргә маташучылар булса...

Нәҗип. Өч йөз дә кырык тугызынчы катгый һәм соңгы кисәтүегез искә алынды.

Гаяз. Браво! Акылыгыз камилләшә бара, мистер. Кичке институтта укуыгызның җимешләре күренә башлады.

Нәҗип. Комплиментыгыз өчен рәхмәт!

Гаяз. Сэр, түбәнчелек белән бер сорау бирергә рөхсәт итегезче?

Нәҗип. Валяй!

Гаяз. Бу фәкыйрь колыгызга хәзинә сандыгыгыздан егерме биш динар сонмассыз микән?

Нәҗип. Җитмеш ике сумыңны кайчан түлисең?

Гаяз. Баеган көннең икенче көнендә үк дидем бит инде. Бу юлы менә лотереяны да күп алдым әле. Кайгырма. Баттымы?

Нәҗип. Батмады.

Гаяз. Сез, сэр — Морган, Рокфеллер, Форд, Һарун-эль-Рәшид, Дженерал-Моторс... Балыгыз бармы?

Нәҗип. Ә? Бал? Нәрсәгә бал?

Гаяз. Үләр алдыннан акчагызны балга манып ашарсыз.

Нәҗип. Ә-ә-ә!.. Дөп-дөп күкрәк сугып, шыр-шыр мактанып йөргәч тә кем икәнлегегезне белмиләр дип уйлама.

Гаяз. Бик шәп. Мин дә үземнең кем икәнлегемне беләм. Маршал Жуков та, Юрий Гагарин да түгел, пып-простой алла бәндәсе.

Нәҗип. Ю-ук, син алла бәндәсе түгел! Кесәндә шыгыр-шыгыр бер пачка перевод кәгазе йөртәсең, бездән яшереп акча саласың. Ә үзең шып-шыр ялгыз. Кемгә саласың? Аракыны да нормальный гына эчәсең, ә гел-гел акча сорыйсың. Ни өчен? Белмибезме? Беләбез, иптәшкәй. Бәләбәйдә сине ни өчен милиция чакыртты, тәпи-тәпи киттең? Күреп торабыз.

Гаяз. Нәрсәне күреп торасыз?

Нәҗип. Шартлатып әйтергәме?

Гаяз. Шартлатыгыз, сэр!

Нәҗип. А-ли-мент исе килә моннан.

Гаяз. Алимент?!

Нәҗип. Җитмәсә, монда берьюлы ике кызның башын әйләндермәкче буласың. Шалиш! Монда без бар әле. Мин бар — Нәҗип.

Гаяз. Авызыгыз ни әйткәнне колагыгыз ишетәме? Да провалитесь вы ко всем чертям, сэр!..

Ләйсән белән Ләйлә чыга.

Ләйлә. Ни булган боларга? Сөзешергә кыҗраган тәкәләр шикелле торалар.

Нәҗип. Менә хәзер шык итеп маңгайга-маңгай бәреләбез, күзләребездән ялт итеп ут күренә.

Ләйсән. Шырпы беткән иде, шуннан гына ут төргезим әле. Я, бәрелешегез.

Ләйлә. Эш беткәч кенә уйнарга ярый, егетләр.

Гаяз. Бәндә эштән бушамас, ди корьән.

Нәҗип. Тсс! Давай эшеңне, Ләйлә!

Ләйлә. Без бүген саубуллашу мәҗлесе үткәрәбез.

Гаяз. Һай, бәрәкалла! Мәҗлестә ашап-эчеп утыру эшмени ул.

Ләйсән. Аны башта әзерлисе бар әле.

Гаяз. Уратып-уратып интектергәнче турыдан шәрран ярып сүз башларга иде. Әйдә, старик, син токмач басарсың, тавык йолкырсың, мин шешә бөкеләре ачармын.

Нәҗип. Мин — шырт-шырт тавык, син — шалт-шолт шампан бөкесе! Батмый!

Ләйсән. Бала-чага шикелле кыланмагыз инде. Токмачына, умачына тыгылмагыз. Өстәл-урындыклар хәстәрләгез.

Нәҗип. Без аны — ялт-йолт, бетте-китте, вәссәләм! Әйдә, Га- Эттин туган!

Гаяз. Тыңлыйм һәм буйсынам, тәкъсир.

Егетләр өйдән өстәл алып чыгалар. Аны кая һәм ничегрәк куярга икәнен кызлардан сорый-сорый, берсе — монда, икенчесе — тегендә, ди-ди, тартышып йөриләр. Ахырында, урын табалар.

Гаяз. Уф, юк, барыбер менә мондарак, мсье. *(Өстәлне үз ягынарак тартып куя.)*

Нәҗип. Минемчә, чут-чут мондарак. *(Өстәлне үз ягына шудыра.)*

Кызлар моны көлеп карап торалар да, менә монда аның урыны, дип, өстәлне бөтенләй икенче җиргә илтеп куялар.

Гаяз. Мин кайчаннан бирле, шунда кирәк, дип, бу кире беткән Голдуотер белән тартышам бит.

Ләйлә. Инде урындыклар куеп чыгыгыз, монда, монда...

Гаяз. Стоп, леди! Җиденчесе кемгә?

Нәҗип. Алты гына борын чыга бит монда.

Ләйсән. Эгоистлар! Яз басып торсынмыни?

Нәҗип. Яз? Нинди Яз?

Г а я з. Ансы нинди Килиманджаро маймылы тагын?

Л ә й л ә. Менә нәрсә, иптәшкәйләрем, без сезнең кызларыгыз белән кызыксынмыйбыз бит. Сез дә безнең егетләр турында артык төпченмәгез, килгәч күрерсез.

Л ә й с ә н. Моряк! Безнең ял йортында ял итә.

Н ә җ и п. Шартлатып кына әйтегез әле, ник тыкшына ул безнең күңелле мәҗлескә? Нинди Яз ул? Монда Гаяз дигәненнән дә теңкә корыган.

Л ә й л ә. Бу мәҗлесне кем өчен дип беләсез соң?

Н ә җ и п. Һем... Кем өчен... Менә безнең... безнең бөтенебез өчен.

Л ә й с ә н. Бу мәҗлес — Яз белән саубуллашу мәҗлесе.

Г а я з. Ул Кавказ бурсыгы, бүлмәсендә генә утырса, ияк астына май төшәр, дип курыкты микәнни?!.

Е г е т л ә р *(өстәлнең астын-өскә аударып, аның бер башындагы ике урындыкка утыралар)*. Хы!..

К ы з л а р *(аларга аркалары белән әйләнеп өстәлнең икенче башына утыралар)*. Һе!..

Г а я з. Афганстан чәүкәсе өчен өстәл ташып интек, ә?

Н ә җ и п. Тыр-тыр йөгерә-йөгерә. Ул килсен дә шыпыр-шыпыр шулпа шупырсын, голт-голт коньяк эчсен! Хы!..

К ы з л а р. Һе!..

Е г е т л ә р *(чыгарга барган җирләреннән кире кереп урындыкларын аударып куялар)*. Хы!..

К ы з л а р *(урындыкларын аударып куялар)*. Һе!..

Г ө л б а н у белән Х а к кереп бу тамашаны сүзсез генә карап торалар.

Г ө л б а н у. Ни кыланалар болар, Хак? Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?

Х а к. Цирк бу, гипноз, Гөлбану.

Л ә й л ә. Егетләр яңа уен өйрәнеп кайтканнар, шуны уйныйбыз.

Г а я з. Мадмуазельләр әзрәк ниткәннәр. *(Башына ымлап, акылларына зәгыйфьлек килгән, дигәнне аңлата.)*

Егетләр чыгарга баралар, ләкин каршыларына кереп килгән Я з н ы күреп туктап калалар. Яз диңгезчеләр фуражкасы, тельняшка кигән. Аның җиңнәрен сызганып җиб[illegible] Кителен иңенә салган. Беләге татуировкалар белән чуарланып беткән. Авызында зур диңгезчеләр трубкасы. Җилкәсендә кызыл бантлы гитара.

Я з *(трубкасын пышкыртып ирен читенә күчерә)*. Безне көткән тыгез [illegible] гавань шушы координаттамы?

Л ә й с ә н. О-о, Яз абый! Килдегезме? Рәхим итегез!

Л ә й л ә. Керегез, Яз абый, без инде сезне күптән көтәбез. *(Гөлбануга.)* Шушы инде ул, әни. Зинһар, сынатма.

Я з. Норд-ост. Исәнмесез!

Л ә й с ә н. Таныш булыгыз, Яз абый — безнең әни!

Г ө л б а н у. Исәнмесез, Гөлбану.

Я з. Исәнмесез, Гөлбану ханым! Без — СССР Кара диңгез сәүдә флотының Одесса портына теркәлгән дөньядагы иң зур мәшһүр «Кошалат» пароэлектротеплоходында планетабызның бөтен диңгез һәм океан державаларына йөрүче потомственный моряк Я[з] Штормовой. Булачак капитан I ранга, так сказать.

Г ө л б а н у. Бик шатмын. Рәхим итегез!

Х а к. Морской волк!

Л ә й с ә н. Монтажчылар бригадиры Хак абзый.

Х а к. Исәнмесез-саумысыз, туган!

Я з. Исәнмесез, исәнмесез, бригадир!

Л ә й л ә. Бу — монтажник Гаяз.

Г а я з. Телебез бар. Үзебез дә таныша алабыз. Без — СССРның Азия континентында бөек Транссибир гадәттән тыш югары вольтлы электр тапшыру линиясен төзегән, СССРның Европа континентында иң зур Кырым, Кавказ, Волга, Днепр, Литва, Латвия, Мәскәү, Ленинград, Казан, Уфа һәм башка шуның ише йөзләрчә тиңдәшсез электр линияләрен монтажлаган, якын киләчәктә Айда һәм Марста электр линияләре сузачак, бөтен тирә-якта атаклы потомственный монтажчы Гәяз... Гаяз Громовой. Булачак министр, так сказать.

Я з. Бик шатмын!

Г а я з. Үтереп шатмын.

Н ә ж и п. Ә без... без... без булабыз... ых... пых... шырт...: *(Кукрәгенә сугып)* Нәҗип инде... *(Тагын суга.)* Нәҗип!..

Я з. Бик шатмын!

Н ә ж и п. Шат, әйтәсе дә юк.

Л ә й л ә. Яз абый, утырыгыз! Хәзер табын әзерлибез.

Л ә й с ә н. Без хәзер. Егетләр, булышыгыз инде.

Я з. Борчылмагыз. Миңа болай да рәхәт. Үземне авыр вахтадан соң кают-компаниядә ял вакытындагы шикелле хис итәм.

Кызлар җәһәтләп, егетләр авырсынып кына өстәл-урындыклар, табын әзерли башлыйлар.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге күренеш. Безнең геройлар өстәл тирәсендә ашап-эчеп утыралар. Түрдә — Яз. Аның ике ягында ике кыз. Ярыша-ярыша, кыстый-кыстый аны сыйлыйлар. Егетләргә бу ошамый, алар кара коелганнар. Әчмиләр. Шуна да карамастан, Хак аларга, эчмәсеннәр, сынатмасыннар, дип, күз-колак булып тора.

Л ә й с ә н. Менә, алмасын ашагыз, Яз!

Л ә й л ә. Хөрмәсеннән дә авыз итегез, Яз!

Н ә ж и п. Шытыр-шытыр кимерегез. *(Шикәр ашый.)*

Х а к *(бармак селкеп)*. Әй!

Я з. Вот Италиядә ул алма. Сөйләргәме?

Г ө л б а н у. Сөйләгез, сөйлә, Яз иптәш!

К ы з л а р. И кызык!

Г а я з. Джентельмен авызын ачканчы ук кызык икән, ә. *(Шикәр ашый.)*

Я з. Юк, мин сезгә башта бер нәрсә күрсәтим әле. *(Кесәсеннән кирпеч ватыгы ала.)* Ни бу, беләсезме?

К ы з л а р *(карыйлар)*. А-яй, бик истәлекле, кадерле таштыр инде бу?

Г ө л б а н у *(карый)*. Каты.

Х а к *(карый)*. Кызгылт төстә.

Н ә ж и п. Шып итеп бәрсәң, шырт итеп сына торган гап-гади кирпеч кисәге.

Я з. Дөрес, кирпеч кисәге. Ләкин кайдан? Нинди? Белмисезме? Колизей кирпече бу! Рим символы Ко-ли-зей!.. Беренче гасырда төзелгән. Антик ый чор, флавилар эпохасы! Белдегезме? Узган ел булдым мин Римда. Шунда сувенир итеп алып тыккан идем.

К ы з л а р. Ах, ах! Сез нинди бәхетле! Моряк!

Н ә ж и п. Сәүдә флотыныкы икәнен онытмагыз, күмер ташый.

Г а я з. Булсын. Тыныч чорда сәүдә итү — безнең илнең төп политикасы. Политзанятиеләргә йөрергә киңәш итәм... Капитан, бу чыннан да бик кадерле таш.

Я з. Капитан ук түгел әле.

Гаяз. Булырсыз. Капитан булырга теләмәгән матрос — начар матрос дип әйтә торган иде минем бер дус контрадмирал. Сувенирыгызны миңа бүләк итегез, ә?

Яз. Булдыра алмыйм.

Гаяз. Сатыгыз?

Нәҗип. Акчасы бик күп.

Яз. Сата да алмыйм. О, Италия! Микеланджело! Помпей! Зәңгәр диңгез!.. Бу ташка Франциядә узган айда бер банкир йөз мең франк бирде — сатмадым.

Гаяз. Сез, иптәш капитан, чын коллекционер.

Яз. Мерси!

Гөлбану. Ашап-эчеп утырыгыз әле, егетләр!

Ләйсән. Менә бу рюмканы эчеп җибәрегез әле, Яз!

Яз *(канәгать)*. Ник мин генә? Ә егетләр?

Ләйлә. И алар! Алар гади халык! Кайчан эчсәләр дә үз кулларында.

Нәҗип *(ачулы)*. Яшь чакта без аны менә болай ялт-йолт, беттекитте и вәссәләм итә торган идек. Ә бүген ярамый — катар желудка.

Гаяз. Кичә мине дә Мәскәүдән килгән атаклы профессор, академик карады. Бери-бери авыруы тапты. Соңгы стадия. Тоже бүгеннән эчәргә ярамый.

Яз. Алай булгач, сезнең саулыкка, Гөлбану ханым, сезнең саулыкка, кызлар! *(Эчә.)*

Гаяз. Синең саулыкка, монтажник!

Нәҗип. Синең саулыкка, монтажник!

Ипи ашыйлар.

Ләйсән. Менә, балык кабыгыз!

Гаяз. Рәхмәт!

Ләйсән. Сиңа әйтмим. Балык кабыгыз, Яз абый!

Яз. Балык дигәннән, быел кораблебез Кара диңгездә дельфин көтүенә очрады. Ә беләсезме, дельфин ничек барлыкка килгән?

Кызлар. Ах, ах! Сез нинди бәхетле. Диңгезләр, илләр кичәсез. Дельфиннар күрәсез. Сөйләгез, сөйлә! Ах, ах!..

Яз. Бер вакытны хәмер һәм шатлык алласы Дионис, гади кеше киемнәре кигән дә, Наксоска бара торган корабльгә утырып киткән һәм юлда менә безнең шикелле морякларны дельфинга әйләндергән.

Кызлар. Ах, ах! Сезнең шикелле?

Яз. Әйе. Алар шуңа күрә дә бик акыллы бит. Хәтта тапкырлау таблицасын яттан беләләр... Менә, шушындый егетләрне әйләндергән инде.

Гаяз. Юк, безне әйләндермәгән. Без кеше, без монтажниклар, сэр. Таблицаны да яттан белмибез.

Яз. Ни өчен әйләндергән дисәгез, моны матрослар әсир итеп коллыкка...

Гаяз аңа үч итеп транзисторын боргалый. Язның сүзе ишетелми башлый.

Гөлбану. Яшьләр, мине гафу итегез, минем хәзер Мәскәү — Пермь теплоходын каршылыйсым бар. Хак, мине озатасыңмы?

Хак. Әйдә, Гөлбану. *(Егетләргә.)* Их, бөркет бит, бөркет! Һичшиксез, адмирал булачак. Ә сез...

Гаяз. Хак абый, Аллямнарның йил тирмәне аман аляна микән? Ул ни?

Нәҗип. Цатыр-цотыр сапкан сакта кәркәш бавым шарт итте. Ул нәстә?

Хак. Тьфү, ана шайтан балалары! Сез хулиганнар белән йөрийөри нәфис мишәр телемне дә онытып бетердем бугай инде. Кулатка-

га кайтсам, капкаларыннан да кертмәсләр. Син, товарищ, безнең Сембер мишәре түгел — кайдан килдең — шунда кит, диярләр. Склероз, склероз харап итә яшь кенә башымны... Әйдә, Гөлбану!..

Китәләр.

Я з. Ах, кызлар, кызлар!

Л ә й с ә н. Синең белән бергәләп илләр-җирләр гизеп йөрсәң иде!

Л ә й л ә. Нинди бәхет бит ул, нинди бәхет!

Я з. Аһ, кызлар, кызлар, теләсәгез, корабльгә урнаштырам мин сезне. Капитан минем бик якын дус.

Л ә й с ә н. Яз абый, әгәр урнаштырсаң, беләсеңме — мин сине үбәрмен.

Г а я з. Башта абый — аннан җаный. *(Чәнечкесен өстәлгә ташлый.)*

Л ә й л ә. Мин дә үбәр идем, мин дә!

Н ә җ и п. Чупылдатып ятларны үбәм дип торсын, син күзеңне чепелдәтеп утыр. Хурлык! *(Өстәлгә чәнечкесен ташлый.)*

К ы з л а р. Сөйләгез әле, сөйләгез әле тагын, Яз абый?

Я з. Фәрештә шикелле кызлар сорагач, ничек сөйләмисең. Мәккәдә булдым бит әле мин, кара ташны күрдем. Шуны сөйлимме?

К ы з л а р. Сөйләгез, сөйлә!

Н ә җ и п. Хаҗга баргач хаҗи буласыз түгелме соң инде сез, ә?

Г а я з. Гафуыгызны үтенәм, бая кызыл таш иде, хәзер кара таш. Бетмәс ташлар. Сез безгә лутчы гитарагызны чиртеп җырлап күрсәтегез.

Н ә җ и п. Ие. Даешь җыр вә музыка! *(Гармонен ала).*

Я з. Була ул. Чиртеп тә, җырлап та күрсәтербез. Бәлки башта кызлар җырлар, ә? Татар көйләрен сагындым.

Л ә й л ә. Әйдә, уйна, Нәҗип!

Н ә җ и п. Нәҗипнең дә кирәк чагы булыр икән.

Нәҗип «Кызлар вальсы»н уйный. Җыр, бию.

Алмагачка чыклар төшкән,
Аны сандугачлар эчкән —
  Күрәсеңме, егеткәй?
Минем күңелем сиңа төште,
Исемнән чыкмыйсың һич тә —
  Сизәсеңме, сизәсеңме, сизәсенме, егеткәй?

Чәчәк аткан алмагачлар,
Чут-чут сайрый сандугачлар —
  Тыңладыңмы, егеткәй?
Ул да тыңлый торгандыр, дип,
Мине уйлый торгандыр, дип,
  Уйладыңмы, уйладыңмы, уйладыңмы, егеткәй?

Яз — гашыйклар үбешкән чак,
Егет-кызлар күрешкән чак —
  Беләсеңме, егеткәй?
Челтер-челтер чишмә ага,
Чибәр кызлар суга бара —
  Килерсеңме, килерсеңме, килерсеңме, егеткәй?

Я з. Браво!.. Рәхмәт!.. Искиткеч!.. Бу глушьта әрәм булып ятканчы — консерваториягә керергә кирәк сезгә.

Л ә й л ә. Ах, сез безне артык мактыйсыз. Үтенәбез, инде сез үз һөнәрегезне күрсәтегез!

Н ә җ и п. Менә әргән. Тартыгыз колагын!

Я з. Һо, что сез. Гармун ул монда гына. Европада гитара патшалык итә. *(Гитарасын ала.)* Бар инде ул сез ишетмәгән яңа җыр, бар.

Менә «Моряклар жыры». Мин аны Нептун бәйрәмендә җырладым. Корабль экватор аша үткәндә шундый бәйрәмчик була. Беренче приз!.. Кызганыч, бик кызганыч. Бармаклар якорь чылбырына кысылган иде, төзәлеп җитмәгәннәр икән — бөгелмиләр. Тамак та карлыккан. Что-то не в форме мин бүген.

Кызлар. Ах, ах!.. Нинди кызганыч!..

Яз. Егетләр үз һөнәрләрен күрсәтер бәлки?

Гаяз. Капитан, рөхсәт итсәгез, без үзебезнең энебезне генә җырлатыр идек. *(Транзисторын бора.)*

Ләйсән. Культурасыз.

Гаяз. Гафу кылыгыз, әдәмиләр. Бүлмә бик бөркүләнеп китте. Безнең кораблар саф һавага дуслык визиты ясамакчы иде.

Нәҗип. Әйе. Полный вперед, монтажник!

Гаяз. Стоп! Трави назад! Бу әргән белән дә танышып китик әле. *(Гитара ала.)* О-о, таш гасырдан бирле настроить итмәгәннәр бу оркестрны. Төрле кылы төрлечә акыра. Яле, коллега, «си»не бир әле миңа.

Нәҗип. Җаныгыз теләгәнне бирәм, коллега. *(Гармонен алып, Гаяз сораган авазларга баса.)*

Гаяз. Әһә, үз тавышыгызны таптыгызмы! До, ре, ми, фа, соль, ля, си, до — до, си, ля, соль, фа, ми, ре, до! Порядок! Монтажник, даешь «Моряклар җыры»н!

Нәҗип. Есть, «Моряклар җыры»н!

Гаяз гитарада, Нәҗип гармоньда уйнап «Моряклар җыры»н җырлыйлар.

Җилферди тасмалар җиләс җилләрдә,
Китәләр кораблар ерак җирләргә.
Тыныч юл теләп, кавышу теләп
Сөйгәннәр кала туган илләрдә.

Кушымта:

Океан, океан,
Океаннар өстендә кораблар.
Еракта, еракта,
Көньякта, төньякта
Ярларын сагынып
Йөзәләр моряклар.

Үтәләр айлар һәм үтәләр еллар,
Озын да бу юллар, авыр бу юллар.
Авыр юлларда йөри егетләр,
Тирбәтә аларны зәңгәр дулкыннар.

Кушымта:

Көннәр үтсеннәр һәм еллар үтсеннәр,
Шауласын дулкыннар, җилләр иссеннәр,
Тик онытмасын безне сөйгәннәр:
Сагынып көтсеннәр, кайтыр, дисеннәр.

Кушымта:

Гаяз. Концерт тәмам, джентельменнар. Тәбрикләр һәм чәчәк бәйләмнәре кабул итә башлыйбыз.

Нәҗип. Чып-чып кул чабарга мөмкин.

Яз. Поразительно!

Гаяз. Право руля, матрос. Курс — саф һавага!

Нәҗип. Есть, право руля.

Гаяз *(чыгып барышлый борылып)*. Ә сезнең теге кызыл кирпечләрне Италия властьлары төн саен бер машина китереп Колизей тирәсенә тараталар. Шулай итмәгәндә, Колизейдан «К» хәрефе дә калмаган

булыр иде инде: туристлар сувенирга ваклап ташып бетергән булырлар иде. Менә шулай, гражданин юнга.

«Монтажниклар» җырын җырлап чыгып китәләр.

Яз. Да-а...

Лэйлә. Уйламагыз аларны, Яз абый. Алар Колизейны барып күргән адәмнәрме!

Лэйсән. Җырларын да ташка үлчим. Бармагыгыз авыртмаса, күрсәтер идегез сез аларга: сез бит әнә нинди егет!

Лэйлә. Белмәгән нәрсәгез юк.

Яз. Капитаннар да шулай диган булалар шул.

Лэйсән. Сез әле адмирал булырсыз.

Лэйлә. Адмиралларның адмиралы.

Яз. Ихтимал. Ният юк түгел.

Лэйсән. Ә тегеләә-р...

Лэйлә. Кызлар артыннан ухаживать итә дә белмиләр.

Яз. Мин сезне, чибәркәйләрем, теләсә кайда урнаштыра алам. Одесса портындагы барлык капитаннар минем дус.

Лэйсән. Безнең дә чит-ят илләрне күрер көннәребез булырмы икән?

Лэйлә. Парижның Елисей кырларында йөрербез микән?

Яз. Сезнең теләк минем өчен закон. Мин аны бик тиз эшлим. Кара диңгез белән Балтик диңгезендәге һәр капитан минем өчен үлеп тора.

Гөлбану тавышы. Лэйсән кызым, төш әле монда!

Лэйсән. Ах, ах!.. Карагыз әле, нинди матур! Өч палубалы туристлар теплоходы! *(Чыгып китә.)*

Яз. Синең исемеңне белеп кушканнар, Лэйлә. Син чыннан да Мәҗнүннең Лэйләсе шикелле гүзәл! Сине тудырган анага мең-мең рәхмәт яусын! Сине беренче күргәч тә, йөрәгемдә давыл кузгалды — мәхәббәт давылы. Ул минем күңелемнән тынычлыгымны, башымнан акылымны алды. Мин сине сөям, Лэйлә!.. Син дә сөй мине, сөй! Мин сөймәслек егет түгел. Без синең белән зәңгәр диңгезләрдә йөзәрбез, пальмалар серләшүен тыңларбыз... Таң алдыннан чишмә янына төш. Кызарып кояш чыгуын карарбыз. Икәү генә, ә?

Лэйлә. Ах, сез минем башымны бөтенләй әйләндердегез. Мин бик яшь кыз бит әле. Егетләр белән ялгыз йөргәнем юк. Без гел Лэйсән белән.

Яз. Юк, юк, аны ияртмибез. Аннан соң ул миңа... бик ошап та бетми. Мин синең белән генә булырга телим.

Лэйлә. Ах, йөрәгем әллә нишләп китте!

Яз. Аккошым минем! Сине генә сөям! Менә шуның билгесе. *(Исле-май бирә.)* Француз ислемае. Бөен дөньяда атаклы, затлы әйбер. Исе, бер сөртсәң, елга җитә. Үткән рейста гына Париждан алып кайттым. Синең өчеч дип...

Лэйлә. Мине ул чагында ук белә идегезмени?

Яз. Сине очратачагымны йөрәгем сизә иде.

Лэйлә. Ах, ах, һуштан язып егылмасам ярар иде.

Лэйсән керә.

Лэйсән. Лэйлә, әни сине чакырды, киңәшләрем бар, ди.

Лэйлә. Ах, ах!.. *(Китә.)*

Яз. Лэйсән, синең исемеңне белеп кушканнар. Син чыннан да лэйсән яңгыр кебек саф, чиста. Шул яңгырның җиңел тамчысы шикелле. Сине тудырган анага мең-мең рәхмәт яусын! Сине беренче күргәч тә, йөрәгемдә давыл кузгалды — мәхәббәт давылы. Ул минем күңелемнән тынычлыгымны, башымнан акылымны алды. Мин сине сөям... э-э-э... Лэйсән! Син дә сөй мине, сөй! Мин сөймәслек егет түгел! Без синең

белән зәңгәр диңгезләрдә йөзәрбез, пальмалар серләшүен тыңларбыз. Иртәгә кояш чыккач чишмә янына төш. Рәхәтләнеп серләшербез, ә? Икәү генә, ә?

Л ә й с ә н. И, Яз абый!.. Оялам ла мин. Без гел Ләйлә белән бергә йөрибез.

Я з. Ул безгә комачаулар. Мин синең белән генә булырга телим.

Л ә й с ә н. Йөрәгем леп-леп!..

Я з. Аккошым минем! Сине генә сөям! Менә шунын билгесе. *(Ислемай бирә.)* Бөтен дөньяга атаклы француз духие. Исе, бер сөртсәң, елга җитә. Гәрәбәне кызганмый салалар. Үткән рейста гына Париждан синең өчен дип алып кайттым.

Л ә й с ә н. Минем дөньяда яшәвемне кайдан белдегез соң?

Я з. Йөрәгем сизде.

Л ә й с ә н. И, Яз абый, әни фонарь сораган иде бит, оныттырдыгыз.

Фонарь алып чыгып йөгерә. Л ә й л ә керә.

Я з. Ләйлә, Ләйләм минем! Я инде, ничек? *(Кочакламакчы була.)*

Л ә й л ә. Ах, ах!.. Ләйсән кайда соң? Әни фонарь көтә ич!

Кулыннан ычкынып, елмая-елмая чыгып йөгерә. Л ә й с ә н керә.

Я з. Әһем-әһем... Ләйсән, Ләйсәнем минем! Я инде, ничек? Чишмә янында дим? *(Кочакламакчы була.)*

Л ә й с ә н. И, Яз абый!

Кулыннан ычкына да елмая-елмая өйгә кереп китә. Л ә й л ә керә.

Я з. Ләйлә бә... *(Чыгып килгән Ләйсәнне күреп туктап кала.)* Бә... бәлки, мин әйтәм, Ләйсән белән өчәүләп Кама буйларында йөреп менәрбез?

К ы з л а р. Бик шәп булыр, әйдәгез!

Г ө л б а н у керә.

Л ә й с ә н. Әни, ник бик моңсу син?

Л ә й л ә. Безнең белән шатланырга, көләргә кирәк.

Г ө л б а н у *(урындыкка утыра, моңлана)*. Ана күңелен аңламыйсыз шул сез, балалар. Сездән аерылуны уйлап борчылмаслыкмыни!

Л ә й л ә. Әллә кая китәбезмени без? Кая барсак та үз җиребез бит, үз кешеләребез!

Л ә й с ә н. Безнең шикелле кызлар тайганы кисеп шәһәрләр сала, нефть, газ торбалары суза. Синең кызларың кемнән ким, әни, ә?

Г ө л б а н у. И балалар, Себер җире диләр шул аны. Сез ким түгел — анысын беләм...

Л ә й л ә. Әнием, безнең күңел давылларга ашкына. Яңа җирләргә, яңа дуслар арасына ашкына. Тормышны сынап карыйсы килә. Аның белән, якасыннан тотып, бер көрәшеп карыйсы килә.

Г ө л б а н у. Ә монда тормыш түгелмени?

Л ә й с ә н. Монда да тормыш. Ләкин без кем дә — Терешкова кем? Уйланырлык нәрсәләр күп. Син, әни, тик яткан таш мүкләнә дип үзең әйтәсең бит.

Г ө л б а н у. Сезгә мүкләнергә иртә әле. Заман үзе кешегә мүкләнергә ирек бирми хәзер. Элекке бер көнне бер сәгатьтә үтә.

Я з. Йөрсеннәр, Гөлбану ханым. Тормыш ул — мәңгелек хәрәкәт. Бер урында бер ай яшәсәм минем эчем поша башлый, тормыш аз эб эдтага әйләнә, ягъни, венгерча, эт тормышы дигән сүз, гафу итегез!

Г ө л б а н у. Сез — ир кеше. Ә болар?

Я з. Безнең боцман әйтмешли, хәзерге заманның ире дә, хатыны да юк. Барысы да бер. Һәммәсе укый, эшли, яңа тормыш төзи.

Л ә й с ә н. Дөрес!

Ләйлә. Яз абый дөрес әйтә. Я инде тынычлан, көл!

Гөлбану. Менә бетте, тынычландым.

Ләйсән. Ә син елмай!

Ләйлә. Порядок!

Гөлбану. Я, я! Сез инде әнә нинди зу-у-ур кызлар. Әйберләрегез җыелып беткәнме?

Ләйсән. Күптән инде.

Гөлбану. Кирәк нәрсәләрегезне онытып калдырмадыгызмы?

Ләйлә. Инде ун көн җыенып та.

Гөлбану. Кипкән кура җиләге алдыгызмы? Салкын тисә кайнатып эчәргә.

Ләйсән
Ләйлә } Алдык, алдык.

Гөлбану. Җылы оекбашларыгызны салдыгызмы?

Ләйсән
Ләйлә } Салдык, салдык.

Гөлбану. Җылы... *(Яз ягына карап ала.)* Җылы ни... *(Кызлардан шыпырт кына сорый.)*

Ләйлә. Ләйсән, син салдыңмы?

Ләйсән. Онытылган.

Гөлбану. Менә, әйттем бит. Монысы инде «порядок» түгел. Салыйм әле. Чемоданнарыгызны да тагын бер барлап чыгармын. *(Өйгә кереп китә.)*

Яз. Әйдәгез, кызлар, без дә!

Кызлар. Әйдәгез!

Кама буена төшеп китәләр. Як-ягына карана-карана Гаяз керә.

Гаяз. Менә иртәгә таң туар да — ул китәр. Мине онытыр. Тормышка чыгар, балалары булыр. Дөньяда Гаяз исемле пешмәгән төче кумәч барлыгын исенә дә кертеп чыгармас.

Ә ник төче кумәч соң әле мин? Ник башкалар шикелле кыю түгел? Юк, ни булса да, бөтен-бөтен батырлыкны җыеп, бүген мин аңа йөрәгемне ачарга тиеш. Менә хәзер, кеше-кара юк чакта. Отказ бирсә дә ул хәтле оят булмас.

Я, батыррак кылан, җебегән!.. Я, бер, ике... Ул хәзер өйдә булырга тиеш... *(Сакланып кына, иелә-иелә тәрәзәгә килә, чиртә.)* Ләйсән!.. Ләйсән!.. *(Тагын чиртә.)* Ләйсән!.. Ләй-сә-ән!..

Тәрәзә пәрдәсе күтәрелә. Гөлбану күренә.

Гөлбану. Ә?.. Кем бу?.. Ә-ә, синмени, Гаяз!

Хак керә. Бу хәлләрне гаҗәпләнеп карап тора.

Гаяз *(урмәләп арты белән чигенә)*. Юк... Ни... Болай гына... Бер-әр... теге... Ни... Шешә төбендә калмаганмы дигән сүз иде. Хе-хе-хе...

Гаяз чигенә-чигенә арты белән Хакның бот арасына килеп керә. Хак җайлап кына аның өстенә утыра.

Хак. Тәк, тә-әк. Кыз эзлисеңмени, тәтәй егет?

Гаяз. Личный эшемә тыгылма, бригадир.

Хак. Йөрисең шунда йоклап. Кызыңны әнә Кама буйларында подручком гулять иттерәләр.

Гаяз. Исебез китеп тормый әле.

Хак. Акылсыз бәрән. Их, үземнең унҗиде яшьлек чагым булса!.. Ну, характер. Әгәр эшеңдә яхшы эшләмәсәң мин сине бригадамда бер көн дә тотмас идем.

Г а я з. Кулларың сау булса, бу фани дөньяда эш бетәрме! Мин — ирекле индивидуум, теләсә кая китә алам. Бездә, ходайга шөкер, Америкадагы кебек эшсезлек юк.

Х а к. Индюм-миндюм! Характерыңны үзгәртмәсәң, кешеләр белән кешечә яши алмассың син, энекәем. Өйләнә дә алмассың. Менә минем шикелле. *(Өйгә кереп китә.)*

Г а я з. Ник туганда ук бәхетсез булып туганмын соң мин? Җавап бирегез — ник? Эх!.. *(Агач төбенә барып ята.)*

Л э й с ә н керә. Як-ягына карана. Гаязны күрми. Күңелсезләнә.

Г а я з. Ләйсән!.. Үзе!.. Җебемә, егет, җебемә!

Н ә җ и п керә. Ләйсәнне күреп шатлана.

Г а я з *(кире ята)*. Э-эх!..

Н ә җ и п. Бәгырем, мин сине тыр-тыр эзләп йөрим. Гаяздан чүт-чүт качтым... Уф, йөрәгем, дөп-дөп тибә... Мин сиңа шартлатып дөресен әйтергә тиешмен... Ялт итеп бер генә кара әле, бәгырем!..

Л э й с ә н *(борыла)*. Менә борылдым, бәгырем, җан кисәгем. *(Көлә-көлә чыгып йөгерә.)*

Нәҗип, каушавыннан, ялт, пылт, былт, дигән бәйләнешсез сүзләр әйтә-әйтә, нелеп арты белән чигенә. Гаяз аны әзерләнеп көтеп тора. Нәҗип борыла да нәкъ борыны белән Гаязның йодрыгына бәрелә.

Г а я з. Мистер, сезнең йөрәк дамагыз кем?

Н ә җ и п. Җибәр!

Тартышалар.

Г а я з. Минем Братскида өч ай да тугыз көн буе бокс түгәрәгенә йөрүем хәтер сандыгыгыздадыр дип уйлыйбыз.

Н ә җ и п. Җибәр!

Тартышалар. Хак, баш селки-селки, боларны баскычтан күзәтеп тора.

Х а к. Менә агай! Теге сухопутный морякка икәүләшеп һөҗүм итәсе урында... Яшь этәчләр... *(Кереп китә.)*

Ярдан к ы з л а р белән Я з менә. Ул кызларга кызык әйбер сөйли, ахры: кызлар көләләр. Бер-берсенә ачуланышып уртада басып торган егетләргә күз дә салмыйча өйгә кереп китәләр. Яз бик горур кыяфәттә. Урындыкка утырып зур трубкасыннан һавага төтен боҗралары җибәрә. Егетләрнең хәтере кала. Көнчелек хисе, Язга ачу, кызларга үпкә бу ике бәхетсезне берләштерә. Җилкәгә-җилкә терәшеп, ихтыярсыз йодрыкларын йомарлап Язга һәм аның төтен боҗраларына карап торалар. Баскычта кызлар күренә. Алар мендәр-одеаллар күтәргәннәр. Сарайга үтәләр. Анда урын җәеп чыгалар.

Л э й с ә н. Яз абый, ял йортында күптән отбой булды. Кайтып йөрмәссез.

Я з *(көйләп)*. Яратам мин чишмә чылтыравын тыңларга-а-а... Бу шомрайлар әвен базарына киткәч, яме?

Л э й с ә н. Эһем-эһем, Яз абый.

Л э й л ә. Без сиңа урынны сарай түбәсенә чәчкә печән өстенә җәйдек. Каютадагы шикелле рәхәтләнеп йокла.

Я з. Аста сыер-тана заты юкмы?

Л э й л ә. Юк.

Я з. Аста төн буена сыер күшәп чыкса, нервыга тия — качкадан да яман.

Н ә җ и п. Ә без, без кая?

Г а я з. Капитаншалар, анда безнең каюта бит.

Л э й с ә н. Кунак барда тыйнак булыгыз... Тыныч йокы, тәмле төш, Яз абый!

Я з *(мәгънәле генә көйләп)*. Яратам мин чишмә чылтыравын тыңларга-а-а... Полный вперед!.. Хәерле төн, кызлар, сезгә дә юнгалар. *(Сапайга кереп китә.)*

Г а я з. Хәерле каза булсын, дип әйтте ди Хуҗа Насретдин, ишәге ачка үлгәч. Без кайсы кунакчага кунаклыйбыз инде?

Л ә й л ә. Өй кунакчасына.

Н ә ж и п. Бәй, мыш-мыш йокларга анда ике генә карават ич?

Л ә й с ә н. Идән иркен безнең. Тәгәрәшеп йокларсыз.

Кызлар өйгә кереп китәләр.

Н ә ж и п. Менә тор... тор... тора торгач бер амин.

Г а я з. Голландский чәүкә! Мин янганчы аракы янсын, дип әйтә торган иде минем бер дус мөәзин. Тәки чөгендер самогоны чөмереп янып үлде, мәрхүмкәй. Урыны оҗмах түрендә булсын. Шуны искә алырлык кына шешә төбендә калмаганмы?

Н ә ж и п. Теге нәстәкәй шешәсен сыгып эчеп бетерде бит, бирән.

Г а я з. Запас та алып кайта белмисең, шәкерт. Әйдә!

Әкрен генә ишектән кереп югалалар.

*П ә р д ә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук ишек алды. Төн. Ай яктысы бөтен дөньяны сихри нурга күмгән. Сандугачлар сайрый. Кама өстендә аллы-гөлле маяклар яна. Вакыт-вакыт кычкыртып теплоходлар үтә.

Г а я з *(мендәрен кочаклап сакланып кына тәрәзәдән чыга. Агач төбенә килеп, кулларын баш астына куеп ята)*. Йолдызлар, сезнең яратып караганыгыз бармы? Юк, йолдызлар, сезнең мәхәббәт утында дөрләп янганыгыз юк. Сез бары тик җирдәге мәхәббәткә карап көнләшеп кенә яшисез. Кызганыч җаннар сез, иптәш йолдызлар... Ә син, ай, Зөһрәне төшер, давай! Аны җирдәге егет көтә. Менә инде йөзләрчә еллар буе өйләнми көтә. Ай, дим, ник дәшмисең? Ник теленне йоттың? Дәшмә, ачуланмыйм. Син ялгыз бит. Ялгыз кешегә үпкәләп буламыни!.. *(Эһ, дип икенче якка әйләнеп ята. Тагын торып утыра. Транзисторын боргалый, транзистор дәшми.)* Тавыш-тын юк. Дикторлар да, җырчылар да йоклап беткән...

Тәрәзәдән мендәрен тотып шыпырт кына Н ә ж и п чыга. Агач төбенә ятмакчы була.

Г а я з. Занято, тәкъсир.

Н ә ж и п. Фу-у, төн пәрие. Котымны алдың.

Г а я з. Ни дип тагылып йөриләрдер. Ят, әйдә. Көндезен әйткән дә юк, инде төнлә дә тынгылык бирми башладылар.

Н ә ж и п *(мендәрен куеп аның янына урнаша)*. Күрәм, бик тынычланып ятасың әле син. Тып-тынычмы?

Г а я з. Әйе, хәлфә иптәш, без — тынычлык кошы.

Н ә ж и п. Кош? Тилгән әнә кызларыбызны тибеп алырга йөри, ә син шунда, мин тынычлык кошы дип, пароход тавышы тыңлап ятасың.

Г а я з. Шәхескә кагылма! Минем йөрәк дамасына кем мәхәббәт сүзләре лыгырдап тора иде, ә?

Н ә ж и п. Ялгыш ла ул. Башлар зыр-зыр әйләнеп, күзләр акаеп бетте инде.

Г а я з. Минем дә башлар шундыйрак чамада.

Н ә ж и п. Кызларны бөтенләй аңламыйм мин бүген: ни булды аларга? Нишләп аның янында күбәләктәй бөтереләләр?

Г а я з. Ут янында бөтерелгән күбәләкнең канаты көя.

Н ә җ и п. Аңа, кадерле кунак дип, сарай сәндерәсенә — печән өстенә урын җәяләр. Печәнен үзем менә шушы нәфис кулларым белән чаптым бит. Җен ачуың чыкмыйча...

Г а я з. Ә безне үз печәнлегебездән оста гына шудырып төшерделәр. Бер төнгә түзәрсез, өйдә ятыгыз, имеш. Бүген кич кенә ипи салынгач, ни хәтле аш кайнаган бит анда.

Н ә җ и п. Позор... Нишләргә соң?

Г а я з. Корабын сайга утыртам мин ул Амазонка аллигаторының. Чөнки андый Хуанхэ бакаларын дога укып түгел, кыйнап акылга кертәләр. Бер дус дипломат шулай ди торган иде.

Н ә җ и п. Нишләтәсең?

Г а я з. Иртән белерсең. Ә хәзер йокла, мыш-мыш итеп.

Н ә җ и п. Йокларсың монда мыш-мыш итеп — йөрәгең сулык-сулык килсен дә...

Г а я з. Нәҗип, синең туган көнең булдымы?

Н ә җ и п. Әкәмәт! Туган көн булмагач, мин кайдан яралган соң?

Г а я з. Туган көнегезне бәйрәм итә идегезме, дим? Бүләкләр эләгә идеме?

Н ә җ и п. Фантастик сорау. Авыл җирендә элек нинди туган көн, нинди бәйрәм, ди! Без, җитмәсә, бер дистә идек. Туган көнебез түгел — туган аебызны да белмибез. Әти-әниләр, син ураза вакытында, син кыш көне, син мунча янган елны тудың бугай, дип йөриләр.

Г а я з. Ә безгә детдомда повидлолы пирог пешерәләр иде. Өстенә түгәрәк камырдан яшебезне куялар. Бүлешеп ашый идек. Рәхәт чаклар!.. Ә менә берәр бәләкәй кызның үз янында этисе дә булмаса, туган көненә бүләге дә килеп җитмәсә, ул бәләкәй кыз, синеңчә, бик борчылырмы? Ул бәләкәй кыз моңаеп еларммы?

Н ә җ и п. Мин кайдан белим. Ә ник кирәк ул сиңа?

Г а я з. Миңа... кирәкми. Степан Фәйзрахманович әйткән иде.

Н ә җ и п. Үз кайгың колагыңны күмгәндә ниндидер Ычтапаннарның кайгысын кайгыртып ятма әле, пажалыста. Елатасы килмәсә, кызы янына кайтсын.

Г а я з. Дөрес, сэр... кайтсын. Я, йокла, хәерле төн!

Н ә җ и п. Һи, мыскыл итәсеңме? Бу төннән дә хәерсезрәк төнне гомеремдә дә күргәнем юк иде.

Г а я з. Мистер, йокларга дигән приказ бар.

Н ә җ и п. Приказ дек приказ...

Өйдән одеалын күтәреп Х а к чыга. Шыпырт кына килеп тегеләр янына ята.

Г а я з. Хак абзый!

Х а к. Йокламыйсызмыни?

Г а я з. Күзгә йокы керерлекме! Мыекны кара син! Нишли бит, әй!..

Х а к. Кызык кына хәлләр килеп чыкты шул.

Н ә җ и п. Нишләргә кирәк инде, Хак абзый?

Х а к. Үзем дә аптырадым. Нишли ул кызлар, ә? Ник шул адәмгә чат ябыштылар?

Г а я з. Яраталардыр. Моряк. Бөтен дөнья буйлап йөри. Романтика.

Н ә җ и п. Ә без кем? Монтажник. Кара эшче.

Х а к. Син, энем, үзеңне кимсетмә. Безнең шикелле кара эшчеләр дөньяны тоталар. Без менә бу җилкәләр белән җирнең үзен күтәреп торабыз. Энәдән алып космик корабльгә хәтле — барысы да безнең шикелле кара эшчеләр кулы белән ясалган.

Г а я з. Анысы шулай. Кайчакта кызлар чиста киемле, йомшак куллы кешеләргә кызыгалар шул.

Х а к. Артык бөгеп ташладың, чиста киемле кешеләр кеше түгелмени?

Гаяз. Язы кеше түгел шикелле.
Хак. Миңа да ошамый ул. Моряк горурлыгы белән моряк тыйнаклыгы юк анда.
Нәҗип. Нишлик соң? Киңәш бир инде, Хак абзыйкай?
Хак. Һе!.. Аптыраганда «Хак абзыкай!», ә? Эштә чагында «Бригадир, тегендә чап, бригадир, моны тап!..» Һе!.. Яраткан кызы янында ятлар чуала башласа, егетләр нишли?
Гаяз. Нишли?
Хак. Оныттым.
Нәҗип. Хак абзыкай!?
Хак. Оныттым. Сөюегез чын булса, анысын үзегез карагыз инде. Ә хәзер, әйдәгез, йоклыйк.
Нәҗип. Хак абзыкай, чүт-чүт кенә?
Гаяз. Хак абзыкай дим!
Хак. Бер ябышсагыз тәки сырганак буласыз, нәкәнис. Нишлик, нишлик, дип атайлардан сорап тормыйдыр идек без егет чакта. Нәрсә генә укыталардыр сезгә мәктәпләрдә.
Гаяз. Хак абзыкай, син әле дә үз мендәрен үзе кочаклап йоклаучы корыч ихтыярлы егет бит.
Нәҗип. Үз күлмәген үзе юып йөрүче батыр буйдак.
Хак. Тәмуг өрлекләре!.. Йокларсың сезнең белән. *(Одеалын алып Кама буена төшеп китә.)*

Тынлык. Яз күренә. Аяк очларына гына басып, өйгә таба бара.

Яз. Ниһаять, йокладылар бугай. Тege картлач та чыгып китте. Полный вперед, Яз, полный вперед!.. Мондый мажаралар төн саен очрап тормый. Полный вперед! Лева руля!..
Гаяз *(аны чабуыннан эләктереп ала).* Полный назад, капитан, право руля!
Яз *(коты очып).* Бу кем?
Гаяз. Мин монтажник Гаяз.
Нәҗип. Мин монтажник Нәҗип.
Яз. Сез... сез нишләп биредә?
Гаяз. Без бу өйдә ике ай буе фатирда торабыз инде. Ә менә сез нишләп биредә?
Нәҗип. Сез безне кунакчабыздан очырып төшергәч, ятим тавыклар шикелле кыт-кытыйк дип йөрдек тә ишек алдында йокларга булдык.
Яз. Белмәгән идем, белмәгән идем.
Гаяз. Әле син күп әйберләрне белеп бетермисең, капитан Немо.
Яз. Аңламыйм.
Нәҗип. Өй эшен эшләгәндә мәсьәләне аңламасам, әти минем башка тимер линейка белән шык-шык итеп аң кертә иде.
Яз. Ә-ә, сез мине кыйнарга итәсезме? Бер кешегә икегез?
Гаяз. Несчастный Дон-Жуан!
Яз. Әйдәгез, ирләрчә сөйләшик әле.
Гаяз. Джентельменнарча!..
Нәҗип. Әйдә! Дөп-дөресен ләкин!..
Яз. Кемдә папирос бар?.. Рәхмәт!.. Сез, егетләр, миннән көнләшәсез бугай?
Нәҗип. Кап-кара, күсе койрыгы кебек нәп-нәзек мыегыгызданмы?
Гаяз. Дәвам ит!
Нәҗип. Ник син аларга тиясең?
Яз. Кем? Минме?
Нәҗип. Син!
Яз. Алай дип уйларга сезнең хакыгыз юк. Мәхәббәт белән шаярмыйлар. Мин чын йөрәгем белән сөям. Чын, изге теләкләр белән. Тор-

мыш юлын бергә үтәрлек якын дус эзлим. Әллә шул гаепме? Мин әле саф егет. Кешенең иң самими хисләре белән шаярырга берәү дә шыр тиле түгел.

Гаяз. Ә без тилеме?

Яз. Минем тиле дигәнем юк.

Нәҗип. Алай булгач, ник безнең кызлар тирәсендә кич буе зыр-зыр бөтереләсең?

Яз. Безнең кызлар дисезме?

Нәҗип. Дисәм соң?

Яз. Кызык фәлсәфә!.. Безнең кызлар, сезнең кызлар!.. Хатын-кызларга феодалларча караш. Хәтерегез калмасын, ләкин алар мине сезгә караганда якынрак күрә шикелле.

Нәҗип. Сөяр сөягең бардыр!

Яз. Бәлки.

Гаяз. Менә нәрсә, сухопутный моряк, сез хәзер, сөяр сөягегезне дә җилкәгезгә күтәреп, моннан табан ялтыратачаксыз.

Нәҗип. Тәпи-тәпи, лып-лып, лап-лап...

Яз. Карагыз аны, егетләр, предупреждаю, кыланышыгыздан статья исе килә.

Гаяз. Без сиңа ул статьяны хәзер үзебез укытабыз.

Яз. Судка эләгәсегез киләме?

Гаяз. Ә-ә, шулаймыни? Без сиңа хәзер үзебез суд ясыйбыз. Дөрес бит, монтажник?

Нәҗип. Точно!

Яз. Суд?.. Нинди суд?

Гаяз. Самосуд.

Хак керә.

Яз. Абый, дим, абый, ирек бирмәгез. Сез монда иң өлкән кеше. Болар әллә нишләгән... Юл куймагыз?

Хак. Ни бар? Нинди тавыш?.. Ә-ә, алай икә-ән! Оланнар, кызмагыз.

Яз. Хак абзый, Хак абзый дим?!.

Хак. Мин нишли алам, энекәем! Алар мине өйдә түгел, эштә дә тыңламыйлар.

Гаяз. Өчкә хәтле санаганчы чыгып чапмасаң...

Яз. Нишләтерсез?

Гаяз. Камага!..

Нәҗип. Муеныңа таш бәйләп... Былт-былт!..

Гаяз. Монтажник, бар, бер зур гына таш тап әле.

Нәҗип. Була ул.

Хак. Бәйләргә тимер чыбык шәп булыр. Чоланнан алып бирим әле.

Гаяз. Бисмилла иррахман иррахим!..

Яз. Каравыл!.. Үтерәләр!..

Өйдән Гөлбану, Ләйсән һәм Ләйлә чыга.

Гөлбану. Нинди тавыш бу? Теплоход утырдымы әллә?

Хак. Тынычлан, Гөлбану, акылга гына утырталар.

Яз. Гөлбану апа, кызлар, карагыз әле боларга — җенләнгәннәр.

Гаяз. Бер...

Яз. Кара-авы-ыл!..

Гаяз. Монтажник, таш булдымы?

Нәҗип. Өч потлысы ярармы?

Яз. Котырганнар алар. Карап торып кеше үтертмәгез... Закон каты хәзер.

Гаяз. ...Ике...

Ләйсән. Сез ник аңа тиясез?

Гаяз. Әлегә тигән юк.
Ләйсән. Хәзер үк гафу үтенегез!
Нәҗип. Гафу?
Ләйсән. Хәзер үк!
Гаяз. Нигә?.. Нишләп?.. Нилектән?.. Ни сәбәпле?..
Ләйсән *(Язны култыклап ала).* Ни сәбәпleme? Чөнки ул мине ярата. Без бер-беребезне ун көн сөябез инде.
Яз. Ләйсән?! Ә әйе, әйе.
Гаяз. Ләйсә-ә-ән!.. Син ни сөйлисең? Акылыңнан яздыңмы?
Ләйсән. Акылдан язсам, шундый чибәр егетне ычкындырган булыр идем.
Яз. Әлбәттә, әлбәттә.
Гаяз. У-у-ухх!!. Телең шикелле батыр булсаң, чык каршыга! Чык бергә-бер шушы мир алдына!
Яз. Чыкмыйм.
Гаяз. Чык!.. Мин сине... Мин сине... *(Бүтән әйбер тапмагач, Яз алдына коткару кругы ташлый.)* Мин сине дуэльгә чакырам!
Нәҗип. Нәрсә белән сугышасыз соң — атышырга пистолетлар юк. Балта алып чыгыйммы әллә?
Яз. Юк, мин риза түгел.
Нәҗип. Күсәк белән ничек булыр? Дөп-дөп!
Яз. Сугышмыйм.
Гаяз. Ул чагында йодрык белән. Үзең әйткәнчә, джентельменнарча. Чык әйдә! Нил крокодилы! Бер, ике, өч!..
Нәҗип. Мин секундант булам.
Яз. Кызлар!.. Ләйсән!.. Ләйлә! Ирек куймагыз!.. Минем күкрәк авыруым бар... *(Тырышып ютәлли.)* Менә күрәсезме?
Ләйлә. Юк, юк, юл куймыйм! *(Икенче ягыннан барып култыклый.)*
Яз. Э-э... Э-э...
Нәҗип. Бу... бу... бу... Нәрсә бу?!.
Ләйлә. Ул мине ярата.
Нәҗип. Бррр!.. Әллә төш күрәм, әллә саташам... Башым карусель шикелле зыр-зыр...
Гаяз. Минеке дә... Гражданкалар, нинди комедия бу, ә?
Нәҗип *(Яз алдына, бүтән әйбер тапмагач, ботинкасын ташлый).* Чык, каһәр суккан нәрсә! Гаязга хәтле синең белән мин үзем сөйләшәм. Р-р-рагу ясыйм мин синнән!
Ләйсән. Яз мине ярата.
Ләйлә. Юк, Яз абый мине ярата.
Ләйсән. Апа! Ул мине ярата!..
Ләйлә. Сеңелем! Ул апаңны ярата!..
Ләйсән. Мине!
Ләйлә. Мине!
Нәҗип. Пульсем — мелт-мелт!
Гаяз. Атнаның кайсы көне бүген? Ничәнче ел быел?!.
Ләйсән. Ул мине ярата, ышанмасаң әйтим инде — ул миңа чишмә буена свидание билгеләде. Париж духие бүләк итте. Менә!.. Сеңелең белән сүз көрәштерәсең.
Ләйлә. Ул миңа свидание билгеләде. Ә менә бу нәрсә?
Гаяз. Эх, сез!.. Мин сезне акыллы кызлар дип йөри идем. Мин сезгә соклана идем, ә сез... Рәхмәт бу мыеклы салагага, чын йөзегезне ачты.
Яз. Ни сөйли ул? Ул сезне хурлый!
Ләйсән. Димәк, син аңа да свидание куйгансың?!. *(Яныннан китә.)* Көлеп кенә йөргәнсең икән. Ә мин, тиле кыз, чын күңелемнән ышанып... *(Елый.)*

Г а я з. У-у-ыхх, Сингапур акуласы, синең самими мәхәббәтең мена ничек икән!..
Н ә җ и п. Гаяз, шып бул. Аның измәсен мин үзем изәм.
Я з. Ә-ә... ә-ә... Үтенәм сездән... Туктагыз... Аңлатып бирәм...
Л ә й с ә н. Изге хисләремнән көлеп йөргән икән... *(Елый.)*
Л ә й л ә. Нинди әдәпле кебек иде...
Л ә й с ә н. Европа тәрбиясе алган, кызларның күңелен ача белә, дигән идем...
Л ә й л ә. Безнең егетләр белән чагыштырып та булмый, дип куанган идем. Ә ул, ә ул...
Г а я з. } Ха!.. Чагыштырып та булмыймы?.. Анымы?.. Безнең
Н ә җ и п. } беләнме?.. Ха!.. Чагыштырып булмыймы?..
Л ә й л ә. Нәрсәләр уйлап йөри икән! Нинди хурлык!.. Камага төшәм!
Г ө л б а н у. Хак!..
Х а к. Ахырын көтик, Гөлбану. Ахыры хәерле булсын.
Г а я з. Ләйлә, синең өчен бу голландский этәчне Камага томырабыз.
Н ә җ и п. Чык кызлар артыннан. Дерелдәмә дер-дер!
Г а я з. Э-эх, аллигатор!.. Монтажник, давай ташны!
Х а к. Я ходай, гөнаһларга кереп чумсак — тартып чыгарырсың...
Я з. Без... сез... акылыгыздамы?.. Мин бит йөзә дә белмим!..
Х а к. Аяк чылатып йөргәнче, ярдан гына шудырып җибәрәсезме әллә?
Г а я з. Алай итсәң дә була, болай итсәң дә була, дип әйтте ди Хуҗа Насретдин, тычкан даруы сатканда. Тот, әйдә, тәпиеннән, алла булса — аллага тапшырдык!

Тотарга баралар.

Я з. Кара-вы-ы-ыл... А-а-а... ы-ы-ы!.. *(Тыпырчына торгач, егетләрнең кулларыннан ычкынып чыгып кача.)*
Н ә җ и п. Эх, эләктерә алмадык.
Г а я з. Өч буынлы ракета шикелле атылды бит.
Я з *(яр астыннан кычкыра).* Кителемне бирегез, кыргыйлар. Мәгез үз аламагызны. *(Бер пинжәк ыргыта.)* Фуражканы бирегез.
Г а я з *(җирдәге пинжәкне алып карый).* Бәй, минеке ич бу. Ярый әле киеп китмәгән. *(Кагып агач ботагына элә.)* Бар, әйберләрен алып төш инде.
Н ә җ и п *(сарайдан алып чыгып, Язның әйберләрен ыргыта).* Барыгыз, бәхетсез киемнәр, юньсез хуҗагыз артыннан. Икенче адашып калмагыз.
Я з *(кычкыра).* Сез хәзер минем кулда. Без әле сезнең белән икенче урында очрашырбыз, корчаңгы юнгалар. Күз яшегез белән еларсыз әле.
Г а я з. Еларбыз, еларбыз, олак кына.
Н ә җ и п. Мо-мо-мор-моряк дус!.. Мышык-мышык еларбыз.
Х а к. Гөлбану, тавыш-тын басылды. Кереп ятасыңмы әллә? Тунгансың.
Г ө л б а н у. Әйе шул, Хак. Балалар, сез дә озакламагыз. Камадан дулкын җиле менә. Әйдә.
Х а к. Әйдә.

Өйгә кереп китәләр.

Кызлар, бер-берсенә карашып торалар да, көлеп җибәрәләр.

Л ә й с ә н. Монтажникларның йөрәгендә кан урынында чөгендер суымы әллә, дисәк...
Л ә й л ә. Болар да егет төсле егет инде әллә?
Н ә җ и п. Төпсез ыштан кигән чаклар үтте.

Л э й л ә. Ләйсән, керәбезме әллә?
Н ә ж и п. Әз генә торыгыз инде?
Л э й с э н. Суык.
Л э й л э. Сез җылыта алмыйсыз.

*Нәҗип Ләйләнең җилкәсенә, Гаяз Ләйсәнгә пинжәкләрен ябалар. Тынлык. Сандугачлар сайрый. Кычкыртып теплоход үтә.*

Л э й с э н. Л э й л э.
Сандугачлар гына кайда сайрый,
Кама буйларында тирәктә...
Тик бу әфәнделәрнең пинжәкләре
Җылы бирми безнең йөрәккә.

*Көләләр.*

Г а я з. Сез нәрсә!.. Диңгез бүрегезне качырдык. Җыларга кирәк, ООНга 348 битлек жалоба җибәрергә кирәк. Ә сез көләсез.

*Кызлар көләләр.*

Л э й с э н. Их, сез!..
Г а я з. Ә?! Димәк?!.
Л э й л э. Димәк!..

Г а я з.
Күзен ачты бер ятим,
Яшә, кызлар, мин яшим!

Н э ж и п. Сезне Тукай шүрәлесе кытыклыймы, әллә автомотолотореяга автосын да, мотосын да оту бәхетенә ирештегезме?

Г а я з. Ирештек, туган, ирештек!.. Кара әле, туган, синең кыр тавыгы белән жираф турында бер гыйбрәт ишеткәнең бармы?

Н э ж и п. Сөйләп бак.

Г а я з. Көннәрдән бер көнне зоопаркта кыр тавыгы таеп егылган.

Н э ж и п. Лып итеп.

Г а я з. Лып итеп. Моны күреп бар җанварлар көлә башлаганнар.

Н э ж и п. Ха-ха-ха, дип.

Г а я з. Ха-ха-ха, дип. Жираф кына, болар нигә көләләр икән, дип аптырап карап тора, ди.

Н э ж и п. Күзен челт-челт йомып.

Г а я з. Күзен челт-челт йомып. Ул мескен фәкать икенче көнне иртән генә кычкырып көлеп җибәргән.

Н э ж и п. Шырык-шырык.

Г а я з. Шырык-шырык. Муены озын булгач, башкаларның нидән көлүе тегенең башына иртә белән генә менеп җиткән, ди.

Н э ж и п. Шуннан ни?

Г а я з. Һаман менеп җитмәдеме?

Н э ж и п. Безобразие. Мин егерменче гасыр кешесе. Мин ирекле ид... пид... инвуд... Тьфу... Әйтеп җибәр инде?

Г а я з. Индивидуум.

Н э ж и п. Мин ирекле индивидуум. Кыр тавыгы, жираф һәм башка шуныңише филләр дип миннән хихайлап көләргә хакыгыз юк... Ләйлә, шуннан тиз-тиз генә тәмәке алып бир әле.

Л э й л э. Кеше кесәсенә керә торган гадәтем юк.

Н э ж и п. Һәй!.. *(Пинжәк кесәләрен актара.)* Бу нинди зажигалка?.. Бу нинди хат?.. Гаязга ич бу!.. Гаяз пинжәген ябынып утырасың ич син!..

Г а я з. Нинди хат?..

Н э ж и п. «Гаяз бәгырем... һе... Сине өзелеп сөюче Гөлбәгъдән... Гөлбәгъдән... Гаяз бәгырем, син мине ягымлы сүзең, акылың белән сихерләдең. Мин ул кичне мәхәббәтемнән, чиксез бәхетемнән тәмам исердем. Унбиш көн буе бәхетемнән айный алмадым... Син бит бер айдан кайтырмын, дигән идең. Ике ай үтте — син һаман юк. Кайтыр юлла-

рыңа карый-карый, кавышу сәгатьләрен саный-саный көттем, бәгырем! Юк, дөрес әйтмим икән — көттек. Ул инде ике айлык. Ул — әлегә безнең гөнаһ җимешебез. Тик ул безнең икебезнең дә бәхет җимешебез булып туачак, шулай бит, Әбелгаяз бәгырем?!

Г а я з. Ә?!. Что за чертовщина?!. *(Хатны тартып алмакчы була.)*

Н ә җ и п *(хатны кызларга бирә)*. Гаҗәп, бик гаҗәп.

Л ә й с ә н. Бәгырем... ике ай... бәхет җимеше... Гаяз?!.

Г а я з. Ләйсән... Юк!.. Әллә нәрсә бу... Әллә нәрсә бу!..

Н ә җ и п. Бу, сэр, оятынны сатып эчү дигән сүз. Сизенүләрем дөрес булып чыга түгелме? Нindирәк бәндәләрне өнәп бетермәвемне беләсең!..

Г а я з. Бензин, күкерт. Гөлт итеп кабынып китмә әле. Башта тыңла.

Л ә й л ә. Тыңларлык сүзең булса.

Л ә й с ә н. Нинди хурлык, нинди хурлык!

Н ә җ и п. Тынычланыгыз, кызлар. Мондый шырантайлар сезнең тып-тып тамган күз яшьләрегезгә тормый... Я әле, чык әле!..

Г а я з. Мине әллә мыек дип беләсеңме?

Н ә җ и п. Син мыектан ун кат мәкерлерәк — астыртын чагасың. Чык каршыма!

Г а я з. Кагылма, тинтәк!

Н ә җ и п. Тинтәкме?

Алышалар.

Л ә й л ә. Нәҗип, дим, Нәҗип, нишләвегез бу, ә? Торыгыз хәзер үк!

Л ә й с ә н. «...Кайтыр юлларыңа карый-карый, кавышу сәгатьләрен саный-саный көттем...». Мин дә бәхет көтмәдемме!?.

Н ә җ и п. Теге таш сиңа булган, шведский чәүкә!

Г а я з. Ахмак... җүләр... беркатлы... тинтәк... туксан тугыз... бер шаригың төшеп калган...

Л ә й л ә. Туктагыз, дим!.. Хак абый, Хак абый!..

Өйдән Х а к белән Г ө л б а н у чыга.

Х а к. Монтажниклар, бу ниткән эш? Торыгыз, адәм көлдермәгез! *(Аера.)* Атаегыз малын бүлешәсезме әллә, юлбасарлар?

Г ө л б а н у. Нинди тынгысыз төн булды соң бу?

Л ә й с ә н. Көчләрен кая куярга белми җәфаланалар.

Л ә й л ә. Язны куып җибәрделәр дә хәзер бер-берсенә ябыштылар.

Х а к. Минем бригадамда талаш-үтереш?!.

Н ә җ и п. Укы, бригадир. Әгәр ул бүген үк безнең бригададан табан ялтыратмаса, мин үзем китәм.

Х а к *(хатны укый)*. Нинди хат бу, монтажник?

Л ә й с ә н. Гөлбәгъдә...

Г а я з. Беренче кат күрүем.

Г ө л б а н у *(хатны укып)*. Бик зур эш бу, балалар. Ашыкмагыз, кызмагыз. Туачак сабый хакын онытмагыз. Пермь каласы каф тавы артында түгел — Гаяз барып кайтыр. Сөйләшерләр, татуланырлар. Булмый торган эш түгел. Теләсәләр, туйларын да шушында ясарбыз.

Г а я з. Туй?.. Нинди туй?.. Зинһар өчен, бер генә минут тыңлагыз әле мине, туганнар?!

Х а к. Пермь?.. Энем, быел кая бардың әле командировкага?

Н ә җ и п. Пермьга!

Г а я з. Синнән сорамыйлар. Пермьга.

Х а к. Кайчан?

Н ә җ и п. Яз көне.

Г а я з. Мартта.

Х а к. Күпме тордың?

Г а я з. Ике атна... Ләкин сез...

Хак. Мә хатынны. Әгәр дә мәгәр шушы атна эчендә киленне алып килеп өйләнеп тора башламасаң... миннән милыс көтмә. Хак абзаңны беләсең, мин ике сөйләшмим. Позор!.. Кызыл Хаҗ җәмгыятенең йөз еллык юбилеенда Мактау кәгазе белән бүләкләнгән Хак Айнетдинов бригадасында шундый-шундый эшләр!.. Позор!..

Гаяз. Хак абзый!.. Бригадир!..

Хак. Молчать!..

Гаяз. Нәҗип!

Нәҗип. Әгәр тиз арада моннан үкчәңне ялт иттермәсәң, сөякләреңнең шырт-шырт килүен рәхәтләнеп үзең тыңларсың.

Лэйсән. Кешеләр ни өчен бер төрле сөйли, икенче төрле эшли икән?.. Ник дөньяда мәкер дигән нәрсә һаман бар икән?!.

Лэйлә. Лэйсән, чын дигәнебез ялган булган. Ә ялганның гомере кыска — тиздән онытылыр.

Лэйсән. Ах, шулай гына булсачы!..

Гөлбану. Гаяз энем, тормыш кору өчен дә җиңел түгел. Борчылма, сезнеке дә рәтләнер. Әле соң түгел. Башта, әгәр теләсәгез, үзебездә булса да торып торырсыз.

Лэйлә. Юк! Ул кабат бу йортның бусагасыннан атламас! Әйдә, Лэйсән!

Гаяз. Лэйсән!..

Лэйсән. Кит!..

Өйгә кереп китәләр.

Гөлбану. И балалар, китәр алдыннан гына болганышып беттегез. Кызым Лэйсән, Лэйлә!.. *(Кереп китә.)*

Хак белән Нәҗип урындыкка утырып сүзсез генә тарталар. Гаяз да алар янына утырмакчы була. Нәҗип аның урындыгын икенче башка илтеп куя. Гаяз ялгызы шунда барып утыра. Тарталар. Тынлык. Гаяз кинәт көлә башлый. Кызганыч һәм рәнҗүле көлү.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Кояш күтәрелеп килә. Бик якты. Кошлар чыр-чуы, теплоход тавышлары. Нәҗип үз урынында, Гаяз үз урынында баягыча тартып утыралар. Шулай таң аттырганнар, көнне житкергәннәр. Уйланганнар, бәхәсләшкәннәр, арыганнар. Хак Нәҗип янында йоклап ята. Сарайда әтәч кычкыра. Хак, ә, нәрсә, дип торып утыра. Өйдән Лэйлә чыга, көянтә-чиләк ала.

Нәҗип. Чишмәгәме, Лэйлә?

Лэйлә. Утын кисәргә.

Нәҗип. Кая, үзем алып меним. Китер чиләкләреңне.

Лэйлә. Кагылма. Мин сиңа ышанып ничек көянтә-чиләк тапшырыйм? Ышанычсыз кешеләр сез.

Нәҗип. Минем ни гаебем бар? Әнә бит, ул бит, ул!

Лэйлә. Ә син аның дусты.

Нәҗип. Лэйлә!

Лэйлә. Белеп тор, без Лэйсән белән бары пар егеткә генә кияүгә чыгачакбыз. Икебез бер көнне, бергә туй ясап. Җибәр чиләгемне. Хуш!..

Нәҗип *(ачуыннан ярсып Гаяз тирәли чабып йөри)*. Синең аркаңда... синең аркаңда җанысем-бәгыремнән колак кагам... Синең аркаңда газиз башкайларым ниләр күрә-ә!.. Э-эх-ух!.. Лэйлә, Лэйлә-ә-ә, без

аны куабыз. Пран-заран китерәбез. *(Чыгып йөгерә.)* Валлаһи, секунд тотмыйбыз...

Гаяз транзисторын боргалый.

Хак. Бетер әле. Торам-торам да карт хатынның колагын борам, дигән шикелле, торасың да шул нәстәкәеңә ябышасың. Таптылар бүләген дә — акча гына бирсәләр...

Гаяз. Эчеп бетерер идем.

Хак. Бетермәс идең. Хатыннар күп синең, алимент түләр идең. Мир арасына чыгарлыгымны калдырмадың. Ну, белеп тор, күрәселәрең алда, парин.

Гаяз. Күрәсене күрми, гүргә кереп булмый, дип әйтә иде минем бер таныш идән асты мулласы. Без фәкыйрьгә көймәгезне биреп торырсыз бит, бригадир?

Хак. Көймәгә, между прочим, мин хуҗа түгел — Гөлбану түтәннән сора. Мин әле монда бер нәрсәгә дә хуҗа түгел.

Гаяз. Сез бер кайчан да, бер нәрсәгә дә хуҗа була алмассыз, сәр, сез бөрчә догалый торган адәм түгел, сезнең бәрәңге каныгызга тау җилләре, урман шаулары сеңгән. *(Транзисторын кычкырта-кычкырта чыгып китә.)*

Хак *(хуҗа шикелле өйне, каралты-кураларны карап, тикшереп йөри).* Әгәр дә мәгәр Гөлбану риза булса, әгәр дә мәгәр Гөлбану риза булса һәм мин шушында хуҗа булып төпләнеп калсам, чишмәне чистартырга, яңа колаша куярга кирәк, кәнишне. Монысы тузган. Көймәне буяп җибәрербез... Көзгә таба сарайны зурайтып күчерербез, исәнтаза торсак. Тәрәзә каршындагы алмагач та картайган, урынына яңаны утыртырбыз... һе... һе...

Өйдән Гөлбану чыга.

Гөлбану. Әйберләрен әзерләп бетердем бугай инде. *(Яшьләрен сөртә.)*

Хак. Гөлбану!.. Җә инде, әйләнеп кайтырлар.

Гөлбану. Ләйсәнемнең күңеле төшенке. Кичә ничек очынып йөргән иде. Төн эчендә күзләре эчкә батты.

Хак. Үземнең улым кебек итеп йөрттем бит, үземнең улым кебек. Эһ, кешене һич белеп бетермисең икән.

Гөлбану. Яшь чак җүләр чак инде. Әз генә кайгыны да тау хәтле итеп күрә, таудай куанычын сизми сикереп үтә.

Хак. Безнең генә сикерер чак үтеп бара... Гөлбану!

Гөлбану. Әү, Хак.

Хак. Ә без икебез монда аларны әйбәт кенә көтеп торырбыз. Кич утырып хатлар язарбыз.

Гөлбану. Гомерлек эшне кинәт эшләмиләр, Хак.

Хак. Кинәт эшләнгән эшнең ахыры хәерле була, диләр.

Гөлбану. Зиһеннәрем таралган чак, Хак.

Хак. Әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, әгәр дә мәгәр, син, ягъни, мин синең күңелеңә ошаган адәм булсам, мин әйтәм, син ризалыгыңны бирсәң, әллә, мин әйтәм... озакка сузмыйча, син, мин әйтәм, боларның колагына ишеттереп кую хәерлерәк булмасмы, мин әйтәм... һем... һем... дип әйтәм.

Ләйлә белән Нәҗип керә. Нәҗип көянтә белән су күтәргән.

Гөлбану. Һай, кызым, егет кешегә көянтә белән су күтәртәләрмени? Килешмәгәнне кыланып...

Ләйлә. Килешә. Ирләр дә безнең белән бер хокукта бит. Мин әле аларга иләк белән бөтен Каманы ташытыр идем.

Нәҗип. У-уфф!.. Бу бишьеллык планда, СССРдагы бөтен өй-

ләргә дә шартлатып водопровод кертергә, дигән пункт бар микән? Кайсыгыз әйтә? Төшеп калган булса, һичшиксез, өстәргә кирәк.

Л ә й л ә. Ләйсән кайда?

Г ө л б а н у. Күлмәген үтүкли.

Л ә й л ә. Чемоданнарны бәйләргә кирәк.

Х а к. Әйдә әле, монтажник, без аны...

Г а я з керә.

Г а я з. Гөлбану апа, мин китәм. Көймәгезне биреп торырсыз микән?

Г ө л б а н у. Моторы ватык бит.

Г а я з. Карадым. Төзәтерлек.

Г ө л б а н у. Төзәтәлсәң ярый. Әйтерсең: пристань малайлары китерер.

Г а я з. Рәхмәт!

Х а к. Кара аны, иртәгә эшкә соңга каласы булма, тәти егет.

Г а я з. Эшкә нәкъ вакытында килермен, сэр, колагым белән ант итәм...

Өйдән Л ә й с ә н чыга.

Г а я з. Ләйсән! Минем гаебем юк. Гөлбәгъдә дигән кызның дөньяда яшәвен дә белми идем... Хат та бөтенләй минеке түгел... Кайда әле... Менә... *(Куен кесәсеннән хат ала. Хатка ияреп бер фоторәсем чыга һәм җиргә төшә.)*

Н ә җ и п *(фоторәсемне алып карый).* Чибәр кыз, чукынган. О-о, күзләр, күзләр — ут!

Г а я з *(омтылып).* Кагыласы булма!

Х а к. Анысы кем тагын? Гөлбәгъдәме әллә?

Г а я з. Бир, дим?.. Хакыгыз юк!..

Н ә җ и п. «Гаязчик! Дружба, рожденная в юности, не забывается всю жизнь. Син минем тормышыма ямь өстәдең, син миңа мәңгелек бәхет бирдең. Рәхмәт сиңа, кадерлем! Целую. Линара». Нәрсә бу?

Г а я з *(фоторәсемне алып кесәсенә салып куя).* Нәрсә булса да синең дәхелең юк!

Н ә җ и п. Бу картечкәне дә беренче тапкыр күрәсеңме? Ул да синеке түгелме?

Г а я з. ...Минеке.

Н ә җ и п. Тизрәк моторыңны төзәт тә — выж-жт!.. Юкса...

Г ө л б а н у. Балалар, балалар, зинһар, акылыгызны югалтмагыз!

Н ә җ и п. Сиңа татарча әйтелде бит, хунвейбин, югал!

Г а я з.

Ул Дию күздән югалды юк булып,
Очты Яңа Бистә якка ут булып.

Ха-ха-ха... *(Китә.)*

Л ә й л ә. Елама, елама, дим... Мондый кешеләр белән елап түгел — җырлап аерылалар.

Л ә й с ә н. Мәхәббәт гөленне йолыксыннар да... көләрсең... Тизрәк, тизрәк бәйләгез чемоданнарны. Китәбез, китәбез!

Г ө л б а н у. Аерылу минутлары килеп тә җиттемени? Бер дә күңелле түгел — хәерле булсын.

Х а к. Яшь чак — тирән диңгез, шауламый, давылланмый тормас, Гөлбану. Картлык кына камышлы күл... Әйдә, Нәҗип энем.

Өйгә кереп китәләр. Бераздан ашыгып Я з керә.

Я з. Берәү дә юкмыни? Юк, уф... Маҗара, маҗара!.. Хатыны килә, диң, ә? Телеграмма суккан. Почтага кагылу ничек башыма килде... Ха... Маҗара, маҗара!..

Өйдән Х а к, Г ө л б а н у, Л ә й л ә, Н ә җ и п чыга.

Я з. Хәерле көн, хәерле көн, дуслар! Менә мин кояш шикелле әйләнеп, тагын килеп җиттем.

Нәҗип. Яр башы бик ошап киттемени?

Хак. Нәрсәң калган тагын? Артыңнан ыргытып бетердек бит.

Нәҗип. Әйдә, выжт-выжт-выжт!

Өйдән Ләйсән чыга.

Ләйсән. Әни, минем зәңгәр күлмәгемне... Нәҗип?!.

Я з. Туктагыз! Бер генә сүз әйтергә ирек бирегез?

Хак. Әйтеп кал!

Я з. Коточкыч хәбәр!

Нәҗип. Сабыр төбенә төшмә!

Я з. Кайбер туташлар өчен зур яңалык!

Нәҗип. Әйтәсеңме-юкмы? Бер...

Я з. Гаяз дигән монтажник кайда соң? Мин аннан сөенче алырга тиеш.

Гөлбану. Сөенче?

Я з. Әйе, Гөлбану ханым. Хәзер аның хатыны килеп җитәчәк.

Ләйсән. Хатыны?

Я з. Хатыны.

Хак. Качкан чагында егылып башы ташка бәрелгәнме әллә? Ни бутый бу?

Я з. Уфа самолеты Казанга иртүк төшә. Озакламый «Метеор» килеп җитәр. Әз генә көтегез.

Нәҗип. Әгәр алдашсаң, ботыңнан тотып быж-быж әйләндереп Камага томырам.

Я з. Ышанмыйсызмы? Ә менә бу нәрсә? *(Кесәсеннән перевод кәгазе ала.)* Сезнеңчә, нәрсә бу?

Нәҗип. Нәрсә? Китер әле?

Я з. А юк! Шушыннан гына укыгыз. Гөлбану апа, Хак абзый, сезнең күзләр аермас, яшьләр укысын. Я, кем кулы белән язылган?

Ләйсән. Аның кулы — Гаязныкы.

Я з. Кая дигән?

Ләйлә. Уфага.

Я з. Хәзер бу ягын укыгыз. Хатын. Укы, егет, укы!

Нәҗип. «Ваня дус, бу акчага кызның туган көненә бер бик шәп бүләк алып бир инде, яме! Үзен өзелеп сөюче әтисе исеменнән котла. Калган акчаны, гадәттәгечә, энисенә тапшыр. Сәлам белән, Гаяз». Һм. Кайдан алдың син моны?

Я з. Анысы икенче мәсьәлә. Фактына кара син, фактына.

Ләйсән. Язып утыруын кичә мин дә күрдем. Мин күргәч, яшерде.

Нәҗип. Ә мин җүләр баштан... бер бәләкәй кызчыкның туган көне, фәлән-төгән, дип төпченеп ятты. Үз кызы турында лыкы-лыкы килгән икән. Хәзер мин ул еланны... ох, ух... пых!.. *(Йөгереп чыкмакчы була.)*

Хак. Сабыр! Мондый чакта сабырлык кирәк. Артык кызсаң — үзең янасың.

Катер тавышы.

Я з. Әнә, «Метеор» килеп тә җитте.

Ләйсән. Тизрәк, тизрәк, китәргә кирәк моннан. Әйдә, Ләйлә, әйдәгез!

Нәҗип. Ну пешердең манный боткасы. Үзеңә ашарга туры килмәсә генә ярар иде.

Я з. Рәхмәт, тамагым тук. Завтракка тана ите белән бик шәп гуляш бирделәр... Бу тирәдә Кама киңме әле? Өч километрмы? Бер өч мәртәбә йөзеп чыгыйм әле үзен. Без — моряклар йөрәгебезгә һәм беләгебезгә шулай итеп куәт алабыз.... Ишкәкләрне суга!.. Бер, ике...

Н ә ж и п. Бар, бар. Куйбышев ГЭСына кадәр агып китмәссеңме.
Я з. Борчылмагыз, комедия башланганчы кайтып җитәрмен. *(Китә.)*

Тынлык. Барысы да аптырап калганнар. Астан Г а я з менә. Ул, киресенчә, шат күренергә тырыша.

Г а я з. Синьорлар, синьоритта һәм синьоралар, белдерергә рөхсәт итегез, мотор төзәлде. Минем йөрәгем кебек шәп эшли.

Тынлык.

Бензин кайда? Бензин кирәк?

Тынлык.

Гражданнар һәм гражданкалар, бу нинди тынлык? Ай тотылганмы әллә кояшмы? Ә-ә, аңлыйм. Тарихи минутлар, аерылышуның ачы минутлары. Җилбәзәк тарихыбызның бу сагышлы кисәген мәңгеләштереп калырга рөхсәт итәрсез, дип уйлыйм.

Фотоаппаратын алып төшерергә әзерләнә, тегеләр аңа артлары белән әйләнәләр.

Г а я з. ...Биографиян никтер башаркан тәпәнләп китте шул, Гаяз дус. Дөреслек соң булса да ачылыр, дип әйтә торган иде минем бер таныш карак.

Тынлык.

Ләйсән, Ләйсән, кара әле... Моторны төзәттем. Хәзер китәм... Мин сиңа соңгы бүләгем итеп чәчәк җыйдым. Син ярата торганнарны... Мә!..

Н ә ж и п чәчәкне читкә ташлый.

Н ә ж и п. Син...
Х а к *(Гаязга бензин канистрын бирә)*. Бар, сал бензиныңны.

Гаяз транзисторын бик каты кычкыртып, башын горур күтәреп, «Монтажниклар» җырын җырлый-җырлый аска төшеп китә.
Ләйлә Ләйсәнне юата. Башкалар хәрәкәтсез. Кечкенә чемодан тотып, як-ягына карана-карана Ф ә н ү с ә керә.

Ф ә н ү с ә. Исәнмесез!
Г ө л б а н у. Исәнмесез, кызым!
Ф ә н ү с ә. Гафу итегез, миңа маякчы Гөлбану апаны табарга кирәк иде.
Г ө л б а н у. Маякчы Гөлбану мин булам.
Ф ә н ү с ә. Ә мин Фәнүсә.
Г ө л б а н у. Утырыгыз. Ерактан киләсезме?
Ф ә н ү с ә. Ю-ук. Моннан — Уфадан гына. Сездә минем ирем торә икән.
Л ә й с ә н. Ләйлә... Мин китеп ятыйм әле. Әллә нигә башым авырта.
Л ә й л ә. Сабыр ит.
Г ө л б а н у. Алай икән... Таныш булыгыз, минем кызларым — Ләйлә белән Ләйсән!
Ф ә н ү с ә. Исәнмесез!
Л ә й л ә. Исәнмесез!

Ләйсән баш кына кагып куя.

Г ө л б а н у. Сезнең ирегез белән бергә эшләүчеләр: бригадир Хак һәм Нәҗип!
Х а к. Исәнмесез? Сезнең белән танышуыма бик шат!
Н ә ж и п. Исәнмесез! Җан... дустымның хатынын күрүемә шаккатып бетә алмыйм...
Ф ә н ү с ә. Исәнмесез!.. Исәнмесез!.. Үзе кайда соң әле?
Х а к. Яр астында иде, хәзер менәр.
Н ә ж и п *(уз алдына)*. Яр җимерелеп шунда күмелеп калсачы...
Ф ә н ү с ә. Күрешмәгәнебезгә ике ел тулды инде...

Гөлбану. Менә хәзер күрешерсез.
Фәнүсә. Ничегрәк икән? Бик үзгәрмәде микән?
Нәҗип. Черт булсынмы аңа. Андый кеше үзгәрәмени! Һаман бы-ты-быты килеп йөри тел бистәсе... Гафу итегез!
Хак. Нәҗип!
Нәҗип *(кул селти)*. Әй!..
Фәнүсә. Гөлбану апа... болай ничек соң... үзе генәме, дип әйтимме?..
Гөлбану. Үзе генә. Ә сез?
Фәнүсә. Без икәү. Бәләкәй кызыбыз бар.
Ләйсән. Башым әйләнә.
Ләйлә. Мә, су эч.
Ләйсән. Су эчеп кенә басылырмы бу йөрәк!?.
Фәнүсә. Сез нәрсә дидегез?.. Ә-ә, йөрәк!.. Йөрәк һаман басылмый шул.
Нәҗип. Иптәш Фәнүсә, ул сезне чакырдымы? Бирегә чакырып хат яздымы?
Фәнүсә. Юк. Мин аннан ике елга бер хат та алмадым. Хат салырлык булгач, качмый инде ул.
Гөлбану. Качты дисезме?
Фәнүсә. Качты. Бала буласын сизгәч тә юкка чыкты. Ваня исемле иптәшенә акча җибәрә дә, ул аны безгә кертеп бирә. Адресын әйтми. Әйтмәсә, күңеле дөрес булмагач, күз көеге булып янда яшәмәве артык. Разводны оформить итеп калыйм, дип килдем.
Нәҗип. Хат язмагач, аның монда икәнлеген ничек белдегез?
Фәнүсә. Ахырында Ванядан әйттердем. Ай буе аптыраткач түзмәде, бар, үзең күреп кайт инде, диде.
Нәҗип. У-у-ух, мин ул типусны!..

Астан канистрын тотып Гаяз менә.

Гаяз. Һа, менә куаныч, безнең бу оҗмахка тагын бер фәрештә кунган икән. Сәлам, мадмуазель!
Фәнүсә. Сәлам!.. Исәнмесез!..
Хак. Хм, хм... Гөлбану, дим, әллә теге ак гөмбәне карап кайтабызмы. Гөлбану, дим. Балалар, сез дә әйдәгез.
Гаяз. Сабыр, джентельменнар! Минем обществом сезгә ошамый, билгеле. Ләкин ник сезгә миннән качып иза чигеп йөрергә! Хәзер үзем китәм ич. *(Юл капчыгына әйберләрен җыя.)* Юк, миңа сөенергә ярамый, миңа беркайчан да сөенергә ярамый, джентельменнар. Ахыры һәрвакыт кайгы белән бетә.
Нәҗип. Гаяз!..
Гаяз. Бүлдермә, егет. Атарга алып барган бәхетсезләргә дә соңгы сүз бирәләр. Кешеләр мине нигәдер яратмый. Мине хәтта үз әнием белән үз әтием дә яратмаган. Тугач та, күрше әбигә ташлап, икесе ике якка качып киткәннәр.
Хак. Гаяз... Гаяз энем!..
Гаяз. Бригадир, сорауларың булса, иртәгә сорарсың. Мин авылга — башка егетләр янына китәм. Мин әллә бу ярда күңелемә җылы таптыммы, дигән идем. Биек баганалар, электр чыбыклары, кырлар, елгалар аша үтеп, бәхетемә китереп җиткерделәрме, әллә бәхетем белән кавыштырдылармы, дигән идем. Юк, ялгышканмын икән. Хушыгыз, җәмәгать... *(Иренен тешләп, күкрәгендәге сагышын чыгармаска тырышып аска карап тора. Көч белән үзен кулга ала. Искитмәгән кыяфәт белән транзисторын кычкырта-кычкырта чыгарга бара.)*
Хак. Монтажник, беркая да китмисең әле!
Гаяз. Һе! Ничек инде китмим? Мин — ирекле индивидуум.
Хак. Фәнүсә... сез бер сүз дә әйтмисезмени?

Фәнүсә. Минме? Ни дип әйтим соң?
Нәҗип. Соң бу сезнең... Гаяз ич инде бу?
Фәнүсә. Гаяз?.. Ю-ук, бу иптәш Гаяз түгел!
Гаяз. Кызы-ык!.. Ничек инде мин Гаяз түгел ди, фрейлина? Ул чагында мин кем соң?
Фәнүсә. Гафу итегез, мин сезнең кем икәнлегегезне белмим.
Ләйсән. Әйтегез әле... ул сезнең... ирегез түгелмени?
Гаяз. Ни сөйлисең, Ләйсән?! Мин нинди ир булыйм, ди! Кемнең ире?
Ләйлә. Менә аның... Фәнүсәнең.
Гаяз. Транзисторым белән ант итеп әйтәм, мин бу туташны гомеремдә беренче кат күрәм.
Хак. Гаяз, монысы тагын нинди ребус?
Гаяз. Ребус кына түгел — өч билгесезле мәсьәлә бу... Фәнүсә.. Фәнүсә!.. Әйтегез әле, сез Уфадан килдегезме әллә?
Фәнүсә. Әйе.
Гаяз. Ул чагында өч билгесезле мәсьәлә чишелде. Сез Әбелгаязның иптәшеме?
Фәнүсә. Әйе, әйе!.. Сез аны беләсезме?
Гаяз. Беләм!
Фәнүсә. Кайда ул?
Гаяз. Белмим.
Фәнүсә. Исәнме ул?
Гаяз. Белмим.
Хак. Гаяз, шаяра торган чак түгел.
Гаяз. Мин шаярмыйм, Хак абзый. Киресенчә, мин бик серьезный.
Ләйсән. Гаяз!..
Фәнүсә. Тизрәк сөйләгез!.. Аның турында ни беләсез?!. Үтенәм сездән!?.
Гаяз. Мин сөйләячәк сүзләрнең шатлыгы юк, Фәнүсә ханым. Моннан ике ел элек, Иркутск өлкәсенә килгәч, мине сезнең ирегез торган баракка, ул торган бүлмәгә, хәтта аның караватына урнаштырдылар.
Фәнүсә. Аның караватына?.. Ә ул?..
Гаяз. Балыкка киткән җиреннән кайтмаган. Көймәсен дулкыннар ярга кагып чыгарган.
Фәнүсә. Ул батканмы?
Гаяз. Атна буе эзләсәләр дә — табылмаган.
Фәнүсә. Туктагыз әле... Ә алимент?
Хак. Нинди алимент?
Фәнүсә. Соң үлгән кеше ничек инде... Ул бит шушы көнгә хәтле кызына акча салып тора.
Гаяз. Ул чак нәкъ сезнең бәбәй тапкан вакытыгыз булган. Сез үзегез ике ай буе больницада үлем белән тартышып яткансыз. Егетләр, уйлашканнар да, сез хәлләнгәч язмакчы булганнар.
Хак. Акчасы ничек?
Гаяз. Ай саен чиратлашып җибәреп тордык.
Фәнүсә. Баласын күрергә теләмәсә дә, бу мәсьәләдә тәртипләнгән, дип гаҗәпләнә идем... Ләкин тагын башым бутала. Бу ничек әле? Хәзер переводлар Себердән түгел — моннан килә ич — Камадан!.. Туктагыз, тукта. Димәк, аларны...
Хак. Монтажник!?
Гаяз. Миңа нәрсә — үзем дә ике күзем. Җитеп арткан. Минем дә кешеләргә әз булса да файда итәсем килмиме әллә?
Нәҗип. Ә үзең получка саен бездән ала идең. Артыгын да эчми инде бу, дип шарран-яра аптыраган чакларым...
Гаяз. Сәр!..

Гөлбану. Гаяз... ускәнем, син болар Фәнүсәгә бер беленер дип уйламадыңмыни? Ул кайчан булса да белергә тиеш иде бит.

Гаяз. Мин дә кайчан булса да дөресен әйтергә тиеш идем. Кешеләргә кайгылы хәбәр җиткерүдән дә авыр нәрсә юк икән, үлем хәбәрен бигрәк тә.

Фәнүсә. Мин сезгә рәтләп рәхмәт тә әйтә алмыйм. Зинһар, кичерегез! Күкрәгемдә йөрәгем юк шикелле — авыр бушлык.

Гөлбану. Фәнүсә сеңелем, өйгә кереп бераз хәл җыегыз.

Кызлар. Әйдәгез, әйдә!

Фәнүсә. Рәхмәт сезгә. *(Өйгә керергә кузгалалар.)*

Хак *(Гаязның юл капчыгын, аппаратларын салдыра)*. Ник бу нәстәкәйләреңне асып торасың әле? Сал.

Ашыгып Яз керә.

Яз. Кайда кунак? Килдеме әле? Әһә-ә, әллә комедия бетте дәме? Миңа ике генә кат йөзәргә кирәк булган икән.

Нәҗип. Тсс!

Яз. Син миңа ата каз сымак теселдәмә, егет.

Хак. Ахмак!

Яз *(кычкырып)*. Нәрсә сез бөтенегез дә, понимаешь.

Фәнүсә *(әйләнеп карый)*. Ай!..

Яз. Ә?!. Юк, юк, юк!..

Гөлбану. Ни булды?

Фәнүсә. Ул!.. Батып үлгән кеше!..

Ләйсән. Ул сезнең ирегезме?

Фәнүсә. Кызымның әтисе...

Яз. Юк, юк, юк!.. Син ничек?.. Ничек монда?!

Гаяз. Мистер, әйт әле дөресен генә — син Ангарага батып үлеп тә ничек һаман исән йөрисең?

Яз. Китегез әле!.. Туктагыз әле!..

Нәҗип. Хәзер маңгаегызга берне шып итсәм...

Яз. Бәлки син ярдәм-мазар турындадыр? Кайгырма. Моңа хәтле чит илләрдә йөреп җай килмәде... Әле яңа гына Бразилиядән...

Фәнүсә. Диңгезләр белән хыяллануыңны һаман ташламагансың икән. Әле кайда идең?

Яз. Фәнүсә! Син нәрсә?!.

Фәнүсә. Я?

Яз. Фәнүсә!..

Нәҗип. Я!

Яз. Пермь ягыннан сал алып төштек.

Фәнүсә *(сумкасыннан хатлар ала)*. Менә болар сиңа килгән хатлар. Элекке адрес буенча. Пермьнан Гөлбәгъдә исемле бер бәхетсез кыз сине эзли. Миңа аларны Кустанайдан таныш почтальон салды. Мә.

Яз. Фәнүсә... Минем Гөлбәгъдә дигән кешене бөтенләй очратканым юк. Ипидер менә...

Фәнүсә. Синең антларыңны беләм мин. Ал!

Хак. Ал!

Нәҗип. Тып туктагыз! Стоп, кран! *(Гаязның кесәсеннән хат ала.)* Сарай сәндерәсендә үз кесәң белән кеше кесәсен бутагансың, миңгерәү бака. Шуның аркасында кайберәүләр тешсез кала язды. Чүт-чүт гражданнар сугышы башланып китмәде.

Яз. Иптәшләр... Фәнүсә иптәш!..

Фәнүсә. Хәзер кай тарафларга юл тотасың?

Яз. Фәнүсә!

Фәнүсә. Я?

Гаяз. Я!

Я з. Бурятиягә язылып китәм. Ләкин син уйлама. Акчаны җибәрермен.

Ф ә н ү с ә. Безгә синең бер тиен акчаң да кирәк түгел һәм шулай ук... үзең дә кирәк түгел. Хуш, Әбелгаяз!

Я з. Син нәрсә, син нәрсә?.. Син бөтенләй үзгәргәнсең...

Ф ә н ү с ә. Сагыш белән кайгы йөзгә — сары, башка — акыл бирә икән. Хуш, Әбелгаяз!

Г а я з. Тәкъсир, сезгә китәргә боердылар.

Н ә җ и п. Фәнүсә, без аны бәлки һоп-дөп кенә итәрбез?

Ф ә н ү с ә. Ничек, һоп-дөп?

Н ә җ и п. Менә болай. *(Кулы белән күрсәтә.)*

Я з. Хак абзый!.. Егетләр, нишлисез?.. Хакыгыз юк... Судка бирәм. Унбиш тәүлеккә утыртам...

Н ә җ и п. Ничего, утырырбыз. Ә менә син үзең выж-выж космоска оча тор.

Хак һәм егетләр. Язны тотып алып, яр башына алып баралар һәм «Раз, два, взяли!» дип чайкый башлыйлар.

К ы з л а р. Туктагыз әле, безнең дә «Раз, два»лыйсыбыз килә.

Г а я з. Пожалуйста, тотыгыз тәпиеннән.

Кызлар да Язны тоталар. «Раз, два, взяли!» дип чайкыйлар да яр астына шудырып җибәрәләр.

Ф ә н ү с ә. Ой!

Н ә җ и п. Борчылмагыз, бу маршрут аңа таныш.

Я з *(астан кычкыра)*. Нахаллар!.. Бер кешегә җидәүләп ябышасыз. Бергә каршы — җидәү.

Г а я з. Матрос, бер кабахәткә җиде каршы икән, димәк, җирдә яхшы кешеләр күп дигән сүз.

Я з *(кычкыра)*. Трубкамны бирегез, нахаллар!

Н ә җ и п. Бәй, тагын төшеп калганмыни? Әйберләрен һич җыеп йөри белми бу кыл мыек... Әһә, монда икән. Мә, держи мулла, төрепкәңне. *(Аска ыргыта.)*

Башкалар Язны карарга чыгалар. Сәхнәдә Гаяз белән Ләйсән кала.

Г а я з *(әйберләрен җыя)*. Ярый, хушыгыз, мамзель!

Л ә й с ә н. Китәсеңмени?

Г а я з. Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, дигән иде эшеннән мәтәлеп төшкәндә минем бер замминистр.

Л ә й с ә н. Гаяз... теге... Лимара... кем димме?

Г а я з *(кесәсеннән Лимараның рәсемен ала)*. Без Детдомда бергә үстек. Алар, минем иптәш егет белән яратышып йөрделәр дә, никтер кинәт үпкәләштеләр. Көч-хәл белән татуландырдым. Бик куандылар. Туйларында рәхмәт әйтеп, Лимара шушы кәртечкәсен бирде. Хатлары килә. Уллары, кызлары бар. Я, хуш... Ләйсән!

Л ә й с ә н. Беренче мәртәбә... Ләйсән... Китәсеңмени инде?

Г а я з. Үзегез приказ бирдегез ич.

Л ә й с ә н. Ә хәзер мин сиңа амнистия игълан итәм һәм икенче приказ бирәм: әйберләреңне куй һәм минем яныма кил!

Г а я з. Матур кызларның приказына буйсынмый булмый. Егет халкының башын шул ашый.

Л ә й с ә н *(җирдән чәчәк бәйләме ала)*. Исләре дә исләре! Син миңа гел болын чәчәкләре генә бүләк итәрсең *(Гаязга сыена.)* акыллы монтажчыгым...

Г а я з. Кайнар йөрәгемдә бары сез генә, синьора!

Л ә й с ә н. Башка сүзләр белмисең, ахры?

Г а я з. Нинди сүзләр?

Л ә й с ә н. Иркә сүзләр.

Г а я з. Лэйсэн алмам, Лэйсэн хөрмәм, Лэйсэн кура җиләгем!

Л э й с э н. Лэйсэн кара җимешем, Лэйсэн әстерхан чикләвегем, аннан соңрак инде: «Лэйсә-эн, мин синнән компот ясыйм!» шулаймы, сэр?

Г а я з. Теге япун сигезаягы башны бутап бетерде... Лэйсән!

Л э й с э н. Әү.

Г а я з. Безнең монда бер айдан эш бетә. Мин синең артыңнан барып җитәрмен. Килимме?

Л э й с э н. Кил.

Г а я з. Көтәрсенме?

Л э й с э н. Көтәрмен.

Г а я з. Лэйсэн, истәлек өчен дә елмаеп кал әле. Бас менә монда. Шулай... Көл-көл!.. *(Фотога төшерә.)* Борыл... Шула-ай... Көл!.. Те-әк... Булды... Тагын... Тагын... Тагын... Тагын...

Л э й с э н. Җитәр инде.

Г а я з. Менә хәзер җитте. Син киткәч, тирә-якка кәртечкеләреңне тезермен дә, уртасына кереп тик карап утырырмын. Әй, кая әле, иреңә чәчәк ябышкан, димме?.. Кил әле, кил, борыл... *(Кочаклап үбә.)* Баллы чәчәк ябышкан икән. У-у-ух!.. Өйләнәм, өйләнәм!..

Л э й с э н. Әле син шундый хәйләләрне дә беләсеңмени? *(Сыена барып.)* Кит, кит, җитәр... Кеше килеп керер, күрерләр.

Көлешеп, куышып Н ә ж и п белән Л ә й л ә керә. Боларны күреп туктыйлар. Гаяз Лэйсәнне пинжәк итәге белән каплый. Шулай чыгып китәләр. Нәжип Ләйләне күтәреп ала да төп өстенә бастырып үбә. Х а к, Г ө л б а н у, Г а я з һәм Л э й с э н керә.

Х а к. Эһемм!

Н ә ж и п. Эһемм, бригадир.

Л э й с э н. Әни, безгә китәргә вакыт.

Г ө л б а н у. И балалар...

Х а к. Гөлбану, әйттем бит инде — ярамый.

Г ө л б а н у. Бетте. Ягез, ерак сәфәргә кузгалыр алдыннан утырып алыйк.

Утыралар. Гаяз үзе дә сизмәстән транзисторын боргалый. Транзистор сөйләп җибәрә. Һәммәсе дә: «Кирәкми, туктат, ни эшлисең инде!» — дигәнне аңлатып, кул селкиләр. Ләкин диктор сөйләгән хәбәр белән әкрен-әкрен кызыксынып китәләр. Дәшми-тынмый тыңлыйлар. Транзистордан д и к т о р т а в ы ш ы:

«...Химиянең бу яңа гиганты Идел һәм Кама буйларында иң зур предприятие булачак. Аны электр энергиясе белән тәэмин итү өчен «Ак яр» таулары итәгендә зур ГЭС салу күздә тотыла. Алар бишьеллыкның шушы елында салына башлаячаклар. Комсомол бу төзелешләрне шефлыкка алды. Алар «Комсомолның удар төзелешләре» дип игълан ителделәр.

Комсомоллар һәм комсомолкалар, яшьләр! Сезне шушы яңа гигантлар көтә. Аның яшь төзүчеләре сафына басарга ашыгыгыз. Шунда рәхим итегез, дуслар!.. Без соңгы хәбәрләр тапшырдык. Укыдылар...»

Л э й с э н. Ләйлә!

Л ә й л ә. Лэйсән!

Л э й с э н. Әфәнде монтажниклар, әй түгел лә, монтажник әфәнделәр, багажларны өйгә шагом марш!

Г а я з. Бу дикторга ходай Әрмәнстанның биш йолдызлы коньягын насыйп итсен! Амин, ходаем!.. Яшәсен минем транзистор! Яшәсен мин үзем!.. Күтәрдек!

Н ә ж и п. Тыңлыйм, галиҗәнап!

Г ө л б а н у. Ни булды соң бу, балалар?

Л э й с э н. Бу, әни, синең яныңнан беркая да китмәвебез була. Шаулап торган зур тормышны эзләп әллә кайларга барып йөрисе юк, дигән сүз булып чыга.

Л э й л э. Ул зур тормыш безне эзләп үзе монда килеп җитте. Безнең бөтен илебез зур тормыш мәйданы, дигән сүз була... Безгә ныклабрак кара әле, әни, кемнәрне күрәсең?

Г ө л б а н у. Кинәт кенә исәрләнеп киткән игезәкләремне күрәм.

Л э й с э н. Син, әни, «Ак яр» таулары итәгендә салыначак заводларның төзүчеләрен күрәсең.

Л э й л э. Я, тоттык, күтәрдек!

Н э җ и п. Әй, иптәшләр, чүт-чүт сабыр итегез әле! Ләйлә!

Л э й л э. Ә.

Н э җ и п. Я.

Л э й л э. Әйе.

Н э җ и п. Эһем!.. Гөлбану апа, йөрәгем леп-леп... Эһем... Гөлбану апа, нык кына итеп... Күз алларымда ниндидер төрткеләр ялт-йолт... нык кына итеп ризалыгыңны бирегез инде? Пожалуйста?

Г ө л б а н у. Нинди ризалык?

Л э й л э. Мена, Нәҗип әйтә... Яңа заводны төзергә... бергәләп парлап китик, дигән була.

Н э җ и п. Чып-чын ирекле Совет иленең ип-ирекле япь-яшь яңа семьясы булып... Пожалуйста, ә?

Г ө л б а н у. Үзең ни дисең соң, кызым?

Л э й л э. Мин ни инде... ни... Син әйтсәң... Синең теләгеңә каршы килеп булмас.

Г ө л б а н у. Үсеп тә җиткәнсез икән, кызым... Бирегез әле кулларыгызны!

Гаяз белән Ләйсән тиз генә бер-берсенә карашып алалар да, икесе ике яктан килеп, Гөлбануга кулларын бирәләр.

Г ө л б а н у. Нәрсә генә әйтим икән сезгә, нинди генә теләкләр телим икән?

Н э җ и п. Шып туктагыз әле! Ә без ничек, без?

Г ө л б а н у. Игезәкләремне үзем дә аермый башладым бугай инде. Ризалыгымны кайсыларыгыз сорый соң?

Л э й с э н.
Г а я з. } Ризалыгыңны без сорыйбыз, әни!

Л э й л э.
Н э җ и п. } Без дә ризалыгыңны сорыйбыз, әни!

Г ө л б а н у. Туганда бергә тудыгыз, туйларыгыз да бергә булырга язган икән. Китерегез әле кулларыгызны. Менә шулай. Мин сезгә ризалыгымны, хәер-фатихамны бирәм, оланнар. Олы мәхәббәт белән яшәгез, тигез гомер итегез!

Л э й с э н.
Г а я з. } Рәхмәт, әни!

Н э җ и п. Рәхмәт, әни.

Л э й л э. Порядок!

Х а к. Эшләр болайга әйләнгәч, мин әйтәм, Гөлбану, мин әйтәм, әллә без дә бергәләшеп шул яңа шәһәрне салырга китәбезме? Алтаулашып, мин әйтәм?

Г а я з. Планетабызның шушы тарихи минутларын кәртечкегә төшереп калыйм әле. Балаларыбызның балаларының балаларының балаларының балалары да, вәт шәп тә булганнар икән безнең элекке монтажник бабайлар, төзүче әбиләр, дип, горурланып карарлык булсын. Басыгыз рәтләп. Монтажник, кит минем кәләш яныннан!..

Н э җ и п. Әйдә, төшер чык-чык итеп...

Тезелешеп басалар. Гаяз, аппаратын автоспускка көйләп куя да, үзе тиз генә Ләйсән янына барып баса. Шул чакта транзистордан кинәт көчле матур музыка яңгырый башлый. Геройлар аңа карап кулларын селкиләр. Әллә көчәйт диләр, әллә туктат диләр — тавышлары ишетелми.

*П э р д э.*



## Зиннур Насыйбуллин

*Үзем турында берничә сүз. Туган җирем — Башкортстанның Нуриман районы. Туган елым 1937. Хәзер Башкортстанның Чакмагыш район газетасында эшлим. Көрәк-сәнәк, балта-пычкы, гайка ачкычы кебек эш коралларын каләмгә алыштырганчы шактый вакыт узды. Армиядән соң читтән торып урта мәктәпне бетердем. Башкорт дәүләт университетында укуны читтән торып дәвам итәм.*

*Шигырьләрне байтактан язам. Газета-журналларда күренгәләгәнем бар.*

*Казан күңелне тарта.*

Уйлый идем: «Мин житлеккән инде,
Күпне күргән, имеш, чыныккан.
Тормыш — дингез?
Әйдә, була бирсен,
Безнең өчен — дингез тубыктан».

И үсмер чак!..
Хәзер аңлашылды,
Бу тормышка чумгач муеннан:
Тубыктан да кермәгәнгә күрә
Ул тубыктан булып тоелган.

Колумбларны тыныч ярлар түгел,
Жил-давыллы дингез бар итә.
Акчарлаклар әнә ял итсә дә,
Дулкыннарга кунып ял итә.

## Кара шәле килә сөйрәлеп

Шомлы еллар иде.
Январь жиле
Өйне-тышны йөри бер итеп.
Сынар күзем белән тышка карыйм,
Тәрәз бозын өреп эретеп.

Ыңгырашкан кебек шыгырдатып
Хат ташучы ачты капканы,

Шомландырып, керер-кермәс торды
Һәм борылып кире атлады.

Нигә китте?
Нигә хат-хәбәрдән
Мәхрүм калды безнең өй генә?
Анам күңеле нидер сизде бугай,
Кара шәлен салып иңенә,
Ул урамга чыкты.
Өерелеп
Кышкы салкын керде ишектән.
(Салкын гынамыни ул елларда
кешеләрнең җанын өшеткән.)
Тиз урады әнкәй, ләкин өйне
Узып китте. Никтер кермәде.
Ялан аяк каршы чыкканымны
Әллә күрде, әллә күрмәде.
Каерылган кош канаты кебек
Кара шәле кардан сөйрәлә.
— Әни, әни.
Нәрсә булды, әни?
Сөйлә, әни.
Хәер... сөйләмә.
Шатлыкларга күнегелә бугай,
Тик кайгыга булмый өйрәнеп.
Ничәмә ел...
Ничәмә ел инде әниемнең
Кара шәле килә сөйрәлеп.

## Җөйсез яра

Табигатьнең бизәкләрен җуйды
Көнбатышның кичке эңгере.
Күкрәгеннән каны белән бергә
Акты җиргә солдат гомере.

Иртәгесен юкка гына кояш
Өмет белән аңа карады,
Юкка гына сыйпадылар нурлар
Әрнүләре тынган яраны.

...Һәр кич саен моңсу кояш бата,
Һәр таң саен офык кызара.
Күкрәгемдә әрни шул солдаттан
Миңа күчкән җөйсез бер яра.

●

Моңсуланып карап калдым әле
Кангылдашып казлар очканын.
Очалар бит,
Авыл карчыклары
Киссәләр дә канат очларын.

Күз життеме, шулай кабатлана:
Иркенлекне казлар сагына.

Яз життеме, күңел канатлана,
Сүрелгән хис кабат кабына.

Җылы якка китәр кебек булып,
Тагын казлар канат ныгыта,
Йорт кошлары гына булуларын,
Ахры, алар көзен оныта.

## Үзгәрттең дә куйдың

Гади генә кызсың. Кешедән
Һич артык та, ким дә түгелсең:
Тик синең бу гаҗәп сәләтең
Каян килгәндер ул, кем белсен.

Томан иде минем күңелдә,
Йөрәк — гүя әрнү төене...
Кагылмыйча, сүз дә әйтмичә
Үзгәрттең дә куйдың син мине.

Миңа хәзер бар да өр-яңа,
Бөтен нәрсә нурга төренгән:
Әйтерсең лә, бүген генә мин
Озак ятып чирдән терелгән.

Табигатьнең бөтен бизәге
Үз төсенә кайтты кабаттан;
Күнегелеп беткән җирләрдә
Әллә нинди серле ямь арткан.

Үзгәрттең син мине, үзгәрттең:
Үзең генә һаман элекке,
Тик сүндермим бер дә өметне;
Көтә-көтә күпме ел үтте.

Сүзсез генә: «Оныт»,— дидең син;
Онытылмыйсың, бар да хәтердә.
Бер утырып әллә еларга,
Әллә сиңа рәхмәт әйтергә.

## Ялганган җеп була төенле

Чигүче кыз, сиңа ни булды,
Күз тидеме әллә үзеңә?
Нигә, нигә бүген җепләрең
Я чуала, яки өзелә,
Туры килми энә күзенә.

Чигүче кыз, сиңа ни булды,
Бармакларың әллә талдымы?
Үзең чиккән нәфис бизәкләр
Күзләреңнең нурын алдымы?
Сөйгәнеңә хәтерең калдымы?

Чигүче кыз, сиңа ни булды,
Күз карашың нигә үпкәле?
Нигә әле бүген сөйгәнең
Турыгыздан җырлап үтмәде?
Өзелдеме күңел җепләре?

Ялганыр ул, көт син, ялганыр,
Тик күңелдә калыр төене.
Ялгаулы җеп белән чиккәндә
Бизәкләр дә була төерле.
Ялганган җеп була төенле.

## Кадыйр Сибгатуллин

●



*Туган ягым — Балык бистәсе. Туган авылым — Кече Укмас. Миргазиз Укмасый авылы. Миңа егерме җиде яшь.*

*Шигырьләрне яшьтән үк яраттым. Мине беренче кат көчле дулкынландырган шагыйрь Такташ булды.*

*Мәктәп елларында шигырь язып, үзе язган һәр нәрсәнең камиллегенә самими инанмаган малай юктыр. Районыбызның «Октябрь юлы» газетасы шигырьләремне бастырып мине тагын да очындырып җибәрде.*

*1960 елда, Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлап, районнан киттем.*

*Техник училище. Мин — электромонтер. Казанның Органик синтез заводы. Аннан солдат. Өч елдан тагын Казанда.*

*Балык бистәсенә борылып кайтканда 1966 елның язы иде. Монтер һөнәрен газета эшенә алыштырдым.*

*Эзләгәнем монда икән.*

*Авылларда йөрим. Гүзәл кешеләрне күрәм. Җәйге таңнарны Камада каршылыйм.*

*Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә, 4 курста укыйм.*

### Тамчылар

Тамчылар тама да,
тама да...
йөрәккә кадала.
Акылым юата:
карама,
тамчыга карама.

Берәүнең яшьләре тамуы
истә бит,
күңелдә.
Авыр ла күтәреп баруы,
баруы... гомергә.

### Эзлим үземне

Йоклыйлар.
Төн инде.
Мин генә
юксынам,
табалмыйм үземне.
...Караңгы, күренми берни дә,
табалмыйм сукмагым, эземне?!
Югалган көннәр бар,
еллар бар.
Яшьлек тә чәчәктә күптәннән.
Үр менеп, уфылдап суларлык
йөгем юк җилкәдә күтәргән.
Узылган еллар бар,
юллар бар.
Ни эзлим,
ни телим бүген мин?
Яшьлегем көнләшә йолдыздан:
Ник үзем бер йолдыз түгел мин?!

Урамнан урамга күченеп,
уз итеп җиде төн карасын
йөргәндә
моңарчы тоймаган
бәхетнең тоям күк яңасын.
Тоям күк,
тик төгәл әйталмыйм...
кайда ул?
Күренми күземә.
Чишмәдәй чылтырап күңелдә
нәрсәдер юл эзли үзенә.

Йоклыйлар.
Урамнар уратып
йөрим дә...
юксынам үземне.
Әллә соң йокысыз бу кеше
Җыр теләп уянган үземме?!

## Таң алдыннан агачларның шавы

Болытларга карап ята юллар,
карангылык йоткан биек тауны.
Кырлар япкан инде кара юрган,
ишетелә агачларның шавы.

Зур бурычын тоеп йөри йөрәк,
Үсә миндә һаман уйлар тавы.
Юкка түгел, юкка түгел, димәк,
таң алдыннан агачларның шавы.

# Тәүфикъ Камалиев



●

*Минем туган елым — кырыгынчы. Башта үзебезнең Буа районындагы Ташкичү мәктәбендә укыдым. Ә бишенче класстан башлап Апас районына кергән, ләкин безгә елга аша гына булган, Кызыл-Тау мәктәбенә йөрдем. Җиденче классны Казанда сиксән тугызынчы мәктәптә тәмамладым. Шуннан уңдүртенче һөнәр мәктәбенә кердем. Анда ике ел. Слесарь булып җиткәч, безнең бөтенебезне заводка җибәрделәр. Көндезен тимер игәдем, эштән кайткач китапларымны кыстырып кичке мәктәпкә дәреско чаба идем. Һич онытасым юк... егерме өченче мәктәп. Аттестат алгач, университетта укый башладым. Хәзер редакциядә эшлим.*

## Казаным

Карап кайттым кырык каланы,
Җитә яздым җирнең читенә.
Тик берсе бер хәзер истә юк,
Йөзек кашы кебеге син генә.

Йөзек кашы кебеге син генә,
Көн-төн шулай балкып торасың.
Кысасына сыеп бетмәгән
Асыл таштай калкып торасың.

Асыл таштай балкып торасың,
Үзен зурга күрә атың зур.
Ни күләгә,
Ни бер шәүлә юк,
Эчең-тышың синең якты нур.

●

Бу Ташкичү инде, Ташкичү,
Җитеп килә зәнгәр кич әнә...
Башны тагын тыгам чишмәгә...
Бу Ташкичү инде, Ташкичү.

Чишмә суын эчеп туялмыйм,
Ширбәт кушкан кемдер шуңарга.

Үзен белән бергә ал да кит,
Ташы белән бергә кубар да.

Бу Ташкичү инде, Ташкичү,
Урап-урап кайткан кешегә...
Тугыз күпер тугыз төшендә,
Бу Ташкичү инде, Ташкичү.

Бөтен нәрсә таныш бик яшьтән:
Качып-качып елаган, көлгән җир.
Кайдалыгын аның мин генә,
Тик бер үзем генә белгән җир.

Бу Ташкичү инде, Ташкичү,
Ә күгендә шул ук иске ай,
Су юлында аңкый ислемай...
Бу Ташкичү инде, Ташкичү.

## Апалар

Сез кыз чакта
Ат-ат уйнап йөргән
Малай гына идем әле мин.
Җүләр булып, сезне тыңламыйча,
Тыңлаганмын сүзен әнинең.

«Бар, апаңны чакырып чыгар әле»
Дигәннәргә мин гел каныккан.
Ә юмалап акча биргәннәргә
Тел күрсәткән бары ярыктан.

Ул егетләр...—
Очрый төрле хәлләр,
Белеп булмый икән алдан ник? —
Кайсы ауга,
Кайсы яуга киткән,
Кайсы кайткан, кайсы калган бит.

Яшьлек дәртен инде мин дә
аңлыйм,—
Йөрәкләргә сала икән ут.
Сезнең яклы булыр идем хәзер,
Тик.. дәштергән кеше генә юк.

●

Баш ими йөргән кызлар бар,
Бар башын игәннәре.
Кил әле! — дигәннәре бар,
Кит әле! — дигәннәре.

Дөньялар үзгәреп тора,—
Алай да болай бит ул.
Баш имәм дигәннәре дә
Баш иде... шулай бит ул!

Син генә баш та имәдең,
Миннән бик бизмәдең дә.
Караттың, шулай караттың...
Яраттым... сизмәдем дә.

**Тәуфыйк Сәгыйтов**

# КҮККӘ ГАШЫЙК ЕГЕТ

**И**юль иртәләренең берсе иде. Болытлар өстеңә ишелеп төшәрдәй булып бик түбән йөзәләр. Менә-менә чиләкләп яңгыр яварга тора. Инде аэропорттагы пассажирларның тиз генә оча алмаулары көн кебек ачык. Шулай да, нәкъ үз вакытында, Сочига очучыларның билетларын теркәү башланды.

Самолетка кереп утыргач та, стюардесса репродуктор аша:

— Хәерле иртә, хөрмәтле пассажирлар,— диде.— Корабль командиры Ибраһимов һәм экипаж сезне ТУ-124 самолеты бортында тәбрик итә. Бу рейс Волгоград аша Сочига бара. Очыш ике сәгать буе дәвам итәчәк...

Ачык чырай белән каршы алып, һәрберсен үз урынына утырту, салондагы чисталык һәм җайлылык, шундый җылы сәламләү сүзләре һәркемнең йөзендә елмаю балкытты. Әле Казан аэропортыннан кузгалып киткәнче үк, аларда аэрофлот кешеләренә карата уңай фикер туды. Пассажирларның һәрберсе аларга үзләренең тормышын ышанып тапшырды. Һәркем очучыларны батыр йөрәкле, гадәттән тыш куркусыз кешеләр итеп күз алдына китерде. Шуңа күрә бер ун яшьлек малайның:

— Әти, очучы героймы, ул сугышта самолеттан бомба ташлап фрицларны шартлатканмы! — дип соравы да бик табигый булып ишетелде...

Әйе, пассажирлар, электән таныш булмасалар, очучыларның кем икәнен белмиләр: аэропорт тирәсендә дә, вокзал эчендә дә аларның рәсеме һәм хезмәте турында язып эленгән матур, игътибарны үзенә җәлеп иткән стендлар юк. Билет сату урыннарында да «Вакытыгызны экономияләгез, самолетларда очыгыз»,— дип, төсле итеп басылган кәгазьләрдән башка берни дә күрмисең. Республикабыз горурлыгы булып җитешкән очучылар, зәңгәр күк киңлекләрен айкап, сезне, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрен белмичә, теләсәгез кая илтеп куючы кешеләр турында кечкенә генә брошюра тәкъдим итсәләр, начар булыр идемени!!. Экипаж, алай гына да түгел, аэрофлот һәм пассажирлар арасындагы мөнәсәбәтне тагы да якынайтыр иде бу!

* * *

Пассажирлар экипаж члennарын күрмәделәр әле. Чөнки очучылар бу минутларда контроль карта буенча очуга әзерлекне тикшерү белән мәшгульләр иде. Самолетның борынына ук кереп утырган штурман Имам Усманов инструкция пунктындагы юллар буенча сораулар яудыра, ә Рәшит Ибраһимов, икенче очучы Федя Митрофанов һәм бортмеханик Рифат Долотказин — һәрберсе дә үз өлешенә тиешле өлкә буенча җаваплар бирәләр.

Озак та үтмәде, көмештәй һава лайнеры, болытларны ярып, югары күтәрелде. Ә штурвалны Рәшит әле һаман үзенә тарткан, димәк, биеклекне яулау дәвам итә. Җиде мең метр, сигез мең, тугыз мең... Приборлар төрледән төрле саннарны күрсәтәләр. Спидометр аэропорттан ничә километр киткәнне белдереп тора, радиокомпас стрелкасы курс буенча туры барасыңмы-юкмы икәнен күрсәтә. Аларга карыйсың да, күренекле очучы Советлар Союзы Герое М. П. Водопьяновның «Күктәге дуслар» дигән китабындагы юллар искә төшә. Ул Казан аэропорты буласы урынга беренчеләрдән булып самолеты белән җиргә төшкән, Мәскәү — Казан — Свердловск арасында шактый очкан кеше. Менә шул трассада адашып йөрүе турында да яза ул. Чөнки ул вакытларда очучыларга тимер юл бердәнбер маяк булып хезмәт иткән. Водопьянов бер тимер юл буйлап ялгыш читкә кергән, чөнки ике-өч көн эчендә бер як читкә таба да яңа бер линия сузып өлгергән булганнар...



Рәшит Ибраһимов штурвал янында

Хәзер инде теләсәң дә, алай адашу мөмкин түгел: җирдәге маякларны ышанычлы приборлар алыштырган...

Менә тагын бер стрелкага күз саласың. Анысы биеклекне күрсәтә. Җир өстеннән тугыз мең биш йөз метр биеклектә барабыз икән. Бортның тышкы ягында температура — минус 50 градус...

Рәшит приборларга карый, таулар артыннан таулар чабышкандай булып өелгән болытларны да күзәтә. Куркынычлары, яшенләре юкмы, әгәр андыйлар очраса, читләтеп үтәргә кирәк...

Ул җирдә дә сүзгә бик үк юмарт кешеләрдән түгел, ә хәзер бөтенләй диярлек тынып калган, йөз чакрымга бер генә сүз ычкындыра. Анысын да бик кирәк чакта гына. Салондагы кешеләр тормышы өчен кайгыртудандыр бу, билгеле...

Күрше өлкәләр территориясенә чыккач, һава шартлары бөтенләй икенче булып китте. Көн аяз, кырларда комбайннардан калган саламнарны җыеп йөриләр. Дисталәрчә гектарларга җәелгән иген басулары да кул яулыгы кадәр генә булып күренә...

Штурвалны икенче очучы Федя Митрофанов алды. Хәзер самолетны ул алып бара. Рәшит урыныннан торды да пассажирларның кәефләре белән кызыксынды.

— Үзләрен ничек хис итәләр икән! — дип салонга юнәлде ул.

Пассажирлар арасында өлкән кешеләр дә, яшьләр дә, балалар да бар. Кайсылары әле мондый югары тизлектә оча торган «ТУ» самолетларына беренче генә утырганнар. Кем белә, сирәк йөри торган кеше булса, Кара диңгез ярларына ике сәгать эчендә очып барып җитү аның күңелендә бик озак еллар буе онытылмас хатирә булып сакланыр.

...Кешенең гомере буена еллар тузаны кунып та искерми торган хатирәләре күп җыела, ләкин шуларның берсе — иң мөһиме була дияр. Шулайдыр. Экипаж командиры Рәшит Ибраһимов өчен ул иң беренче мәртәбә якыннан самолет күрү иде.

Малай чаклар иде әле. Бервакыт, Кәшә авылы өстендә берничә мәртәбә әйләнеп, читкәрәк кенә бер самолет төшеп утырды. Малайлар авыл читеннән үк башланып китеп, тигез булып җәелеп яткан Еланлы күл болынына йөгерделәр. Абыйсы Фатих белән Рәшит тә шунда чапты. Самолеттан ниндидер врачлар чыктылар. Авылның бер авыруы артыннан килгәннәр икән, шуны алып, самолет китеп тә барды.

Авыл малайларының тынлыгын тәмам югалтты бу сакитар самолет. Күбесе, берничә группага оешып, үзләре планерлар ясарга керештеләр.

Бу елларда лачыннар илебезнең горурлыгы иде. Төньяк боз океанынннан Челюскинчыларны коткару, Төньяк полюс аша Мәскәүдән Америкага АНТ-25 самолетында бер дә төшмичә очып үтү — бөтенесе дә яшь буын өчен үрнәк булдылар. Һәр мәктәптә, һәр класста шул очучыларга охшарга тырышу чиксез көчле иде. Рәшитнең абыйсы Фатих та Чкалов кебек булырга хыялланды.

— Синең буең бик кечкенә, аннан таза гәүдәле дә түгел, сине мин техник итеп алырмын,— дия иде ул Рәшиткә. Аның кушуы буенча Рәшит такталар шомартты, абыйсы белән планерлар ясады. Аны өй кыегына менеп очыралар иде. Кайсы җимерелә, һавада ук таралып, җиргә төшеп тузанга күмелә...

Салам белән япкан өй түбәсенә малайлар төркеме көнгә берничә мәртәбә менеп йөри башлагач, олылардан да сүз булмый калмады, әлбәттә.

Балта остасы Габдрахман абыйның эш кораллары, үзе өйдә юк вакытта, тәмам яраксызга әйләнеп бетәләр иде...

Ә ул, шулай булса да, балаларын орышмады.

— Булырсыз, очучы да булырсыз, — дия иде ул. Абыйсы һәм иптәшләре, син кечкенә буйлы дип, Рәшитне кимсетсәләр:

— Кайгырма, улым, күккә менәргә буй гына түгел, йөрәк тә, белем дә кирәк,— дип, аны юата да торган иде.

Җиденче классны тәмамлаганда, Фатихның теләге һәркемгә билгеле иде: очучы, бары тик очучы гына булу! Училищега барып сынаулар да тапшырып кайтты ул. Ата кеше улының иңбашыннан сөйде. Үзе тар гына итеп калдырган мыекларын сыйпады. Улының хыялын тормышка ашыруы өчен ул да шатлана, хәтта эчтән генә горурлана да иде.

Илгә дошман бәреп керү Фатихның хыялларын чәлпәрәмә китерде.

Ул пехота училищесына эләкте, аны бетергәч тә сугышка керде.

Өч ай үткәч, аның белән бергә киткән Халиков бик каты яраланып әйләнеп кайтты. Бергә иңгә-иң сугышуларын, бер авыл өчен барган сугышта Фатихның каты яралануын һәм шул вакытта да очучы була алмый калуына әрнүен бик озак итеп сөйләде ул.

Абыйсының үлүе бик кызганыч һәм үкенечле булды. Инде тормыш йөген үзендә тарта башлаган Рәшит күзеннән дә яшь тамды. Күз яшьләрен кешегә күрсәтмәс өчен ишек алдына чыкты ул. Күз карашы ирексездән абыйсы менеп планерлар очырган өй кыегына төбәлде. «Синең хыялыңны үзем дәвам итәргә тырышырмын, абый»,— дип кабатлады Рәшит үзенә-үзе.

Абыйсының хыялы Рәшитнең омтылышы булып әверелде. Ләкин аны ничек тормышка ашырырга соң!

Кешеләр, ирләре, балалары, әтиләренең үлүе турында кара печатьле хәбәр алсалар да, күз яшьләренә буылып булса да эшлиләр: бөтенесе фронт өчен, фашисттан үч алу өчен!

Эш куллары җитешми. Шулай да ФЗӨга малайлар җибәрергә кирәклеге турында әледән-әле авыл Советына кәгазьләр килә. Әйе, анысы да ил өчен бик мөһим, заводларга да эшчеләр кирәк. 1944 елда Рәшит, тимер юлчылар хәзерли торган училищега эләгеп, электромонтер һөнәрен үзләштерә.

Сугыш тәмамланды. Халык җиңү көнен бәйрәм итте.

Рәшит абыйсы өчен биргән вәгъдәнең үтәлмәвенә борчыла иде. Кая барасың, белемең нибары алты гына класс... Авиация бит ул укуыңны сугыш әзде дип тормый, көн саен катлаулана бара, тирәнрәк белем таләп итә...

* * *

Бүгенге авиация турында сүз алып барганда, Россиядә туган, Советлар власте урнашкач тамырдан яңа үсеш алган, Бөек Ватан сугышында фашист илбасарларны кыйнап чыныккан һәм бүгенге көндә тынычлык сагында нык торган, дөньяда тиңдәше булмаган көчле Совет авиациясе иң беренче булып күз алдына килеп баса.

Хәзер авиация халык хуҗалыгының барлык тармакларына да хезмәт күрсәтә. Аэрофлот йөк ташу, почта күчерүдән тыш, авыл хуҗалыгында, урман байлыкларын саклауда, балык һәм җәнлек аулау промыселларында, кешеләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүдә дә киң кулланыла.

Соңгы елларда җирле һава флоты линияләре үскәннән-үсә бара. Авиация транспортыннан файдаланучы пассажирлар саны да елдан-ел арта. Моңа, һава флотының кешеләргә яхшы хезмәт күрсәтүе белән бергә, билет бәяләренең ел саен 10—15 процент күләмендә төшүенең дә сәбәбе зур булуын әйтергә кирәк. Күп линияләрдә түләү тарифы поездның купелы вагонына булган билет бәясе кебек кенә. Ә капиталистик илләрдә самолетка билет бәяләре бездәге тарифка караганда ике, ике ярым тапкыр югарырак.

Казан аэропорты да пассажирларга хезмәт күрсәтүдә зур роль уйный. Ул Мәскәүдән Себергә оча торган почта ташучы транспорт-самолетларын кабул итү өчен 1929 елда салынган.

1933 елның 18 августында Казанга «У-2» маркалы өч самолет килә. Алар Татарстан районнарында почта йөртә башлыйлар. Бу авиация элемтәсенең пионерлары Захарий Нахов, Николай Белов һәм Вера Тихомировалар була. Башта самолетлар Мамадыш, Алабуга, Чаллы, Минзәлә, Мөслим, Бөгелмә һәм Чистайга очалар.

1937 елда Казан аэропортындагы самолетлар саны унбишкә җитә. Ә тагын ике елдан Татарстандагы һава линиясенең озынлыгы 2.446 километрга кадәр үсә.

1939—40 елларда инде аэропорт чит шәһәрләрдән килгән самолетларны кабул итә, озата.

Бөек Ватан сугышы башлангач та, коллективның күп өлеше илнең азатлыгы өчен көрәшкә китә. Ә калганнары тылда, үз постларында эшләп, фронтны кирәк-ярак белән тәэмин итүдә көчен кызганмый. Шулай итеп, Казан аэропорты коллективы сугыш көннәре батырлыгына зур өлеш кертә.

Төп линияләрнең берсендә урнашкан бу аэропорт сугыштан соң самолетларны тәүлек буе кабул итүгә күчә. 1956—58 елларда Казанга яңа тип самолетлар кайта. Татарстан очучылары һәм инженерлары, илебездә беренчеләрдән булып, «ИЛ-14» һәм «ЛИ-2» самолетларын районнар арасында эксплуатацияли башлыйлар. Алар, Бөгелмә, Чистай, Чаллы, Минзәләгә очып, пассажирларны, почтаны һәм йөкләрне күпләп йөртүгә ирешәләр. Яңа линияләргә «АН-2» маркалы самолет чыга. Бу яңалыкларны кертүдә очучы Әбдрәшитов, Труднев һәм Корнеевларның тырышлыгы аеруча зур була.

Соңгы еллардагы үзгәрешләр күңелне тагын да шатландыралар. Казан аэропорты хәзер югары тизлектә оча торган күп урынлы АН-10, ИЛ-18, ТУ-124 кебек зур самолетларны кабул итә, аларга хезмәт күрсәтә. Моның нинди зур уңышлар алып килүен күрсәтү өчен бер генә сан китерү дә җитә: Казан аэропорты 1968 елдан алып һәр елны бер миллион пассажирларны озата башлады.

Кеше, меңнәрчә чакрымнар белән исәпләнгән ерак араны бер-ике сәгать арасында, яисә республиканың иң ерак районыннан да 30—40 минутта килеп җиткәч, очучыларга рәхмәтен әйтә дә, үз юлы белән китеп бара. Ә зәңгәр күк лачыннары яңадан һавага күтәреләләр.

Рәхмәтләр, рәхмәтләр... Кешеләргә яхшы хезмәт күрсәтеп, күтәренке күңел белән шулай озатып калучылар арасында бай тәҗрибә туплаган ветераннар да, яшьләр дә бар.

Менә Михаил Васильевич Родных. Ул күп очышлар белән җитәкчелек итә. Михаил Васильевич фашистлар белән баһадирларча сугыша. Советлар Союзы Герое исеме бирелгәч, аның күкрәгенә Алтын йолдыз медален Михаил Иванович Калинин үзе кадый... Нинди генә авыр һава шартлары туры килмәсен, Михаил Васильевич

һәрвакыт очышка әзер. Аңа бу эштә бай тәҗрибәсе ярдәм итә. Чөнки ул авиациядә инде 1929 елдан бирле эшли!

Диспетчер Василий Георгиевич Корнилов 1946 елдан бирле самолетлар белән җитәкчелек итә. Иң катлаулы очышларда ярдәм күрсәткәне өчен аңа берничә мәртәбә рәхмәт белдерелде.

Механика мастерское слесаре Гайнанов та алдынгылар исәбендә. Ул хезмәт батыры гына түгел, яу батыры да. Ул партизан булган. Алар отрядының көрәше И. Козловның «В крымском подполье» дигән китабында киң яктыртыла.

Иван Абрамович Лугинец та уннарча ел бертуктаусыз оча. Ул Бөек Ватан сугышында да кан койган. Хәзер үз тәҗрибәсен яшьләргә бирә. Ул дистәләрчә очучыларны корабль командирлары итеп тәрбияләде инде. Аның белән бергә үк хатыны Анна Николаевна да күптәннән бирле эшли.

Шундый кешеләрне Рәшит ул вакытта белми иде әле. Аэропорт, андагы берничә очучы, самолетларга хезмәт күрсәтүчеләр дип кенә күзаллый иде ул коллективны. «Очучы була алмам инде, һич югында, самолетлар тирәсендәге берәр эшкә урнашып булмасмы»,— дип, кадрлар бүлегенә килде ул.

— Кайда эшлисез! — диде бүлмә түрендәге зур өстәл артында утыручы.

— Моторлар төзү заводында. Электромонтер,— диде Рәшит һәм костюм кесәсеннән берничә кәгазь тартып чыгарды. Менә мин быел ДОСААФ оешмасы каршындагы радистлар курсында да укыган идем.

Кадрлар бүлеге начальнигы алдына куйган таныклыкны бик озак кына игътибар белән карады. Ничектер, берәр хата, кәгазьдән берәр кимчелек эзләүчене хәтерләтә иде ул. «Фатих абыйсының хыялын тормышка ашыру теләге белән күпме генә тырышсаң да, еллар буе кечкенә мәктәптә укулар, шул ук вакытта курс тәмамлаулар — барысы да юкка чыкты, күрәсең. Булмады, берәр самолет тирәсендә эшләү бәхетенә дә ирешә алмады, ахрысы»...

Рәшит тәрәзә аша урамга карады. Агач яфраклары да гүя аның борчылуын уртаклашып лепелдәшәләр. Алар кыска гына вакытка тынып торалар, әйтерсең лә егеткә күз тегеп, аны үгетлиләр: кайгырма, юләр, тормыш тотнагы бу аэропортның кадрлар бүлеге начальнигы гына түгел ич, илебездә башкалары беткәнмени, дия кебек тоелды аңа.

Шул вакыт начальник әйтеп куйды:

— Утырып тор, кем әле, әйе, Ибраһимов.

— Өлгергәнлек аттестатында белгеләрең әйбәт икән,— дип сүзен дәвам итте ул.— Эшләгән килеш алай яхшы укыгач, димәк, башың эшли синең...

— Белмим,— диде Рәшит. һәм башын күтәреп кадрлар бүлеге начальнигының күзләренә карады. Начальник та аңа карап аталарча бер сөйкемлелек белән елмая иде. «Белмим» сүзен бик дорфа әйтмәдемме икән! Әллә гафу үтенергәме!»

Рәшит кинәт кенә торып басты, кулына урын таба алмагач, урындык артына тотынды.

— Юк, юк, энем, утырып сөйләшик әле,— диде начальник.— Синең эшең заводта да начар түгелдер. Шәп коллектив бит ул. Әллә берәр таныш кешең бездә эшлиме, я булмаса башка берәр сәбәп бармы!

«Ни дияргә! Әллә барын да сөйләп бирергәме! Яшең егермедән узган, әле һаман балалык хыялы белән яшисең икән димәсме!»

— Гомумән, самолетны яратам мин,— диде Рәшит, уңайсызланып кына.

— Син акыл кергән егет инде,— дип, кадрлар бүлеге начальнигы аңа тагын да текәлебрәк күз салды.— Эшче коллектив арасында да чыныгу алган кеше. Әгәр без сине очучылар хәзерли торган училищега җибәрсәк, ә! Ничек карыйсың моңа! Сәламәтлек ягың сынатырлык түгелме!

Рәшит моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде, ни әйтергә дә аптырап калды.

— Әллә нимә... андый вариант та булуы мөмкинме! — диде ул.

— Мөмкин. Сәламәтлек ягың ничек, комиссия үтәрлекме!

— Врачлар әле берниндидә авыру тапканнары юк.

— Уйлап кара. Без заводыңа махсус кәгазь язып бирербез. Анда тоткарлык булмас. Ә училищега документларыңны бергәләп үзебез әзерләп җибәрербез...

* * *

Авыл белән Богырыслан гражданлык авиациясе очучылары училищесы арасында хатлар бик еш йөри башлады. Хыялның тиздән тормышка ашачагына бер Рәшит кенә түгел, гомумән, семьяда да чиксез шатланалар иде.

Рәшит ялга кайткач, Габдрахман ага, улы белән сөйләшеп утырганда, болай ди торган иде:

— Мин башта җирдән карап торырмын, улым, аннан соң, әгәр яраса, яныңа да утыртып карарсың әле, яме.

— Ярар, әти, ярар. Исән булсак, ул көннәр килеп җитәргә тиеш бит инде.

Ләкин Габдрахман ага никадәр зарыгып көтсә дә, аңа самолетка утырып йөрергә туры килмәде. Рәшит училищены тәмамларга санаулы гына көннәр калгач, ата кеше дөнья куйды.

Шулай да әнисен утыртып Ульяновск шәһәренә алып барырга туры килде Рәшиткә. Үзләренең Кәшә авылы һәм үзләре малай чакта самолет төшеп утырган Еланлы күл болыны өстеннән очып үттеләр алар. Өстән озак кына карап баргач, ана гаҗәпләнүен эчендә тотып кала алмады:

— Һәй, улым, бигрәк тә киң икән бу дөнья! — дип куйды.

Дөнья матур, дөнья киң шул. Казан белән Ульяновск арасындагы маршрутка гына да сыеп бетми ул. Рәшит, 1953 елда училищены уңышлы тәмамлап кайтканнан бирле, зәңгәр күгебез киңлекләрен иңли. Башта Татарстан районнарына хатлар, газета-журналлар ташыды, аннан пассажирлар йөртә башлады. АН-2 самолетына күчкәч, берничә ел рәттән Урта Азиягә барып, Фәргănă үзәнендә мамык кырларына ашлама сиптереп тә йөрделәр, хәтта мамык җыюда да үзбәк кардәшләргә зур ярдәм күрсәттеләр: махсус химикатлар сиптереп, яфракларын көйдерттеләр алар. Бу ысул комбайннарга мамыкны тиз арада чиста килеш җыеп алырга мөмкинлек бирде.

Рәшиткә Татарстаннан шактый ерак булган башка урыннарга да очарга туры килде. Илебезнең иң ерак төньяк шәһәре Норильскига да җибәрделәр аларны. Анда тайга урманнары уртасына экспедиция йөрттеләр. Аннары, хөкүмәтебезнең махсус заданиесе буенча, Татарстан егетләре Норильск шәһәреннән Красноярскига пассажирлар ташыдылар.

Рәшит эштә сынатмады, осталыгын күтәрү өстендә туктаусыз өйрәнде, укыды. Аннары аны «Ил» самолетларына утырту өчен Ульяновскидагы гражданлык авиациясе училищесының югары курсларына укырга җибәрделәр.

Шәһәргә килеп, шул бинаны эзләп тапкач, аптырап калды ул. Яшьлек елларындагы йөрәкне әрнеткеч көннәр искә төште. Кара әле, ничек туры килә. Нәкъ шушы бинада булганы бар бит аның. Абыйсы Фатих: «Сугышка китәбез»,— дип язгач, кышкы салкын буранда илле километр араны җәяү үтеп, Рәшит аңа йон оекбашлар китергән иде. Әле шунда Фатих абыйсы:

«Без авылны чыккан чакта  
Күтәрелде бураннар.  
Я кайтырбыз, я кайтмабыз  
Сау булыгыз, туганнар»,—

дип җыр да сузган иде. Соңгы күрешү булган икән шул. Менә хәзер энең Рәшит бирегә, син үлгәч биргән антны үтәп, күк баскычларыннан тагын да югарырак менү өчен өйрәнергә килде...

Курсларны уңышлы тәмамлады Рәшит. Берничә елдан яңадан бирегә килеп, ТУ-124 самолетында очарга укыды. Инде хәзер Рәшит Ибраһимов «ТУ-124» лайнерында беренче очучы, экипаж командиры булды. Зәңгәр күк киңлекләрен айкап, ун мең сәгатькә якын очарга һәм 3 миллион километрдан артык араны үтәргә өлгерде инде ул. Бу бит җир әйләнәсе тирәли 75 мәртәбә очып үтү дигән сүз.

Төрле хәлләргә очрады ул күктә.

Көз айлары иде. Рәшит, Харьковтан күтәрелеп, Симферопольгә таба юнәлде. Берникадәр араны үткәч, яңгыр башланды. Бу ни тагы: һава шартларының торышы турында кызыксынганда, явым буласы ачык әйтелмәгән иде ләбаса. Рөхсәт бирделәр, ул очып китте... Яңгыры бер хәл әле, дөбер-шатыр күк күкри, яшен камчылый башлады.

Ә җирдән һаман, куркыныч очравы бар, дип хәбәр итмиләр. Кинәт ниндидер бер сихри көч аскы яктан самолетка китереп бәрде. Самолет биеклеген югалта башлады...

Рәшит штурвалны кулыннан ычкындырмады. Берничә секунд эчендә хәлне чамалап алып, як-ягына каранды. Канатлар исән, димәк, зарар булмаска тиеш.

Биеклекне һәм тизлекне рәткә салгач, ул, штурвалны икенче очучыга тапшырып, үзе пассажирлар янына юнәлде. Шуннан соң Харьков аэропортына мөрәҗәгать итте:

— Ту-124 корабле командиры Ибраһимов сөйли. Ике минут элек кенә...

Аңа Запорожье, я булмаса Днепропетровск аэропортына төшәргә куштылар.

— Юк, хәзер барып җитәбез инде,— диде Рәшит.

Бу вакыйга аэрофлот кешеләрен аякка бастырды, шул сәгатьтән үк тикшерүләр, сорашулар башланды. Хәтта Рәшиткә берничә көннән СССР гражданлык авиациясе министрлыгы коллегиясендә дә җавап тотарга туры килде.

Коллегия утырышын министр урынбасары алып барды. Рәшит мондый бүлмәләргә кереп, андый зур белгечләр алдында үзе белән булган очракны тикшерүдә катнашырмын дип уена да кертмәгән иде. Орышырлармы! Төрле сораулар биреп тәп башына утыртырлармы! Дөрес, Рәшитнең төрле аудитория алдында чыгышлар ясаганы бар. Казан шәһәр Советы депутаты буларак та бик күп төрле мәсьәләләрне хәл иткәндә катнашырга туры килә иде аңа. Ләкин алар илебез күләмендәге коллегия түгел шул.

Ярар, монда да кешеләр утыра бит әле дип, Рәшит үз-үзен кулга алырга тырышты. Хәлнең ничек булуы турында барын да ачык итеп сөйли башлады.

Өстәл янында утыручылар бүлдермичә генә тыңладылар. Игътибарның шулай җылы булуы Рәшитне тынычландырды.

— Шундый каты итеп, кинәт кенә нәрсә бәрелүен әйтә алмыйм,— дип тәмамлады ул сүзен.— Авиация буенча белгеч-галимнәрнең бер хезмәтендә дә мондый хәл язылмаган. Һава бушлыгы да ун километр биеклектә булмаска тиеш...

— Бу хәл әле беренче мәртәбә,— диде министр урынбасары, Рәшит сүзләренә кушылып.— Үзебез дә сәбәбен аңларга телибез. Галимнәр үзләренең сүзен әйтерләр әле. Тик шунысы мөһим: сез, иптәш Ибраһимов, иң кирәкле вакытта югалып калмагансыз, самолетны, пассажирларны исән-имин килеш төшереп утырткансыз. Өстәвенә, кирәкле урынга кадәр барып та җиткәнсез. Молодец, батыр икәнсез, киләчәктә дә шулай уңышлы очыгыз...

Әйе, очышлары уңышлы аның. Экипажындагы Имам Усманов, Федя Митрофанов, Рифат Долотказин белән Ленинградка һәм Свердловскига, Мәскәүгә һәм Чиләбегә, Уфага һәм Симферопольгә, Куйбышев һәм Сухумига оча ул...

...Безнең рейс — иң катлаулылардан саналган Сочи — Адлер рейсы. Төшү полосасына Кавказ таулары арасыннан килеп чыгарга кирәк анда. Күнекмәгән кешегә, очучылар кабинасыннан карап торганда, самолет шул югары тизлектә борыны белән җиргә кереп китәр кебек тоела. Юк, Рәшитнең оста куллары сәгатенә мең километр белән очкан гигант-кошны тиз буйсындыра икән... Төшү полосасы буйлап бераз баргач та, самолет туктап калды. Шунда Рәшит маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларын сөртеп алды. Нәрсә, очучы кабинасы бик эссеме әллә! Һич юк, җайлы итеп баш өстенә генә урнаштырылган вентилятор да әйләнеп тора әле. Җаваплылыкны тоюдан һәм моментның киеренке булуыннан бәреп чыккан тир тамчылары иде бу. Ни әйтсәң дә, салон тулы кеше, алар өчен миллионнарча сумнарны тотып ясалган җайлы, уңайлы самолет. Аны исән-имин килеш күтәреп, очып барып, төшереп утырту зур җаваплылык сорый шул.

...Ял итеп, кызынып кайтучы пассажирлар белән Казан аэропортына килеп утыргач, кешеләр рәхмәт әйтеп төшә башлаганнар иде инде. Шул вакыт трап янына аэрофлот формасы кигән бер кеше ашыгып килеп җитте.

— Корабль командиры Ибраһимов кирәк! Рәшит! — дип кычкырып ук җибәрде ул, һәм траптан йөгереп менде дә кыска буйлы, шомырт кара чәчле очучыга кулын сузды.— Сөенеч, дус кеше, сөенеч. Сиңа беренче класс очучы исеме бирелгән. Бүген Мәскәүдән СССР гражданлык һава флотыннан таныклыгы килеп җитте...

Азат Җәләлов

# ЯШЬЛЕК КӨРӘШТӘ ЧЫНЫКТЫ

„Эшче яшьләр кемгә иярсә — киләчәк шуныкы», — РКП(б) Үзәк Комитеты органы «Правда» 1917 елның язында шулай дип язды. Меньшевикларга һәм эсерларга карамастан, газета революцион яшьләрне большевиклар тирәсенә тупланырга чакырды. Бу, февраль буржуаз демократик революциясеннән соң, большевиклар җитәкчелегендә эшләүче яшьләр оешмаларын төзү буенча В. И. Ленин тарафыннан партия алдына куелган бурычны тормышка ашыра башлау иде.

1917 елның мартында большевикларның Петроград комитеты яшьләрнең революцион оешмасы турында мәсьәләне карый. Шушы чорда Петроград, Мәскәү, Ростов-Дондагы эре заводларда һәм фабрикаларда, Уралда большевиклар катнашы белән пролетар яшьләрнең беренче революцион оешмалары — Эшче Яшьләрнең Социалистик Союзлары — комсомолның яралгылары төзелә башлый. Шул язда ук Казанның зур промышленность предприятиеләре тупланган елга аръягында да эшче-яшьләр түгәрәге барлыкка килә. Александр Табейкин, Петр Ильин, Сергей Шмаков, Татьяна Романова, Захар Путилов аның актив членнарына әвереләләр. Түгәрәкнең оешып китүе большевикларның эшлекле ярдәме аркасында була.

Түгәрәк активистларының РСДРП(б) ның Казан комитеты председателе В. А. Тихомирнов белән очрашулары һәм бу очрашуларда эшче яшьләрнең революцион оешмасын төзү мәсьәләсен тикшерүләре билгеле. Партиянең шәһәр комитеты яшьләрнең инициативасын яклап чыга, аларга тиешле ярдәм күрсәтүне өстенә ала. Хезмәт иясе яшьләрен союзга берләшергә өндәп берничә тапкыр сугышчан чакырулар һәм листовкалар таратыла. Яшь коммунистлар егетләргә һәм кызларга илдәге хәлләр турында сөйлиләр, аларны большевиклар тирәсенә тупланырга өндиләр.

1917 елның 17 (4) июлендә Бишбалтадагы Алафузов эшчеләре театры бинасында (хәзерге В. И. Ленин исемендәге Җитен комбинаты клубы) Казан революцион яшьләренең беренче җыелышы үткәрелә. Анда казна заводы егетләре, Алафузов фабрикасының тукучы кызлары, солдатлар, укучы яшьләр катнаша. Җыелыш Казанда большевиклар җитәкчелегендә эшче-яшьләр союзын төзү турындагы тәкъдимне бертавыштан яхшы дип таба. Шул ук җыелышта яшьләрдән 150 кеше Союзга член булып языла. Комитет составына механик һәм яшь шагыйрь Александр Табейкин, хәрби фельдшер Петр Ильин, Алафузов фабрикасы тегүчесе Татьяна Романова, эшчеләрдән Сергей Шмаков, Захар Путилов кебек революцион рухлы яшьләрнең иң алдынгы вәкилләре сайлана. Утырыш Союз комитетының председателе итеп А. Табейкинны, секретаре итеп П. Ильинны сайлый. Комитет шунда ук түбәндәге карарны кабул итә: «Бары тик большевиклар җитәкчелегендә генә эшләргә, гомуми җыелышларның беркетмәләрен һәм карарларын Казан большевиклары газетасы «Рабочий»да гына бастырып чыгарырга».

Шулай итеп, революцион яшьләр оешма-

сы турында В. И. Ленин күрсәтмәләре Казан большевиклары тарафыннан тормышка ашырыла.

Яшьләр хәрәкәтенең алга таба үсеше өчен РСДРП(б) ның VI съезды аеруча зур роль уйнады. Билгеле булганча, анда коралы восстаниегә әзерлек белән бергә, яшьләр союзы турындагы мәсьәлә дә карала. Союзның бурычларын билгеләгәндә съезд, яшьләр союзы бары тик культурагарту эшләре белән генә шөгыльләнергә тиеш дигән фикерне дә, һәм ул партиянең состав өлеше булырга тиеш дигән фикерне дә кире кагып, В. И. Ленин карашын, ягъни большевиклар җитәкчелегендә эшләүче һәм партия белән идея ягыннан бердәм оешма булган яшьләр союзының мөстәкыйльлеген яклап чыга.

Партиянең VI съездыннан соң яшьләр хәрәкәтендә яңа этап башланды. Россиянең күп кенә промышленность үзәкләрендә оешмалар төзелде. Бу оешмалар Ленин комсомолын төзү юлында җитди адым булдылар.

В. И. Ленин алда торган кораллы восстаниедә эшче яшьләрнең роленә югары бәя бирә. һәм аларны иң кыю элементлар рәтенә кертә. Бу фикер В. И. Ленинның мәкаләләрендә, чыгышларында һәм Үзәк Комитетка язган хатларында күп тапкырлар очрый.

«Иң кыю элементларны (безнең «ударникларны» һәм эшче яшьләрне, шулар белән бергә иң яхшы матросларны) барлык иң мөһим пунктларны яулап алу һәм бөтен җирдә, барлык иң әһәмиятле операцияләрдә катнаштыру өчен аерып алырга...,— дип яза В. И. Ленин». (Әсәрләрнең тулы җыелмасы. 26 том. 152 бит.)

Эшче яшьләрнең социалистик союзы членнары, билгеле булганча, Октябрь революциясен әзерләүдә актив катнаштылар. В. И. Ленин һәм Коммунистлар партиясе тарафыннан аларга багланган өметне тулысынча аклап чыктылар.

Заводлардагы партия оешмаларының күрсәтмәләре буенча Казан яшьләре союзы аңгәмәләр үткәрә, эшчеләр һәм солдатлар арасында большевистик газеталар, лозунглар тарата. Союз членнары матбугатта да актив катнашалар. «Рабочий» газетасында, мәсәлән, Захар Путиловның проза белән язылган «Кояшка» исемле поэмасы басылып чыга. Партиянең Казан комитеты «Рабочий»га материаль ярдәм күрсәтү хакында эшчеләргә мөрәҗәгать иткәч, союз членнары акча җыюда катнашалар. Эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан Советына һәм шәһәр думасына сайлау алды компаниясендә союз членнарының авазы эшчеләрне, солдатларны большевиклар партиясе кандидатларына тавыш бирергә өндәп яңгырый.

Җыелышларда, түгәрәкләрдә егетләр һәм кызлар тарафыннан В. И. Ленин мәкаләләре өйрәнелә, большевистик газеталарны, пролетар язучылар М. Горький, Д. Бедный әсәрләрен укулар оештырыла. Еш кына агымдагы хәлләр турында дискуссияләр, руслар һәм татарлар катнашында концертлар, кичәләр үткәрелә. Бу чаралар үз чиратында ике милләт яшьләрен үзара тагын да якынайта төшә.

Билгеле булганча, июль көннәре илдәге шартларны һәм сыйнфый көчләр бәрабәрен шактый үзгәртеп җибәрә. Меньшевиклар һәм эсерлар тәмам контрреволюция лагеренә күчәләр. Ике властьлылык бетә. Ул буржуазия кулына гына күчә. Эсер-меньшевистик советлар буржуаз хөкүмәткә тәлинкә тотучыларга әвереләләр.

Илдәге мондый шартлар большевикларны авыр хәлгә куя. Партия матбугатын тар-мар итүләр, эшче кварталларын тентүләр башлана. В. И. Ленинны кулга алу һәм аны юк итү турында приказ биргән буржуаз хөкүмәт революцион рухны бөтен чаралар белән җимерергә омтыла. Бу хәл большевиклар сафына очраклы рәвештә генә килеп кергән, яки әле тиешле чыныгу алып өлгермәгән элементлар арасында аптырау, каушап калу, еш кына очракларда идеалга хыянәт итүгә сәбәп була.

«Июль вакыйгаларыннан соң союзның эше бераз сүлпәнләнде,— дип искә ала А. Е. Табейкин,—...безнең арада вак җанлыларның барлыгы беленде һәм алар оешманы ташлап чыктылар. Калганнарыбыз, йодрыкларны йомарлый төшеп, киләчәк көрәшләргә әзерләндек».

1917 елның 21 сентябрендә яшьләрнең социалистик союзы комитеты Казан егетләрен һәм кызларын тагын да ныграк берләшергә чакырып өндәмә бастырып чыгара. Анда болай диелә:

«Иптәшләр! Безнең изге бурычыбыз — куәтле бердәм союзга туплану һәм оешкан төстә бөтен чаралар белән өлкән иптәшләребез эшчеләргә капитал изүеннән азат булу өчен көрәштә ярдәм итү.

Дуслар, кәеф-сафа корып торучы тамашачылар булмыйк. Бөтен яшьлек көчебезне, куәтебезне революция эшенә бирик! Кыю һәм бердәм рәвештә алга!»

Бу өндәмә, Казанның барлык районнарында да таратылып, завод һәм фабрика яшьләре арасында ныклы яклау таба. 1917 елның сентябрь азагында инде Союз 200 чамасы членны берләштергән оешмага әверелә.

Яшьләрнең революцион оешмалары Казанның башка җирләрендә дә барлыкка киләләр.

1917 елның маенда Бондюгта татар яшьләренең алдынгы өлеше «Мөселман яшьләре түгәрәге» оештыра. Оешманың җитәкче группасына укытучы А. Сәхәбетдинов, эшче яшьләрдән Г. Бәһаветдинов, Г. Фәсхетдинов, М. Шакиров, Ш. Саттаров, А. Галимбеков һәм М. Лотфуллин кертелә.

Партия оешмалары җитәкчелегендә яшьләр тырышып коралны бәрелешкә әзерләнәләр. Сугыш серләрен өйрәнәләр, корал туплыйлар.

Казанда 25 октябрьга кадәр кызыл гвардия отрядларына йөзләрчә яшь эшчеләр керә. Коралы восстание көннәрендә алар, эшчеләр һәм солдатлар белән кулга-кул тотынып, баррикадаларда юнкерларга, буржуазиягә каршы сугышалар. Санитария отрядларына берләшкән кызлар яралапучыларга беренче ярдәм күрсәтәләр, патронтажларга, пулемет ленталарына пуля тутырып торалар.

РКСМның беренче съездыннан соң гражданнар сугышының дәһшәтле көннәрендә урыннарда беренче комсомол оешмалары төзелә. Алар ленинчыл принцип нигезендә чын-чынлап интернациональ оешма буларак барлыкка киләләр.

1919 елның 12 апрелендә 330 меңле Колчак армиясенең авангарды Казаннан 100—120 километр ераклыкта гына торганда «Яшьләргә мөрәҗәгать» игълан ителә. Аның ялкынлы юлларыннан түбәндәгеләрне укырга мөмкин:

«Иптәшләр! Сез коммунизм өчен көрәшчеләрнең сирәкләнә барган сафларын тулыландырырга тиеш. Сез бүген — революциянең өмете һәм терәге, иртәгә — социалистик тормышны коручылар.

Үзегезгә багланган өметне аклагыз — берләшегез, чөнки бары тик оешканлык кына азатлык, республика бәхете өчен сезгә бөтен көчегезне һәм сәләтегезне күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк.

...Яшьләрнең теләген иско алып, РКП(б) ның Казан комитеты яшьләрнең шәһәр конференциясен чакырырга карар кыла. Аның төп бурычы бөтен Россия коммунистик яшьләр союзының программасы һәм уставы нигезендә Казанда эшче яшьләре белән укучы интеллигент коммунистик яшьләрнең бердәм союзын төзүдән гыйбарәт булырга тиеш».

Бу мөрәҗәгать Казан яшьләре арасында җанлы теләктәшлек таба. Эре заводларда һәм фабрикаларда яшьләрнең җыелышлары, митинглары булып үтә.

1919 елның 21 апрелендә университетның өченче номерлы аудиториясендә коммунистик яшьләрнең беренче шәһәр конференциясе чакырыла. Анда күп кенә заводлардан килгән делегатлар, шулай ук Казан коммунистлар союзы вәкилләре — барлыгы йөзләп кеше катнаша.

Конференциядә партия губерна комитеты председателенең комсомол оешмаларының бурычлары турында доклады тыңлана һәм Казан комсомол оешмасы төзү турында карар кабул ителә. РКСМның шәһәр комитеты сайлана. Аның составына Петр Ильин, Валентина Бабикова, Алексей Елисеев кебек партия эшенә бирелгән, революцион көрәш мәктәбен үткән кешеләр кертелә. Шулай итеп, 1919 елның 21 апреле Казан комсомол оешмасының туган көне булып тарихта кала.

Конференциядә катнашучылар партиянең Казан губкомы секретаре иптәш Карповның агымдагы хәл турындагы докладын зур дикъкать белән тыңлыйлар. Бу мәсьәлә буенча революциядә комсомолларның партия эше өчен бөтен көчләрен бирергә ант итүләре әйтелә.

«...Коммунистик яшьләрнең беренче Казан конференциясе Иделне һәм Каманы Себернең «бердәнбер хакиме» Колчак кулына бирмәс өчен бөтен көчне куәчагын, мөмкин булганның барысын да эшләячәген белдерә.

Конференция бөтен коммунистик яшьләр исеменнән дошман белән көрәшкә барлык көчен куячагына ант итә.

Конференция социализмның җиңүе хакына коммунистик яшьләрне тыгыз сафларга берләшергә һәм тончыгып баручы контрреволюция белән хәлиткеч көрәшкә чакыра».

Бөтен көчне мобилизацияләү турында В. И. Ленин чакыруына җавап итеп, Казан комсомоллары конференциядән ук фронтка комсомол отряды җибәрәләр. Ә 1919 елның 30 апрелендә Казан шәһәр оешмасының экстренный җыелышы була. Анда «Җыелышта катнашучыларның барысын да фронтка мобилизацияләнгән дип исәпләргә» дигән карар кабул ителә. 75 кешелек

отряд фронтка юл ала. Әгәр шәһәр комсомол оешмасының 220 кешедән торуын исәпкә алсак, бу аз түгел.

Комсомолның Казан шәһәр комитеты конференциядән соң ук яңа ячейкалар оештыру буенча зур эш җәелдереп җибәрә. Шәһәрнең төрле районнарына инструкторлар беркетелә.

Татар яшьләре арасында да шактый эш алып барыла. Шуның нәтиҗәсе буларак татар учительский семинариясендә Казанда татар яшьләренең беренче комсомол ячейкасы төзелә. Ул Г. Камай, М. Нуретдинов, Коләхметов, Яһудин, Әхмеров, кызлардан Хәдичә Сәидова, Наилә Бикмуллина, Фатыйма Хәбибуллина кебек кайнар йөрәкле яшьләрдән тора.

«Бу хәвефле көннәрдә без еш кына учительский семинария каршындагы бакчада митинглар һәм җыелышлар үткәрә идек,— дип искә ала Казанның беренче комсомолларыннан берсе хәзерге көндә Казан-химия технология институты профессоры, Дәүләт премиясе лауреаты Гыйлем Камай.— Коммунист Бабаев митинглардагы ялкынлы чыгышлары, шәхси төстә үткәргән җылы әңгәмәләре белән безгә бик көчле йогынты ясады. Аның ярдәмендә революцион рухтагы яшьләр, буржуаз милләтчеләрне фаш итә барып, коммунистлар тирәсенә тупландылар, комсомол ячейкасы төзеделәр».

1919 елның маенда Пролетар районының татар яшьләре арасында комсомоллардан Нур Сәйфи, Хәмит Үтәгәнов, Абдулла Хөсәенов актив эш алып баралар. Шул елның җәендә Елга аръягы райкомы каршында татар секциясе төзелә. Комсомолның губерна комитеты бирегә татар яшьләрен оештыруда җаваплы итеп Сафиулла Фәйзуллинны җибәрә [1]. Комсомолның Казан шәһәр комитеты шәһәрдәге эшләр белән генә чикләнми, губернаның Колчак бандаларыннан азат ителгән өязләренә комсомол ячейкалары оештыру өчен инструкторлар җибәреп тора. 1919 елның 11 июлендә партиянең өяз комитеты секретарьлар киңәшмәсе, «Яшьләр съезды турында»гы мәсьәләне тикшереп, яшьләр арасында эшләүгә игътибар бирергә, съездны июльдә чакыру өчен ярдәм күрсәтергә», дигән карар кабул итә. Моңа кадәр үк инде партиянең губерна комитеты өяз яшьләре арасында агитацияне көчәйтү өчен естәмә рәвештә 40 мең сум акча бүлеп биргән. Азат ителгән җирләрдә комсомол ячейкалары оештыру өчен 200 агитатор җибәрелә.

1919 елның 19 июнендә Мамадышта, Спасста, 23 июньдә Чистайда, 25 июньдә Алабугада комсомол оешмалары төзелә. Ә инде 1919 елның июлендә исә алар губернаның барлык өязләрендә дә оештырылалар.

1919 елның 14 июлендә Казанда коммунистик яшьләр союзының беренче губерна конференциясе ачыла. Ул көнчыгыш фронтта Колчакка каршы каты сугышлар барганда, Көньяк фронтта Деникин гаскәрләре һөҗүм иткән хәтәр көннәрдә уза.

Делегатлар агымдагы хәл турындагы докладны зур игътибар белән тыңлыйлар һәм Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә бөтен көчләрен куярга бердәм ант бирәләр. Конференция Ю. Фемидин, Э. Цимхес, Федотов, Г. Подузов, Х. Гарбер һ. б. лар составында комсомолның губерна комитетын сайлый.

Шулай итеп, 1919 елның 14 июле Татарстан комсомол оешмасының төзелү көне булып тарихка керә.

Шунысы игътибарга лаеклы, конференциядән соң губком татар һәм башка милләт яшьләре арасында эшне тагын да активлаштыра төшә. 1919 елның 25 августында комсомолның губерна комитеты янында Мөхәммәтов (председатель), Гатиятуллин (секретарь), Әхмеров (член) составында Мөселман (татар) бюросы төзелә. Бюро үзенең беренче утырышында ук татар яшьләре арасында агитация һәм оештыру эшчәнлеген җәелдерү турында карар чыгара [1]. Моның өчен комсомолның Тәтеш, Зөя, Мамадыш, Чистай комитетлары янында бюро секцияләрен оештырырга карар кылына.

1919 елның июль — август айларында өязләрдә татар яшьләренең беренче комсомол оешмалары барлыкка килә.

3 августта Бөгелмәдә татар укытучылары семинариясе укучыларның гомуми җыелышында комсомол оешмасы төзү турында карар кабул ителә. Союзга 30 кеше член булып языла. Комитет составына күпчелек тавыш белән Абдрахман Хикмәтов (председатель), Фатих Махъянов (предсе-

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. Ф. 80. Оп. 1. д. 5. св. 1. 36 бит.

[1] Партиянең Татарстан өлкә комитеты архивы. Ф. 80. ОП. 1. д. 5. СВ. 1. 1—2 битләр.

датель иптәше), Хөсәен Исхаков (секретарь), Сәетнур Фәхриев һәм Хәмзә Әхметов (членнар) сайлана. Беренче гомуми комсомол җыелышларының берсендә үк «өязгә җибәрү өчен агитаторлар сайлап алу» мәсьәләсе тикшерелә. Август азагыннан декабрь башына кадәр авылларда ун яңа комсомол ячейкасы оеша.

Шундый татар бюролары комсомолның башка өяз комитетлары янында да төзеләләр.

1919 елның 2 октябрендә комсомолның Казан губерна комитеты янында чуваш бюросы барлыкка килә. Аның беренче составына Семен Абу (председатель), Александр Зайцев, Яков Иванов, Кузьма Шайбин һәм Андрей Кузнецов (членнар) сайлана[1].

Шулай итеп, Татарстан комсомолиясе беренче көннәреннән үк төрле милләт яшьләрен бердәм-тату семьяга туплаган интернационал оешма буларак үсеп һәм ныгып китә.

Беренче комсомол оешмаларының төзелүе гаять авыр шартларда, кулаклар, руханилар, һәртөрле буржуаз элементлар белән аяусыз көрәш шартларында бара. Бу хакта өязләрдән килгән хәбәрләр аеруча ачык сөйлиләр. Авылларда еш кына хәлләрдә башта түгәрәкләр, аннан соң, бары тик бик четерекле оештыру һәм агитация чаралары үткәргәч кенә, ячейкалар төзелә. Мәсәлән, комсомолның губерна комитеты секретаре Эсфир Мосеевна Цимхес (хәзер персональ пенсионер) 1919 елның сентябрендә болай дип яза: «Лаешка килеп төшкәч, авылларга чыгып киттем. Чырпы авылында 42 кешедән торган культура-агарту түгәрәге оештыру мөмкинлегенә ирештем. Хәзергә әле союз төзү мөмкин түгел. 31 исемдәге 97 китаптан китапханә оештырдым... Алексеевский авылына килеп төшкәч, митинг үткәрдек. Митингтан соң берничә кеше союзга язылырга теләк белдерде».

1919 елның көзендә Көньяк фронтта Деникин бандаларына каршы көне-төне каты сугышлар дәвам итә. Биредә революция язмышы, Совет власте язмышы хәл ителә. Партиянең чакыруына җавап итеп, Көньяк фронтка комсомолның Казан губерна комитеты үзенең иң яхшы вәкилләрен җибәрә.

Ә Колчакка каршы сугышу өчен чаңгычылар кирәк булгач, Казан губернасыннан 300 комсомолец үзләре теләп Көнчыгыш фронтка китә. 16—18 яшьлек бу патриотлар арасында Казанның Елга аръягы, Суконный бистәсе, Плетән районнары һәм Зөя, Тәтеш, Лаеш, Чистай, Алабуга, Мамадыш, Бөгелмә егетләрен аеруча еш очратырга мөмкин була. Комсомолларның бу фидакарьлеген яшьләр кайнар тестә яклап чыгалар. 18 октябрьда, отрядның фронтка китәсе көнендә, партия һәм комсомол оешмаларының рекомендациясе белән патриотлар сафына тагын 900 егет кушыла. Ә инде октябрь азагында Көнчыгыш фронттагы чаңгычылар отрядының сафларында 7000 кеше исәпләнә. Аларның күбесе Казан, Нижний Новгород һәм Сембер губерналарыннан килгән егетләр була.

Документларда сакланган мәгълүматлар аша үзләре теләп фронтка китүчеләр арасыннан кайберләренең исемнәрен белергә мөмкин. Отрядка беренче булып язылучыларның берсе Антон Михайлов рота командиры була. Аның ярдәмчесе итеп Александр Иванов, ротаның политкомиссары итеп Александр Сидоров билгеләнгән. Рота руслар, татарлар, чувашлар, марилар, украинлылар һәм башка милләт вәкилләреннән тора. Иңне-иңгә куеп туган ил язмышы өчен көрәшү төрле милләт вәкилләре арасындагы революция тудырган дуслыкны тагын да үстерә, чыныктыра төшә.

Татарстан комсомолы үзенең членнарын фронтларга гомуми мобилизацияләр тәртибендә озатудан тыш, өч Бөтенроссия комсомол мобилизациясенең өчесендә дә актив катнаша. Якташларыбыз революция казанышларын саклап калуда искиткеч батырлык һәм егетлек күрсәтәләр.

1919 елның мартында гражданнар сугышы герое М. А. Азин командалыгындагы 28 нче дивизия Минзәлә юнәлешендә каты сугышлар алып бара. Полклар дошманның өзлексез кабатланып торган атакаларын көч-хәл белән генә кире кагалар. Хәл торган саен кыенлаша. Сугышчыларның сафлары сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Шул чакта Петроград полкының иң авыр һәм иң куркыныч участокларында тәбәнәк буйлы егетне әледән-әле күрергә мөмкин була. Ул бер окоптан икенчесенә күчеп сугышчыларны нык торырга өнди, җиңүгә рухландыра. Бу 23 яшьлек егет Казан комсомолларының элекке җитәкчесе полк комиссары Сергей Шмаков була. Көр күңелле, кыю, тапкыр, революция эшенә җаны-тәне белән бирелгән бу принципиаль егетне һәркайда яратып каршы алалар.

[1] Шунда ук, 59 бит.

Полкның хәле соң дәрәҗәдә кыенлаша. Акларның көчле пулемет уты һәм шрапнельләре сугышчыларга баш күтәрергә дә ирек бирми. Дошманның көчле ударына дучар булган кайбер участоклар чигенгәли башлыйлар. Озак та үтмәс, бөтен полк паникага бирелер сыман. Менә шул чакта Сергей Шмаков сикереп тора да, «Революция өчен алга!» — дип, дошманга ташлана. Комиссар артыннан бөтен полк контратакага күтәрелә. Акларның пулеметлары котырынып атса да, һөҗүмгә күтәрелгән сафларны туктата алмыйлар... Шушы сугышта Сергей Шмаков мәңгегә ятып кала. Аның кабере өстендә кызылармеецлар Совет власте өчен батырларча көрәшергә ант итәләр. 1919 елның 16 мартында «Красный воин» газетасы батыр комиссарның сугышчан юлы турында мәкалә урнаштыра. Ул түбәндәге сүзләр белән тәмамланган: «Без, синең исән калган дусларың, үлемең өчен үч алырбыз, мәңгелек дан сиңа, кадерле дус!»

Совет властеның тантанасы өчен гражданнар сугышының дәһшәтле фронтларында үзләренең гомерләрен биргән Татарстан комсомолларын, әлбәттә, бик күпләп санарга мөмкин булыр иде.

Мәсәлән, Бохара фронтында басмачыларга каршы көрәштә 9 нчы татар-башкорт кавалерия курсларында укучы комсомоллардан Гайсин, Павел Курицын, Захар Пузырев, Әхмәт Өхмәдуллин искиткеч батырлыклар күрсәтәләр. Алар бу фидакарьлек өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнәләр.

Фронтларда һәлак булганнар урынын яшьләр тулыландыра тора. Татарстан комсомолы эшче һәм крестьян яшьләрнең яңадан-яңа буыннары исәбенә үсә, ныгый һәм чыныга бара.

1919 елның азагы Татарстан комсомол оешмасының сафларын массовый төстә тулыландыру дигән чакыру астында үтә.

— Фронтка китүчеләргә алмашка! Союзның кызыл әләме астына! — чакыралар ул чакта яшьләрне газеталар, листовкалар һәм плакатлар.

Бу көннәрдә Татарстан партия оешмасы яшьләр арасында зур гына оештыру һәм тәрбия эше алып бара. Җирле газеталар битләрендә бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы геройлары турында мәкаләләр еш басылып тора. Алар үрнәгендә партия оешмалары яшьләрне коммунизм идеалларына чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләүне үзләренә максат итеп куялар.

Партия губерна комитеты яшьләр турындагы мәсьәләне берничә тапкыр тикшерә. 1919 елның 19 сентябрендә Казан губкомы, партиянең өяз комитеты вәкилләре катнашында киңәшмә җыеп, яшьләр арасында оештыру эшләре алып бару буенча тәҗрибә уртаклашу үткәрә.

Чистай вәкиле киңәшмәдә болай ди: «Яшьләр союзы яхшы эшли... Союздагы яшьләрдән 17 кеше мобилизацияләнде, ләкин бу эшне таркатмас дип уйлыйм, чөнки оештыручы көчләр бар».

Яшьләрне тәрбияләүгә гражданнар сугышы фронтларыннан кайткан коммунистлар һәм комсомоллар да житди өлеш кертәләр. Өлкән коммунистлар һәм беренче комсомолларның яшьләр белән очрашулары күркәм традициягә әверелә.

1919 елның 25 октябрендә Татарстан комсомолы органы «Клич юного коммунара»ның беренче саны чыга. 1920 елның 22 январенда «Кызыл яшьләр» басыла башлый. Аларның битләрендә комсомолларның паеклы эшләре киң чагылыш таба.

Совет власте өчен героик көрәштә Ленин комсомолы үзен сугышчан дан белән бизәде. 1928 елның февралендә аңа, гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен, сугышчан Кызыл Байрак ордены бирелде. Бу фидакарьлек символында Татарстан егетләренең һәм кызларының да өлеше мул.

Бүген коммунистик җәмгыять төзү өчен актив көрәшүче яшь замандашларыбызның оешмасы — Татарстан комсомолының төүге адымнары әнә шундый якты сәхифәләрдән гыйбарәт.

Тәлгат Галиуллин

# ШИГЪРИ АЧЫШЛАР ҺӘМ ЮГАЛТУЛАР ЕЛЫ[1]

1968 елда да шигърият чишмәсе, тормышның катлаулы һәм сикәлтәле юллары буйлап, алга таба баруын дәвам итте. Х. Туфан, Н. Арсланов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Ә. Баянов, Р. Әхмәтҗанов, Х. Камалов, Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин һәм башка шагыйрьләр укучыларны үзләренең яңа әсәрләре, шигырь китаплары белән сөендерделәр. С. Хәкимнең «Сайланма әсәрләре» басылып чыкты. Өлкән сүз остасының күп еллар уйлану-эзләнүләрен үз эченә алган бу китапны үткән елның зур шигъри казанышы дип санарга мөмкин. Бер ел эчендә дөнья күргән шигырь-поэмаларның күп һәм төрле булуы поэзиябезнең үсеше турында иркенләп сөйләшеп, киңәшеп алырга мөмкинлек бирә.

Тулаем алганда, 1968 ел поэзия үсешендә нинди дер яңа чор башламады. Бу — аерым жанрлар үсешендә дә ачык күренә. Сатира-юмор өлкәсендә, җыр жанрында уңышларыбыз санаулы. Чынбарлыкның яңа катлауларына тирән үтеп кергән, замандашыбыз образын яңача сурәтләгән һәм форма-композициядәге камил яңалыклары белән хәтергә сеңгән поэмалар да аз рак язылды. Ләкин поэзия бер урында таптанмады. Татар шигърияте мәңгелек хакыйкатьләр, бөтен кешелекне борчыган әхлакый-фәлсәфи проблемалар, революцион гуманизм принциплары турында тагын да киңрәк һәм ныграк уйлана башлады. Теге яки бу вакыйганы рифмага калыплаган урта кул шигъри лозунгларның азая, кими төшүе һәм шигъри культураның үсә, интонация-аһәңнең төрлеләнә, профессиональ осталыкның чарлана баруы да поэзия белән азмы-күпме таныш кешеләрне сөендерми калмас, дип уйларга кирәк.

Әлбәттә, поэзиягә хас бу сыйфатлар соңгы бер елда гына барлыкка килмәде. Татар шигърияте тарихына күз салсак, без анда элек-электән гражданлык хисләренең, иҗтимагый мотивларның зур урын тотканын күрербез. Бу гуманистик традиция соңгы елларда бөтен күркәмлеге белән ачылып китте. Үтеп киткән елда укучыга ирешкән шигырьләрнең иң яхшыларына менә шул гражданлык хисе, тирән оптимизм хас. Югары пафос, киң иҗтимагый яңгыраш шагыйрьләребезгә чынбарлыкны иңләбрәк сурәтләргә, илне, кешелекне борчыган әхлакый һәм фәлсәфи проблемаларны, яшәеш коллизияләрен тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирде. С. Хәкимнең «Тышта буран», «Таулар, таулар», «Татарлар елмаеп үлделәр», И. Юзеевның «Соңгы сынау», Х. Туфанның «Кулмәгең талда», «Атларым», Н. Арслановның «Унике батыр турында баллада», Х. Камаловның «Тормыш дулкыннары», Р. Фәйзуллинның «Көрәшчеләр», Р. Харисовның «Мулланур» шикелле шигырь-поэмаларын искә төшерик. Ул әсәрләрнең лирик герое үзенең гуманистик омтылышы, халкыбызга хас күркәм сыйфатларны үстерүе, кыю һәм киң фикер йөртүе, шәхес белән җәмгыять арасындагы якынлыкны дөрес аңлавы белән хәтердә кала һәм укучыны җәлеп итеп тора.

---

[1] Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

һәр талантлы шагыйрь иҗтимагый мотивларны, чор пафосын үзенчә чагылдыра. С. Хәким өчен гражданлык поэзиясе ул — кеше бәхете өчен кискен көрәш, олы хисләр һәм тирән фикерләр поэзиясе. Шуңа күрә дә аның һәр уңышлы әсәре ил, халык язмышы турында борчылып уйлану буларак кабул ителә. «Казан утлары» журналында басылган «Озын чылбыр, бик күп боҗралар» шигыренә тукталыйк. Төрле чор көрәш-вакыйгаларын янәшә куюга, шәхес язмышы турында уйлануга корылган бу әсәрдә гражданлык тойгысы гаҗәеп үзенчәлекле бер чагылыш тапкан.

Хәзерге тормыш, заман турында уйланганда, хәтер канатында үткәнгә кайтып, шагыйрь межачы якташын исенә төшерә. Гомерен буын башында үткәргән Мәмкә туктаусыз хакыйкать эзләгән, аны таба алмагач, «елаган ул ятып чылбырга». Язмыш чылбырын сөйрәүне үз өстенә алган шагыйрь дә межачыга якын. Икесе дә җир, туган ил белән тыгыз бәйләнгәннәр. Шагыйрь дә, Мәмкә шикелле, «заман межасын» дөрес сызарга, халык намусын гәүдәләндерергә тиеш.

С. Хәким лирикасы үсә, тирәнәя бара. Үткән елда иҗат ителгән шигырьләрендә ул, вакыйганың үзен сурәтләүдән бигрәк, күренешнең төбендә яткан иҗтимагый-фәлсәфи нигезне эзли. Конкрет вакыйга киерәнкә хис белән үрелеп китә, киң гомумиләштерүләргә алып килә. С. Хәким телнең әчке җегәрлеген, музыкасын, аһәңен тоеп эш итә. Шагыйрь үзен борчыган, уйландырган аерым мәсьәләләрне кайта-кайта эшкәртә. Мәсәлән, «Син иренеп...» исемле шигырь белән берничә ел элек үк ул тормышта һәркемнең үз язмышы, үз юлы була дигән идеяне үткәргән иде. «Тышта буран» шигырендә С. Хәким шул гуманистик темага яңадан әйләнеп кайта. Шагыйрь табигый һәм әчкерсез интонация белән картлар йортында яшәүчеләрнең шактый катлаулы һәм бай тормыш юллары хакында сөйли, авыр язмышлы шәхесләргә карата кешелекле булырга чакыра.

Үтеп киткән елда гражданлык поэзиясе үсешендә ике тематик юнәлеш ачык төсмерләнә. Аларның берсен олы язмышлы кешеләргә игътибар арту дип атарга мөмкин булыр иде. Икенчесе поэзиядә тарихилык принцибы көчәю белән бәйле.

1968 елда поэзия халкыбызның батыр улларын романтик, хәтта патетик биеклеккә күтәреп җырлауга зур көч куйды. Бирeдә үзәк һәм мактаулы урынны Муса Җәлил образы алып тора.

**Өемнең янында җил елый,**
**Бик ерак юл узган ул, беләм;**
**Мусалар турында хәбәр бар:**
**«Татарлар елмаеп үлделәр»...**

С. Хәкимнең «Татарлар елмаеп үлделәр» исемле шигыреннән алынган бу юлларда татар халкының батырлыгы, туган иленә тугрылыгы белән горурлану хисе аңкып тора. Шагыйрь, тормыштан алынган реалистик детальләргә һәм лиризмга таянып, кешелек идеалын байрак итеп күтәрә, хис тирәнлекләренә юл ала.

«Күлмәгең талда» шигырендә Х. Туфан герой-шагыйрьнең һәйкәле каршында торганда туган хисләре белән уртаклаша... Лирик геройның масштаблы фикерләве, омтылышлы хисе укучыны ил һәм халык язмышы турындагы уйланулар ташкынына алып кереп китә:

**Карый да Ил**
**һәйкәлеңә, Җәлил,**
**Үзен күрә синең төсеңдә:**
**Ул да шулай — кулын бәйләтмичә**
**Гомер итә бу җир йөзендә.**

И. Юзеевның «Соңгы сынау» әсәре дә Муса Җәлилгә багышланган. Үз иҗат юнәлешенә, эстетик принцибына тугрылыклы калып, бу поэмасында шагыйрь тормыш-көнкүреш детальләренә, вак эпизодларга артык тукталмыйча, героен тормышының иң хәтәр, иң фаҗигале бер моментында сурәтли. Шушы мизгелдә Җәлилнең туган иленә мәхәббәте, намусы һәм идеалына тугрылыгы соңгы сынауны кичерә. Бу ситуациядә поэмага Мефистофель образының килеп керүе дә аклана. Хикмәт Җәлилнең үлем җәзасы алдыннан Гетеның «Фауст»ын укуында гына да түгел. Шагыйрь фашистлар

Германиясе белән Фауст һәм Мефистофель турындагы легендаларны тудырган урта гасыр вәхшилеге арасында якынлык күрә. Гете трагедиясендәге шикелле үк, Мефистофель явыз һәм хәйләкәр рухлы булып калган. Азатлыкка һәм гуманизмга омтылышы, рухи ныклыгы белән тиранны да таңга калдырган шагыйрь өстенә иблис үзенең сыналган «җимнәрен» ташлый: таң кызын алдына китереп бастыра, җанын сату бәрабәренә йөз ел гомер вәгъдә итә, туачак көннең дәһшәтләрен сурәтли, шагыйрьнең күңел ныклыгын, идеалын какшатырга омтыла:

> **Аллаң да юк синең, муллаң да юк.**
> **Һәммәсеннән үзең баш тарттың.**
> **Ә кешенең җаны таш түгел бит,**
> **Кемгә ялварырсың җан сорап!..**

Ләкин гаҗәп хәл. Рухи үлемсезлеккә, азатлыкка омтылышы белән шагыйрь шайтаннан да көчлерәк булып чыга. Чөнки ул куәтне Алып батырлардан, Алпамышлардан, туган җирдән ала. Явызлык, караңгылык якты идеал, гуманизм белән көрәштә чигенергә мәҗбүр була.

«Соңгы сынау»ның композициясе дә, шигъри алымнары да ышандыра. «Тынлык белән сөйләшү» поэмасында башлап җибәргән кыю эзләнүләрен дәвам итеп, И. Юзеев шартлылыкка, символикага, күпертү ысулларына таяна, шулар аша реалистик поэзиянең офыкларын киңәйтеп җибәрә.

Ләкин шагыйрь уңышлы табылган шигъри алымнарны ахыргача файдаланмаган, аларның байтагын потенция хәлендә калдырган. И. Юзиев акцентны Җәлилнең рухи батырлыгын, әхлакый ныклыгын сурәтләүгә юнәлтә. Әлбәттә, аяк-кулы богауда килеш тә Җәлилнең сугышчы һәм көрәшче булып калуы, тиранлыкның нигезен какшату өчен көрәше җыр канатында гасырларга үтәргә тиеш. Ләкин Җәлил талантлы һәм олы шагыйрь дә бит әле. Тормышының соңгы минутларында аны, барыннан да бигрәк, шигырьләренең язмышы, киләчәге борчыган булса кирәк: йөрәк каны белән язылган җырлары иленә кайтып җитәрме? Халкы аларны ничек кабул итәр? Акыллы иблис булса, Мефистофель дә шагыйрьнең бөтен өмете, ышанычы, язмышы булган Моабит дәфтәрләре белән кызыксынырга, аның җанын сатып алу өчен шулардан файдаланып калырга тиеш иде шикелле. Кызганычка каршы, автор Мефистофель образына укучыга электән таныш булмаган яңа сызыклар өсти алмаган. И. Юзеевка киләчәктә бу юнәлештә эзләнүләрен дәвам иттерергә мөмкинлек тә, зарурият та бар.

Татар халкының батыр улларын калкурак, масштаблырак итеп сурәтләүгә омтылу яшьләр иҗатында да ачык сизелә. Р. Харисовның «Мулланур» шигырендә динамика, киеренке драматизм, «лирик накал» хас. Шагыйрь Мулланур батырлыгының бөекләгеҗ, эчке рухи матурлыгын, үлемсезлегенең нигезен ачып бирергә ниятли. Ул иске теманы яңача чишә, героена яңа сызыклар өсти. Бәхәсле һәм кытыршы урыннар булуга да карамастан, бу шигырь — һичшиксез, яшь шагыйрьнең зур иҗат казанышы.

Р. Фәйзуллинның «Көрәшчеләр» шигырендә дә гуманистик хис, кыю гражданлык мотивлары алгы планда тора. Әсәрдә фикер киңлеге, масштаблылык, тарихның буыннан-буынга үсеп-күчеп баруын дөрес сиземләү бар. Ләкин шигырьгә конкретлык җитми.

Х. Туфанның «Шигъри елъязмалар» дип исемләнгән яңа циклында тарих һәм кеше язмышы турында уйланулардан торган истәлекләр, поэтик портретлар зур урын алган. Өлкән шагыйрьнең бу авыр жанрга чын-чынлап керешүе — мактаулы күренеш. Бу — бөек Тукай традицияләрен дәвам итү, аның иҗат васыятьләрен үтәү дигән сүз. Мәрхүм Ә. Давыдов язып чыкканча, циклга кергән аерым әсәрләрдә «фактларны рифмалап регистрацияләү», вакыйга артыннан ияреп, гомумиләштерүдән баш тарту үзен сиздергәләп куйса да, «Зыя идең, якты идең син», «Отелло» шигырьләрендә Х. Туфан кызыклы шигъри табышларга юлыга.

Ә. Маликов үзенең «Салкын-Алан» поэмасында татар халкының батырлыгы, кырыслыгы, чыдамлыгы хакында сүз алып бара. Язмыш драматизмын матур лирик буяулар, табигать хозурлыгы белән чигеп, бизәп барган ялтыравык урыннар ярылып-ярылып үтсәләр дә, үзәккә реаль шәхесне алып язылган «Салкын-Алан» поэмасын зур шигъри ачыш итеп санавы кыен. Әсәр тигез язылмаган. «Салкын-Алан»ның безгә якынрак чор вакыйгаларын сурәтләүгә багышланган соңгы бүлекләре мәгълүм еллар-

ның «конфликтсызлык теориясе» өлгесе белән язылган әсәрләрне хәтерләтә. Ә. Маликов кирәкмәгән кабатлаулардан да котыла алмаган.

Ил һәм Татарстан алдында торган бөек бәйрәмнәргә якынлашкан саен, татар поэзиясендә халыкның үткәнен аңларга, чорны иңләргә омтылган әсәрләр күбрәк языла башлады. Мисалга Х. Туфанның «Еракларга алып киттеләр», Ш. Галиевнең «Чаң турында баллада» әсәрләрен китереп булыр иде. Тарихилык тенденциясе яшьләр иҗатында да бер агым булып килә. Г. Рәхимнең «Октябрь», Р. Вәлиевнең «Илле яшь тутырган абыйлар», З. Маликовның «Мәскәү», «Шушындый ташлар бар Казанда», «Шушы халык чабатадан йөргән» шигырьләрендә илнең, халыкның үсеш юлларын, аның характерын аңларга омтылыш сизелә.

«Еракларга алып киттеләр» шигырендә Х. Туфан җәмгыять тарихы белән шәхес язмышы арасындагы эчке бәйләнешләр турында уйлана. Дәвернең өермәле һәм фаҗигале тарихи баскычларын Туфан йөрәге аша уздыра, аларны шәхси кичерешләре, заман аһәңе белән баета килә. Халык — тарихның иң олы иҗтимагый-политик көче; ил тормышында урын алган әһәмиятле вакыйгалар бөек шәхесләрне тудыра, Тукай, Ямашев, Мулланур шикелле кешеләр язмышы шуны раслый, ди шагыйрь.

Ләкин Хәсән ага үзенең тылсымлы талантының барлык мөмкинлекләрен дә «эшкә җикмәгән». Шигырьгә фикер киңлеге, ачыклык һәм урыны белән конкретлык та җитенкерәми. Олы һәм масштаблы тема үзенә тиң шигъри интонация, сурәт киңлеге таләп итә. Ә шагыйрь лирик интонациягә генә таяна. Шуның нәтиҗәсендә, эчтәлек белән форма арасында гармония, тәңгәллек югала, шигырь фрагментларга, аерым кисәкләргә телгәләнә. 1968 ел Х. Туфан өчен артык уңдырышлы булмады. «Шигъри елъязмалар» көлтәсендә «Битараф ай», «Ромашкалар», «Ландыш», «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» белән янәшә куярлык, чор драматизмын шәхес язмышы, шәхес кичереше аша гәүдәләндергән тирән һәм нәфис шигырьләр юк диярлек. Ә бит хәзер генә санаган әсәрләрнең барысы да бер ел эчендә — 1956 елда язылганнар. Дөрес, шагыйрьнең уйлану, эзләнү, яңа сукмаклар барлау чоры да булырга мөмкин. Узган ел Х. Туфан өчен шундый чорларның берсе булды. Әмма олы сүз остасына зуррак таләпләр белән килү, һәр елны ачышлар көтү — шулай ук табигый хәл.

Татар поэзиясендә тирән һәм колачлы фәлсәфи лириканы үстерүгә омтылыш көчәя бара. Акмулла, Дәрдмәнд шигырьләренә игътибар үсү дә шуны күрсәтә. Фәлсәфи хөкем, күренеш-вакыйгаларның нигезенә төшенергә, шәхесне ил һәм галәм белән бәйләнештә күрсәтергә тырышу тенденциясе С. Хәким белән Г. Афзалда да, Х. Туфан белән Н. Арслановта да, И. Юзеев белән Р. Фәйзуллинда да, З. Маликов белән Р. Харисовта да үзен ачык сиздерә.

Ш. Галиевнең «Борын заман...» дип башланган шигыре бар. Әсәр шагыйрьнең дөнья язмышы турында олырак һәм масштаблырак итеп уйларга омтылуы турында сөйли. Лирик герой кеше йөрәге белән җир шары арасындагы якынлык хакында фикер йөртә. «Су һәм җил шавы»ннан да көчлерәк тавышларны белмәгән борынгы бабабызга Җир шары галәмәт зур булып күренгән. Хәзер зәңгәр планетабыз кечерәйгәннән-кечерәя бара, анда туган һәр үзгәреш, һәр яңалык һәм афәт шагыйрь йөрәгенә килеп кадала. Чөнки шагыйрь йөрәге — җир шарының нерв үзәге ул.

Үткән елда, гомумән, соңгы еллардагы шикелле үк, фәлсәфи лирика үсешендә берничә юнәлеш ачык төсмерләнде. Аның бер тармагы хикмәтле сүз, халык мәкале, Акмулла поэзиясе традицияләре белән тыгыз бәйләнгән. Бу башлангыч Г. Афзал, Р. Гатауллин, М. Шабаев, Р. Фәйзуллиннар иҗатында ачык сизелә. Ләкин поэзия халык мәкален яисә Акмулланы кабатлау юлына басмый. Ул кешенең фикерләү дөньясына, интеллектына үтеп керү, фән, техника дөньясын киңрәк чагылдыру юнәлешендә үсеп бара. Поэзия ассоциациягә, символикага, халыкның сөйләм теленә иркен таяна. Тәнкыйтьтә бу юнәлешне интеллектуаль поэзия дип тә атыйлар.

Р. Фәйзуллинның «Казан утлары»нда басылган шигырьләренә игътибарны юнәлтик. «Элегияләрдән» дип аталган бәйләмдә дә, «Ишетәсеңме...», «Балачактан туры...» шигырьләрендә дә иң элек эзлеклелек күзгә ташлана. Шагыйрь темадан-темага, образдан-образга килә, чынбарлык күренешләре, вакыйгалары арасында уртак нигезләр, эчке бәйләнешләр эзли. Бу — инде җитди поэзия тудыруга омтылыш дигән сүз. Татар теленең афористик көченә, мәкаль-әйтем канатына таянып, шагыйрь кешенең хис-кичереш дөньясына, фикерләү рәвешенә, интеллектына үтеп керергә омтыла

(«Ишетәсеңме...», «Сәерсең, дисең, яши...», «Хәерлегә булсын...»). Р. Фәйзуллин үз шигырьләрен тирән мәгънәле халык мәкаленә якын юллар белән тәгәлләп куярга ярата:

**Ул елларны инде даулап булмый,**
**Сагынып кына була.**
**Үткән бөеклеккә кайтып булмый,—**
**Табынып кына була...**

*(«Ул елларны...»)*

Р. Фәйзуллин иҗатының яңа чорына кереп бара. Хәзер шагыйрьдән зуррак ачышлар көтәргә була. Әлегә кадәр аңа «җилкәнен киргән кораблар» җибәрерлек фикерләү киңлеге, иркенлек җитеп бетми иде. Югарыда телгә алган «Көрәшчеләр» шигырендә исә автор киңлеккә чыгарга да уңышлы омтылыш ясый.

Гамил Афзал «Дөнья сакта», «Дулкыннар», «Читкә киткәннәр сүзе», «Ике кеше», «Болын-хәтфә...» кебек парчаларында яшәешнең төрле-төрле хәлләре арасындагы якынлыкны һәм каршылыкны аңларга омтыла. Шигырьләрнең төп алымы — хикмәтле сүзгә, мәкаль традициясенә барып тоташкан фәлсәфи антитеза. Антитезаның нигезендә мәхәббәт һәм нәфрәт, яктылык һәм караңгылык, яшәү һәм үлем, гуманизм һәм вәхшилек арасындагы кискен, килешүсез бәрелеш ята. Менә «Ике кеше...» шигыре:

**Тәхет терәгенә терсәк куеп**
**Утыручы хәтфә урында,**
**Фикер йөртә бар дөньяны сүеп,**
**Зур каберлек ясау турында.**

**Тар урында дүрт урындык тезеп**
**Яткан кеше пальто ябына,**
**Бөтен дөнья бәхет, рәхәт күреп**
**Яшәячәк чорны сагына.**

Г. Афзал эзләнүләрен төрле юнәлештә алып бара. Мәсәлән, ул соңгы елларда публицистика белән интим лирика ачышлары, иҗтимагый тойгы белән табигать ямә синтезына нигезләнгән шигырьләрен язып чыкты. «Моң», «Кышкы иртә», «Урман сукмагы», «Өянкеләр моңы» шигырьләрендә Г. Афзал табигать сурәте аша ил һәм шәхес язмышы, кешелек идеалы турында уйлануларга килә.

Дөрес, шагыйрьнең эзләнүләре һәрвакытта да кирәкле нәтиҗәгә алып килми әле. Ул вакыты белән чынбарлыкны фәлсәфи иңләүне гыйбрәтле хикәя, мәзәк сөйләү белән алыштыра («Патша һәм шагыйрь»), абстракт аскетизм юлына баса яки үзен билгесез идеалга корбан итү турында хыяллана («Вәгъдә»)...

Фәлсәфи лирикадагы икенче юнәлеш табигать сурәте, табигать һәм кеше проблемасы белән тыгыз бәйләнгән. Шагыйрь бакый чынбарлыкны күзәтә, андагы матурлыкны аңларга, табигатьнең кеше күременнән яшеренгән эчке халәтенә үтеп керергә тырыша һәм шуның аша кеше күңеле киңлекләренә, хис тирәнлекләренә юл ала. Бу милли традиция дә Х. Туфан, Ф. Кәрим, Такташлар аша Тукай һәм Дәрдмәнд поэзиясенә, халык иҗатына барып чыга. Табигать һәм кеше турында фәлсәфи уйлану Н. Арсланов, Ш. Галиев, С. Хәким шигырьләрендә, яшьләр иҗатында үстерелде.

«Диңгездә», «Сагындым», «Көлеп бакса иде», «Айга карап» шигырьләрендә Н. Арсланов табигатьне нечкә психологизм белән сурәтли, аның әлегә чаклы беркем игътибар бирмәгән чагылышларын тотып ала («биноклыдән карыйм Айга тәрәзәмнән — тамып төшәр төсле Ай бал кәрәзеннән»; «барган саен яңа җилләр, илләр... диңгез ача тылсым сандыгын»). Шагыйрь табигать белән кеше язмышы арасында рухи һәм матди якынлык күрә. Табигать матурлыгы лирик геройның хис-кичереш дөньясын актарып җибәрә, уйларына ачыклык кертә:

**Әй, диңгез, шаула, дулкынлан,**
**Талпынып уйначы бер,**
**Әйдә, синең дәһшәтеңнән**
**Рухланыйм туйганчы бер!**

*(«Диңгездә»)*

Кап-караңгы диңгез өсте,
Ай — маяк кына.
Җанымда шул маяк төсле
Өмет яктыра.

*(«Көлеп бакса иде»)*

Кызганычка каршы, фәлсәфи лирика үсешендә барысы да ал да гөл түгел. Аңа аналитик фикерләү тирәнлеге, хыял очышы, масштаблылык җитми. Традиция колы булу, үткәндә ирешелгән үрләрне кабатлау үзен ачык сиздерә. Әдәби алымнарның сирәк яңартылуы, көн таләпләрен тар мәгънәдә аңлау үсешне тезгенләп тора. Анализ аша нәтиҗәгә киләсе урынга, яшь шагыйрьләр еш кына билгеле бер тезисны эләктереп алалар да, шуны объективта тотып, шигырь язалар. Шуның аркасында безнең поэзия, Татарстан чикләрен үтеп, ил киңлекләрендә яңгырый алмый. Фәлсәфи лириканы тагын да үстерү өчен безгә, Дәрдмәндләр белән бергә Мартыновлар, Межелайтислар кирәк.

Поэзия күп төрле һәм көтелмәгән юнәлешләрдә үсүе белән кадерле. Шулай булмаганда ул төссезләнә, нәфислеген югалта, үсештән туктый, абруен җуя. Ә. Баяновның яңа шигырьләрен укыганда тагын бер мәртәбә әнә шуңа ышанасың.

Шагыйрь тасвирчылыктан медитациягә, тышкы күренешләрне сурәтләүдән эчке халәткә атлый. Кыскасы, поэзиядә психологик юнәлешне үстерүгә күч куя. Үткән елда дөнья күргән «Уйладым да кабат...», «Сөйгән җирем...», «Агып бара...», «Тыйнак кеше» шигырьләрендә Ә. Баянов «күңел сюжетын» катлауландыра бара, шатлык һәм кайгы, мәхәббәт һәм нәфрәт, ышану һәм алдану шикелле абстракт тойгы-төшенчәләрне материальләштереп сурәтли. Туктаусыз бер юнәлештә эзләнүләр алып баруы аның омтылышлы, максатлы, үзенчәлекле шагыйрь булуы турында сөйли.

Ләкин Ә. Баянов, тар, субъектив интонация стихиясендә калу кебек, тәнкыйть күптәннән күрсәткән җитешсезлегеннән дә аерыла алмый. Әйтерсең лә, шагыйрь, ачыклыктан, фикер һәм хис киңлегеннән йөз чөереп, йөрәгенең бер читен генә ача, күңел симфониясен яңгыратасы урында укучыны тар лабиринтларга алып керә. «Ышан елларга» шигыренең идеясе дөрес, бәхәссез: «ышанма син минутларга, ышан елларга!». Ләкин шул хакыйкатьне әйтер өчен, лирик герой сөйгәненең рәнҗетә, ә үзе өзгәләнә, әрни, омтыла... «Мин — диңгез» шигыре тирән уйланылган. Диңгез образы үлгән геройларга һәйкәл куюу, бәйрәм көннәрендә баш орып алу белән чикләнмәскә, аларны мәңге хәтердә тотарга, ихтирамлы булырга чакыра. Ләкин ачудан талчыккан, «бәхет белән мавыгып», батыр туганнарын онытканн кешеләрне «тәнкыйть утында» көйдергән диңгез үзе үк һәйкәлне, ярны җимереп ташлый.

Яңа шигъри бәйләмнәрне, җыентыкларны укыганда, шагыйрьдән әлегәчә күрелмәгән яңалык көтеп дулкынланасың, иҗатының үзгә бер чорын башлап җибәрүен телисең. Р. Әхмәтҗановның «Еллар яна» җыентыгын мин шундый хис белән укыдым. Шагыйрь революцион романтик поэзия казанышларына киң таяна, иҗтимагый ялкынлы, пафослы лирика тудыру юнәлешендә эзләнә. Ул шигъри детальләрне, контрастлы ситуацияләрне уңышлы куллана.

Җыентыкта «Елъязмадан бер көн» дип исемләнгән шигырь бар. Ул илаһи бер җәйге таңны сурәтләү белән башланып китә. Дөнья тигез... Төклетура Рейн ягыннан Вислага оча, «җылы яңгыр Одер аша чыгып, рәхәтләндереп сугара Дунай розаларын». Кешелек тыныч йокыга талган шул таңда фашист сугышка старт бирү өчен кулын күтәрә. Тиздән партизан учаклары кабынып, Җир шары Зоя, Гастелло, соңрак Җәлил батырлыклары турында ишетер. Тарихның иң фаҗигале һәм дәһшәтле шул төнендә «төшендә елмая сабый — баш очында алма күрә». Вәхшилек белән сабый елмаюын янәшә урнаштыру, контрастлы сурәт укучы күңелендә авыр хатирәләрне яңартып кына калмый, бүгенге заман язмышы турында уйлануларга да алып килә. Р. Әхмәтҗановның соңгы китабында «Елъязмадан бер көн» шикелле тыгыз фикерле, тирән хисле шигырьгә тартылып торган әсәрләрне тагы да табып булыр иде. Шагыйрь бизәкләрнең ачыкларын, метафораларның күзне чагылдырып торганнарын ярата. Бу — поэзиядә романтик башлангычны үстерүгә омтылыш дигән сүз. Ләкин Р. Әхмәтҗанов шигъри күременең бу мөмкинлегеннән тиешенчә файдалана алмый. Туктаусыз эзләнү, яңага омтылу урынына, уңышлы табылган метафораны, детальләрне кабатлау юлына баса.

Бер мисал китерик. Җыентыгын шагыйрь «Еллар яна» дип исемләгән. Түгәрәк утсак: «гөлләр яна, урманнар ялкынлана» («Лирик әкият»); «җәй яна, күз ялкынлана» («Торналар оча»); шуның артыннан ук күзгә яфраклар дөрлиләр, урманнар яна башлыйлар («Кызыл яфраклар»). Кыскасы, бөтен табигатьне, бөтен чынбарлыкны ут чолгап ала. Бу метафора үзе татар поэзиясендә күптәннән билгеле. Мәсәлән, Х. Туфан 1947 елда ук аны шигыренә кертеп җибәргән иде:

**Сәмум килә чүлләрдән, туган:**
**Сулар кибә, үләннәр яна.**
**Юлы аның Иделгә таба...**
**Ничек аны борыйк бу юлдан!**
**Сәмум килә чүлләрдән, туган.**

Әлбәттә, Р. Әхмәтҗановның бу рәвешле кабатлануын китап традициясендә эшләү, фикерләү пассивлыгы белән генә аңлатып булмый. Ул шигъри сурәт белән тормыш материалы, метафора белән кеше кичереше арасындагы якынлыкны таба алмый һәм урында таптана башлый. «Күңел кыры», «Күзгә диалог» шигырьләренең таркау булуы, фикер һәм хис үсеше ярты юлда калуы да шул сәбәп белән аңлатыла. «Кар кеше»нең биләгән мәйданы да укучыга алып килгән яңалыгыннан күп тапкыр киңрәк. Ялтыравык матурлыкка, кичереш-фикер эзлеклелеге авазлар яңгырашына, эчтәлекне форма белән алыштыруга мисал рәвешендә «Бүген, иртәгә» шигырен китереп булыр иде. Р. Әхмәтҗановның йөрәк түрендә урын алырлык, кешене рухи яктан баетып җибәрерлек шигырьләр язарлык мөмкинлеге бар. Укучы шагыйрьдән иҗатының яңа битен ачып җибәргән әсәрләр көтә.

Әдәби тәнкыйть тә, җәмәгатьчелек тә соңгы елларда яшьләр иҗатына зур әһәмият бирә. Бу — очраклы хәл түгел. Шигъриятькә яңа буын яшьләр килә. «Казан утлары» үткән елда да каләмгә ябышкан егетләр, кызлар иҗаты белән таныштыруны дәвам итте. Миңа, мәсәлән, Мөдәррис Әгъләмов дебюты ошады. Яшь шагыйрьнең тынгысыз кына үз тавышы, үз моңы, нечкә хисләрне аңлый торган йөрәге бар. М. Әгъләмов татар поэзиясенең үткәне, хәзерге даны белән горурлана, төрле дәвер кешеләрен якынлаштырган эчке бердәмлекне аңларга тырыша:

**Каберләрне бүлеп бүлә,**
**Бүлеп бүлә дөньяны...**
**Үткәннәрне ташлар белән**
**Бүлеп куеп буламы!..**

*(«Көнчыгышны эзли кеше...»)*

«Эзләүчеләргә», «Томан арты», «Туганнар» кебек шигырьләрендә ул кичереш динамикасын чагылдыруга зур урын бирә, эмоциональ киеренкелеккә бәрабәр интонация, рифма эзли. Дөрес, дебютантның шигъри келтәсендә кабатлаулар да, сүлпән һәм нигезе табылып җитмәгән әсәрләр дә, грамотасыз язылган юллар да байтак кына. Циклга исем биргән «Еракка китеп кара» шигыренең идеясе дә яңа түгел. Бу фикер М. Әгъләмов кулланган мәгънәдә, С. Есенин поэзиясендә еш очрый....

Киләчәктә М. Әгъләмов иҗаты нинди юнәлештә үсеп китәр? Бу сорауга кистереп җавап бирүе кыен. Чөнки хәзерге яшьләр әдәбиятка тәпле белем белән, шигъри культураны, дөнья поэзиясе казанышларын, бай традицияне үзләштереп киләләр һәм, традицион шигырьдә дә, ирекле шигырьдә дә үзләрен иркен тотып, иҗатларын бик җиңел башлап җибәрәләр. Р. Гатауллин сүзләре белән әйткәндә, «а елгалар шулай: башланганда гел ташлардан сикерә түбәнгә». Юлында комлы далалар, таулы-урманлы, чокырлы җирләр очрый башлагач, елга агышын акрынайта, янсә бөтенләй туктап кала. Яшь шагыйрьләребез белән дә еш кына шундыйрак хәл килеп чыга. Мәсәлән, 1964 елда тәнкыйть Мәгъсүм Хәкимов, Әхәт Гайнуллин, Хәниф Хөснуллин, Илгизәр Фазлуллин, Борһан Садретдиновларны «бөреләнгән чәчәкләр» дип атаган иде. Аннан бирле биш елга якын вакыт үтте. Шагыйрь гомере өчен зур срок бу. Әлеге яшьләрнең аерым уңышлы шигырьләре, детальләре булса да, аларның иҗаты поэзиядә яңа сүз булып кабул ителми.

Бездә сәләтле яшьләрнең дә эволюциясе, үсеше акрын бара, бик озакка сузыла. Мисалга Р. Гатауллин иҗатын алыйк. Йомгаклау мәҗлесенә ул «Диңгез эзлим» исемле

яңа җыентыгы белән килде. Шагыйрьнең лирик герое ил һәм шәхес язмышы турында уйлана, галәмне борчыган проблемалар, язмышлар уртасыннан атларга тырыша, шуннан ямь, илһам ала. «Диңгез эзлим»нең төп юнәлеше, рухы түбәндәге юлларда чагыла:

**Бар бит әле Җирдә**
**эзләп табу бәхете —**
**аруларны онытып, беркөн**
**Шатлык кичерү вакыты...**
*(«Эврика»)*

«Диңгез ярында да диңгез эзлим», ди шагыйрь икенче шигырендә. «Юлга ияреп, уйлар сәяхәткә чыга... Күрше авылдан соң ул юл, әй, кая илтә?.. Юлның ахыры кайда? Җирдә? Күктә?» («Марс авылы»). Кеше туктаусыз үсә, үзгәрә, мәңгелек су — абелхаят эзли, көрәш һәм югалтулар аша бәхеткә килә. Аны, барыннан да бигрәк, бер уй борчый: «Шәүлә түгелме син? Үзеңме син?» Бу сорау мөнафикълык галәмәте генә түгел. Биредә ирләрчә кыюлык та, хакыйкать орлыгы да бар.

Яшьлек хисен дәртләнеп җырлавы, балачактан күңеленә сеңгән хатирәләрен иркен шигъри формаларга төреп бирә алуы, кеше интеллектына үтеп керергә омтылуы белән Р. Гатауллин әдәби җәмәгатьчелекне үзенә каратты. Өченче җыентыгында исә ул «Шәүлә түгелме син?» дигән сорау куя. Монда гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Шагыйрьне поэзия юлына алып чыккан яшьлек җиле үтеп китте. Яшьлек илһамы үзен кызганмыйча ачып салды. Поэзия Р. Гатауллиннан драматик киеренкелекне, тирәнлекне, фикер киңлеген һәм кеше кичерешләрен сурәтләү нечкәлеген таләп итте. Шагыйрь беркадәр югалып, каушап калды. «Диңгез эзлим» китабының нигезендә менә шул тойгы ята.

Биредә шигъри энҗеләр белән шиңеп чәчәк аткан гөлләр, халык күңелендә, поэзия тарихы битләрендә урын дауларлык әсәрләр белән күптән мәгълүм төшенчәләрне рифмалаган юллар бергә яшиләр. Вакыты белән шагыйрь теманы артык гадиләштереп чишә («Зур тормышка»), җисемсез декларативлыкка урын бирә («Чао, аморе»), фикерен ачыклап җиткерми («Күңел диңгезендә...») яисә «дусларымнан, бәлки алданырмын, дусларымны үзем алдамам» дип үз шәхесен калкытыбрак куярга тырыша.

Р. Гатауллин, кайбер яшь шагыйрьләр шикелле, үз шәхесе турында язарга, поза алырга тырыша, манерачылыкны ярата. Менә «Башкалардан мин өстен дә түгел...» шигыре:

**Башкалардан мин өстен дә түгел,**
**һәм көчсез дә... Алдау нәрсәгә?!**
**Сөю һәм сөелмәү — ирләр өчен**
**Уртак булган кыен мәсьәлә.**
**Бу урамда мин олы да түгел**
**һәм, яшермим, түгел нарасый...**
**Үттем инде күптән тын өметләр,**
**Шаулы бәхетләрнең арасын.**

Мәхәббәт шикелле олы һәм изге хис турында шул рәвешле фикерли торган герой белән без Е. Евтушенко иҗатында 7—8 ел элек очрашкан идек. Үткәнне кабатлауның хаҗәте юк иде. Р. Гатауллинның динамик сюжетлы, бизәкләү чараларына бай, уңышлы мәхәббәт шигырьләре дә аз түгел. Соңгы җыентыкта бу тойгы белән шаяру, уйнау яисә артык баналь фикерләр тирәсендә әйләнү үзен сиздерә («Юллар ерак...», «Хәерле иртә...»).

Теләсә кайсы чорда, шул исәптән Тукай, Такташ, Җәлилләр яшәгән чорда да, дистәләрчә кеше шигырь яза, рифма чарлый. Берәүләре мәңгелек өчен иҗат итә, кешенең гуманизм һәм мәхәббәт өчен көрәшен, бәхеткә, үлемсезлеккә омтылышын җырлый, табигый матурлыкны, нәфисләкне укучыга җиткерү хыялы белән яна. Икенчеләре исә, көн кадагына суга, момент өчен яза, урта кул укучының зәвыгына ярарга тырыша. Р. Гатауллин хәзер урталыкта тора. Аның чын шагыйрь булып үсеп китү мөмкинлеге дә, шигырь язучылар рәтендә калу ихтималы да бар...

С. Хәким бер чыгышын «Тукайларны эзлим» дип атаган иде. Әдәбиятка килүче яшьләр арасында сәләтле каләмнәр күрсә дә, өлкән шагыйрь поэзиянең бүгенгесе, киләчәге турында борчылып яза. Татар шигъриятe соңгы елларда зур кыйммәтләр туплады, яңа үсеш юллары ачты. Ләкин бу байлык, комдагы алтын шикелле, төрле җирдә сибелгән. Шуларны бергә туплап, йомгак ясап, поэзияне микъдари үсештән сыйфат үсешенә алып килерлек, киң мәйданнарга алып чыгарлык яшь талантлар кирәк. Яшьләр арасында әлегә Тукай да, Такташ та күренми.

«Беренче карлыгачлар»ның 1968 нче елда чыккан китабына күз салыйк. Биредә без З. Маликов, Р. Харисов, Рәшит Гатауллин, С. Гәрәева шикелле иҗат алымнары ачык төсмерләнгән, уй-фикерләре, мәхәббәт-нәфрәтләре шактый кискен аерылып торган шагыйрьләр белән дә очрашабыз. Ләкин күпчелек шигырьләр темалары, ритмик калыплары, интонацияләре, хәтта иҗек саннары буенда да ике тамчы су шикелле бер-берсенә охшаганнар. Бер карасаң, юллар да шома, тигез ага, политик ялгышлар да, идеологик хаталар да юк. Тик кеше хисләренә, фикер яңалыгына, шигъри оригинальлеккә генә урын калмаган. Шигырьләрне сайлап алуда нәшрият җентекләп эшләмәгән, авторларга тиешле ярдәм күрсәтмәгән. Әхмәт Сәйфетдинов, Фирая Шиһапова, Рифгат Закиров һәм башкаларның күпчелек шигырьләре истәлек дәфтәрендә генә калса, үзләре өчен дә, поэзия өчен дә яхшырак булыр иде. Әхмәт Сәйфетдинов шигырьләренә бүгенге тормышны анализлау тирәнлеге, кеше язмышын кешелек язмышы белән бәйләп сурәтләү җитми. Артык тар, интим интонация Ф. Шиһаповага киңлеккә, иҗтимагый темаларга чыгарга комачаулый. Ул олы һәм киеренке хисләрдән читләшә («Сагыну җыры», «Кешеләргә җылы кирәк»). Р. Закировның «Бер әйләндем», «Тәүге тапкыр» шигырьләренең хикмәте, нигезе табылмаган. Хәер, андый шигырьләрне саный башласаң, җыентыкны биләгән әсәрләрнең яртысыннан артыгын атап чыгарга туры килер иде.

Яшьләр иҗатында бер нәрсә күңелне хәвефләндерә. Башлап язучылар олы язмышлар турында олы итеп язудан, илне, чорны дулкынландырган мәсьәләләрне күтәреп чыгудан, биеклектән куркалар. Мәгълүм булганча, татар совет поэзиясендә тормыш романтикасы, ачык һәм куе төсле бизәкләр зур урын тота. Халык күңеленә уелып куелган әсәрләрнең күбесендә реализм романтизм белән үрелеп үсә. Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Әхмәтҗановлар иҗатында да романтик башлангыч ачык төсмерләнә. Яшьләр поэзиясе бу йоланы читләтеп үтә, тормышны үз табигыйлегендә генә кабатларга омтыла, җирдән шуышып бара. Бу хәл, үз чиратында, сурәтләү алымнарының тоныклыгына, бертөрлелегенә алып килә.

Шигъри форма турында сүз чыккач, шуны да әйтәсе килә. Берничә ел элек яшьләр поэзиянең формасын, ритмикасын төрләндерү, баету эшен башлап җибәргәннәр иде. Без аларга формализм мөһере сугарга ашыктык һәм аларны бу «яман эштән» биздердек шикелле. Үткән ел әдәбият бусагасын атлаган егетләр-кызлар формага өркебрәк карыйлар һәм я Туфанча, я Хәкимчә язуны, халык иҗаты стилен кабатлауны артыграк күрәләр. Нәтиҗәдә, күңелсез уртачалык, бер төслелек килеп чыга. Кыскасы, югары тойгылы, тирән фикерле поэзия өчен көрәш — яшьләр алдында торган бурычларның әһәмиятлесе булып кала бирә.

Соңгы еллар татар поэзиясе, сыйфат үсешенә караганда, сан ягыннан тизрәк үсә. Газета-журнал битләреннән, радио-телевидениедән, җыентыклардан көчле ташкын булып шигырь агыла. Поэзия, шагыйрьнең язмышы, намусы, яшәү рәвеше булудан бигрәк, профессиягә, кәсепкә әйләнеп бара. Укучы шигырьнең күплегеннән югалып, каушап кала. Тәнкыйть бу хәлне күрмәмешкә салыша. Лирик макулатура үскәннән-үсә бара. Шул арада яшь шагыйрь икенче, өченче, дүртенче... җыентыкларын чыгарып өлгерә. Аңа инде «син шагыйрь түгел» дип әйтүе дә кыенлаша. Чөнки шагыйрьнең тәнкыйтьче каләмен бәреп төшерерлек дәлиле бар: аны басып чыгаралар.

Яшьләр иҗатына игътибарлы булу, аларга матбугат битләрендә юл ачу белән бергәттән, таләпчәнлекне дә киметергә ярамый. Без талант төшенчәсе белән сак эш итмибез, аны артык еш кулланабыз, янсә яшь шагыйрьнең беренче тәҗрибәләрендә үк проблема бөтенлеге, камил фәлсәфи система күреп, аның ныгып җитмәгән җилкәләренә артык йөк салабыз һәм, ахыр чиктә, шагыйрьне кыен хәлдә калдырабыз.

Р. Мингалимовның «Эзләр» җыентыгы поэзия сөючеләр өчен куанычлы вакыйга булды. Яшь шагыйрь күктән йолдыз чүпләми, бөтен барлыгы белән туган җиренә

береккән, шигъри матурлыкны шуннан эзли. Р. Харисов «Дружба народов» һәм «Казан утлары» журналларында аның шигырьләренә багышлап матур мәкаләләрен бастырды. Ләкин сөйләшү мактау характерындарак барды. Шагыйрь үтеп киткән елда басылган тәҗрибәләрендә дә эстетик тәгаллек, фикерне ачык һәм образлы итеп әйтеп бирү турында хыяллана. Ләкин әлегә зур эчке үсеш сизелми, шагыйрь «Эзләр» җыентыгында яулаган үрне узып китә алмый. Мәсәлән, «Раузага», «Хәтерләү», «Шигырьләрем белән сөйләшү» әсәрләрендә кичерешне сурәтләүнең дөрес алымы табылмаган.

Әдәби ел йомгакларына багышланган чыгышларда үткән һәм алдагы елларда да поэзиянең төп җитешсезлекләре итеп примитив фикерләү, вәгазьчелек, тасвирчылык, кичереш торгынлыгы, субъективизм, сурәтлелек чараларының тонык һәм ярлы булуы күрсәтелә иде. Кызганычка каршы, 1968 ел поэзиясе дә шул «гөнаһлар»дан котыла алмады. Алар «Беренче карлыгачлар»да гына түгел, А. Сәләхетдиновның «Бөртекләр», Р. Вәлиеваның «Якты йолдызым», К. Фәсәховның «Текә ярлар» китапларында да тулып ята. Сайлап-нитеп тормастан, К. Фәсәхов җыентыгының беришә шигырьләрен күздән кичерик.

«Борчак чапканда» исемле күләмле әсәрдә вакыйгага да, сюжет канвасы да, рифма да бар шикелле. «Чү, ни булды әле кинәттән? Йөрәк әрни, күзгә яшь килә» шикелле мелодраматик юллар да аз түгел. Тик шигырь генә юк. Әйтер фикерең ачык булмаганда, әсәр һәрвакыт озынга китә. Автор вакыйганың энәсеннән-җебенә чаклы сөйләп чыгарга омтылып, тасвирчылык юлына баса, күренеш драматизмына тиң яңгыраш таба алмый. «Эзләвем — күзләре», «сак кына — чакыра», «үнбишәү — ул кичтә» шикелле рифмаларны да яшьләргә үрнәк итеп китерүе кыен. Яисә редактор һәм рецензент кулы аша үткән түбәндәге юлларга игътибар итик:

**Сибелмәгез җиргә, борчаклар,**
**Хәтерләтеп хәсрәт яшьләрен.**
**Минем дә бит улым — Маратым,**
**Кузак җыя, эзләп яшелрәген.**

«Дуслык кодрәтендә» эмоциональ киеренкелекне, лиризмны җисемсез риторика, декларативлык кысрыклап чыгара. Шигырьнең үзәге булмагач, аны «кылыч күтәргәннәр шул кылычтан үлем тапты», «күтәрелде илем Антей кебек» шикелле прокатка алынган фразалар гына коткарып кала алмый. Югары гражданлык хисен, иҗтимагый яңгырашны коры публицистика белән бутарга ярамый. «Мин пионер хәзер» шигыренең җыентыкта урын алуын аңлатуы кыен. Материалы һәм бирелеш рәвеше буенча ук ул гади информация булып калган.

Күләме буенча шигъри повестька якын булган «Күңел ярасы» поэмасының эстетик нигезе йомшак, фикере ярлы, характерлары уйланып җитмәгән, ситуацияләре каршылыклы. Шуңа күрә ул тормышны яңача сурәтләгән әсәр дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган. Хәлбуки, поэма гаилә һәм әхлак шикелле бервакытта да «картаймый» торган актуаль темага багышланган. Күренә ки, теманың актуальлеге генә үзеннән-үзе уңышка алып килми әле. К. Фәсәхов иҗатының төп җитешсезлеге шунда: ул вакыйганың, күренешнең асылына, эченә кермичә, аның тышкы ягын, фасадын гына сурәтли, мәсьәләне санап чыгу белән чикләнә. К. Фәсәхов һәр елны диярлек бер җыентык чыгарып килә. Хәзер аңа, бөтен продукциясен матбугатка тәкъдим итәсе урынга, сыйфат турында, үзенең поэзиядәге урыны, шигъри тирәнлек хакында уйланырга вакыт.

1968 ел поэзиясе шигъри ачышлар һәм югалтулар, илһамнар һәм хәвефләр елы булды. Поэзия үскән, катлаулана барган саен, тормыш аның алдында яңа бурычлар куя, чынбарлык белән тагы да ныграк якынлашуын таләп итә. Татар шигърияте, бөтен ил белән бергә, В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм республикабызга илле ел тулу бәйрәмнәренә атлый. Укучы поэзиядән Ленин образына, халкыбызның фидакарь хезмәтенә, социалистик чынбарлыкны дәртләнеп җырлауга багышланган һәм тирән гражданлык хисе белән сугарылган югары художестволы әсәрләр көтә.

## Ренат Харисов

# ЭРЕДӘНРӘК, ОЛЫДАНРАК[1]

Газета-журналларда һәм төрле җыентыкларда басылган, шулай ук аерым китап булып чыккан шигъри әсәрләр белән танышып, аларның гомуми хәлен күз алдына китергәч, үткән 1968 елгы поэзиябезнең үсеше фәлсәфи яктан тирәнәю юнәлешендә барган икән, дигән нәтиҗә ясарга була. Бу — һәр сүз мәгънәлерәк яңгырый башлаган, һәр җөмлә күбрәк фикер сыйдырган, һәр шигырь, олырак, тирәнрәк мәгънәгә ия булып, тормышыбызның социаль-фәлсәфи ягына ныграк үтеп кергән дигән сүз. Шагыйрьләребезнең дөнья, тормыш күренешләренең асылына үтеп керү осталыгы үскән, алар үзләренең гражданлык хисләренә фәлсәфи тирәнлек өстәгәннәр, һәм бу тирәнлек, әгәр шулай дип әйтергә мөмкин булса, илебез шигърияте «стандартларына» якынлашкан. Ә кайбер шагыйрьләребезнең иҗатында ул чын мәгънәсендә илебез әдәбиятының кырыс «стандартлары»на җавап бирә алырлык. Сибгат Хәкимнең «Германия циклы», минемчә, нәкъ шундый әсәр. «Германия циклы»ндагы уй-фикерләр, хисләр, проблемалар ил, халык, хәтта гомуми кешелек масштабындагы фәлсәфи категорияләрне үз эчләренә сыйдырганнар. Шуның белән беррәттән, шагыйрьнең чын коммунистик идеяләре, идеал-өметләре, принциплары көн кебек ачык, алар һәр укучыга якын, үз. Ул идеяләр зур осталарча табылган, көмешчеләрчә төгәл, зәвыклы итеп эшләнгән образларга төреп бирелгән.

Гамил Афзалның «Казан утлары» журналында чыккан шигырьләрендә дә, Роберт Әхмәтҗановның «Еллар яна» китабында да, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ында да, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баянов, Хисам Камалов, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Марс Шабай шигырьләрендә дә шигъриятебезнең үсешен күреп була. Өлкән шагыйрьләребез дә, урта һәм яшь буын шагыйрьләребез дә шигъри формаларны эчтәлеккә якынлаштыру, баерак, тыгызрак итү буенча нык ытып эшләгәннәр. Эчтәлекле һәм сәнгатьчә грамоталык ягыннан чыгып якын килгәндә хәтта Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләмов, Эдуард Мостафин кебек иң яшь шагыйрьләрнең әсәрләре дә шактый куандыралар. Тагын шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер, моннан берничә генә ел элек өч буыннан гыйбарәт булган шагыйрьләр коллективы, алда саналган исемнәр белән дүрт буынлы гаиләгә әверелде. Һәм бу дүртенче буын алдагы елларда тулылана төшәр әле дип уйларга да урын бар. «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Казан утлары» журналында күренеп-күренеп киткән яңа исемнәр шул хакта сөйли. Шагыйрьләр гаиләсенең тагын бер буынга баюы һәм бу буынның шактый талантлы булуы безнең буын шагыйрьләренә, ягъни 25—30 яшьтәгеләргә, иҗади стимул өстәп җибәрде. Алар шактый активлашып киттеләр, һәм бу активлашу урта һәм олы буын шагыйрьләренә дә йогынты ясады дип әйтсәк, ялгыш булмастыр. Гомумән 1968 елда ярышчылар күбәйде, иҗади ярышка мәйдан киңәйде. Бу — узган әдәби елның зур казанышларының берсе.

1968 нче шигъри елның уңышлары гомумән әнә шундый.

Узган елгы шигъриятебезне игътибар белән күздән кичереп аның казанышларын күреп куангач, минем күңелдә үзеннән-үзе бер сорау туды: ә ни өчен безнең шигъриятебез бөтенсоюз мәйданында зур булып яңгырамый соң! (Сәнгать әсәренә шушы

[1] 1968 әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

яктан килү бер шигъриятькә генә хас сорау түгел. Композиторларыбыз һәм рәссамнарыбыз да үзләренең әсәрләрен Бөтенсоюз аренасына чыгарырга телиләр, шуның өчен тырышалар. Башка халыклар сәнгатендә дә шул ук хәл. Күрәсең, Бөтенсоюз аренасына басарга тырышу ул — күп милләтле совет сәнгатен үстерүдәге бик зур стимулларның берсе һәм совет сәнгате өчен зарури күренештер.). Бәлки, бездә көннең иң мөһим проблемаларын күтәргән, чор, сәясәт сорауларына җавап, я, киресенчә, фәлсәфи, социаль сорау яки таләп булып яңгырый торган публицистик шигърият юктыр? Бар, һичшиксез, бар.

Гомуми шигърият дөньясында шактый дефицит булган сатирик поэзиябез дә бар, юмор поэзиябез дә. Һәм алар, бәхеткә каршы, эпиграмма, пародия белән генә дә чикләнмиләр. Алар безнең шигъриятебездә мөстәкыйль бер мәйдан биләп, үзләренең тулы канлы тормышлары белән яшиләр. Кем әйтмешли, бер карасаң, бу дефицит товар белән курыкмыйча әллә кайларга чыгып китәргә мөмкин. Ләкин андый шигырьләребез дә Бөтенсоюз мәйданында яңгырамыйлар.

Әлеге «ни өченнәргә» җавап табу ниятеннән чыгып шигъриятебезнең зур, матур казанышларын Бөтенсоюз шигърияте белән чагыштыра башласак, минем уемча, берничә зур сәбәпкә юлыгырбыз. Шуларның берсе — **монументальлекнең** җитенкерәмәве.

Монументальлек, беренче чиратта, шигъриятнең эпик төрләренә хас. Дастаннар, эпослар, поэмалар еллардан елларга, дәверләрдән дәверләргә үзләрен тудырган халыкларның, чорларның акыллы, гыйбрәтле тәҗрибәләрен алып киләләр. Без, эпик әсәр дигәч тә, поэманы күз алдына китерәбез. Алай гына да түгел, күпләребез озынрак шигырь яза да, аны поэма дип исемли.

1968 елда унбишләп зур күләмле әсәр басылып чыкты. Ләкин шуларның бик азын — Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ын, Хисам Камаловның «Тормыш дулкыннары»н, Равил Фәйзуллинның «Көрәшчеләр»ен һәм Нәби Дәүлинең «Кеше турында монолог»ны гына шигъриятебезне үстергән эпик әсәрләр рәтенә кертергә мөмкин. Ләкин шушы әсәрнең икесендә генә — «Соңгы сынау» һәм «Көрәшчеләр»дә — монументальлек чаткылары күреп була.

«Тормыш дулкыннары»нда Хисам Камалов үзенең гаҗәеп киеренке, кешелекле хис-фикерләрен сентиментальрәк агымга кертеп җибәргән һәм әсәренең яңгырашын чикләгән.

Нәби Дәүли «Кеше турында монолог»ында, безгә — укучыларга — нотык сөйләп, аерым вакыйгаларны, аерым проблемаларны гомуми масштабка, вакыттан өстенрәк масштабка күтәреп җиткерә алмый.

Ә «Соңгы сынау» белән «Көрәшчеләр»дә эш башкачарак. «Көрәшчеләр» — кешенең аңы, җаны өчен дау барган безнең чорның рухын, ритмын, киеренкелеген шактый төгәл күрсәтә торган әсәр. Анда:

> **Беләкләләр җитә,**
> **Йөрәкләләр кирәк,**
> **Куәтлеләр җитә,**
> **Көрәшчеләр кирәк,**

— кебек, озак вакытлар безнең гасырның чакыруы булып яңгырый алырлык юллар да бар. Бу катлаулы, күп планлы әсәрдә, минемчә, аның гомуми тышкы киеренкелегенә ятышлы, ләкин эчке киеренкелеге өчен артыграк булган детальләр, фикерләр дә очрый. Алар әсәрне таркау итәләр. Шушы яңгырашы сакланып, иң кирәкле детальләр белән генә эшләнсә, бу әсәр публицистик поэзиябезнең монументальлектә җитешкән бер үрнәге булыр иде.

Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ы — монументаль кешенең монументаль үлеме турында. Әсәрнең әдәби алымы да — мәңге монументаль Мефистофель белән Мусаның диалогы. Шушылар үзләре генә дә «Соңгы сынау»га монументальлек бирергә тиешләр иде. Ләкин Муса белән Мефистофель арасында чын мәгънәсендә зур фәлсәфи бәхәснең була алмый калуы (ә кай ара Муса бер нәрсә, ә Мефистофель икенче нәрсә турында аңлашылмый торган сөйләшү алып баралар), Мефистофельнең Мусага «җанны саттырырлык» бернәрсә дә тәкъдим итә алмавы, аллалар булышмаганда да кешегә ярдәм кулы сузган Мефистофельнең кинәт, бернинди сәбәпсез, тиран ярдәм-

чесе булып китүе, ниһаять, әсәрнең башында ук Мусаның җанын, идеалларын сатмаячагы сизелеп торуы — Илдар Юзеевка алган проблемасын монументаль югарылыкта чишәргә комачаулаган.

Безнең әсәрләрнең гомум халык, гомум кешелек өчен хас фикерләр белән сугарылып җитмәве әнә шул монументальлекнең җитмәвенә кайтып кала да инде. Әгәр дә без «барлык дәверләр һәм халыклар өчен» дигәнрәк таләп куябыз икән — моны артыксынмаска кирәк. Безгә инде күптән зурдан каера башларга вакыт. Безгә инде күптән үзебезнең уңышларны, казанышларны үз җирлегебез бизмәне белән генә үлчәмичә, илебезнең күп милләтле әдәбияты калыбындарак карарга вакыт.

1970 елда без В. И. Ленинның 100 еллыгын һәм Совет Татарстанының 50 еллыгын бәйрәм итәбез. Бу бәйрәмнәр безнең шагыйрьләребезгә публицистик илһам бирә. Әледән-әле республикабыз, илебез, халкыбыз турында шигырьләр һәм җырлар туып тора. Ләкин эшләнгән эшләребез белән генә канәгатьләнмичә, чорыбызга, зур казанышларыбызга һәйкәл булып калырлык әсәрләр иҗат итәргә тиешбез.

Шигъриятебез алдында торган, алай гына да түгел, әдәбиятыбыз алдында торган икенче бер зур проблема ул — **милли колорит.** Милли колорит сәнгатебезнең барлык тармаклары алдында торган мәсьәлә. Рәсем сәнгатендә ул, беренче чиратта, милли төсләр гаммасын табуга, милли сызыклар, алымнар булдыруга кайтып калса, шигъриятебездә милли, традицион жанрларны үстерүгә, образларны детальләрнең татар халкына гына хас төсмере, төшенчәсе нигезендә баетуга һәм, иң мөһиме, әсәрләрне халкыбызның психологик үзенчәлекләренә таянып башкаруга барып тоташа. Ул, ахыр чиктә, милли әдәби алымнарның, татар халкына гына хас тормыш атрибутларының, образларның конкрет әсәр эчендә гармоник укмашуы дигән сүз. Милли колорит — халыкның язмышында, аның бөтен тарихында, бүгенгесендә, гореф-гадәтләрендә, әхлакый кануннарында, сынамышларында, йолаларында, җыр-биюләрендә... Ә без әлегә милли колоритны тел үзенчәлекләренә, образлы тәгъбирләргә, җөмлә төзелеше канунныарына һәм географик атамаларга гына (Казан, Кабан, Ослан тавы һ. б.) кайтарып калдырабыз кебек. Кайчандыр безнең дә үзебезгә генә хас колоритыбыз булган.

Ул колоритның булганын Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Фатих Кәрим һәм башка зур шагыйрьләребезнең әсәрләре белән исбатлап булыр иде.

Дагстан шагыйре Әфәнде Капиевның бер шигыре искә төшә:

**Оттого, что влюблены,**
**Нет добра нам, добрый друг,**
**Коль разлучены сердца**
**Как вершины снежных гор.**
**Если б можно было нам**
**Так сердца соединить,**
**Как в стволе ружья слиты**
**Пуля с порохом в одно.**

Күрәсез, рус телендә дә шигырь үзенең тау ягы колоритын, ритмын саклап кала алган. Ә тел нюансларына гына корылган безнең кайбер шигырьләрне тәрҗемә итсәк, шигырь бөтен ямен һәм мәгънәсен югалтып, тессез бер массага әверелеп кала. Ягъни, шигырьнең төп гүзәллеге, үзенчәлеге һәм миллилеге поэтик детальләрдә, образларда булу отышлырак диясе килә. Бу, билгеле, сүзнең матурлыгына, җөмләнең яңгырашына игътибар итмәскә дигән сүз түгел. Киресенчә, сүзләрнең тагы да мәгънәлерәк, җөмләләрне тагы да тыгызрак, аерым фикер белән контекст арасын өзелмәгәнчә яңарак ассоциацияләр белән тутыру дигән сүз. Бу нисбәттән үрнәк итеп Дәрдмәнд шигырьләрен китерергә булыр иде. Кайберәүләр, тәрҗемә итү аша әсәрнең сыйфат дәрәҗәсен, үтемлелеген билгеләргә тырышу — кирәкмәгән эш, диярләр. Бәлки, бәлки... Әмма әгәр дә без шигъриятебезне Бөтенсоюз бизмәнендә үлчәп карарга теләсәк, илебезнең барлык халыкларына ирештерергә теләсәк, тәрҗемә белән исәпләшмичә мөмкин түгел.

Ә бездә нинди генә телгә тәрҗемә иткәндә дә үз колоритын саклап калырлык шигырьләр табу кыен. Кабатлап әйтсәк, колорит ахыр чиктә милли психологиягә, халкыбызга хас булган тормыш-көнкүреш атрибутларына, халкыбызның рухына һәм, форма ягыннан, милли жанрларга, аларны үстерүгә, алардан вариацияләр, модифи-

кацияләр ясауга, халык авыз иҗатының потенциаль мөмкинчелекләре булган шигъри алымнарын үстерүгә кайтып кала.

...Ә хәзер Резеда Вәлиеваның «Якты йолдызым» дигән поэмасыннан өзек китерик:

**Авыр сулап куйды Сания:**
**— Әйдә, дустым, кайтыйк, кич җитә...**
**Тик Гөлниса озын толым очын**
**Бер урә дә һаман бер сутә:**
**— Якын сердәшем син, дустым син,**
**Хәлләремне ләкин белмисең.**
**Һәм сыенды дусты күкрәгенә,**
**Кызлар кинәт тынып калдылар.**
**Гөлнисаның зәңгәр күзләреннән**
**Энҗедәй саф яшьләр тамдылар...**
**— Газап чикмә. Хәйдәр үзе дә**
**Түзә алмас сине күрмичә.**
**Күз яшеңә кадәр сөйкемле,**
**Гаҗәп кеше бит син, Гөлниса...**
**— Син әйтерсең инде, дускаем! —**
**Онытылып Гөлкәй бер көлде.**
**Яңгырдан соң чыккан кояш төсле,**
**Күзләреннән нурлар бөркелде...**
**Имән яфракларын лепердәтеп,**
**Йомшак кына талгын җил бәрде.**
**Җил уяткан таңгы сандугачтай,**
**Кыз өздереп җырлап җибәрде:**
**Мирхәйдәрем — яшьлек язларым,**
**Мирхәйдәрем — күңел назларым,**
**Бәхетемнең сүнмәс яктысы,**
**Сагышымның чиксез татлысы...**

Күз алдыгызга китерегез: егетә белән үбешеп йөри торган Гөлниса бернинди сәбәпсез иптәш кызының күкрәгенә сабый бала кебек сыена. Аннан соң елап җибәрә. Минут та үтми, көлеп җибәрә, аннары (игътибар итегез) «кич җиткәндә», «таңгы сандугачтай кыз өздереп җырлап җибәрә»:

**Мирхәйдәрем — яшьлек назларым...**

Беренчедән, автор үзе дә сизмәстән үзенең героен табигый булмаган ситуациягә куя. Бу ситуация, билгеле, ышандырмый, автор теләгән эффектны бирми. Киресенчә, комик вакыйга булып тәсмерләнә. Икенчедән, кирәкмәгәндә һәм кирәкмәгәндә бу хикәягә (мин аны хикәя кебегрәк әсәр дияр идем) мелодрама дисәк тә ярый торган, опера элементы дисәк тә ярый торган җыр китереп кертә. Әлеге дә баягы комик ситуация хәзер бер мәгънәсез нәрсәгә әйләнеп кала. Өченчедән, авторның эпитет сайлаудагы талымсызлыгы, культурасызлыгы күзгә ташланып тора. Автор үзе «кич җитә» ди, үзе «таңгы сандугачтай җырлап җибәрде», ди. Әгәр дә «таңгы» дигән чагыштыру янына «яңгырдан соң чыккан кояш төсле»не дә, «өздереп»не дә, «энҗедәй саф»ны да, «күздән бөркелгән нурларны»да һәм тагын йөзләгән шундый сүзләр, чагыштырулар өстәсәк, әдәби осталыкның тагы ике ноктасына китереп басабыз:

Берсе — **детальләрнең, образларның әдәби алымнарның** шигырь халәтендә табигый булмаулары. Икенчесе — **детальләрнең, образларның штампланулары.** Боларның икесенә дә, кызганычка каршы, мисалларны шактый күп китереп булыр иде. Вакытны мисал китереп әрәм итмичә, бу ике сәбәп турында бернична сүз әйтеп китик, бәлки, файдалырак булыр. Шигырь, беренче хәрефеннән алып соңгы ноктасына кадәр бер организм, бер халәт. Эчтәлек шигырьнең ритмикасын да, логикасын да, аерым бер төрле детальләр сайлап алуны да, образлар, алымнар характерын да билгели, боларның барысын да эчке бер канунга буйсындыра. Бу инде стильләштерү дип аталадыр. Тукайның «Кисекбаш»ы — әнә шундый стильләштерүнең гүзәл бер үрнәге. Андагы образлар һәм детальләр әсәрнең буеннан буена бер стильдә, сатирик гротеск стилендә

бара. Бер-берсе янында детальләр, образлар бик тыныч, табигый яшиләр. Грамоталы итеп стильләштерергә өйрәнү — күп шагыйрьләребез алдында торган бер мәсьәлә.

Дөрес, кайбер очракта осталарча стильләштерелгән әсәрләр дә очрап куя. Мәсәлән:

Дөнья —
Зур ашханә,
Минут —
Шеф-повары аның.
Кулында уйната
    язмыш чүмечен.
Бирәүгә —
Тутырып сала
    шатлык шәрабен,
Бирәүгә:
— Хәсрәт өйрәсен чөмерсен.

*(А. Сәләхетдинов)*

Шигырь, һичшиксез, эш кораллары (һөнәр атрибутлары) ягыннан бик төгәл стильләштерелгән, ләкин эчке пөхтәлеге, гүзәллеге, байлыгы булмаган детальләр белән эш итү авторны вульгарлыкка китергән, зәвыксызлыкка кертеп батырган. Мондый һәм моңа охшаш талымсызлыклар безнең шигъриятебезнең үсешенә дә, укучыларыбызның зәвыгы камилләшүгә дә файда китермиләр. Аннан соң, штампланган образлар һәм детальләр шигъриятебезне төче, төссез һәм көчсез итәләр.

«Нәрсә булды!» —
Җиңел соравы.
Өзелгәндә к ү ң е л  к ы л л а р ы...

*(К. Фәсәхов)*

Күкне иңләр  х ы я л  к а н а т л а р ы ң
Сугыш утларында янмасын!

*(Э. Мөэминова)*

К а н н а р  к о й д ы к  сугыш кырларында...

*(М. Мазунов)*

Боларны күпме кабатларга мөмкин инде? Андый образлардан, детальләрдән торган шигырьләрнең тәэсир итү көче дә чамалы гына, кыйммәте дә бик кечкенә. Шигырьнең хәтта гаҗәп кызыклы логик-композицион төзелеше дә, кызыклы әдәби алым да штампның штамплыгын алып ташлый алмый. Безнең шигъри детальләрнең җегәрсез булуы, ахыр чиктә, шигырьләребезнең дә буш булуына китерә. Ә җегәрле детальләр, образлар — социаль хәрәкәтне, халыкларның тел очында торган уй-фикерләрен сыйдырган, тормыш фәлсәфәсенә турыдан-туры мөнәсәбәте булган детальләр һәм образлар алар.

Шагыйрьләрнең юлын кан кискән,
Эше беткәч, алып пистолетын
Безнең чорга чөйгән Дантеслар.
. . . . . . . . . . . . . . .

Сибгат Хәкимнең бу юллары укучы аңында зур ассоциацияләр тудыра. Шул ук вакытта кайбер укучыларга алар шагыйрь теләгәнчә үк тулаем аңлашылып җитмәскә дә мөмкиннәр. Шушы нисбәттән «аңлашылмый торган» дигән шигырьләр турында да берничә сүз әйтеп үтәргә кирәктер. Чөнки «бу шигырь аңлашылмый» дип кайвакыт шактый көчле, оригиналь фикерле, катлаулы шигырьләрне танып җиткермәү дә булгалый. «Аңлашылмый торган» шигырьләр, минемчә, берничә төрле һәм аларны буташтырмаска кирәк. Кайберләре, зур җегәрле образлар, детальләрне кочып, катлаулы логик-композицион алым белән башкарылганнары, чыннан да, кат-кат укуны таләп итәләр. Андый шигырьләрне аңлар өчен, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә киң белем дә, тормыш тәҗрибәсе дә, культура да кирәктер. Билгеле, алар шул дәрәҗәдә үк

катлаулы һәм эчтәлекле булып, сай шигырьләр кебек үк «аңлашыла» торган да булсалар начар булмас иде. Ләкин алай булу я бөтенләй мөмкин түгел, я даһилык сорый.

«Аңлашылмый торган» шигырьләрнең башка төрләре дә бар. Мәсәлән:

**Һай, күңелсез түшәк кырында.**
**Кайчан, димен, савыгыр көн туар!..**
**Ә күңелем сезнең җыенда,**
**Петрарка, Байрон, Элюар!..**

**Ә кем белә, синдә, мендәрем,**
**Тынар, бәлкем, кайнар йөрәгем...**
**Юк, суынмас, тынмас йөрәгем:**
**Яктыртыр ул юлын меңнәрнең!**

**Саф сулышлы җилне сагындым.**
**Шуңадыр шул учым кычыта!**
**Әмеренә баш иеп аңымның,**
**Күңелкәем былбыл очырта.**

**Үлемсез җыр итсәң илеңне,**
**Туктатыр ил синең үлемне.**

*(М. Хөсәен)*

Менә бу шигырь, чыннан да, аңлашылмый.

1. Нинди «түшәк кырында»? Кырыенда мәгънәле кырындамы, арыш кыры мәгънәсендәге кырындамы?

2. Ни өчен М. Хөсәеннең күңеле «Петрарка, Байрон, Элюар җыенында»?

3. Ни өчен автор «йөрәгем меңнәр юлын яктыртыр!» дип әйтә ала? «Мендәрем, бәлки, синдә тынар йөрәгем!» дип әйтә алгангамы?

4. Уч кычыткач, саф җил исәме әллә? Әллә уч кычыту акча килү ырымымы? Әллә «саф җил» дип әйтү зур акчаны сагындым дип әйтүме?

5. Аң әмеренә баш игән күңелнең былбыл очыртуы нәрсә соң ул?

6. Ниһаять, шигырьнең ике актыккы юлы алдагы 12 юлга ничек бәйләнә һәм нәрсәне аңлата?

7. **Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла,**
**Илең турында уйласаң**
**Гомерең озын була,**

— дип Фатих Кәримчә генә әйтеп булганда, китапның редакторы бу шигырьне һәм моңа охшаган тагын бик күп шигырьне ничек үткәрде икән?

Менә болары инде аңлашылмый.

Шушы ук мисалга бәйләп, шигъриятебезгә керергә маташа торган тагын бер авыру турында да әйтеп китик. Мәхмүт Хөсәеннең «Мәрҗәннәр»ендә бик күп исемнәр бар: Бурнаш, Тинчурин, Зоя, Шура, Газинур, Петефи, Алиш, Муса, Йоһан, Андре, Сәйдәш, Тукай, Лермонтов, Маяковский, Шекспир, Юрий Гагарин, Шевченко, Терешкова, Чапай, Павел Попович, Ленин, Назыйм Хикмәт, Петрарка, Байрон, Элюар, Мистраль һ. б. һ. б. Исем шигырьгә килеп керсә — ул инде гомумиләштерелгән образга әйләнгән була. Мәсәлән: Сибгат Хәким әгәр Дантес сүзен куллана икән, безнең аңда кеше үтерүче генә түгел, шагыйрьне үстерүче образы калка. Образ белән тарихтагы Дантес арасында һичнинди аерма юк. Әгәр дә Хәсән Туфан:

**Анда — Буби, Лена, Ямаш, Тукай.**
**Анда — матәм, олы дүрт матәм.**
**Аларны мин**
**Абына-егыла гына,**
**Кочка-кочка гена күтәрәм,**

— ди икән, анда татарның жандармнар тарафыннан тапталган мәгърифәт учагы, Россиянең канга баткан революцион көрәш мәйданы, үтерелгән Ямаш, Тукай образлары калка. Алар тарихтагы мәгънәләренә шулай ук тугрылыклылар һәм шигырьнең фикер агышына да туры киләләр. Ә М. Хөсәеннең китабындагы исемнәрнең ничәсе

генә шундый икән соң? Бик тә, бик тә азы. Шигырьгә интеллектуальлек өстим дип, тышкы эффект, җегәрлек өстим дип, әсәрне абсурд хәленә җиткерү, шуны укучыга тәкъдим итү — һич тә күркәм эш түгел. Бу, билгеле, бик күпләребезгә хас авыру.

Фикерләрнең очын очка ялгап шуны әйтәсе килә: зур аренага чыга алмый торуның әдәби осталыкка бәйле сәбәпләре, менә шулар. Һәрберебезнең әдәби осталыгыбызны үстерүдә, аңыбызны гомумхалык масштабына күтәрүдә бик күп эшлисебез бар икән әле. Ак шигырь начар да, традицион шигырь яхшы дип сөйләнеп йөрүләрне ташлап, зур мәгънәле, тирән эчтәлекле, осталык ягыннан да грамоталы әсәрләр иҗат итәргә тырышу, шушы юнәлештә бер-беребезгә булышу — менә безнең төп бурычларыбыз!

Новаторлыкка омтылган һәр шагыйрьгә ярдәм итәргә кирәк, чөнки бүгенге новаторлык иртәгә традициягә әверелмәячәк дип кайсыбыз ышанып әйтә ала?!.

Шулай икән, эзләнүләрнең җимешенә: «Шәхсән бу шигырь, я алым миңа ошамый»,— дип кенә катгый һәм соңгы хөкемне чыгарырга кирәкмидер. Я, киресенчә, «бу миңа ошый» дип кенә күккә чөюләр дә булмаска тиештер.

Мин еш кына бөек шагыйрьләрнең иҗатындагы дөньяга карашның, яшәүгә, үлемгә карашның даими булып калуы турында уйланам. Ни өчен, мәсәлән, Хәйямның барлык шигырьләрендә фани дөньядагы яшәүдән соң башка яшәү юк, шуның өчен фани дөньяда мөмкин кадәр күбрәк ләззәтләнеп, татып, шатланып кал, теләгеңә ирешеп кал дигән фикер саклана. Чөнки Хәйямның күңелендә моңа фәнни, шагыйрьнең үзе өчен үзе исбатлаган нигезе булган. Кешенең фәнни инануы шигъри инануга әйләнгән һәм Хәйямга гына хас булган эзлекле, төгәл, һәрвакыт даими булган оригиналь шигъри дөньяга әверелгән. Бәлки, безнең шагыйрьләребез арасында да, Хәйям масштабында ук булмаса да, эзлекле эстетик принципларны, фәлсәфәсендә, дөньяга карашында оригиналь даимилек күрсәтә алырлыкларыбыз бардыр. Менә шуларны тану, шуларны үстерү — тагын бер зур бурычыбыз.

Шунысын да әйтик, алда саналган сәбәпләрне бетердек тә, Бөтенсоюз аренасына килеп тә чыктык дигән сүз түгел, билгеле.

1968 елда Мәскәү нәшриятларында бары өч татар шагыйренең генә китабы чыкты: Сибгат Хәким, Әхсән Баян, Шамил Мәхмүдов китаплары. Шигырьләрнең тәрҗемәләре гомумән алганда уңышлы гына. Җентекләбрәк тикшерә башласаң, тагы да яхшырак тәрҗемә итеп булганы ачыклана. Тәрҗемәләрнең тиешле кондициягә килеп җитмәвенең берничә сәбәбе бар. Берсе — тәрҗемәче подстрочник аша эш итә. Икенчесе — тәрҗемәче автор белән көндәлек бәйләнештә булмыйча эшли. Ә безнең татар теле гаять бай колоритлы, күп төсле, катлаулы тел. Аның бөтен бизәкләрен булдыра алганча максимум кабатлар өчен безгә подстрочниксыз эшли торган тәрҗемәчеләр булдырырга кирәктер. Ул тәрҗемәчеләрне Казанда булдырырга кирәк. Бу турыда үткән съездда да сүз булган иде, кызганычка каршы, бүген дә кабатларга туры килә. Болардан чыгып бер тәкъдим әйтәсе килә: «Шигырь бәйрәме»н, ел саен русча да чыгарсак, бу тәрҗемәчеләр үстерергә зур матди база булыр иде, татар шагыйрьләренә үзләренең интернациональ бурычларын үтәргә дә бер сукмак булып, бу сукмак тора бара Бөтенсоюз аренасына илтә торган юлга тоташыр иде.

Үзәк матбугатны күзәтеп барганда, тагын бер нәрсәне искәрәсең — төрле халык шагыйрьләренең китапларына рецензияләр күп басыла. Бездә күпме китап чыга, күпме әсәрләр туып тора, шуларның берсе турында да үзәк матбугатта рецензия күренгәне юк диярлек. Үзебезнең татар матбугатында чыккалаган рецензияләребез, бигрәк тә газеталарыбызда басылганнары сыйфат ягыннан шактый түбәннәр. Ә яхшы рецензияләрдән, тәнкыйть мәкаләләреннән бер генә газета да, менемчә, баш тартмый. Күрәсең, шигырь буенча каләм чарлаган тәнкыйтьчеләребез аз, булганнары да шигърияттебезне Бөтенсоюз мәйданында пропагандалау турында уйламыйлар, ахры. Оператив тәнкыйть булдыру, ә моның өчен зур әзерлекле яшь тәнкыйтьчеләр булдыру бүгенге көндә шигърият проблемасына әйләнде.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Бөтенсоюз аренасына чыгарырга тырышу ул үзмаксат түгел. Беренчедән, ул укучыларга яхшы кондицияле, ачык идеяле, тирән фикерле әсәрләр бирүгә барып тоташа, икенчедән, безнең әсәрләребезнең иҗтимагый бәйләнең арттыруга барып бәйләнә, иҗади активлыкны арттыра, ә безнең иҗади активлыгыбыз — безнең иҗтимагый активлыгыбыз ул.

*ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫНА*

## Абдулла Сәләхетдинов

# КАНЛЫ ТУФРАК

Мәйданга җыелган халык тынып калды.

Тынлы оркестр «Интернационал» уйнап җибәрде. Гүя шул музыканың тылсымлы көче тәэсирендә мәйдан уртасындагы һәйкәлне каплап торган ак ефәк әкрен-әкрен төшә башлады. Һәркемгә таныш кеше сынының киң маңгае ачылды, җилкәләре пәйда булды, алга таба сузылган кулы күренде. Иреннәр тавышсыз гына тибрәнеп алды.

— Ленин!..

Тантаналы минут, онытылмаслык мизгел иде бу. Подберезьега Ленин килде! «Интернационал» гимны яңгырап торган мәйдан уртасында, җәйге җилдә талгын гына тирбәлгән әләмнәр астында тынып калган халык алдына Ленин басты. Шул ук минутта һәйкәл тирәсенә гөлле савытлар куелды, чәчәкләр ява башлады.

Савытка утыртылган өй гөлләре һәм кыр чәчәкләре тотып Ильич янына агылган кешеләр арасында карсак буйлы, юантык гәүдәле бер карт та күренде. Ул, салмак кына атлап, һәйкәл янына килде, постаментның мәрмәр ташын капшап карады һәм, җиргә тезләнеп, бер уч туфрак алды. Кулындагы шул хәзинәне зәгыйфьләнгән күзләренә якын ук китереп торды да иреннәренә тидерде. Картның күксел тамырлары бүртеп торган куллары калтырый иде. Аннары, тезләнгән җиреннән торып, кулындагы газиз туфракны гөл савытларының берсенә салды.

Гомер баскычларының инде туксанынчы дистәсенә атлаган бу аксакал Никифор Игнатьевич Уткин иде. Аңа сәерсенеп караучылар да булды. Карт кеше бит, ни кыланмас, янәсе. Ләкин район газетасыннан килгән бер журналист күңеле йомшарган картның, җиргә тезләнеп, туган туфракны үбүенә гаҗәпләнмәде. «Җир кадерен ир белер» дигәннәр, бәрәр хикмәте бардыр моның», дип уйлады ул. Шундук бабай янына килеп, аны култыклап алды.

— Узган гомерләр искә төштеме, бабай?

— Гомеремдә икенче тапкыр тезләндем,— дип куйды Никифор Игнатьевич, үзалдына гына сөйләнгән шикелле.— Икесендә дә шул мәйданда...

Аксакалның иреннәре дерелди, күзләре яшьле иде. Аның тел төбендә Апас якларының тарихына кагылышлы ниндидер вакыйга ятуын чамалап өлгергән журналист түзмәде, төпчеnергә тотынды.

Никифор бабай, яңа бура янына өеп куелган бүрәнәләрнең берсенә җайлап кына утырды, гадәте буенча, махрасын көйрәтеп җибәрде. Журналист, аның авызына керердәй булып, тынып калды. Картның беренче сүзләре үк уйларны ерак үткәннәргә алып киттеләр.

I

Һәр елны язгы сулар казый торгач, нәкъ уртасында шыксыз ерганак хасил булган үйсулыкның ике ягына сибелеп утырган Подберезье авылы, йокымсырап яткандай, тын гына яши иде. Олы юллардан читтә, өяздән еракта булгангадыр, аның басу капкасыннан узгынчылар сирәк үтә. Карага ягудан корымланып беткән мескен өйләр, түбә саламнарының сәләмәләрен дөньяга күрсәтүдән оялгандай,җиргә сеңәргә тырышып утыралар. Аларның вак өлгеле кечкенә тәрәзәләре авылны урталай бүлгән котсыз ерганакка ниндидер шик-шөбһә белән карап торгандай күренә. Кырык казык белән туксан терәүгә таянып утырган читән-каралтылар көчлерәк җил иссә дә калтырана башлыйлар, менә-менә таралып китәрләр дә чыбык-чабык өеменә әйләнерләр төсле. Авыл уртасындагы чиркәү генә шул мескен өйләр һәм гарип каралтылар арасында үзенең биеклеге, тазалыгы белән масайгандай, төреле манарасын күккә чөеп, тез утыра.

Көз иде. Авылда кабер тынлыгы. Вак яңгыр сибәләп тора. Тездән пычрак урамнарда ник бер җан иясе күренсен. Эт өргән тавыш та ишетелми, ичмасам. Мондый көннәрдә Подберезье халкы юкә каезлый, мунчала ясый. Урасы күптән урылган, сугасы — сугылган. Кырларда бушлык. Мужикның келәте дә әллә ни тулы түгел. Җитенкерәмәгәнне тартып-сузып җиткерергә тырышалар — чабата тукыйлар, чыпта үрәләр.

Шау-шулы бишенче еллар узды. Нәләт уты белән патша җиләненең итәген көйдергән, кайнар сулышын бөтен илгә сиздереп торган революция вулканы сүрелде. Аның яңадан атылачак лавасы кайдадыр тирәндә — пролетариат күкрәгенең түрендә кайный, гөрелтесе үтә зирәкләргә генә ишетелә. Подберезье кешеләренең колагына керми әле ул. Боларның үз хәле хәл: дөнья булгач — нужасы бар, нужасы булгач — җигелеп тартырга кирәк.

Мужиклар ни салсаң да тулмый торган шул төпсез нужа арбасын сөйрәп яткан көннәрнең берендә, басу капкасында җайдак күренде. Бу якларны белгән-күргән кеше булса кирәк, сорашып-нитеп тормастан, атын староста йортының капкасы төбенә туктатты. Тезгенне баганага бәйләп, өйгә кереп өлгермәде, әйләнеп тә чыкты һәм, атына атланып, китеп тә барды. Староста Никифор Мироныч аны озатып калды. Җайдакның нинди хәбәр китерүен хәзергә ул гына белә иде. Ләкин авыл, шом сизенгән ат көтүедәй, колакларын шомартты.

Кичкә таба Мироныч десятникларны җыеп алды:

— Иртәгә җыен уздырабыз. Өяздән земский киләсе,— диде. Эшнең нәрсәдә икәнен белергә теләп күпме төпченсәләр дә, староста тел ачмады. Әмма аның «земский киләсе» дигән сүзләре дә уйланырга җитәрлек иде. Халык, корт иледәй, гөжләргә кереште.

— Авылдан сөрәләр икән...

— Җирләрне алалар, ди...

— Хуторга чыгармакчылар, имеш...

Һәр эштә җиде үлчәп бер кисәргә яраткан сабыррак ирләр авыз ачып сүз әйтергә ашыкмадылар.

— Урманда йөргән аюның тиресен бүлешмик, җәмәгать,— диде Захар Потапов.— Башта үзен күрик, аннан тиресе турында уйлашырбыз.

Әмма үзе, старостаны аулакта гына күреп, бәйнә-бәйнә сорашты. Мироныч үз кеше иде. Элекке старостаны мең бәла белән куган сайлап куйганнар иде аны, бик теләп сайлаганнар иде. «Мир белән бул, Мироныч, мир синең белән булыр!» дип наказ бирделәр. Староста булды, түрә булмады, кукраймады Никифор агаең, җае килгән саен авылдашларын яклады. Бу юлы да Захар аның тел төбеннән шуны сизде.

— Үзең әйтмешли, Захар, башта аюны күрик,— диде староста.— Аннары миләрне кыймылдатып карарбыз.

Җыенга килгән халык алдына чырадай нечкә гәүдәле, ак чырайлы, урта буйлы кеше чыгып басты.

— Земский начальник,— дип таныштырды староста.— Аның сүзгә әйтсә сүзе бар.— Үзе, хәйләлә генә елмаеп, күз кысып куйды.— Бик яхшылап тыңлагыз, җәмәгать.

Земский начальник, тиешле урынында утырмыйча һаман борын очына төшеп кунакларга тырышкан зур күзлеген сала-кия, үзенең һәм мөхтәрәм пристав әфәнденең Подберезьега ни өчен килүләрен аңлатты. Бик тә җитди, үтә дә җаваплы, гаять тә мактаулы эш йөкләнгән икән аларга. Әгәр земскийга ышансаң, император галиҗәнаплары Рәсәй мужигының тормышын бөтәйтү турында гына кайгыртып ята, ди, шул хакта гына уйлый, ди. Бигрәк тә Столыпин хәзрәтләре тырыша икән.

— Менә ул — Гали затларның кайгыртуын күрсәтүче шаһитлар,— дип кычкырып җибәрде земский, кулындагы кәгазьләрне селки-селки. Чамасыз көчәнүдән аның аксыл йөзенә кызыллык йөгерде.— Күрегез, бу — җир турында яңа закон.

Авыл кешесенең иң газиз нәрсәсе турында сүз чыккач, җыен тып-тын булды. Хәзер инде сөйләүченең күзлек белән маташуын авыз ачып тамаша кылучылар калмады. Барысы да аның һәр сүзен йотып баралар.

Земский да рухланып китте. Общинада яшәүнең эт тормышы булуын сөйләде-сөйләде дә, хуторда торуның рәхәтлекләрен саный башлады.

— Анда сез үзегез хуҗа, үзегез князь. Күршегездән сезгә бүре күзе белән карап торучы да булмый. Хутор — крестьян хуҗалыгының иң кулай формасы...

Кешеләр бер-берсенә карашып куйдылар. Әнә, кая себертә Столыпин себеркесе. Тел төбен аңлагач, яңа законның бәдрәф исе борыннарга кергәч, җыен дәррәү гөжли башлады.

— Чыкмыйбыз общинадан.

— Көн күрсәк тә мир белән, гүр күрсәк тә мир белән!

Захар үз янында торган энесе Андрианга пышылдады:

— Хәтәр аю булып чыкты.

Аның кинаясе: килешерлек нәрсә түгел, юл куярга ярамый, дигәнне аңлата иде. Энесе, тәшендем дигән кебек, ым какты һәм артка шылды.

Җыен гөжләве земскийның тавышын күмеп китте.

— Кончай базар! — дип кычкырып җибәрде пристав, урыныннан торып.

Халык тына төште. Күзлекле чыра сүзне тегәлләргә ашыкты:

— Өяз начальствосы сездән җыен карарын көтә. Хуторга күчәргә ризалык бирүегезгә өметләнә.

— Тот капчыгыңны!

Бу тавыш арткы рәтләрдән килде. Андриан инде кырмыска оясына таякны тыгарга өлгергән булса кирәк, кычкырулар ешайды:

— Өяз юлы такырмы? Такыр булса — табан ялтыратыгыз.

— Приговор бирмибез...

— Әбиеңә сәлам әйт!

— Риза түгел.

Шау-шу купкач, приставның баганадай озын һәм юан гәүдәсе халык алдына тагын күтәрелде. Торып басты да кара мыекларын боргалап алды, күзләре белән мужикларны сөзеп торды һәм кычкырып җибәрде.

— Молчать!

Аңа җавапка хатын-кыз тавышы яңгырады.

— Көчәнмә, шартларсың.

Авылда чая хатыннардан саналган Татьяна Панкратова иде бу. Аңа кушылып, кемнәрдер Столыпинның җиденче буын бабасына тозлап-борычлап «кайнар сәлам» күндерделәр, яшьләр сызгырыша башлады. Пристав наган кабурасына тотынды. Хәзер ул атып җибәрәчәк. Башта һавага...

Шул чак халык арасыннан Никифор Миронычның чал башы күтәрелде.

— Тыңлап бетерик, авылдашлар. Тагын ни әйтерләр икән?

Үз кеше булганга, чал башын хөрмәт иткәнгә күрә генә колак салдылар аңа. Ул үтенгәч, гөжләү кимеде. Пристав, наганга ябышкан кулын алып, сүзен очлап куйды:

— Ихтыярыгыз! Яхшылык белән бармасагыз, җитәкләп илтербез. Приговорыгыз иртәгә өяздә булсын. Тиздән землемер киләчәк, карагыз аны, чәч бөртеге дә селкенмәсен. Башыгыз белән җавап бирәчәксез. Ишеттеңме, староста?..

— Ишеттем лә,— диде Мироныч.

— Расходись! — дип кычкырды пристав. Монысы инде гадәт буенча, нидер әмер итәргә кирәклектән әйтелгән сүз иде.

Юан гәүдәле пристав белән нечкә чырадай земский җыеннан тизрәк сызу ягын карадылар. Аларны сызгырып озаттылар...

II

Өч көннән землемер килде.

Аның эзенә басып, авылга, иңнәренә мылтыклар аскан, билләренә кылыч таккан командасы белән исправник керде.

Җыен карары җибәрелмәсә дә, өяз түрәләре эшне үзләре теләгәнчә үткәрергә булганнар. Земский белән пристав авылдан буш кул белән китмәгәннәр икән, бернечә кулактан прошение яздырып алганнар. Без, янәсе, общинадан чыгарга, хуторга күчәргә разый. Әгәр безгә, гаиләләребездәге җаннар башына исәпләп, әйбәтрәк җирләр бирелсә, бүген үк йорт-каралтыларны тиешле урынга илтеп салырга әзер торабыз. Император галиҗәнапларына рәхмәт укып яшәрбез, аңа исәнлек-саулык теләп, ходайга баш орудан туктамабыз.

Хәйлә-мәкерне бал-шикәргә бутап язылган шундый прошениеләрне бирүчеләрнең берсе авылда кансызлыгы һәм комсызлыгы белән яманаты чыккан Багрин иде. Ике башлы каракош сурәте төшерелгән мөһер белән раслаткан кәгазьләргә ышансаң, аның моннан өч-дүрт ел элек дөнья куйган тилемсәрәк энесе дә исән, аңа да җир бирелергә тиеш икән. Өяз түрәләре ничек караганнардыр, һәрхәлдә, Багринның «үле җаннар»ы да терелгән булып чыкты.

Землемер эшне шуларга җир бүлүдән башлады. Авылга килеп төшү белән, хуторга күчәргә ризалашкан биш-алты кулакны иртәп, кырга юнәлде. Исправник белән коралл отряд авылда күз-колак булырга калды.

Беренче нәүбәттә алучыларга община җирләренең «каймагы» эләкте. Өлешенә тигән кәмештән бик тә канәгать Багрин, булачак хуторының чикләрен билгеләп, кызыклар кагарга кереште.

Ничек шулай туры килгәндер: Багрин беренче казыкны җиргә кадап, кулындагы балтасы белән кизәнеп сугуга, авылда чиркәү чаңы кага башладылар. Кулак, аучы этенең исен ерактан сизгән бүре шикелле, сагаеп калды. Ләкин эшен ташламады.

Ә авыл кайный иде. Өзлексез чыңлап торган чаң тавышы кешеләрне урамга чакырды. Ә чиркәү янындагы мәйданда мәхшәр, ата улны, ана кызны белми иде. Барысының да телендә бер сүз:

— Җирсез калдыралар!..

Кемнәрдер үкереп елый, кайсыларыдыр сүгенә, патша хәзрәтләренең ата-бабасын иске төшерә.

— Мироныч!.. Кайда безнең Мироныч?..

Халык арасында, бәрелә-сугыла, Захар йөри, старостаны эзли. Ниһаять, табып алды.

— Нишлибез, Мироныч?

— Котүгә бүре иярләшсә, нишлиләр?

Чиркәү баскычында Татьяна Панкратова күренде.

— Мужиклар! Нәрсә йоклап ятасыз?.. Җирсез калдыралар бит...

Кешеләр шунда гына чиркәү чаңының тынып калуына игътибар иттеләр. Күпләр моның Татьяна эше булуын абайлап алды. Ни арада төшеп тә өлгергән, кычкырыпмы кычкыра:

— Кырга-а, мужиклар! Землемерны куарга-а!

— Кырга-а! — дип күтәреп алды халык.

Кешеләр ташкыны бер ара дулкынланып торды да басу юлына ыргылды. Шундук, зур киртәгә юлыккандай, тукталып калды. Халык барасы юлда атлы исправник һәм коралл отряд тора иде. Көтелмәгән хәлдән аптырап, бөтенләй югалып калгандай булдылар. Тынлык урнашты. Исправникның мәсхәрәле тавышы яңгырады:

— Кая юл тотасыз, күгәрченкәйләрем? Оҗмах кошы эзләргә түгелдер бит?..

— Аны эзлисе юк, исправник әфәнде, безнең якларга ул үзе килгәли.— Шулай

сөйләнә-сөйләнә, имән төбедәй таза гәүдәле Антон, төркемнән аерылып, атлыларга табан китте. Исправник кычкырып куйды:

— Назад!

Кораллыларның берсе мылтык затворын шалтыратып алды. Ләкин Антон, берниго исе китмәгән кыяфәт белән, исправникка якынлаша иде.

— Назад!..

Исправникның тагын акыруы булды, Антон житез мәчедәй сикереп, ул атланган колаdebian тезгеннәреннән эләктереп тә алды. Шул ук мизгелдә мылтык тавышы яңгырады. Тезгенгә чытырдап ябышкан Антон иелеп төште. Ул яраланган иде.

Мылтык тавышы кешеләрнең икеләнүләренә чик куйды. Захар ике-өч сикерүдә исправник янына килеп житте һәм аны ат өстеннән сөйрәп төшерде.

— Кан белән шаярасыңмы, бүре токымы! — Захарның йонлач йодрыгы, яшен ташыдай атылып, исправникның ияк астына кунды. Ул чайкалып китте, шул ук минутта кайсыдыр, икенче яктан, аның чигәсенә тондырды. Канга баткан исправник Захарның аяк астына егылды.

Ачуы ташып торган халык отрядны уратып алды. Барысын да өзгәләп ташларга житеп ярсыган кешеләр стражникларны дөмбәсләргә керештеләр.

— Бир кабахәтләргә!..

— Муеннарын бор!..

Эшнең үтә зурга китүен аңлап өлгергән Захар бөтен тавышына акырып жибәрде:

— Туктагыз!..

Стражниклар башы өстенә күтәрелгән йодрыклар тагын бер уйнап алды.

— Туктагыз! — дип кабатлады Захар. Үзе аяк астында яткан исправникны якасыннан күтәреп торгызды да артына тибеп алды.

— Менә шулай, ваше благородие. Юлыгызга ак жәймә, сыпыртыгыз моннан!

Стражниклар исправникның канлы башын бәйләделәр. Аларны камап торган авылдашларына Захар кул изәде:

— Юл бирегез! Үкчәләрен күтәрсеннәр...

Кешеләр теләр-теләмәс кенә юл бирделәр, божра өзелде. Стражниклар яралы исправникны арбага салдылар. Атлар кузгалып китте. Шунда, нигә кирәк булгандыр инде, Иван Таланов халык төркеменнән аерылып алгарак чыкты да, йодрыкларын селки-селки, кычкырды:

— Борыныгызны тыкмагыз бүтән, муеннарыгызны борырбыз!

Атлыларның берсе аңа мылтыгын төбәде.

— Ваня, саклан! — Захар кычкырырга гына өлгерде, мылтык шартлады. Талановның жансыз гәүдәсе жиргә ауды. Пристав командасы атларны юыртып китте.

— Эх, исән килеш жибәрәсе калмаган үзләрен! — дип үкенде кайсыдыр.

Яралы Антон белән Иван Таланов гәүдәсен күтәргән халык авыл буйлап кара күләгәдәй үрмәләде.

Землемер кырдан ук өязгә качты.

### III

Талановны бөтен авыл жирләде.

Антонны, үзара киңәшеп, «озын колаклар ишетмәслек, очлы күзләр күрмәслек» жиргә, күрше өязгә озатып куйдылар.

Өяз начальствосы бүтән борчымады. Бер-беренә охшаган соры көннәр, соры атналар үтә торды. Көннәр суытты. Моңарчы тездән пычрак урамнар шакырдап катты. Ниһаять, беренче кар төште.

Шул беренче кар яуган көнне Багринны үтерделәр.

Ул инде хутор дигәненә күченеп өлгергән, яңа урында шыңгырдап торган нарат-тан өй житкергән иде. Аның белән бергә жир эләктергән кулаклар саграк булып чыктылар, берсе дә күчәргә ашыкмады. «Язга кадәр вакыт бар әле» дигән булып, алар мужикларның тынычлануын көттеләр. Ә Багрин ашыкты, тимерне кызуында сугарга тырышты. Үз башына булган. Эш эзләп йөргән чуваш осталарын ярты бәя белән көнлек ашау хакына яллап, ай ярым дигәндә йорт житкерде, атна-ун көндә каралты-

куралырын торгызды. Беренче кар яуган көнне иртән яңа йортка күченде, ә кич белән аучы мылтыгыннан атылган бүре ядрәләре аның күкрәген теткәләгән иде. Яңа хутор хуҗасы, Столыпинга таяныч буласы бәндә, үзенең комсыз җанын ходайга тапшырды.

Бу вакыйгадан соң инде хуторга чыгу турында авыз ачып сүз әйтергә теләүче дә калмады.

Багринның уллары һәм туганнары үзләре шикләнгән кешеләрдән үч алырга керештеләр. Шикле кешеләр — җирләре Багринга бирелгән мужиклар иде, билгеле.

Башта Василий Фролов дигән кеше югалды. Аның шакырдап каткан гәүдәсен кырдан табып кайткач, авылда:

— Сихерләп үтергәннәр,— дигән хәбәр таралды. Монысы тынарга өлгермәде, Александр Семчуковның канлы гәүдәсен табып алдылар. Бу юлы да:

— Багриннар каргышы төшкән,— дип сөйләделәр.

Нинди юл белән «сихерләгәннәр», ничек «каргаганнар» — моны белүче юк иде. Хәер, ишеткән-күргән кешеләр дә булгандыр, әмма тел тибрәтергә базмадылар Ходай сакласын, үзеңне сихерләп куюлары бар.

Ә Багрин нәселенең «каргышы» яңадан-яңа корбаннар башына төшә торды. Авыл зиратында тагын ике кабер артты: Тимофей Романов белән Кирилл Канашевны күмделәр.

Үч тустаганына кан тутырган, шул канны комсызланып эчкән Багрин токымының кулына сугар көч, ерткычлыгын чикләр власть юк иде шикелле. Сакчысыз кетүгә кергән бүредәй, алар бөтен авылга шом салып йөрделәр.

Исправникның чигәсен тишеп, стражникларны дөмбәсләп озаткан авылны өяз түрәләре онытмады. Өяз генә түгел, хәтта губернатор үзе аны мыегына урап куйган икән.

Раштуа бәйрәме алдыннан, беркөнне кич белән, десятниклар авылны иңләп-буйлап чыктылар.

— Губернатор килә. Таң белән чиркәү мәйданына!..

Иртәгесен кояш бик кызарып, «колаклы» булып чыкты. Ярма кар күзләрне чагылдырып җемелдәде, салкыннан сукрангандай, чабата астында шыгырдады.

Чиркәү мәйданына җыелган халык, попка ияреп, авыл читенә, губернаторны каршыларга чыкты. Дин башлыгы зур икона күтәргән, ә старостаның кулында икмәк-тоз иде. Тәресе бар, ипи-тозы бар, ачык йөз дигәне күренми. Барысының да чырайлары караңгы. Мужиклар малахайларын батырып киеп, колакчыннарын бәйләгәннәр, хатын-кыз җылырак нинди нәрсә туры килсә, шуңа төренгән. Ә күзләре зәһәр ялтырый.

Еракган кыңгырау чыңы ишетелде. Озакламый карлы юлда атлылар күренде. Алда — тройка җигелгән артлы чанада — төлке толыпка төренгән бераү утыра. Аның артыннан юыртып атлы сотня килә.

Халык төркеменә җитәргә йөз-йөз илле сажен калгач, җилдереп килгән тройка һәм атлы сотня кинәт тукталдылар. Төлке толыплы кеше — аның губернатор булуында шик юк иде инде — сотня башлыгына нәрсәдер әйтте. Тегесе, честь биреп, атын борды да халык каршысына килеп туктады.

— Нәрсәгә җыелды бу көтү?

— Халык губернатор хәзрәтләрен каршыларга чыкты, рәхим итегез,— диде поп. Әллә суык үзәгенә үткәнгә, әллә куркуыннан ходай хезмәтчесе дер-дер калтырана иде.

Сотня башлыгы, килгәндәге шикелле үк юыртып, атын губернатор чанасы янына туктатты, честь бирде һәм, шундук борылып, халык төркеменә килде.

— Разойдись! — дип боерды ул.— Галиҗәнап таралырга боера, разойдись!..

Поп, бияләйле кулын маңгаена ашык-пошык тидереп алды да, тәресен күтәреп, авылга юнәлде. Кешеләр, кабалана-сугыла, аның артыннан ыргылдылар. Кайсыдыр старостага бәрелеп үтте. Мироныч кулындагы бөтен икмәк кар өстенә тәгәрәде.

Авылга атлы казаклар сотнясы белән губернатор керде.

Бер-ике сәгатьтән аңа өстәмә көч — ике йөз кешелек полиция отряды да килде. Полиция авылны камап алды. Беркем дә кермәсен, беркем дә чыкмасын — губерна башлыгының әмере шундый иде.

Губернатор үзе, өяздә әзерләнгән исемлек буенча, сорау алырга керешә. Суды — кыска, хөкеме — бер: казаклар җилтерәтеп кертсән кешегә берничә сорау бирә дә алдындагы исемлектә аның фамилиясе янына тәре билгесе куя. Аннары сотня башлыгына әмер бирә:

— Арестовать!

Ике казак арестантны алып чыгалар да тимер ишекле келәткә ябып куялар.

Казакларның үз шөгыле бар: азык-төлек җыялар, фураж даулап, йорт саен кереп йөриләр. Бер хуҗалыктан — тавык, икенчесеннән — каз, өченчесеннән — сарык әләктереп чыгалар.

Губернатор төнгә кадәр сорау алды. Келәткә ябылган тоткыннарның саны илледән узды.

Казаклар казанына салынган мал-туарны санап торучы булмады. Һәрхәлдә, ике йөз кылычлы полиция отряды белән казаклар сотнясы күп нәрсәнең башына җиттеләр, күпләрне ач калдырдылар.

Келәткә ябылган тоткыннарга каравыллар куелгач, губернатор тукталган йорт хуҗасы Яков Яшонин белән авылдагы бердәнбер кибетне тотучы Зиновий Шалин, бергәләшеп, олы кунак хөрмәтенә зур мәҗлес үткәрделәр. Поп та чакырылган иде. Дәрес, мәҗлестә ул үзен арбаның бишенче тәгәрмәче халәтендә тойды. Олы кунак аңа әллә ни игътибар күрсәтмәде. Азрак төшереп алгач, чөгендердәй кызарган симез битен, чиртсәң каны тамарга торган муенын тастымал белән сөртә-сөртә, губернатор попка:

— Начар эшлисең, атакай,— дип куйды.— Мәхәлләң симергән. Христиан сабырлыгы какшаган.

— Тырышабыз да бит, ваше превосходительство...

— Сафсата,— дип бүлдерде дин башлыгын губернатор.— Онытмагыз: ил тезгене ике кулда — безнең белән сездә. Бездә — власть, сездә — дин. Үзебезнең кулдагысын без, аллага шөкер, нык тотабыз, ә сез ычкындыргансыз. Ярамый.

Мондый кисәтүдән соң ходай хезмәтчесенең ашаганы аш булмады. Кара коелып утырды поп, мәҗлес тизрәк тәмамлануын көтте. Ә губернатор ашыкмады.

— Керәне шәп! — дип хуҗаларны мактый-мактый, кыздырылган чучка ашады, тулы-тулы стаканнарны күтәрде. Ниһаять, йокларга ята инде дип торганда, адъютантына әмер бирде:

— Сотскийга әйт: авылны уятсын. Чиркәү янындагы мәйданны,— губернатор кикереп куйды, тастымал белән битен сөртеп алды — чистартсыннар. Карын көрәсеннәр, бозын ватсыннар... Ә сәгать унга бөтен кеше — карты-яше шунда килгән булсын.

Сотский төрле йортларга таралып урнашкан казакларын уятырга керешә, казаклар десятникларны сөйрәп торгыздылар. Икешәрләп-өчәрләп йорт саен кереп йөрделәр. Әледән-әле мылтык тавышлары яңгырады: чакырылмаган кунаклар үзләрен ауһаулап каршылаган этләрне кырдылар.

Куркынып уянган сабыйлар, мич башында песи балаларыдай бөгәрләнеп, елапшыңшып ятты. Олылар, караңгы лапасларда капшана-капшана, тимер көрәкләр, ломнар барлады.

Мужикларны таң төбеннән мәйдан чистартырга чыгардылар. Сүзсез, кышкы таң кебек караңгы чырай белән эшләде кешеләр. Атлы казаклар, кулларында җүрмәләрен[1] селти-селти, аларны ашыктырып торалар иде.

— Тизрәк кыймылда, ужым бозавы.

— Әй син, мир үгезе, нәрсә мөгезләреңне җиргә терәдең?.. Казы!

Сәгать ун була дигәндә туң җир чыкканчы чистартылган мәйданга бөтен халыкны куып китерделәр. Казаклар белән полиция мәйданны уратып алды. Сотня башлыгы губернаторга рапорт бирергә китте.

Бер сәгать узды — губернатор күренмәде. Кышкы кояш шактый күтәрелгәч кенә, власть башлыгы килеп чыкты. Аякларында җылы киез итекләр, өстендә затлы тирә тун. Тунның каптырмаларын ычкындырып җибәрде дә, итәкләрен артка каерып, кулларын биленә куйды. Бу кыяфәте белән ул сугышырга җыенып койрыгын кабарткан

---

[1] Җүрмә — нагайка, камчы.

куркәгә охшый иде. Шактый вакыт шулай сүзсез генә басып торды. Аннары бөтен көченә акырып җибәрде:

— Тезләнегез!..

Халык тезләнергә ашыкмады. Җырмалар ходка китте, полицейскийлар кулында прикладлар уйный башлады.

Губернаторның камчылар һәм прикладлар телендә кабатланган әмере үтәлүгә, яңа боерык:

— Торыгыз!..

Миңгә якын кеше ашыкмыйча гына торып басты.

— Тезләнегез!..

Сыртларда тагын җырмалар сызгырды, прикладлар уйнап алды. Кешеләр абынып киткәндәй булдылар.

— Башларыгыздан салыгыз!..

Бу әмер дә үтәлде.

Каршысында туң җиргә тезләнеп, кышкы суыкта ялан баш торган кешеләрне күрүдән ләззәт тапкандай, губернатор көлемсерәде. Аңа рәхәт иде, күрәсең. Тезләнгәннәр алдында көлемсерәп йөрде-йөрде дә йодрыгын күрсәтте.

— Я, нигә бунт күтәрмисез?.. Исправникка кул тидерергә йөрәк җиткән бит үзегездә!.. Мөгезләрегезне сындырырмын мин сезнең, община үгезләре. Исләп карарсыз менә!..

Бүтән сүзе юк, булса да башкача әйтә алмас иде, ахры, бу бәндә. Хәер, кара мужикларга аңлатып буламыни соң? Аңа власть көчен күрсәтергә кирәк һәм ул моны эшли. Сүз белән аңлатудан бигрәк, җиргә тезләндереп төшендерә. Мужикның акылы сыртында, муен тамырында аның. Нотык сөйләп торганчы, шул тамырына тондыр, сыртына тамыз — тизрәк аңлый, бик озак онытмый.

— Менә шулай,— диде губернатор.— Тагын бунт күтәрергә теләүчеләр юкмы? Булса, белеп торыгыз: анда урын җитәрлек! — ул кулларын җәеп, күккә ымлады.— Озатырбыз.

Губернатор әкрен генә атлап, мәйданны урап, кузгалып киткән урынына яңадан килеп басты да:

— Ә хәзер арестантларны озатырга атлар бирегез,— диде һәм сотня башлыгына боерды:

— Исемлекне укы.

Тегесе ат бирергә тиешле кешеләрнең фамилияләре язылган кәгазьне укып чыкты.

— Исемлектә бар кешеләр торсыннар,— диде губернатор.— Хәзер үк атларыгызны җигеп, басу капкасына чыгыгыз. Живо!..

Конвой тоткыннарны алып чыкты.

— Бәбәк төпләреннән уздырыгыз, күреп калсыннар,— диде губернатор, халыкка ишеттереп.

Арестантларның кулы артка каерылып бәйләнгән иде. Әнә, Захар атлый, артыннан ике энесе — Андриан белән Кузьма бара. Татьяна Панкратова да шунда, Мироныч та. Тезләнеп торган халык алдыннан үткәндә, ул башын иде. Гүяки моның өчен мин дә гаепле, кичерегез мине,— дип әйтергә теләде ул. Ә Захар, халыкка борылып, чая тавыш белән:

— Хушыгыз! Бирешмәгез! — дип кычкырырга өлгерде. Шул ук минутта аның битен камчы көйдереп алды, ярылган иреннәреннән кан акты. Халык арасыннан тавышлар ишетелде.

— Хушыгыз, туганнар!

— Хуш, Захар!

— Сау бул, Мироныч!

Бозлы җирдә тезләрнең туңуын да, салкын җилнең колакларны чеметеп-чеметеп алуын да сизмәде кешеләр. Җир өчен барган дауда баш булып, мылтыкларга каршы күкрәген куйган асыл ирләр белән хушлаша иде авыл. Яшьсез елады, өнсез сыкранды тезләнгән халык.

Арестантлар теземе узып киткәч, көмеш кыңгырауларын чыңлатып, тройка килеп җитте. Губернатор чанага менеп басты, адъютанты аның иңенә төлке толыпны салды.

— Онытмагыз моны!

Губернатор тагын бер тапкыр йодрык күрсәтте дә толып эченә чумды. Тройка кузгалып китте. Тезләнгән халыкны камап торган атлы сотня һәм полиция аның артыннан юырттылар.

Кешеләр әкрен генә торып басты. Ирләрнең күбесе, бүрекләрен киярга дә оныт-тып, арестантлар киткән якка борылды. Барысы да бик озак, күзләре талганчы карап тордылар. Авылның коныой астында атлаган кешеләре үргә күтәрелә башладылар. Ерактан караганда алар торналар теземенә хәтерләтә иде. Әйтерсең, туган яктан китәргә теләмичә, канатларын алпы-салпы гына селтиләр, бик акрын баралар.

Губернатор тройкасының кыңгырау чыңы да ишетелми башлады.

Авылда тагын тынлык урнашты — авыр тынлык, хәсрәтле тынлык.

* * *

Никифор Игнатьевич сүздән туктагач, без беравык аның хикәяте тудырган авыр тойгылардан аерыла алмый утырдык. Ул үзе дә көрсенеп:

— Тозлы иде безнең туфрак. Кан чылаткан, яшь сеңгән җир. Шулай тезләндерделәр безне,— диде һәм, китәргә җыенып, тора башлады. Тик, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кире утырды:

— Бүген тезләнүемә гаҗәпләнмәгез, балалар, ул вакыйгага быел алтмыш ел тулды. Авылдашларны искә алдым, аларның каны тамган җирне олыладым. Ленинга рәхмәтемне белдердем,— диде. Аннары акрын гына торды да кояш нурына чумган урам буйлап китте.

— Яңарган Подберезье буйлап иске авылның җанлы тарихы бара!

Бу уй ничектер үзеннән-үзе туды. Менә ул, тыкрыктан борылып, күздән күмелде.

Мәйданда Ленин һәйкәле калды, чәчәкләр калды, бәйрәмгә җыелган халыкның шатлыклы авазлары калды.

Бүгенге яктылык, бүгенге тормыш калды.

**Нәкый Исәнбәт**

Тукай премиясе лауреаты

# ОЛЫ ИҖАТ, ХАЛЫКЧАН ИҖАТ

Бакый Урманченың иҗади хезмәтенә 50 ел... Бу безнең өчен гадәттә билгеләп үтә торган бер юбилей гына түгел, ә әһәмияте белән тормышыбызда сирәк була торган олы вакыйга. Бөек Октябрь революциясенең икенче елында башланган бу 50 еллык хезмәт юбилее Татарстан республикасының 50 яше белән дә бер заманга туры килә. Совет чорына кадәр бездә гасырлар буе тыелып килгән сурәтчелек иҗатының профессиональ милли сәнгатебез булып башланып китүенә дә бүген 50 ел. Дөрес, элегрәк тә аз-маз сурәт төшерүче һәвәскәрләр, «Ялт-йолт», «Яшен», «Чүкеч» кебек көлке журналларына карикатура ясаучылар булган. Тик аларның һичберсен профессиональ сурәт осталары дип атарга мөмкин түгел. Чын осталар булмаганлыктан гына алар ара-тирә рәсем ясау белән шөгыльләнгәннәр. Шуның өчен алар олы сәнгать юлына кермәгәннәр, я теләмәгәннәр, яисә батырлыклары җитмәгән.

Милли сәнгать тудыру өчен аны ярату гына җитми. Моның өчен туган халкының рухы белән рухланырга, аның булган мәдәнияте белән мәдәниятләнергә, аннары күрше мәдәниятләрнең җитештергән орлыгын да кирәгенчә сайлап ала һәм тагын аларны да үз туган туфрагында үрчетә белергә кирәк. Бакый аганың ул җирлеге бик таза. Ул башта татар мәдрәсәләрендә белем ала, яңа татар әдәбияты белән рухлана, көнчыгыш, гарәп, иран мәдәнияте белән коралллана. Аннары, рус югары сәнгать мәктәбендә укып, сынлы сәнгать осталыгын үзләштерә һәм җиң сызганып эшкә керешә. Берәү дә йөрмәгән, тапталмаган җирдән сукмак салып, олы юлга чыгу өчен күп тырышлык кирәк булгандыр.

Урманчены заман тудырган. Ул чагында бу сурәтле сәнгать өлкәсендә андый кешебез юк иде. Аның шул дөньяга ярып керүе, бу сәнгатебезнең пионеры булудан башлап, комсыз рәвештә нәгышне дә, скульптураны да, графиканы да өйрәнеп өлгерүе, авыр көрәш елларында татар сурәтчелек сәнгатенең бөтен тармакларында остасы һәм аның нигез салучысы булып әверелүе — үзе бер героизм. Әйтергә була, Урманчены заман тудырып кына калмады, ул бездә үзе сәнгать заманы тудырды. Аның артында хәзер сәнгатебезнең барлык тармакларында эшләүче яшь һәм урта буыннан көчле сәнгать кадрларыбыз тора. Болар һәммәсе дә урта һәм югары сәнгать мәктәпләрен тәмамлап чыккан кешеләр. Ләкин Урманче сәнгать юлына кергән заманда әле сәнгать мәктәбенең кайда икәнен һәм аның ишеге кай якка ачылганын белмәгән яшьләр бик күп булган. Бакый ага, зур кыюлык күрсәтеп, беренче буларак ул ишекне ачкан һәм соңыннан, сәнгать техникумында педагог буларак, башкаларга да ул ишекне ачарга булышкан кеше.



Бакый ага сәнгатебезне бүгенге дәрәҗәсенә үстерүгә үзеннән гаять бай өлеш кертә. Менә ни өчен аның иҗат төрәне борынгы тарихларыбыз тирәнлегенә үтеп керсә, үзенең офык киңлеге белән дә хәзерге Татарстанда гына чикләнми, аның әсәрләре бүген Мәскәү, Уфа, Алма-Ата, Ташкент һәм башка шәһәрләрнең музейларын, мәдәният сарайларын, сәнгать галереяларын бизи.

Урманче бер генә пландагы сурәтче түгел. Безнең рәсем, нәгыш, график, декоратив һәм сынлы сәнгатебез бөтен яктан артта калганга, Урманче барысына да җитешкән һәм шушы сәнгатьтә кайсы тармагына ихтыяҗыбыз зур булса, шул юнәлештә күбрәк иҗат иткән. Ул 1919 елда ук сынлы сәнгатьнең өч төп тармагында эшли башлый (скульптура, нәгыш, графика) һәм бөтен гомере буе шушы өлкәләрдә эшләвен дәвам иттерә. Боларга янә театр декорацияләре өстәлә. Әле 1928 елларда мәрхүм Кәрим Тинчурин белән бер спектакльне декорацияләргә әзерләнеп эскизлар ясый. (Ләкин болар эшкәртелми калалар.) Ул ук — безнең әллә кайчан ук ваттырылып кырылган Болгар, Казан сарайлары диварларындагыча элпәле таш бизәкле майолик сәнгатьне тергезүче дә. Ләкин ул бу тармаклар белән генә калмый, аның талмас көчле кулы агач, ташларны да сәнгать әсәрләре итеп уймалый. Үзенең иҗат көчен



Ильич исемендәге шахта.

алар өстендә сыный башлый. Һәм менә аның кулындагы кискеч белән чүкечкә каты ташлар бирешә. Нәкъ Тукайның Пушкинга карата «синең шигырьләрең алдында, минемчә, агач белән таш та бии» дигәненчә, Бакый ага кодрәте белән «җансыз ташка җан керә»: кул астына төшкән агач, ташлар чыннан да терелә, безнең белән сөйләшә, яши, җырлый башлый.

Яңадан Казанга кайтып урнашуына 10 ел да үтми, Урманче кулыннан иң элек Тукай, аннан соң Муса Җәлил, Фатих Әмирхан, Дәрдмәнд, Бабич, Галимҗан Ибраһимовларның сурәтләре терелеп, берәм-берәм алдыбызга кайтып баса башлыйлар. Бакый ага безнең бу якындагы классикларыбыз белән генә чикләнеп калмый, аларга җирлек булган борынгы, тәүге классикларыбызга да игътибар итә: әнә борынгы дастаннар остасы «Коркот ата», «Йосыф-Зөләйха» поэмасын тудыручы Кол Гали, менә бу якта — мәгърифәтче, тарихчы Мәрҗани... Халкыбызның үткән һәм хәзерге бөек затлары. Бары да Урманче тылсымы белән терелеп яңадан сәнгать әсәре буларак үзебезгә кайталар. Пантеон!

Шулар белән бергә без Урманчеда ниндидер тар милли чикләнүчәнлек һәм шулай ук заманадан аерылу да күрмибез. Әнә бу якта казакъ акыны Җамбул, әнә скульптор Дмитрий Жилов портреты, Үзбәкстанның халык художнигы Виктор Уфимцев, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Луганский, менә «Ишембай нефть промысеслары», «Шахта лампасы күтәргән хатын», ниһаять, менә Ленин!

Бу гаҗәп зур галереяны әйләнеп, бер күреп чыкканда да, Урманче колачының киңлегенә һәм шуңа торырлык дәрте, энергиясенә сокланмыйча мөмкин түгел. Аңа әле 70 яшь бирүе дә кыен. Киң иңсәле, нык, төз, сагълам гәүдәле бу оста бүгенге көндә дә кешегә кадәр иртүк торган, кулында тукмак, кискеч һәм өтергеләр, ул таш кисә, агач юна, балчыктан сылаштыра, киндергә нагышли, кәгазьгә каләм сыза, сынлый, сурәтли.

Әйтергә кирәк, сәнгать сөям дигәч тә, Бакый ага корыга гына аңа табынучылардан түгел. Галереясыннан күрәбез ки, ул сәнгатькә буйсынып кына калмый, бәлки, иң элек безнең тарихи-мәдәни хәлебезгә карап, сәнгатьнең үзен халкыбызның рухына буйсындыра. Аның иҗаты — халыкчан. Әсәрләренең милли йөзе бар. Шул ук вакытта аларда сентименталь төчелекләр юк. Натуралистик вак детальләр белән мавыгырга яратмый. Ул — реалист.

Ләкин моңа карап, аның портретлары туры гына, берьяклы, яки бер планда гына кырыс чырайлы булып чыкмыйлар. Ул аларның шәхси төсмерен таба. Әйтик, әнә сезгә үзенең җегәрле-җитез кыяфәте белән композитор Нәҗип Җиһанов. Яки менә сезгә аталарча җылы, ягымлы һәм мәгънәле карап торучы Габдулла Кариев — гаҗәп бер эчке җыйнаклык, акыллылык аңарда. Урманченың иң яраткан жанры портрет булса кирәк. Портрет өчен скульптура сынлы сәнгатьнең иң табышлы төре түгел микән! Скульптурада бит кешенең кыяфәтен ничәмә-ничә аспектта күрсәтергә мөмкин. Нур һәм күләгә уйнавыннан файдалана белү скульптурага мул мөмкинлек бирә.



Нәҗип Җиһанов

Күренә ки, Урманче әсәрләренең тематикасы бик киң. Шулар арасында иң мәсъүлиятлесе — Ленин портреты. Ленин портреты күп осталар тарафыннан кат-кат ясалган. Урманченың Ленинны сурәтләвендә аерым бер үзенчәлек, яңалык бар. Көчле, кодрәтле Ленин. Бакый аганың Ленин портретын яңача күрсәтә алуы тәкъдир итәрлек хәл.

Бакый аганың колачы «Ибн-Фадланның Болгарга килүе» кебек күп белем, тикшерену таләп итә торган тарихи темаларга хәтле җәелә.

Урманче әсәрләрендә сәнгатьтә әһәмияте зур булган стиль эзләү, шуны сәнгатьчә тәгъбир итеп бирүнең рәвешен табу зур урын тота. Шуңа күрә ул көнчыгыш

миниатюр стильләрен тикшереп, соңгы эшләрендә, мәсәлән, «Уралтау эргәсендә» яки «Ибн-Фадланның Болгарга килүе» дигән декоратив-нәгыш эскизларында терек-иран миниатюра һәм татар бизәкләре стиле белән файдалана. Тукай, Дәрдмәнд әсәрләренә ясаган графиk рәсемнәре, театр өчен ясалган эскизлары, павильон формалаштыру, тарихи-милли костюм эскизлары — болар иллюстрация гына түгел, бәлки этнография өчен дә зур хәзинә. Тукайның «Яңа кисекбаш» дигән әсәренә ясаган рәсемнәрендә шул заманның тормышын, бигрәк тә Казанның Печән базарын сурәтләүләре тарих өчен дә, сәнгать өчен дә кыйммәтле бай чыганак булып әверелә. Аның иллюстрацияләре һәм гомумән бөтен әсәрләре ялгыз хыял, фантазия белән генә ясалмаган. Гыйльми һәм фәнни әзерлеге, ясаячак әсәрләре өчен кирәкле материал җыйганда, тирән тикшеренүләр ясарга мөмкинлек бирә. Ул ясалачак объектларның бөтен хас булган сыйфатларын җентекләп тикшереп үтәргә тели. Аның әсәрләренең тәмам канәгатьләндерерлек булуы шуннан килә.

Бакый Урманче — сынлы сәнгатебезнең патриархы, аның ыру башы, аксакалы. Без «яңа татар поэзиясенә һәм татар музыкасына нигез салучылар кемнәр!» дип соралганда, беренчесе Тукай, икенчесе Сәйдәш, дип җавап бирсәк, инде «татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем!» дигәнгә дә: «Бакый ага Урманче!» дип, бүген хаклы рәвештә әйтә алабыз.

Менә ни өчен 50 еллык хезмәт бәйрәме безнең өчен гадәттәге билгеләп үтә торган бер хәл булып кына кала алмый. Һәм менә ни өчен дә бу юбилей безнең иҗтимагый, мәдәни тормышыбызда сирәк була торган әһәмиятле, зур вакыйгаларның берсе булып тора. Шуның өчен без сәнгатьчебез Бакый Урманченың үзен дә, иҗатын да олы бәялибез, аны яратабыз һәм аның белән горурланабыз.

**Хәсән Гобәйдуллин**

Сәнгать фәннәре кандидаты

# БАЙ ГОМЕР ЮЛЫ

*Б. Урманченың шәхси күргәзмәсе ачылу уңае белән*

Татарстанның халык рәссамы, Тукай премиясе лауреаты Бакый ага Урманче 1897 елның 23 февралендә Казан губернасының элекке Тәтеш өязе (хәзерге Буа районы) Күл Черкене авылында мәхәллә мәктәбе укытучысы гаиләсендә туа.

Уку-язуга әтисеннән өйрәнә.

Әтисе Идрис Хәсән улы, алдынгы карашлы, укымышлы кеше булып, Буа мәдрәсәсенең прогрессив караштагы шәкертләр түгәрәге белән бәйләнештә торган. Бу түгәрәктә язучы Шакир Мөхәммәдев, педагог Фатих Садыйков, шагыйрь Зариф Бәшири, журналист Кәрим Сәгыйд, китапчы Шиһап Әхмеров кебек XX нче гасыр башында татар халкының алдынгы хәрәкәтендә күренекле хезмәт калдырган затлар була. Бакый аганың искә төшерүенә караганда, алар өендә «Урал» газетасы рухы аеруча нык сизелеп торган. Моңа, күрәсең, Оренбургта «Урал» газетасын чыгарышкан Шакир Мөхәммәдев, Фатих Садыйков, Зариф Бәшириләрнең Буа мәдрәсәсендәге хөр фикерле шәкертләр белән якын мөнәсәбәттә торулары сәбәп булгандыр.

Идрис абзый газета-журналлар алдырып торган, шулар арасында иллюстрацияләнгән бер рус газетасы да булган. Җәйләрен агачтан юнып, балчыктан сылап, кечкенә Бакый төрле фигуралар ясаган, кышларда исә шул рус газетасыннан рәсемнәр күчергән. Бигрәк тә ат рәсемнәре ясарга яраткан ул. Идрис абзый улының рәсем

белән маташуларын кире күрмәгән генә түгел, хәтта хуплаган да. Аның рәсемнәрен Буа мәдрәсәсенә илтеп, дусларына күрсәтә торган булган. Булачак сурәтченең әнисе һәм апалары оста чигүчеләр булганнар. Әнисенең эш арасында мич агына күмер я карандаш белән чигү үрнәкләре ясап куюын Бакый ага әлегә хәтле хәтерендә саклый.

1907 елда Идрис Урманче гаиләсе белән шул ук өязнең Казанга якынрак Салтык авылына күчеп килә, чөнки Идрис абзый үзенең улларын Казанның иң яхшы мәдрәсәләрендә укытырга тели. Шул ук елны Бакый Урманче Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе үз заманында Казанда гына түгел, ә бөтен төрки Россия өчен билгеле булган алдынгы уку йортларыннан санала. Анда, ислам белән бер рәттән, тарих, география, математика, физика, татар, рус теле, гарәп, фарсы телләре укытылган. Татар халкының Хөсәен Ямашев, Камил Якуп, Фатхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәт кебек күренекле эшлеклеләре шушы мәдрәсәдә укыганнар.

1914 елда Бакый Урманче мәдрәсәдән китә, чөнки ул сәнгать мәктәбенә керергә хыяллана, ә анда керер өчен акча эшләргә кирәк була. Ул Уралга китә, Надеждинск заводларында эшли. Ләкин, эшчеләр көрәшендә катнашкан өчен, бераздан аны заводтан куып чыгаралар. Урманче урман эшләренә китә. Ләкин, сазламык Урал урманнарында акча табу урынына, бизгәк белән чирли һәм өенә кайтырга мәҗбүр була.

...Донбасс шахталары. Иске бараклар. Аларда вак милләт шахтерларының ярлы гаиләләре. Соңыннан сурәтче бу баракларның күренешен ясап бирә. (Бу эш Донецк музеенда булса кирәк).

Өйгә кайтып бер атна да тормый, аны патша армиясенә солдатка алалар һәм Казагыстанга озаталар. Перовскида солдат уеннары үткәннән соң, Б. Урманчены австрияле әсир офицерларны сакларга Коканд шәһәренә җибәрәләр. Әсирләр төрлесе төрле эш белән шөгыльләнәләр, кайберәүләре нәгыш тә ясаган.

Тәэсирләнүчән табигатьле, нечкә күңелле егет бөтен нәрсәне күрә, булачак сурәтчене бар нәрсә кызыксындыра. Ул мөмкин хәтле күп укый, сәнгать мәктәбе турында хыяллана. Теләсә нинди кыен вакытларда да Урманче рухи азыксыз яшәми. Әле Донбасста ук үзе белән йөрткән скрипкасыннан, акварельләреннән аерылмый. Ул хәтердән «Ямле Агыйдел буйлары» дигән картина яза. Кокандтагы әсирләр (алар арасында бәлки профессиональ сурәтчеләр дә булгандыр) майлы буяулар белән язалар. Урманченың андый буяуларны тотып та караганы булмый. Шуңа күрә әсирләрнең мольбертлары аны бик кызыксындыра.

Ул февраль революциясен Кокандта солдат булып каршылый һәм революцион хәрәкәттә актив катнаша: солдатларның революцион рота комитеты секретаре, солдатларның шәһәр комитеты члены була. Коканд татарлары җыелышларында да катнаша.

1917 ел. Август. Демобилизация. Урманче Вятка губернасының Глазов өязенә татар мәктәпләренә мәгариф инструкторы булып китә. Шунда гына ул беренче мәртәбә рәсем дәресләре ала башлый. Ирләр гимназиясе каршында рәсем студиясе ачыла. Бу чорның әсәрләре һәм «Ямьле Агыйдел буйлары» югалган.

Октябрь революциясе. Глазовның яшь инструкторы шәһәрнең революцион вакыйгаларында кайный. Башка бик күпләр кебек ук, төрле җәмәгать эшләрендә катнаша. Шулай Тәтеш өязе мәгарифчеләре съездына да күлеп чыга, һәм аны үз өязендә инструктор итеп калдыралар. Монда сурәтче Идел пейзажлары, В. И. Ленин һәм К. Либкнехт портретлары ясый.

Иделдә акгвардиячеләр. Ничек булса да үзебезнекеләр — кызыллар ягына эләгергә кирәк була. Ул мөмкинлекне табып, Урманче Мәскәүгә, Мөселман комиссариатына килә. Аклар куылгач, аңа Тәтеш мәгариф органнарын торгызу өчен мандат биреп җибәрәләр, һәм ул Тәтеш мәгариф бүлегенең мөдире булып эшли.

Ниһаять, 1919 елның гыйнварында Урманче үзенең күптәнге хыялын гамәлгә ашыра: Казан сәнгать мәктәбенә укырга керә. Нәгыш буенча В. К. Тимофеевта укый, скульптура буенча — Г. Козловта. Шул ук елны беренче мәртәбә «Чабатачы карт» скульптур фигурасы белән студентлар күргәзмәсендә катнаша. Бу фигура күргәзмәдән югала. «Бу хәл мине кайгырттты да, шатландырды да,— ди Бакый ага,— димәк, ул кемгәдер ошаган».

Хәзерге күргәзмәдә ул еллардан сакланып калган бердәнбер әсәр: 1919 елда ясалган һәм «Кышкы юл» дип аталган линолеум гравюрасы күрсәтелә.

1920 ел башында Урманче, Кызыл Армия сафларына алынып, Мөселман хәрби коллегиясе политотделында сәнгать секциясе мөдире булып хезмәт итә. Татарстан республикасы игълан ителгән көннәрдә Казан урамнары һәм демонстрацияләрен формалаштыруда катнаша. 1920 ел азагында Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе Мәскәүгә күчерелеп, республикабызның Реввоенсоветы эчендә шәрык бүлеге оештырыла. Урманче анда шулай ук сәнгать секциясе мөдире булып эшли. Шул ук елны Кызыл Армиядән командировка белән ВХУТЕМАСка (югары сәнгать институты) укырга җибәрелә.

Яшь художник өчен чын-чынлап уку еллары башлана. Урманче муеннан эшкә чума. Институтта ике факультетта укый: нәгыш һәм скульптура факультетларында. Офорт буенча профессор Шевердеевтән практик дәресләр ала. Аннан башка әле Көнчыгыш телләре институтының фарсы разрядында (факультет) укый, анда гарәп һәм инглиз телләрен өйрәнүне дәвам иттерә. Шул ук вакытта Мәскәүдә чыгарыла торган татар-башкорт газета һәм журналларында рәсемнәр дә ясый.

ВХУТЕМАСның нәгыш факультетында Урманче бик тиз алдынгы урын ала. 1924 елда беренче мәртәбә студентларның яхшы эшләренә премия бирү кертелә. Нәгыш факультетында беренче премияне «Ялангач хатын» картинасы өчен студент Бакый Урманче ала.

1926 елда уку курсын бетерә һәм Казанга кайтырга, Мәскәүдә алынган белемнәрен халкына бирергә ашыга. Ул еш кына үзенең татар язучысы Фатих Әмирхан белән әңгәмәсен исенә төшерә. Бакый ага аны әле «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган вакыттан ук күреп белгән һәм бер каникулда аның хәлен белергә кергән була. Ф. Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт» дигән фантастик әсәрендә татар халкының да кайчан да булса үз рәссамнары, композиторлары булуы турында язган. Күрәсең, ул яшь художникның киләчәккә планнары белән кызыксынган булгандыр. Урманче аңа нәгыш һәм рәсем укытучысы була алсам, канәгать булыр идем, дип җавап биргәнен хәтерли. Ф. Әмирхан моңа каршы: «Бер кеше өчен шул хәтлесе дә җиткән», дип куйган.

Шулай, Урманче Казан сәнгать техникумында нәгыш һәм рәсем укытучысы, укыту бүлеге мөдире булып эшли башлый. Бер үк вакытта ул зур көч белән шөгыльгә керешә. Ул елларны Урманче әле скульптура белән аз шөгыльләнгән.

Бу елларда язылган картиналардан «Сепаратор янында», «Бикбулатов портреты», «Кичү янында» кебекләре аның осталыгы тиз үсүен һәм иҗатының үзенчәлекле булуын ачык күрсәтәләр. Кызганычка каршы, бу чор әсәрләренең күбесе, шул исәптән берничә автопортрет, фигура этюдлары да югалганнар.

Техникумда эшләве хакында язганда шуны искә алыйк: 1926 елның көзендә ул Казанга кайтып, сәнгать техникумына эшкә керешкәч, анда татар яшьләреннән рәссамнар тәрбияләүгә зур игътибар бирә.

Тукай әсәрләренә уңышлы иллюстрацияләр ясаган Мусин, татар академия театрының декорацияләр остасы Мәэмүн Сутюшев, шул ук театрда эшләгән мәрхүм Мортаза Абдуллин, китап графикасы өлкәсендә эшләп, күп еллар Татарстан китап нәшриятының баш сурәтчесе булып торган Шакир Мөхәммәтҗанов, күп еллар Казан мәктәпләрендә рәсем дәресләре биргән һәм рәсем өйрәтү методикасы хакындагы мәкаләләре белән танылган Зәки Мөхәммәтшин, Мәскәүдә революция музееның өлкән реставраторы булып эшләүче Мөхәммәтша Кәримов, Ташкент педагогия институтында рәсем дәресләре биргән мәрхүм Солтан Брундуков, график Гата Йосыпов, Оренбургта сурәтче булып хезмәт итүче Газизова һәм Алмаевлар һәм башкалар — шул вакыт Бакый Урманче тәрбиясендә канатланган беренче карлыгачлар. Алар һәммәсе Бакый аганы хөрмәт белән телгә алалар. Күренекле язучы Мирсәй Әмир дә шул вакыт сәнгать техникумында укыган. Ул вакытларда ачылган татар мәдәнияте йорты янында Бакый ага җитәкчелегендә сынлы сәнгать түгәрәге оештырылу хакында «Безнең юл» журналының 1929 елгы 2 санында Мирсәй Әмирнең һәйбәт мәкаләсе бар. Фрунзе шәһәреннән Харис Ситдиков үзенең укытучысы Бакый Урманчега җибәргән хатларында зур хөрмәт белән: «Чын белемне миңа Сез генә бирдегез. Мин хәзер сәнгать училищесында укытканда, Сез өйрәткән рәвештә, Сезнең метод белән укытам!» — дип яза.



Мөхтәр Әүэзов

Ташкентта күренекле график Әнвәр Назыров, Бакый агадан укыган булмаса да, аның киңәшләреннән күп файдаланган, аны «безнең остазыбыз» дип атый.

1934 елда Б. Урманче Мәскәүдә яшь рәссамнарның ВЛКСМ ҮК һәм РСФСР наркомпросы тарафыннан оештырылган Бөтенсоюз күргәзмәсендә катнаша. Бирелә аның график эшләре куелган була. Алар матбугат игътибарын җәлеп итәләр һәм «Комсомольская правда» газетасында, «Творчество» журналында Б. Урманче эшләренең репродукцияләре урнаштырыла. Шушы елдан Б. Урманче Мәскәүдә тора башлый һәм Всекохудожникка (рәссамнарның кооператив союзы) керә. Әлеге күргәзмәдә катнашканнан соң заказлар алу мөмкинлеге ачыла. Бу чорның беренче зур эше булып югарыда әйтеп үтелгән «Шахтачылар барагы» санала. Шул ук вакытта «Шахтада лампа йөртүче татар хатыны» языла. Бу эшләр икесе дә «Донбасс — нәгыш сәнгатендә» дигән күргәзмәгә алына. Аннан соң 1935 елда «Социализм индустриясе» дигән күргәзмә өчен «Ишембай нефть промыселлары»н язарга дип Башкортстанга бара. Ишембайдан кайтышлый Уфада туктап, 1 Май исемендәге шырпы фабрикасы эшчесе, алдынгы комсомолка Шәрифә портретын яза, 1936 елда Татарстанга кайтып, хатын-кызлардан беренче буларак Ленин ордены алган, куян үстерүче Баян Нуриҗанова портретын яза.

Шул вакыттан бирле Б. Урманче Мәскәү күргәзмәләрендә даими рәвештә катнашып килә. 1937 елда, илебезнең башка рәссамнары кебек үк, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә эшли башлый. 1941 елга хәтле Күргәзмәнең бик күп павильоннары өчен скульптура һәм нәгыш эшләре ясый. Мәсәлән, терлекчелек павильоны фасадындагы «Социалистик терлекчелек» дигән зур барельеф, башкорт павильоны өчен ясалган зур нәгыш әсәре «Салават Юлаев», бу павильон гөмбәзе барабанында декоратив нәгыш һ. б.

1941 елда, Абайның юбилей комитеты тарафыннан бөек казакъ шагыйренең 100 еллыгына карата скульптура һәм нәгыш эшләре башкарыр өчен, Б. Урманче Алма-Атага чакырыла. Бу чор сугыш елларына туры килә. Авырлыкларга карамастан, Урманче бу елларны бик күп һәм уңышлы эшли. Сугыш беткәч, семьясы белән Мәскәүгә кайта, ләкин Казагыстан темаларына эшләвен дәвам иттерә. Бу чорның иң яхшы эшләре: Абай, Әүэзов, академик Сатпаев, артистка Җандарбекова, Советлар Союзы Геройлары Малик Габдуллин һәм ике кат Геройлар Луганский һәм Бигельдинов, кызыл киемле кыз портретлары, «Казагыстанда 1918 ел», «Амангельде» исемле картиналары, Абай, М. Әүэзов, С. Муканов әсәрләренә, казакъ халык әкиятләренә иллюстрацияләр, пейзажлар, натюрмортлар (тын табигать) һәм башкалар.

Балхаш бакыр кою заводының культура сараен эчке һәм тышкы формалаштыру буенча да рәссам зур эшләр башкара. Балхашта майоликадан ясалган су эчү па-

вильоны һәм культура сарае өстендәге 5 метрлы хатын-кыз фигурасы сокландыргыч зәвык һәм фантазия белән эшләнгән.

1956—1957 елларда Бакый ага Каспий диңгезендә ике тапкыр иҗади командировкада булып, Каспий һәм Җаек балыкчылары тормышыннан байтак этюдлар һәм картиналар яза. Бу хакта «Огонек» журналының 1956 елгы 44 санында Я. Фомичевның төсле фотографияләр белән иллюстрацияләнгән «Южнее Гурьева» дип аталган кызыклы мәкаләсе бар. Күргәзмәдә Гурьев балыкчылары темасына эшләнгән берничә картина бар. Аларда Гурьев ландшафтының төс һәм яктылык характеристикасы бик нәзек чагылган. Үтә күренмәле диңгез һавасы, көмеш кебек иртәнге колорит һәм кояш баешындагы эсселек сурәтче тарафыннан зур осталык белән бирелгән.

Эшлекле һәм сәләтле оста, сынлы сәнгатьнең төрле өлкәләрендә, төрле шартларында эшләп, зур тәҗрибә иясе була. Күп күргәзмәләрдә катнашып, матбугат һәм сәнгать дөньясында хөрмәтле һәм күренекле урын ала.

1956 елда Бакый ага Урманче Ташкент сәнгать институтының педагогик эшкә чакыруын кабул итә, анда скульптура һәм нәгыш сәнгатен укыта башлый. Скульптура группасын бу институтта ул үзе ачып җибәрә. Үзбәкстанда ул «Йөзем җыю» дигән зур картина яза, «Бану» дигән матур портрет, «Йөзем кырлары осталарыннан бер төркем Социалистик Хезмәт Геройлары» куш портреты һәм берничә пейзаж эшли. Агачтан ясалган «Коркот ата» скульптурасы (төрки дастаннар буенча) һәм Үзбәкстанның халык рәссамы Уфимцев портреты эшләнә. Ибн-Синага һәйкәл төзү конкурсына катнаша. Б. Урманче проекты югары бәя ала. Бу һәйкәлнең архитектура өлешен дә үзе проектлый.

1957 елда Бакый ага Урманчены, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлекләр алып баруда катнашыр өчен, Казанга чакыралар. Шул ук вакытта Бакый аганың бөтенләй Казанга күчүе мәсьәләсе дә куела һәм 1958 ел азагында ул туган шәһәренә күчеп кайта. Декадада Бакый ага архитектор Исмәгыйл Гайнетдинов һәм нәгышче Чыңгыз Ахмаров белән бергәләшеп СССРның зур театрында тәмамлау концертын җиһазлый. 1958 елда Казанга кайткач ук, аңарга Кәрим Тинчуринның «Беренче чәчәкләр»ен декорацияләүне тапшыралар.

Бакый ага эшләгән театр декорацияләре хакында уйлаганда, бер фактны искә алмыйча үтәргә мөмкин түгел: ул 1943 елларда Алма-Ата опера театры өчен «Аршин-мал алан» исемле музыкаль комедиягә эскизлар ясый. Бу — аның Казагыстанда ясаган бердәнбер декорациясе. Шуңар карамастан, бу декорация эскизлары һаман сәнгать дөньясының игътибарын җәлеп итеп килә. Алма-Атада күргәзелгәннән соң, ул эскизлар Мәскәүдә 1945 елда Бөтенсоюз сәнгать күргәзмәсе экспозициясендә булып, оригиналь үзенчәлекләре белән тамашачылар дикъкатен казаналар. 1958 елда Алма-Ата рәссамның 60 еллыгына аталган хосуси күргәзмәсендә, 1959 елда Мәскәүдә Казагыстан сәнгать һәм әдәбият декадасы вакытында оештырылган күргәзмәдә, 1967 елда янә Мәскәүдә Бөтенсоюз театр рәссамнары күргәзмәсендә булалар. Бу эскизларның чирек гасыр буенча һаман сәнгать әсәре буларак күздән төшми торулары үзе бу әсәрләрнең иҗади кыйммәте зур икәнне күрсәтә.




Коркот ата

Күбрәк театр өлкәсендә тикшеренүләр ясаучы булу сыйфатлары белән мин шуны әйтер идем: без спектакльләргә бәя биргәндә бары уенга гына игътибар итеп, декорацияләрне бер-ике сүз белән генә атап китәбез. Бакый аганың декорацияләр ясау сәләтеннән безнең театрлар файдаланганы юк диярлек. Ә кирәк иде.

Әле Ташкентта ук скульптор Тукай портретын ясый башлый. Гипста хәлендә ул 1960 ел Алма-Атада Б. Урманченың 60 еллык юбилеена багышланган персональ күргәзмәсендә куелган була. Казанга кайткач, Тукай портреты мәрмәр ташка күчерелә.

Әкренләп аның каты материал турындагы күптәнге хыялы гамәлгә ашырыла башлый. Үзе Уралга барып, Чиләбе өлкәсенең Куелга дигән җиреннән бер тимер юл платформасы мәрмәр блоклар алып кайта. Татар фән һәм культура эшчәннәренең портретлар сериясен тудыра: язучылар Тукай, Дәрдмәнд, Кол Гали, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәйхзадә Бабич, Муса Җәлил, Нәкый Исәнбәт, тарихчы Мәрҗани, татар театрына нигез салучы Габдулла Кариев, композитор Нәҗип Җиһанов, профессор Гыйлем Камай, революционер Н. Шейнкман һәм башкалар.



Сагыш

В. И. Ленин сурәте Бакый ага Урманченың игътибарын бик күптәннән тартып килгән. Ниһаять, мәрмәр бюст туа. Бөек юлбашчының тормыш юлын һәм иҗатын тикшергәндә, рәссам алдына фидакарь ана Мария Александровна Ульянова фигурасы да килеп баса. Бу гүзәл хатын-кыз портреты хәзер Кокушкино мәктәбен бизи. Хәзерге көндә Бакый ага яшь Володяның Кокушкинодагы сурәте өстендә эшли. 70 яшьтә булуына карамастан, рәссам күпкырлы талантының чын-чыны белән чачәк ату чорын кичерә, рәхәтләнеп эшли, икенче иҗат яшьлеген кайтара. Бу чорның нәгыш композицияләре, Дәрдмәнд, Тукай темасына график эшләре Урманче талантының бу өлкәдә дә күкрәп үсүен күрсәтәләр. «Уралтау эргәсендә» дигән декоратив-дивар нәгышендә милли декоратив традицияләргә һәм бизәк фольклорына таяну ачык күренә. Ә «Ибн-Фадланның Болгарга килүе» дигән картина эскизы Урманченың тематик арсеналы бетмәс-төкәнмәс бай икәнен күрсәтә. Ләкин ул һәр тема өчен үзенә хас яңа тәгъбирләр эзли.

График сурәтләрне төрле юллар белән бирү Дәрдмәнд, Тукай һәм Хуҗа Насретдин мәзәкләренә ясалган иллюстрацияләрне чагыштырганда ачык күренә. Дәрдмәндкә иллюстрацияләргә лаконик бөтенләй хас, Хуҗа Насретдинда нәфис төсләр белән тонланган рәсем халык юморының нечкәлегенә ишарә итә. Шүрәле темасына скульптур шаярулар һәм график иллюстрацияләр туктаусыз эзләнүче рәссамның чиксез фантазиясен күрсәтәләр.

# ШИГЪРИ ДУЛКЫННАР

Мәхмүт Газизовның «Миләш сиртмә»[1] исемле беренче җыентыгын укыдым, аның шигъри дулкынын тотып алырга, үз күңелемне шушы дулкын «озынлыгына куярга» тырышып укыдым. Дөресен әйтәм, шигырьләр башта ничектер корырак, сүлпәнрәк кебек тоелдылар. Әмма лирик геройның чын күңелдән, фальшьсыз сөйләве, тормыштагы теге яки бу күренешкә мәгънәле гепә бәя бирергә тырышуы акрынлап үзенә җәлеп итте. Мин Мәхмүтнең шигъри дулкынының үзенчәлеге яңа темалар, яңа проблемалар күтәрүдә түгел, ә аның теге яки бу темага үзенчә якын килүендә, аны үз кичерешләре яктылыгында чишәргә омтылуында икәнен аңладым.

Үз күзләре кебек зәңгәр чәчәк
Тотып килде дә ул кулына:
— Нинди нәфис! — диде.—
 Бирәр шигырь
Язып бирче чәчәк турында...

«Җир» циклындагы икенче шигырь әнә шулай башлана. Һәм өч кенә строфалык бу әсәр бөтенләй көтелмәгәнчә йомгаклана:

Искә алмады һичкем,
 дымын биреп
Гөлне үстергән җылы туфракны.
Чәчәк түгел, никтер,
 җирне кочып,
Бер үбәсем килде шул чакны...

Төп фикер соңгы строфага салынган. Баштагы юллар, логика теле белән әйткәндә, укучыны фикергә китерергә ярдәмләшә торган «силлогизмнар» гына. Әгәр соңгы строфа алдыннан автор тарафыннан пауза ясарга ишарәләп калдырылган ачыклыкны күрмичә, аны алдагы юллар белән тоташ һәм бер тонда укып китсәң, шигырьнең сине дулкынландырырга тиеш булган төп фикерен тота алмый калуың да мөмкин.

«Алма» шигырендә исә сүз укытучыга укучыларының алмалар бүләк итүе турында бара. Алмагачларны алар беренче класста укыганда укытучы апалары белән бергәләп утырткан булганнар. Болар «гади алмалар» түгел.

Яшь аша күлә апа,
Әллә нишләтте
 алма... —

дигән юллардан соң моның шулай булуына тагын бер кат ышанасың. Дөрес тотып алынган психологик момент, уңышлы деталь үз җимешләрен күреп горурланган, шул ук вакытта гомер үтүгә беркадәр сагышланган карт укытучы образын тулы күзалларга ярдәм итә.

Җыентыктагы шигырьләрнең күпчелеге («Яңгырлы көз», «Маңгай сырлары», «Нигез ташы», «Кубань кызы Анита», «Пар миләш» һ. б.) әнә шулай тормышның берәр күренешеннән этәрелеп, поэтик фикер эченә алган юллар аша тормыш күренешләренең төп асылына төшенергә тырышкан, тауларның мәгърур буй-сыныннан битәр, андагы нигез ташларына, диңгезнең башка бик күп якларыннан битәр, аның сафлык чыганагы булуына игътибарын юнәлткән, тормыштагы гади нәрсәләрдә шигърият күрә торган үзенчәлекле лирик геройны тасвирлыйбез.

Әлбәттә, М. Газизов шигырьне йомгаклый торган юлларда һәрвакыт уңышка ирешмәгән әле. «Ике икең — дүрт» шикелле тапталган яки буталган фикерле шигырьләр дә бар. Мондый шигырьләр, күңелне ничек кенә шагыйрь дулкынына куярга тырышсаң да, тәэсир итә алмый-

[1] Мәхмүт Газизов. Миләш сиртмә. Татарстан китап нәшрияты, 1969 ел.

лар. «Күзләрең — күлләрең...», «Көнләшәм», «Билгесез солдат һәйкәле», «Бәйрәм җыры», «Зәй-Каратай», «Кавказ топольләре», «Йөрәк» шигырьләре әнә шундыйлар. Бу шигырьләрдә, мәнемчә, эмоциональ сөйләмнән битәр, коры акыл сатуга күбрәк урын бирелгән.

«Билгесез солдат һәйкәле» шигырендә автор «Билгесез дип әйтсәләр дә, бу солдат кемнеңдер улы, кемнеңдер этисе, сөйгәнедер» — ди. Әмма әсәрне:

Исеме билгесез булса да,
Йөрәккә ул билгеле... —

дигән берниндә яңалык алып килми торган юллар белән тәгәлли. Ә мондый бер детальле шигырьләрнең бөтен энергиясе, бөтен көче аның тәгәлләнешендә бит. Поэзиянең гомумән кыскалыкны-осталыкны яратуы берәүгә дә сер түгел.

Мәхмүт Газизов шигырьләргә «әрәм тамак» юлларны кертмәскә тырыша. Ул хәтта детальләрне ишәйтү хисабына шигырьне тагын да тыгызларга, камилләштерергә дә омтыла. Әмма бу яктан да, уңышлар белән бергә, уңышсызлыклар юк түгел. «Улым миннән акыллырак яшәр...» дип башланган шигырьне укып чыккач, автор белән бәхәскә керәсе килә. Автор киләчәкнең матурлыгын, башлыча, улының үзеннән акыллырак яшәячәгенд..., тәмлерәк ашаячагында күрә. Бу деталь автор әйтергә теләгән фикернең дереслегенә ышандырмый. Шуңа күрә аннан соң килгән уңышлы юллар да укучыга тиешле тәэсирне ясый алмыйлар.

Атылган кадәр пуля —
атылмас,
Ватылган кадәр шәһәр —
ватылмас,
Сытылган кадәр чәчәк —
сытылмас,—

ди автор. Әмма шушы уңышлы детальләрдән соң янә тиешенчә уйлап җиткерелмәгән фикерне өсти: «Җир йөзе тулар шагыйрьләр белән».

Детальләрнең әнә шундый мәгънәви яктан бер-берләреннән ерак булулары, ахыргача уйланып җиткерелмәүләре фикер каршылыгы тудыра, шигырьнең тәэсир көчен киметә.

Үз җирлегендә торып, поэзиягә өметле адымнарын ясаучы иптәшебез киләчәктә укучылары белән тагын да камилрәк, тагын да тирәнрәк шигъри дулкында сөйләшеп, ул дулкыннарны тагын да күбрәк күңелләр тотар, дигән өметтә калабыз.

ШАМИЛ МАННАПОВ.

# ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТ

Соңгы елларда татар әдәбияты тарихын өйрәнү өлкәсендә кайбер сизелерлек казанышларга ирешелде сыман. Ләкин моннан чыгып, эшләнәсе эшләрнең саны кимемәде, бәлки, киресенчә, бермә-бер артты гына. Һәм бу аңлашыла торган нәрсә.

Чөнки яшь бала үскән, балигълыкка җиткән саен, аның матди ихтыяҗларына кушылып, рухи таләпләре дә арта бара.

Татар әдәбияты белемендәге алга килеп баскан шундый ихтыяҗларның берсе сыйфатында әдәби текстология мәсьәләсен күрсәтергә кирәк. Чөнки бүген без әлгәрге берәр әдәби әсәрне тикшереп-белү юлында моннан 80-90 ел элек нәшер кылынган текстларның берәрсен сайлап, аның эчтәлеген аннотацияләү белән канәгатьләнә алмыйбыз инде. Бәлки, бу тикшерелә торган истәлекнең барлык басмаларын, хәтта аларның кул җиткән язма нөсхәләрен дә тикшереп, эчке уртаклыгын да, үзгәлеген дә ачыклап, шул рәвешчә оригиналга иң якын булган (яисә шулай булуы ихтимал) текст вариантын табарга тиешбез. Әдәби текстологиянең төп бурычы, кыскача әйткәндә, менә шулай дөрес текстны тергезүдән гыйбарәт.

Мәгәр бу төп ихтыяҗны канәгатьләндерүдән элек тагы бер мөһим таләпкә җавап бирәсе бар: теге яки бу истәлекнең басылган (әсәр шулай публикацияләнгән булса) текстлары күпме һәм кульязма килеш сакланган нөсхәләре бармы? Булса, никадәр? Ниһаять, алар ни сыйфатлы?.. Менә шул сорау-таләпләргә җавап бирмичә торып, әдәбиятыбыз тарихын өйрәнүдәге төп ихтыяҗ булган текстология мәсьәләләрен дә тиешле дәрәҗәдә хәл кыла алмаячакбыз. Димәк, конкрет текстологиягә керешкәнче безгә археография өлкәсендә дә җиң сызганып эшләргә кирәк икән. Археография фәненең бурычлары исә, мәгълүм булганча, кульязма истәлекләрне барлау, аларны тышкы сыйфатлары буенча үзара чагыштырып тикшерү һәм

тасвирлау, күзәтүләр нәтиҗәсен исә гыйльми җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итүдән гыйбарәт. Нәкъ менә бу мәсьәлә татар филологиясендә иң артта калган өлкәләрнең берсе иде, һәм шуның өчен дә бездә текстология фәненең торышы гаять түбән дәрәҗәдә булып килде. Ләкин, ниһаять, бу тирәдә дә беркадәр җанлану барлыкка килеп, кайбер нәтиҗәләр дә күзгә күренә башлады.

Бу әйтелгәннәргә мисал рәвешендә Казан дәүләт университеты каршындагы Н. И. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәдә саклана торган татарча кулъязмаларның систематик планда тасвирлана башлавын күрсәтергә мөмкин. Һәм шуны да махсус күрсәтергә кирәк: бу хезмәтләр очраклы инициатива җимеше булмыйча, гыйльми китапханә җитәкчеләре тарафыннан эзлекле рәвештә тормышка ашырыла торган план нәтиҗәсе сыйфатында чыгарылып киленә. Мәсәлән, соңгы ун ел эчендә (1958—1968) шул «Кулъязмалар тасвирламасы» циклыннан 12 чыгарылыш дөнья күрде. Боларның алтысы рус һәм башка Европа телләрендәге, калган алтысы исә татарча кулъязмаларны тикшереп тасвирлауга багышланган. Шуларның русча истәлекләргә багышланганнары хакындагы хөкемне үз белгечләренә калдырып, татарчалары турында берничә сүз әйтәсе килә.

Тасвирламаларның беренчесе күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри кулъязмаларына багышланган иде [1]. Белешмәне төзүче М. Ногман галимнән калган төрле характердагы язуларны тикшерү нәтиҗәсендә аның архив мирасын төрле яклап ачып бирде.

Моннан соң дөнья күргән чыгарылышлардан «Татар халык иҗаты» һәм «Төрки телләр белеме» дигән кисәкләрне (төзүчесе Ә. Кәримуллин) күрсәтергә кирәк [2]. Боларның икесе дә үз белгечләре өчен бик файдалы белешмә булып хезмәт итәләр, чөнки күрсәтелгән темаларга караган материаллар эзлекле рәвештә системага салынып, шактый төгәл тасвирланган. Нәтиҗәдә, үзеңә кирәк нәрсәне җиңел эзләп табудан тыш махсус фондның байлыгы турында да беркадәре мәгълүмат алырга мөмкин.

Әмма мондый тасвирламалар арасында әчтәлек ягыннан иң бае китап белгече Альберт Фәтхи тарафыннан төзелгән хезмәт дисәк, дөресрәк булыр. Чөнки бу тасвирлаучы, бер генә автор яисә бер генә жанр белән чикләнмичә, татар әдипләре һәм галимнәренең эшчәнлегенә, иҗатына караган барлык шәхси фондларны, кулъязма истәлекләрне тулаем тикшереп чыгуны үзенә бурыч итеп куйган [1]. Хәзергә хәтле публикацияләнгән өч чыгарылышның 70 тән артык галим һәм әдипнең кулъязмалары яки алар әсәрләренең төрле күчермәләрен эченә алган булуы да игътибарга лаек.

Дөрес, бу «70 тән артык» дигән сан хезмәтнең чын әһәмиятен ачып җиткерми әле; чынлыкта исә тикшерелгән объектларның, ягъни тасвирланган шәхси фондларның күләмен дә игътибарга алырга кирәк. Мәсәлән, икенче бүлектә тасвирланган тарихчы Хәсәнгата Габәши кулъязмалары 43 берәмлектән гыйбарәт булып, аларның тулаем күләме 900 кәгазьне ягъни 1800 битне тәшкил итә. Ә менә атаклы галимебез Шиһабетдин Мәрҗани кулъязмаларына килсәк, биредә инде күләм микъдары 8—9 мең бит белән генә исәпләнә ала. Кыскасы, тасвирлаучы 70—75 авторның исеме, яисә аларның аерым әсәрләре белән генә түгел, бәлки зур күләмле кулъязма документлар дөньясы белән эш иткән, аларның эчтәлекләрен билгеләп, хосусый сыйфатларын ачыклаган.

Ә бу кулъязмаларның ниндиләре генә юк соң! Менә матур каләмле, нык куллы оста каллиграф — хаттат тезеп чыккан энҗе хәрефләр, аларны укуы да бер хозур. Менә җүн генә почерк... Ә менә бусы инде бүген үзе язып, иртәгә кайбер төшләрен үзе дә көчкә-көчкә таный торган каралама текст — иҗат процессында анннан-моннан төртеп ташлаган «гыйльми тавык тәпиләре!..» Димәк, тасвирламаның әһәмияте каралып чыккан фондларның бит күләме белән генә түгел, бәлки укылган, дөресрәге, күп очракта дешифровкаланган текстларның график сыйфатлары белән дә билгеләнергә тиеш икән.

[1] Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кулъязмалары. Казан. 1958.

[2] Шул ук цикл. VI чыгарылыш. Казан. 1961; IX чыгарылыш. Казан. 1962.

[1] Шул ук цикл. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. V чыгарылыш. Беренче бүлек. Казан. 1960; X чыгарылыш. Икенче бүлек. Казан. 1962; XII чыгарылыш. Өченче бүлек. Казан. 1968.

Тасвирлаучы галим алдында торган кыенлыкларны әле генә күрсәтелгән моментлар белән чикләп кую да мәсьәләнең әһәмиятен бик тарайтуга ялтер иде. Алар, дөресен әйткәндә, эшнең беренче һәм әзерлек өлеше генә. Хезмәтнең әһәмияте исә нәтиҗәсе белән билгеләнә. Икенчеләй әйткәндә, тасвирлаучы үзе нәрсәләр белән, ничек танышуын гыйльми җәмәгатьчелеккә әзер продукция кыяфәтендә тәкъдим итәргә тиеш. Биредә инде алга тасвирламаларның нинди принципта төзелгән булуы килеп баса. Ә андый принциплар төрлечә. Мәсәлән, гади каталогтан чак кына киңрәк булганы да, ярыйсы гына тулыраклары да, ниһаять, сирәклэп кенә бик тафсилллылары да була. А. Фәтхи, болардан иң файдалы булган соңгы принципны сайлап, бик эзлекле рәвештә төзелгән бай эчтәлекле тасвирлама тәкъдим иткән.

Төзүче иң элек әйберләре тасвирлана торган әдип һәм галим турында кыскача, мәгәр мөмкин кадәр тулы гына биографик мәгълүмат биргәч, аның иҗатын, эшчәнлеген дә беркадәре яктыртып чыгарга тырыша. Аннан соң шул иҗат, шул эшчәнлек турында иң әһәмиятле махсус әдәбият исемлеген тәкъдим итә, ягъни мәсьәлә белән якыннан кызыксынган кешеләр өчен кайдан нәрсә эзләргә кирәклеген күрсәтә. Бары болардан соң гына төзүче конкрет кульязмаларга күчеп, аларның эчке һәм тышкы сыйфатларын ачып, кайсы бүлекнең нинди әһәмияткә ия булуын билгели. Нәтиҗәдә без, мәсәлән, университет китапханәсендә Габдерәхим Утыз Имәни дигән шагыйрьнең нинди әсәрләренең ничәшәр кульязмада саклануын, аларның сыйфатларын, шул әсәрләрнең кайчан никчегрәк басылуын белүдән тыш, бу иҗат, теге конкрет әсәр турында кайда һәм нинди фикерләр әйтелү хакында да тиешле мәгълүмат алабыз. Хәзер инде мәсьәләгә конкретрак килеп, тикшеренүгә тирәнрәк тукталасы кала. Чөнки беренче — т а н ы ш у  э т а б ы узылган. Янсә бер әсәргә караган өч-дүрт күчермәнең кайсы нөсхәсе тугәл һәм тулырак булуы да хәл ителгән; димәк, текстологик эзләнүләрнең дә беренче этабы әзме-күпме башкарылган икән. Хәзер без Ленинград, Мәскәү һәм Уфа китапханәләренә барып өстәмә кульязмалар белән шактый компетентлы рәвештә эш итә башлыйбыз инде. Мондый җиңеллекне без бер Утыз Имәни әсәрләрен генә түгел, бәлки И. Бикмөхәммәт, С. Вахиди, М. Гафури, Х. Габәши, Х. Гали, Г. Кандалый, Г. Курсави, Мөхәммәдьяр, Ш. Мәрҗани, Г. Рәхим, Г. Тукай, М. Фәйзи, Р. Фәхретдинов, И. Хәлфин, Г. Чокрый, Ф. Әмирхан һәм башка бик күп төрле характердагы әдипләребез, галимнәребезнең кульязма мирасларын өйрәнгән чакта да сизәчәкбез.

Җыеп әйткәндә, бастырып чыгарган тасвирламалары белән А. Фәтхи татар филологиясен, культура тарихын өйрәнүчеләр өчен гаять файдалы һәм бик мактаулы хезмәт башкарган. Дөрес, бу хезмәттә дә кайбер хосусый кимчелекләр бар, һәм аларның булуы бик табигый (мәсәлән, кайбер очракларда аерым иҗатларга, теге яки бу әсәрләргә бирелгән гомум бәяләрдә каршылыклы хөкемнәр, аерым төгәлсезлекләр һ. б.) Ләкин мин бу кечкенә рецензиядә аларга тукталмадым. Чөнки, беренчедән, алар т а с в и р л а м а л а р н ы ң төп әһәмиятенә зыян китермиләр; икенчедән, андый хаталар бер Альберт Фәтхи шәхсенә түгел, бәлки безнең филологиябезнең гомум торышына күбрәк бәйләнгән. Төзүче исә үз өстенә йөкләнгән төп бурычны — кульязмаларны тасвирлап, аларга археографик бәя бирүне — тиешле гыйльми югарылыкта яхшы сыйфат белән башкарып чыккан. Ниһаять, соңгы сүз өчен, шуны да әйтәсе килә. Бу чыгарылган тасвирламаларга университет китапханәсенә 1962 елга хәтле кабул ителгән кульязмалар һәм шәхси архивлар гына кертелгән. Укучылар өчен тәкъдим ителгән махсус әдәбият та шул ел белән чикләнә. Мәгълүм булганча, моннан соң археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә китапханәнең кульязмалар бүлегенә тагы йөзләгән китаплар, берничә шәхси архив кабул ителде. Аерым әдипләребез, галимнәребез турындагы махсус эзләнүләр дә чыгып тора. Димәк, «Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары» дигән циклның өстәмә чыгарылышын да әзерли башларга кирәк. Моннан соң борынгырак дәвер татар әдәби истәлекләрен тасвирлап чыгаруны да тизләтәсе иде. Һәм киләчәктә шундый аерым чыгарылышларны җыеп, унификацияләп махсус җыелма тасвирлама итеп чыгарганда тагы да яхшырак булыр иде. Һәрхәлдә, бу тәкъдимне китапханә җитәкчеләре дә, тасвирлама төзүче белгечләр дә игътибарга алырлар дип өмет итеп, файдалы эшнең нәтиҗәле рәвештә дәвам итүен көтеп калабыз.

М. ГОСМАНОВ

## *ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...*

**Туфан Миңнуллин**

# ШИКЛЕ КЕШЕ

ХИКӘЯ

Парк аллеясы буйлап ир белән хатын атлый. Ашыкмыйлар. Язгы матур көннең рәхәтлеген татып калаcылары килә.

Бик яратышалар булса кирәк. Хатын иренең кочагына сеңеп беткән, ә ир, җәннәт кошы тоткандай, хәләл җефетенең иңнәренә кулын салган да мысыр күгәрченe кебек гәрли:

— Бүген син гүзәлләрнең гүзәлләреннән дә гүзәлрәк. Хәтта әнә чәчәкләр дә сиңа сокланып карап калалар. Юк, карамагыз, чәчәкләр, көнләштермәгез мине!..

— Исәнмесез, Сабира Сәлимовна...

Ирнең күккә төбәлгән карашы җиргә төште дә сәлам биреп үткән кара мыеклы кешенең сыртына кадалды.

— Кем ул?

— Белмим,— диде Сабира Сәлимовна,— күргән кешем түгел.

— Ничек инде үзеңә сәлам биргән кешене танымыйсың?

Сабира ханым кеткелдәп көлеп куйды.

— Көнләшәсең, ахры, җаным?

— Яшермим, иркәм, көнләшүем хак. Бүтән чак булса бер хәер... Ә бүген...

Ир тагын хисләр дәрьясына сикереп, колачлап йөзә башлады. Ниндидер операдан ария җырлап ташлады, бәлки шигырь үк чыгарып өлгергән булыр иде, хатын, кинәт туктап, тирә-ягына каранырга кереште.

— Кемне эзлисең, җанкисәк?

— Сусадым, Хәйдәрем, шашып су эчәсем килә.

Алар өч тиенлек су сатучы автомат янына килделәр. Ир кесәсеннән акча эзләп маташкан арада каяндыр теге Кара мыек пәйда булды. Тишеккә өч тиен ташлады да, бер стакан су алып, Сабира Сәлимовнага сузды.

— Рәхим итегез,— диде һәм яңадан юкка чыкты. Бик сусаган иде шул хатын, абайлап та тормыйча суны эчеп җибәрде. Ир ике кулын ике кесәсенә тыккан килеш тораташ булып катып калды. Телдән язды. Ә Сабира, иренең кызганыч кыяфәтен бөтенләй күрмәгәндәй:

— Әйбәт булды, суы салкын икән — дип сөйләнде.

— Күреп торам,— дип телгә килде ир.— Башта исәнмесез, Сабира Сәлимовна, аннан су... аннан...

Бу юлы хатын үзе дә аптырады:

— Чыннан да кем икән ул? Бәлки, синең танышыңдыр? Көнләшә торган гадәтеңне беләдер, шаяртадыр,— диде.

— Белмим инде, кем шаяртадыр монда.

Ир белән хатын бераз әйткәләшеп алдылар. Икесенең дә кәефләре көзге яңгырлы көнгә охшап калды.

— Әйдә, кайтабыз,— диде ир һәм җәннәт кошын, кулыннан әләктереп, капка ягына сөйрәде.

Ә капка төбендә әлеге дә баягы Кара мыек басып тора иде. Кулында чәчәк букеты. Менә ул аны Сабира Сәлимовнага тоттырды да китеп барды. Ирнең сабырлыгы кучәреннән ычкынып, Кара мыек артыннан тәгәрәде.

— Тукта!!!

Кара мыек әйләнеп карарга өлгермәде, Хәйдәр аның якасыннан каптырып алды.

— Кем син?!

— Жи-жи-бәре-гез,— диде Кара мыек, тыпырчынып.

— Ычкына алмассың. Әйтеп кал. Син минем хатынны кайдан беләсең? Кайчаннан бирле аның тирәсендә бөтерелэсең? Чынлап яратасыңмы? Ул да сине яратамы?

— Нишләп яратсын, ир хатыны ласа ул,— дип акланырга тотынды Кара мыек.— Шөкер, минем дә үз хатыным, бала-чагаларым бар.

— Ә болар нәрсә? Су нәрсә, чәчәк нәрсә?..

— Гафу итә күрегез, Хәйдәр Хәкимыч. Алты ай буе, иптәш управдом, квартирамны ремонтлагыз дип яныгызда йөрим. Күтәрелеп карамадыгыз да юк. Бүген менә файдасы тимәсме дип, танып калмассызмы дип азаплануым иде. Зинһар инде... иртәгә яныгызга керсәм, күз салыгыз инде. Менә мин инде ул. Үзем булам. Квартирам...

# МАЛАЙЛАР

### хикәя

Үзебезнең ишек алды малайларын мактап балалар газетасы өчен мәкалә язып утыра идем, чалтыр-р!.. — тәрәзәмнең бер өлгесе коелды һәм өстәлгә, мәкаләмнең нәкъ өстенә, күне кыршылып беткән туп... доп итеп килеп төште.

Бу ни хикмәт? Кайсы дошманы?

Тәрәзәдәге туп ясаган тишектән (тишек кенәме соң) ишек алдына карадым, кеше заты күренми. Тупны култык астына кыстырып урамга чыктым, йорт тирәсендә әйләнгәләдем — беркем юк, тып-тын. Инде нишләргә дип аптырап басып торганда, каршы йортның өченче катындагы балконнарның берсендә бер әби пәйда булды.

— Малайлар,— диде ул, кулы белән урам якка күрсәтеп.— Качтылар. Милиция чакыр. Азындылар, җүнсезләр.

— Үзебезнең ишек алды малайларымы?

— Кемнәр булсын тагы! Бездә инде җыен шайтан котүчесе. Чакыр, милиция чакыр.

Ачуым ташып чиктән ашса да, эшне зурга җибәрәсем килмәде. «Шайтан көтүчеләре»нең үзләрен күреп колакларын бормакчы булдым. Тик аларны кайдан табарга? Тукта, бер кайтмый булмаслар әле. Туп өстенә утырып көтәргә керештем. Кайтмыйлар. «Эх, малайлар, малайлар,— дип эчтән генә рәнҗеп тә алдым үзләренә,— мин сезнең турыда... Ә сез? Аш белән аткан таш белән ату... Таш түгел лә, туп...»

Юк, кайтмыйлар. Мәкаләмне ертып ташлау нияте белән бүлмәмә керергә җыенган идем, бер тавыш ишетеп туктап калдым.

— Абый, тупны бир әле.

Тавышның иясен эзләп карасам, йорт чатыннан сап-сары бер баш күренеп тора.

— Абый, бир инде тупны.

— Синме ул минем тәрәзәмне ватучы?

— Әһе, без.— Малай лышт иттереп борынын тартып куйды.

— Кил әле монда.

— Ай-яй... Тупны ыргыт кына. Без бит ялгыш... Лышт!..

Белмим, ни өчендер, бу малайның кыяфәтен күргәч ачуым кинәт басылды.

— Килегез, кил, тимим.

— Честно,— диген.

Мин сүз бирдем. Чаттан тагын берничә малай чыгып бастылар. Боларын мин таныйм. Мәкаләмнең геройлары. Тик сары малай гына таныш түгел.

Ике арада «дипломатик» сөйләшүләр булып, берничә тапкыр минем вәгъдәмне алгач, малайлар бер-берсенә сырыша-елыша якынрак килделәр, гафу үтенделәр, пыяла табып бирергә ант иттеләр.

— Абый, хәзер бир инде. Туп минеке,— диде сары малай.

— Син кем соң?

Малайлар аңлаттылар, ул күрше урамныкы икән, абыйсының тубын гына алып торган. Тупны алып кайтмаса, абыйсы кирәген бирәчәк.

Мин тупны бирергә ашыкмадым, җае туры килгәндә, үз-үзеңне тоту мәсьәләсендә бераз вәгазь сөйләп алырга кирәк таптым.

— Туп тибеп тәрәзә ватарга ярамаганны беләсезме?

— Беләбез.

— Ә нигә ваттыгыз?

— Әнәс капкада торды, тота алмады.

— Тота алмады сиңа, кыек типтең.

— Шауламагыз,— дидем мин,— ничек кенә булса да хәзер тәрәзә ватык инде. Әгәр ишек алдында уйныйсыз икән, капканы тәрәзәләр ягына ясамагыз.

— Монда гел тәрәзә. Абый, бир инде.

— Юк, гел тәрәзә түгел. Менә, мәсәлән, монда.

Безнең ишек алды, таш койма белән уратып алынган. Мин малайларга шул урынны күрсәттем.

— Ә без шунда уйнадык та инде,— диделәр.

— Алдашмагыз, анда типкән туп бу тәрәзәгә берничек тә тия алмый.

— Кыек типсәң, тия.

Малай халкы сүзгә ышанмаучан була, аларга һәр нәрсәне мисалда күрсәтеп исбатларга кирәк.

— Яле, бас әле койма янына,— дидем мин сары малайга.— Тибеп карыйм.

Сары малай кушканны бик канәгатьләнеп эшләде. Туп тотарга әзерләнеп борынын тарта-тарта бер урында сикергәләргә тотынды. Мин чит-

кәрәк китеп тупны җиргә җайлап куеп типкән идем, туп туп-туры минем тәрәзәгә очты. Ярый әле, бәхеткә каршы, тәрәзәнең үзенә тимәде.

— Я, я! Менә!.. Менә!..—дчештеләр малайлар.

— Монысы аяктан ычкынды.

— Безнеке дә.

Малайлар алдында сер бирергә ярамаганлыкны яхшы беләм мин. Шуңа күрә:

— Тавышланмагыз. Монысын карагыз,— дия-дия тупка тагын бер типтем, һәм, ничек төгәл бәрелгәндер, туп тәрәзә тишегеннән бүлмәгә кереп китте, анда нәрсәдер чылтырап ватылды.

Малайлар бу юлы бер сүз дәшмәделәр. Ни белән бетәр дигәндәй, миңа карап каттылар. Мин нәрсә, мин, үземнен ялгышымны аңладым инде. Шулай да көлгәндәй иттем.

— Юри шунда төзәп типтем,— дигән булдым.

Беренче булып сары баш телгә килде.

— Абый, тупны чыгарып бирәсеңме инде?

— Билгеле, билгеле...

Бүлмәгә керсәм, туп идән уртасында ята. Ә тәрәзәгә каршы як стенадагы көзгенең арт тактасы гына калган. Шуңа карадым да уйга талдым. «Эх, малайлар, малайлар. Мин сезне мактап язарга җыенам, ә сез...»

— Алыгыз тубыгызны!..

# ГАПТЕЛВӘЛИ

**хикәя**

Гаптелвәли дигән кеше бар иде безнең авылда. Өстендә кышын-җәен кия-кия каешланып беткән тун булыр иде. Аягында ниндидер могҗиза белән сакланып калган «шахтер галошы».

Без аңа:

— Акчаң бар бит, Гәптелвәли, салып ыргыт шул сәләмәләренне, авылыбызның ямен бозып йөрмә,— дип тә әйтеп карый идек. Колагына да элми иде сүзебезне. Унбиш бөртек сакалын сыпырып, төймә кебек борынын җыера да, сары каш астындагы керфексез зәп-зәңгәр күзләрен кыса төшеп, кулын гына суза. Кул суздымы, без аңлап ала идек инде: Гаптелвәлинең папиросынны биреп сөйләш дип әйтүе иде ул. Гомере буе кеше кесәсеннән көн иткәнгә, без аның кул сузуын көтеп тормаска өйрәндек, Гаптелвәлине күргә үк папирос алып авызына каптырып куя идек. Күпләр аны акылга тулы түгелдер дип шикләнәләр иде. Ләкин мин анын тиле кешеләр кыланышына ошаган бер генә нәрсә дә эшләгәнен хәтерләмим. Кемнең-кемнең, ә Гаптелвәлинең акылы якты күк йөзеннән дә аязрак иде.

Бәлки, аның шаянлыгы өчен шулай дип әйткәннәрдер. Чөнки Гаптелвәли уен-көлкене бик ярата иде. Салам өйгәндә дисеңме, силос салганда дисеңме, дөнья рәхәте кеше инде. Авызына папиросыңны гына каптырып өлгер, берсеннән-берсе тапкыррак, мәзәгрәк сүзләр сибелеп кенә торыр иде. Эш мәсьәләсенә килгәндә дә аңа сокланмаган кеше юк иде.

Мин һаман «иде, иде», дигәч тә, мәрхүм кеше турында сөйли дип уйламагыз. Гаптелвәли исән-сау. Тик ул инде элеккеге Гаптелвәли түгел. Үзгәрде. Алыштырып куйганнар диярсең. Өстендә хәзер үтүкләнмәгән булса да, ак күлмәк, аягында күн итек, башында эшләпә, сакалы кырылган, бите-кулы юылган. Элек «Исәнме, Гаптелвәли!» — дигәнгә уны белән җавап бирә торган кеше сәламне дә алмый үтеп китә. Папирос сузсаң, син биргәнне чиертеп кенә җибәрә дә, уз кесәсеннән «Казбек» алып теш арасына кыстыра. Мәзәк дигән нәрсә юк та юк инде ул. Кеше мәзәк сөйләгәнне дә тыңламый. Эшкә килсә, кулында сәнәк-көрәк булмый, бүтәннәр эшләгәнне күзәтеп тора да черт итеп төкереп кайтып китә.

Тәки аптырашка төшерде ул безне. Бөтен авыл Гаптелвәлине генә сөйли. «Ни булган аңа?» — дип баш вата. Ай буе җавап эзләдек бит, агай, тәки таба алмадык. Икенче айга киткәч кенә ачыкланды.

Көннәрдән бер көнне, эштән кайтып килешли, урамда очраттым да мин моны...

— Гаптелвәли, нигә эшкә чыкмыйсың? — дип сорадым.

Мине беренче тапкыр күргәндәй, аптырап карап торды да бу:

— Мина приказ бирергә ни имиеш права,— дип әйтеп салмасынмы.

— Мин приказ бирмим, сорыйм гына,— дидем.

— Сорарга да ни имиеш права.

— Менә әкәмәт. Ни өчен?

— Пытамушта син призидум түгел, мин призидум! Мин присидәтел белән, районнан килгән кеше белән рәттән утырган кеше.

Шуннан барысы да искә төште.

Колхозның отчет-сайлау җыелышында, хәтерләмим инде, кемдер Гаптелвәлинең исемен кычкырган иде. Без кул күтәргән идек. Гаптелвәли бүтәннәр белән беррәттән җыелышта президиум члены итеп сайланган иде. Әйтәм аны, кукыраеп утырды ул вакытта. Мәкер корып утыруы булган икән.

## Зәки Нури

### Хатынга ярамагач...

— Төне буе нидер сөйләп яттың
Бүген тагын йокы аралаш.
— Ахры, инде тиздән төшемдә дә
Сөйләшергә миңа ярамас?!

### Икесе дә көтә

— Нишләп йөрдең? Кайда олактың син?
Мин бит көтәм һаман ятмыйча.
— Ә мин синең йоклап киткәнеңне
Көтәм, хатын, өйгә кайтмыйча.

### Килен белән кайнана

— Ташлады бит улың! Ә дөньямны
Сиңа гына бирәм, диде ул...
— Ул чагында, килен, географияне
Әле бик аз белә иде ул.

### Әйтүе дә авыр...

— Кайда хәзер теге кара кашың?
Гашыйк идең былтыр син аңа.
— Ул кияүдә инде.
— Кемгә чыкты?
— Әйтүе дә авыр... миңа ла...

## Күршең нинди?

— Күршең нинди?
— Начар.
— Тавышлыйммы?
— Күрәсе дә килми күзләрем:
Я һич дәшми, я пышылдап сөйли —
Ишетеп булмый гайбәт сүзләрен.

## Улы атасын юата

— Дәресеңне кен дә мин хәзерлим,
Ярты кичем шуңа китә бит.
— Түз инде, түз, әти, безнең тиздән
Җәйге каникуллар җитә бит!

## Тиздән буласы ярдәм

— Үстең, улым, ләкин ярдәмең юк...
Эшкә йөрим, өйдә чиләнәм.
— Булыр, әни, ярдәм булмый калмас,
Чөнки инде быел өйләнәм.

## Ике күрше сөйләшә

— Бакчама мин өч карачкы куйдым,—
Түтәл бозып кошлар котыра...
— Без куймыйбыз... Чөнки көне буе
Исерек ирем шунда утыра.

## Хушлашканда

— Аерылабыз. Китәм. Стаж тулды.
Шулдыр теләк, шулдыр киңәшем:
Урыныма минем бер туң йөрәк,
Берәр ахмак килә күрмәсен!

Китә башлык. Дуслар озаталар.
Җыелып чыга күрше-күләне.
Борчылалар ләкин бар да нинтер:
Әллә тагын шундый киләме?

## ӘЗЕРБӘЙҖАН КУЛЬТУРАСЫ АТНАЛЫГЫ

Шушы елның 26—31 май көннәрендә Казанда Әзербәйҗан культурасы бәйрәме үткәрелде. Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга әзерлек уңае белән уздырылган бу дуслык атналыгында Әзербәйҗан ССРның 400 дән артык сәнгать осталары катнашты. Алар арасында Әзербәйҗан республикасының атказанган җыр һәм бию ансамбле, радио һәм телевидение камера оркестры, Әзербәйҗан дәүләт капелласы, радио һәм телевидение эстрада оркестры, «Гая» вокаль квартеты, М. Ф. Ахундов исемендәге педагогия институтының үзешчән «Айгюн» бию ансамбле, ашуглар, зурначылар, язучылар һәм шагыйрьләр дә бар иде.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында тантаналы шартларда башланган ул атналык көннәрендә Әзербәйҗан сәнгать осталары В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары һәм укытучылары, Куйбышев исемендәге, «Теплоконтроль» һәм авиация заводлары, Ленин орденлы мех берләшмәсе эшчеләре алдында чыгышлар ясадылар, әдәбиятыбызның мәшһүр классигы Габдулла Тукайның туган ягында — Арча районында булып кайттылар.

Атналык көннәрендә Казан кинотеатрларында Әзербәйҗан фильмнары фестивале дә үткәрелде. Әзербәйҗан киностудиясе тарафыннан эшләп чыгарылган «Мин чибәр түгел идем», «Балачакның соңгы төне», «Закон исеме белән», «Монда дәреслек эш итә», «Әзербәйҗанга килегез», исемле фильмнарны Казан тамашачылары бик яратып карадылар.

Атналык барышында Казанның сынлы сәнгать музеенда һәм күргәзмә залларында Әзербәйҗан сынлы сәнгате, скульптура әсәрләре күрсәтелде. Республика китапханәсенең зур залында Әзербәйҗан китаплары күргәзмәсе булды. Республикабыз радиосы һәм телевидениесе тыңлаучыларны һәм тамашачыларны Әзербәйҗан радио һәм телевидениесе хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән материаллар белән таныштырды.

31 майда республикабызның иҗат коллективлары һәм сәнгать осталары Казанның А. М. Горький исемендәге культура һәм ял паркында төрле культура чаралары үткәрделәр. Анда Әзербәйҗаннан килгән кунаклар да бар иде. Алар дуслык паркы утыртуда катнаштылар. Ул паркның бер аллеясы Әзербәйҗан ССР исеме белән аталачак.

Атналык көннәрендә Әзербәйҗан сәнгать осталары Казанның В. И. Ленинга бәйләнешле урыннарда булдылар, тарихи һәм революцион истәлекләр белән таныштылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының шушы елның 16 маенда игълан ителгән Указы нигезендә, татар музыка сәнгатен үстерүдәге һәм пропагандалаудагы зур хезмәтләре һәм югары дәрәҗәле башкару осталыгы өчен, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты **Илһам Гыйльметдин улы Шакировка Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАССР Верховный Советы Президиумының шул ук көнне игълан ителгән Указы нигезендә, совет музыка культурасын үстерүдәге хезмәтләре һәм иршелгән иҗади уңышлары өчен композитор **Әнвәр Закир улы Бакировка,** Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры дирижеры, композитор **Алмаз Закир улы Монасыйповка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** һәм совет цирк сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, **Николай Григорьевич Жеребцовка Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Балалар — безнең тормышның киләчәге, коммунизм төзүдә актив катнашырга тиешле буын. Ә коммунизм төзүчеләрнең мораль яктан да, политик яктан да югары

сыйфатларга ия булуы мәҗбүри. Менә шуңа күрә дә партиябез һәм хөкүмәтебез балаларны югары кешелек сыйфатларына ия итеп, коммунизм идеалларына турылыклы итеп тәрбияләү мәсьәләсенә соңгы елларда аеруча зур әһәмият бирә башлады.

Яшь буынны тәрбияләүдә әдипләребезнең дә роле зур, чөнки әдәби әсәр бала күңеленә теләсә нинди үгет-нәсихәттән артыграк һәм нәтиҗәлерәк тәэсир итә. Тик ул әсәрләр югары художестволы итеп эшләнгән һәм коммунистик идея белән сугарылган булырга тиешләр. Ә безнең язучыларыбыз шул җаваплы бурычны ничек үтиләр соң? Балалар матбугатында алар ничек катнашалар?

Язучылар союзының 21 майда Г. Тукай клубында үткәрелгән ачык партия җыелышы әнә шул мәсьәләне тикшерүгә багышланган иде. Язучыларыбыз алдында торган бурычлар, аларның «Ялкын» журналында һәм «Яшь ленинчы» газетасында ни дәрәҗәдә актив катнашулары һәм нинди әсәрләр белән катнашулары турындагы докладны Язучылар союзы каршындагы халык контроле группасы председателе Асия Гыйниятуллина ясады. Балалар матбугатында, диде ул, язучыларыбыз әле җитәрлек дәрәҗәдә актив катнашмыйлар, катнашкан тәкъдирдә дә аларның әсәрләре күп очракта бүгенге укучының зәвыгына тиешенчә җавап бирерлек булмый. Докладчы газета һәм журнал редакцияләренең дә язучылар белән элемтәсе йомшак булуын билгеләп үтте һәм киләчәктә өлкән, тәҗрибәле әдипләрне балалар матбугатында ешрак катнаштырырга, аларга заказлар биреп яздыртырга кирәк, дигән фикерне әйтте.

Аннары «Ялкын» журналының узган елгы һәм быелгы саннарында басылган поэзия әсәрләре турында шагыйрь Марс Шабаев сөйләде һәм ул да әлеге редакциянең язучылар белән элемтәсе җитәрлек булмавын, шуның нәтиҗәсендә балалар өчен яхшы шигырьләр язучы шагыйрьләрнең әсәрләре журналда аз басылуын, ә художество дәрәҗәсе түбән булган шигырьләргә күбрәк урын бирелүен искәртте.

Җыелышта Самат Шакир, Вакыйф Нуруллин, Нәби Дәүли, «Ялкын» журналы редакторы Роза Хафизова, «Яшь ленинчы» газетасы редакторы Венера Ихсанова, Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясе мөдире Шамил Рәкыйпов иптәшләр дә сөйләделәр һәм барысы да язучыларны балалар матбугатында активрак катнашырга чакырдылар.

Җыелыш балалар әдәбиятын тагын да ныграк үстерү өчен конкрет чаралар билгеләде.

## ТАТАРСТАНГА БАГЫШЛАНГАН

Мәскәүдә басыла торган «Культура и жизнь» («Культура һәм тормыш») журналының бу елгы дүртенче саны тулысы белән дип әйтерлек Татарстанга багышлап чыгарылган. Анда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыевның Совет властe елларында республикабызда булган бик зур үзгәрешләрне чагылдыруга багышланган мәкаләсе, Казанда яшәүче рус язучысы Виктор Байдерииның В. И. Ленин турындагы хикәясе, элекке һәм хәзерге Казан күренешләрен чагылдыручы фоторәсемнәр, язучы Габдрахман Әпсәләмовның публицистик мәкаләсе, язучы Гомәр Бәшировның Алексей Максимович Горькийның Казанда яшәгән чорына, Рафаэль Мостафинның Муса Җәлилгә багышланган мәкаләләре, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры ТАССРның атказанган артисткасы Рәшидә Җиһаншинаның театр тормышы, РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, профессор Гыйлем Камайның Казан химиклары турындагы материаллары урнаштырылган.

## ФОТОКҮРГӘЗМӘ

Май аенда Казанның В. И. Ленин исемендәге культура сараенда «Волга» клубы фото сөючеләренең традицион күргәзмәсе үткәрелде. Анда тормышның төрле якларын чагылдырган 145 фоторәсем куелган иде. Күргәзмәдә яхшы бәя алган фоторәсемнәр В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап Мәскәүдә үткәреләчәк документаль һәм нәфис фотография күргәзмәләренә кую өчен лаеклы дип табылды. Казан фото сөючеләренең рәсемнәре Польшада, Югославиядә, Венгриядә һәм Германия Демократик Республикасында үткәреләчәк фотокүргәзмәләргә дә җибәреләчәк.

* * *

Әдәбият сөючеләргә үзенең күп шигырьләре һәм поэмалары белән таныш булган рус шагыйре Евгений Евтушенко «Казан университеты» дигән яңа поэма яза. Шагыйрьнең әйтүенчә, бу әсәрдә ул Казан университеты студенты, яшь революционер Владимир Ильич Ульяновның үлемсез об-

разын иҗат итәргә ниятли. Моңарчы ул В. И. Ленинның шушы чор тормышына һәм эшчәнлегенә кагылышлы бик күп материалларны җентекләп өйрәнгән. Поэмасының аерым бүлекләрен, фрагментларын язган да инде. Шул поэмасын тагын да тулыландыру максаты белән шагыйрь Казанга килде. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында студентлар һәм галимнәр белән очрашты, аннан соң шагыйрь Казан шәһәренең Ленин исеменә бәйле һәм башка истәлекле урыннарында, шулай ук В. И. Ленинның беренче сөрген урыны — Ленино-Кокушкино поселогында булды.

Казанда булган көннәрендә Е. Евтушенко татар әдәбияты үрнәкләре белән дә танышты, Габдулла Тукай туып-үскән якларда булып кайтты, язучылар һәм журналистлар белән очрашты.

* * *

Май аенда күренекле рус шагыйрәсе Ирина Волобуева да Казанда булып китте. Ул В. И. Ленинның Казандагы һәм Кокушкинодагы музейларындагы документлар белән танышты. Казан дәүләт университетындагы В. И. Ленин бүлмәсен карады һәм шунда алган тәэсирләре нәтиҗәсендә В. И. Ленинга багышлап шигырь язды. И. Волобуеваның ул шигыре безнең журналның алдагы санында басылып чыгачак.

## ШАГЫЙРЬ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Майның җидесеннән алып унбишенә кадәр Ләйлә Кәримова (Фатих Кәримнең кызы) һәм шагыйрь Ренат Харисов Калининград өлкәсендә булып кайттылар. Алар җиңү көненә багышлап Багратионовск шәһәрендә үткәрелгән митингта катнаштылар һәм Фатих Кәримнең каберенә чәчәкләр куйдылар. Аннары Ләйлә Кәримова һәм Ренат Харисов Южное сигезьеллык мәктәбенең Фатих Кәрим исемен йөрткән пионер отряды белән очраштылар, пионерларның шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүдәге эшләре белән таныштылар. Владимирово поселогының шагыйрь исемендәге китапханәсен карадылар.

Фатих Кәримнең күмелгән урыны 10—11 ел эзләгәннән соң гына табыла. Ләйлә Кәримова, Ренат Харисов ул каберне табучы Бронюс Антонович Малинаускас һәм Бронислав Ионович Тарнаускас белән очраштылар һәм шагыйрьнең сугыш кырында ятып калган урынына бардылар, ул урынның ориентирларын билгеләделәр, киногa һәм фотога төшерделәр, Ф. Кәрим кабере өстеннән кәс кисеп алып кайтып Татарстан дәүләт музеена тапшырдылар.

Л. Кәримовага һәм Р. Харисовка Фатих Кәрим эзләре буйлап йөрергә шундагы хәрби частьнең командиры подполковник В. А. Луконин һәм запастагы гвардия подполковнигы П. М. Базов бик зур ярдәм күрсәттеләр.

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Шушы елның 5 маенда Мәскәүдәге Атеистлар йортында Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле повесте буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Анда йөздән артык китап сөючеләр һәм автор үзе дә катнашты.

Конференциядә беренче булып отставкадагы генерал Якуп Чанышев сөйләде һәм әсәрне бик яратып укыганлыгын, андагы вакыйгаларның гаҗәп оста, җанлы образлар аша сурәтләнүен әйтте.

Аннары пенсионерлар Ә. Галикәев, М. Кутуева, инженер И. Акчурин, экономист Ә. Галимов, студентлар Төхфәтуллина, Ә. Саттаров, укытучы Х. Соловьев, тарих фәннәре докторы Х. Ярмөхәммәтов, профессор И. Нигъмәтуллин, яшь язучы М. Юныс, шагыйрә М. Таһирова һәм тарих фәннәре кандидаты И. Мавлютов иптәшләр «Туган ягым — яшел бишек»не укыганнан соң күңелләрендә туган фикерләре белән уртаклаштылар һәм ул әсәрдә халкыбызның тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары бик киң һәм уңышлы чагылдырылуын билгеләп үттеләр.

Соңыннан язучы Гомәр Бәширов сүз алды һәм конференциядә сөйләгән иптәшләргә рәхмәт әйтте, иҗат планнары турында сөйләде.

## ГАСТРОЛЬЛӘР УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Мәгълүм булганча, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көннәре якынлашу уңае белән РСФСР Министрлар Советы «Сәнгать — халыкка» дигән девиз астында Бөтенроссия сәнгать фестивале үткәрү турында карар кабул иткән иде. Фестиваль совет халкының социализм һәм коммунизм төзүдә ирешкән уңышларын, илебезнең экономик һәм культура тормышында Ленин идеяләренең тантанасын киң чагылдыру, профессиональ һәм үзешчән сәнгатьнең тагын да ныграк үсүен тәэмин итүне күздә тотып үткәрелә.

Бу карарны тормышка ашыру җәһәтен-

нэн республикабызның иҗат коллективлары һәм сәнгать осталары да актив катнашырга булдылар. Быелгы җәйге гастрольләр планы да шул максатны күз уңында тотып төзелде. Сәнгать осталарыбыз быел җәй нигездә үз республикабыз районнарында чыгыш ясыйлар һәм авыл хезмәт иялəре алдында иҗади отчетлар бирәләр. Май аенда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры коллективы, дүрт группага бүленеп, республикабызның унсигез районында булып, авыл тамашачыларына йөздән артык спектакль күрсәтеп кайтты. Бу коллектив репертуарындагы М. Байдәшевның (кыргыз язучысы) «Хуш, Назлыгөл», Ю. Әминовның «Гөлҗәннәтнең җәннәте», Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» һәм «Дуслык законы» исемле әсәрләрен тамашачылар бик хуплап каршы алдылар.

В. И. Качалов исемендәге рус Зур драма театры коллективы республикабызның нефть районнарында, Ленин комсомолы исемендәге Яшь тамашачылар театры Бөгелмә, Минзәлә, Әлмәт районнарында спектакльләр куеп, шулай ук тамашачыларның ихтирамын казанып кайттылар.

## ИСЕМНӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ


Горький шәһәрендә ялгызлык исемнәре буенча конференция булды. Анда Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Алма-Ата, Фрунзе, Рига, Киев, Петрозаводск, Казан, Астрахань һәм башка шәһәрләрдән барлыгы 136 кеше катнашты. Пленар утырыш һәм секцияләрдә 130 лап доклад һәм белдерү тыңланды. «Ономастика һәм социология» дигән темага доклад белән Пенза галиме Б. Бондолатов чыкты. Топоним (тау, елга, чишмә, үзәннәр исемен өйрәнү) гыйлеме галиме Э. Мурзаев «Топонимиядә географик терминнар» дигән доклад ясады. Г. Донедзенең (Мәскәү) «Төрки топонимнарның грамматикасы» дигән темага ясаган доклады сөйләшүдә катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Г. Саттаровның «Казан (шәһәр исеме) сүзенең килеп чыгуы» турындагы доклады галимнәрдә шулай ук кызыксыну тудырды. Р. Субаеваның (СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты) «Татарларда интернациональ исемнәр» дигән хәбәре буенча җанлы фикер алышу булды. Г. Саттаров һәм А. Сираеваның (Казан университеты студентлары) «Казан галиме И. Износковның татар топонимнарын өйрәнүе» һәм Ә. Булатовның «VI—XVI йөзләрдә яшәгән борынгы болгарларда кеше исемнәре» дигән темага докладлары да җанлы үтте.

## МӘКТӘПТӘ ЭСТЕТИК ТӘРБИЯГӘ БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯ

Шушы елның 23—25 апрелендә ТАССР мәгариф министрлыгы, Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты, педагогия җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының педагогика кафедрасы, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап, «Мәктәптә эстетик тәрбия» дигән темага фәнни-практик конференция үткәрделәр. Анда ТАССР Мәгариф Министры, СССР Педагогия Фәннәре Академиясенең член-корреспонденты М. И. Мәхмүтов «Татарстан мәктәпләрендә эстетик тәрбия», СССР Педагогия Фәннәре Академиясе вәкиле Е. Я. Гембицкая «Художестволы тәрбия системасы», Мәскәү профессоры И. Л. Любинский «Эстетик тәрбия проблемалары», Казан консерваториясе доценты В. Г. Лукоянов «Хор сәнгате чаралары белән эстетик тәрбия», шул ук консерватория укытучысы Ф. Ш. Бикчурина «Эстетик тәрбия бирүдә милли музыка», республикабызның Мамадыш шәһәре укытучысы И. Г. Сафина «Г. Тукай иҗатын өйрәнгәндә укучыларга эстетик тәрбия бирү», Казанның 62 нче мәктәбе укытучысы Г. В. Федорова «Биология укытканда матур әдәбияттан файдалану», сәнгать белгече А. Б. Файнберг «Татар совет сынлы сәнгатенең үсү проблемалары», Минзәлә шәһәренең беренче мәктәбе укытучысы В. Е. Казанцева «Әдәбият дәресләрендә сынлы сәнгатьтән һәм музыкадан файдалану» дигән темаларга докладлар сөйләделәр. Аннары докладлар буенча фикер алышулар булды. Конференция бик җанлы үтте һәм, һичшиксез, аның файдасы зур булыр.

## ЯКТАШЫБЫЗ КОНЦЕРТЫ

Курган музыка училищесын тәмамлап чыккан якташыбыз — пианистка Йолдыз Хөсәенова шушы елның 10 маенда Троицк музыка мәктәбендә концерт бирде. Ул Бах, Гайн, Моцарт, Шуберт, Скрябин, Прокофьев һәм Шопен әсәрләрен башкарды һәм музыка сөючеләр күңелендә җылы тәэсир калдырды.




# ТӘГӘРМӘЧЛӘР

ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙП
сүзләре

ЗИННУР ГЫЙБАДУЛЛИН
музыкасы

Тәгәрмәчләр тәгәриләр
Келдер-келдер.
Гармун тартып җырлап
Бара кемдер.
Хуш ис бөркеп кала кырлар
Тирә-якта.
Тәгәрмәчләр көйләп бара
Шушы хакта.
Тәгәрмәчләр бәхет ташый,
Шатлык илтә,
Еракларга сәлам-хатлар
Илтә.
Тәгәрмәчләр вокзалларга
Туктый килеп.
Әллә каян:— Саумысыз дип,
Сәлам биреп.
Тәгәрмәчләр кузгала да
Тагын китә.
Җәяүлеләр җитмәс җиргә
Барып җитә.
Якынайта, ерагайта
Араларны,
Тоташтыра авылларны,
Калаларны.
Тәгәрмәчләр кавыштырсын,
Аермасын!
Кешеләрнең канатларын
Каермасын.
Тәгәрмәчләр тәгәрәсен
Келдер-келдер.
Бу юллардан бер йөргә
Бер гомердер.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210